
ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

12.1997






# Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты карары

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты Россия Федерациясе гражданынын яңа паспортын Россиядә яшәүче татарларның мәнфәгатеннән чыгып бәяли һәм бу документның милләтләр һәм милли республикалар үсешенә, милләтара һәм социаль вәзгыятьнең тотрыклылыгына зыян китерүен белдерә.

Башкарма комитет, Россия Федерациясе республикаларында, өлкәләрендә, төбәкләрендә яшәүче татарларның теләген һәм хокукларын исәпкә алып, гражданлык һәм паспорт тапшыру мәсьәләләрен демократик юл белән хәл итәргә кирәк, дип саный. Моның өчен:

1. Күпмилләтле Россия Федерациясенең гражданлык мәсьәләләре, паспорт, туу турында таныклык һәм гражданлыкка бәйле башка документлар үрнәген Россиядә яшәүче барлык халыкларның тулы хокуклы вәкилләре катнашында раслауны тәкъдим итәргә.

2. Паспортта милләтне күрсәтү хокукын яклап чыгарга һәм яңа паспорт үрнәкләренә милләтләрен күрсәтергә теләгән гражданнар өчен юл (графа) калдыруны зарур дип санарга.

3. Татарстан Президентына, Дәүләт Советына һәм Хөкүмәтенә «Гражданлык турында» Закон һәм башка рәсми актлар кабул итүне, Татарстан гражданлыгын чагылдырган һәм милләтне күрсәтү мөмкинлеген күз алдында тоткан гражданлык документын булдыруны тәкъдим итәргә.

4. Күпмилләтле Россия Федерациясе гражданы паспортында тиешле рәвештә расланмаган һәм бер конфессиянең генә тамгасы (тәре) күрсәтелгән дәүләт гербының башка дин тотучыларның рухи, дини хисләрен рәнҗетүен искә алып, Россия Хөкүмәтеннән паспортта бернинди дини тамгалар күрсәтелмәвен таләп итәргә.

5. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының Россиядәге региональ үзәкләренә, паспорт мәсьәләсен тикшереп, һәр төбәкнең таләпләре чагылдырылган мәгълүматларны һәм тәкъдимнәрне хакимият органнарына һәм БТК Башкарма комитетына җибәрергә.

6. Татарлар яши торган барлык төбәкләрдә 1999 елда халык санын алуга әзерлекне башлап җибәрергә.

7. Бөтендөнья татар конгрессының җирле оешмаларында милләттәшләребезне теркәүне, татарлар яши торган өлкәләрне, шәһәрләрне, торак урыннарын барлау, милли-мәдәни мөмкинлекләрне исәпкә алу эшен җанландырырга.

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты.

*1997 ел, 19 ноябрь.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**12**

**(902)**

**1997**

КАЗАН


## *Бу санда*


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Р. СИБАТ. Исабәт. *Роман* . . . . . . . . . . 3
Ә. БАЯНОВ. Су өсләрендә пароход. *Истәлекләр китабыннан* . . . . . . . . . . 88
М. МИРЗА. Килен. *Шигырьләр* . . . . . . 121
Г. ӘХТӘМОВА. Егерменче гасыр. *Шигырьләр* . . 124

АЛЬБЕРТ ХӘСӘНОВКА — 60 ЯШЬ

А. ХӘСӘНОВ. Балыкчы мажаралары. *Хикәя* . . 62

ШАМИЛ МАННАПКА — 60 ЯШЬ

Ә. БАЯНОВ. Даһилык дәгъваламыйча гына . . 52
Ш. МАННАП. Дәръя йөрәге. *Шигырьләр* . . . 55

ДУСЛАР ЖЫРЫ

Р. ГАТАШ. Салават йөргән сукмактан . . . . 81
С. ӘЛИБАЙ. Сөенче. *Шигырьләр* . . . . . 81

МӘХМҮТ ХӘСӘНОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Н. ГАМБӘР. Ул тормышны ярата иде . . . . 126
М. ХӘСӘНОВ. Зәбәрҗәт. *Хикәя* . . . . . . 131

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Өметне аклыйк. *(1997 елда журнал битләрендә барган «Бүгенге проза турында сөйләшү»гә йомгак)* . . . . . . . . . . 135

МӨСӘГЫЙТЬ ХӘБИБУЛЛИНГА — 70 ЯШЬ

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Тарихтан гыйбрәт, халыктан гайрәт алып . . . . . . . . . . 140

ХӘТЕР

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ. Татар зиратлары . . 143

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Р. ӘМИРХАН. Казанлы Әмирханнар . . . . . 155

ӘНВӘР ХӘЙРИГӘ — 50 ЯШЬ

Р. ГОСМАНИ. Мул җимешле иҗат . . . . . . 172

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Ә. СИБГАТУЛЛИНА. Төркиядә — безнең турыда . . . . . . . . . . 178

Безнең календарь . . . . . . . . . . 185
1997 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге . 187
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . . . . 191

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Хәлим Гайнуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Нажар Нәҗми**
**Рашат Низамиев**
**Булат Солтанбәков**
**Камил Сәгадәт**
*(җаваплы сәркатип)*
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*
шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа Р. Сибата «Исабет», воспоминания А. Баяна, рассказ А. Хасанова «Приключения рыбака»; стихи М. Мирзы, Г. Ахтямовой.
«К 60-летию Шамиля Маннапова»: статья А. Баянова о творчестве поэта; лирические стихи юбиляра.
«Песни друзей»: стихи поэта Башкортостана С. Алибая.
«К 70-летию Махмута Хасанова: статья Н. Гамбара «Он любил жизнь» и рассказ юбиляра.
«Литературная критика»: итоги дискуссии о современной прозе.
«К 70-летию Мусагита Хабибуллина»: статья Ф. Галимуллина посвящена творчеству писателя.
«Память»: статья Марселя Ахметзянова «Татарские кладбища».
«К истории культуры»: статья Р. Амирхана «Казанские Амирханы».
«К 50-летию Анвара Хайри»: Р. Гусмани. «Плодотворное творчество».
«К истории народа»: статья А. Сибгатуллиной «В Турции про нас».
Наш календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: из сокровищницы Кубрат хана; писатель Вахит Имамов.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: R. Sibat's novel «Isabet», A. Bayan's recollections, A. Khasanov's story «Adventures of Fisherman»; the verses of M. Mirza, G. Akhtyamova.
«Commemorating the 60th Anniversary of Shamil Mannapov»: A. Bayan's article of author's creative work; Sh. Mannapov's lyrics.
«Friends' Songs»: the verses of Bashkortostan poet S. Alibai.
«Commemorating the 70th Anniversary of Makhmut Khasanov»: N. Gambar's article «He Loved Life», M. Khasanov's story.
«Literary Critique»: the results of discussion on modern prose.
«Commemorating the 70th Anniversary of Musagit Khabibullin»: Ph. Galimullin's article devoted to M. Khabibullin's creatibe work.
«Memory»: Marsel Akhmetzyanov's article «Tatar Cemeteries».
«To the History of Culture»: R. Amirkhan's article «Kazan Amirkhans».
«Commemorating the 50th Anniversary of Anvar Khairi»: R. Gusmani «Fruitful creative work».
«To the History of Nation»: A. Sibgatullina's article «In Turkey about Us».
Our calendar.
The diary of social and cultural life.
In our covers: from Kubrat khan's treasure-house; the writer Vakhit Imamov.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.**
*Гамәли хезмәткәрләр:* Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 29.09.97 ел. Басарга кул куелды 9.12.97 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 12 196. Заказ Н-598.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1997 ел.

## Рафаэль Сибат

# ИСАБӘТ

ӨЧ ХИКӘЯТЛЕ РОМАН

Балык кичкә таба тагы да шәбрәк эләгә башлады, әйтерсең аларның патшасы әмер биргән:

— Әй сез, балыклар! Елга төбендәге чытырманга эләккән кармагын ычкындырам дип суга кергән Фәрит исемле адәм баласы, көзән җыерып, батып үлде. Кешеләр күп еллар буе безнең итебезне ашаган һәм суыбызны пычраткан өчен корбан бирделәр. Әмма бик зур һәм кыйммәт корбан бу. Чөнки Фәрит исемле әлеге егет яңа гына армиядән... Кешеләрнең армия дигәннәрен аңлатып китәм: армия кешеләргә үз илләрен дошманнардан саклау яисә чит илләргә һөҗүм итү өчен кирәк. Әгәр ул һөҗүм дигән нәрсә башланса, җирдә мәхшәр туа, адәм уллары арасында корбаннарның саны чиксез була. Елга балыкларына маймычларын кертеп санаганда гына туа ул сан. Кешеләрнең һөҗүм дигәннәре була күрмәсен, чөнки ул вакытта хәтта безгә дә елгада урын калмый, суны шартлатып күккә күтәрәләр... Азрак читкә тайпылдым бугай, баштагы сүземне дәвам итәм... Фәрит исемле әлеге егет яңа гына армиядән кайтуына карамастан, авыл кешеләренең хөрмәтен казанып өлгерде. Аларда ничек хөрмәт казаналар, дисезме? Җир сөреп. Әйе, җир сөреп һәм икмәк үстереп! Икмәкне беләсездер — яр буена каз сакларга яисә су коенырга төшүче малайлар безгә ыргыткалыйлар аны. Кабатлап әйтәм, Фәрит безнең өчен зур корбан. Әгәр үлмәгән булса, үзенең гомере буена ул әле күпмебезнең башына җитәр иде. Шуңа боерык бирәм: кем дә кем бу тормыштан туеп, утлы табада кыздырыласы килә, төбе чытырманлы борылмадан астарак ау белән Фәритнең үле гәүдәсен эзләп йөрүчеләргә эләгегез!

...Ауга бер-бер артлы судак, бәртәс һәм бигрәк тә корбан балыклары керә торды...

* * *

Фәритнең гәүдәсе һаман табылмады. «Инде бүгенгә җитәр, ардык... хәлдән тайдык»,— ди иде ирләрнең карашлары.

— Ярый бүгенгә... Иртәгә тагын да астанрак эзләргә булыр,— диде кемдер.

— Ул якта балык та...— дип башлаган иде Кәбир, йөзен чытып, комлы юан бармакларын пычранып беткән куе чәчләренә батырган

[1] Ахыры. Башы 11 санда.

Минвәлине күргәч, шым булды. Читкәрәк китеп, чәчелеп яткан ауны җыештыра башлады.

Беркем бер сүз дәшми...

Күбесе суга чыланып беткән күлмәк-ыштаннарын сыгалар, кайберәүләр сигарет артыннан сигарет кабызып, тукталышларны белми бара торган пароход кебек төтенлиләр, ә берсе Бәдәр җинги җибәргән азык-төлекне яр кырында яшел ашъяулык күк яткан йомшак чирәмгә җәеп, ике шешә аракыны алып куяргамы, юкмы дип баш вата, бер Минвәлигә, бер башкаларга карый...

Минвәли кемгәдер ачулангандай һаваны кискен хәрәкәт белән кисеп, кулын селтәп куйды һәм авыр адымнар белән яр кырые буйлап югарыга таба китте.

— Минвәли абый, син кая?— дип кычкырды Фәритнең иптәше.

Ул аңа ярым борылып:

— Теге чытырман янында кичә җизнинең бер ботинкасы төшеп калган... Эзләп килим әле,— диде.

Ул киткәч, ирләр сүзсез генә капкалап алдылар, әмма ипи, суган кыяклары һәм ит кисәкләренә каяндыр күпләп ком кергән, чәйнәгән саен бөтен тәннәрен чымырдатып тешләре шытырдый иде, гүя ачлыктан пыяла чәйнәргә мәҗбүр булганнар.

— Тьфү!— дип җиргә төкерде берсе.

— Ха-ха-ха! Нәрсә, елга комын шикәр комы белән бутадыңмы әллә?— диде, шаркылдап көлеп, икенчесе.

Шулвакыт йөзе агарып калган, түше-көне беткән Минвәлинең аларга таба йөгереп килгәне күренде. Кояшның батып барган нурларында ул ниндидер алып гәүдәле шыксыз хайванга охшап калган иде.

— Ни булган?— диде Кәбир, куркынып китеп.

Барысы урыннарыннан сикереп тордылар.

— Минвәли абый, нәрсә бар?!— дип сорады Фәритнең иптәше, салкын канлы булып калырга тырышып.

— Тегендә... тегендә ни...— аның куллары чак кына дерелди иде.

— Ну? Бәй?! Нишләп торасың инде?

Кәбирнең җан ачуы чыкты.

— Тегендә ул... бар...

— Кем бар? Ни бар?!— Кәбир Минвәлинең җилкәсеннән алып селки башлады.

— Җибәр әле!— диде Минвәли аның кулларын алып ташлап.

Аннан соң тирән итеп сулыш алды һәм үпкәсендәге һаваны өзек-өзек чыгарып әйтте:

— ...Фәрит... Җиз-нинең ботинкасын эз-ләп күкрәктән... суга кергән идем... аягыма... эләкте... юк... бер аягымны ике кулы белән кочып алгандай булды... Чы-тыр-ман янында...

Бер минутка сүзсез калдылар. Минвәлинең әле моңарчы бервакытта да күренмәгән ят кыяфәте, сүзләрен өзеп-җимереп әйтүе һәм алар янына чабыш атыдай атылып килүе һәркайсының күңеленә җиңелчә булса да шом салды.

— Чытырман Фәрит баткан урыннан өстәрәк бит. Үлгән кеше ничек инде суга каршы аксын?— диде, ниһаять, Кәбир.

— Бәлки балыкчылар бу урынны дөрес күрсәтмәгәндер,— диде Фәритнең иптәше.

— Бик мөмкин...— дип килеште өнгә килгән һәм үзен кулга алып өлгергән Минвәли.— Алар аннан... шактый ерак булганнар бит... Аннан соң без гел... түбәннән сөзеп йөрдек, ә аның бөтенләй акмаган булуы ихтимал...

Ул хәзер куркудан түгел, кичке салкыннан дерелди иде, әмма торышы һаман хәвефләнгән кыяфәттә, шуңамы аңа ышанып җитмәделәр:

— Курыкканга куш күренә!

— Үлек аякны кочаклый димени?!

— Үлеп кара — кочакларсың микән?— диештеләр.
Шулай да тикшереп карарга булдылар...
Чытырман янына килеп җитүгә иң беренче сорау шул булды:
— Кем керә... суга?
Берәү дә чатнатып: «Мин!» димәде — Минвәлинең «аякны кочаклады» дигәне аларда куркудан битәр, ниндидер чиркандыргыч, өшетә торган, күбесе моңарчы тоймаган хис, аңламаган уй тудырган иде.
Ул арада Кәбир тиз генә чишенде һәм анадан тума калган килеш, сул кулы белән оят җирен каплап, ә уңын нигәдер сәгать маятнигы кебек алга һәм артка нык кына селкеп, суга кереп китте. Менә су тездән... кендектән... муеннан.. Кәбир кыска буйлы шул. Араларында иң кыскасы.
«Буе җитәр микән?»— бу сорау күбесенең уенда иде.
«Әгәр кире чыкса, һәрхәлдә, миңа керергә кирәк булыр... Нәрсә, Кәбирдән кимме әллә? Куркак булып калмам бит инде! Фәритнең үле гәүдәсе генә... әллә ничек... Нигә аптырарга ди? Без аның белән, ачуым килмәгәе, йөз тапкырлап мунчаны бергә кердек... Нигә аның шәрә тәненнән куркырга ди? Күргәнем бар... Хәтта кочаклаганым да...» — дип уйланды Фәритнең иптәше.
«Ник үзем генә кермәдем... Җизнигә... апага... Кәбир алып чыкты диярмен микәнни?— дип өзгәләнде Минвәли, дер-дер килеп.
Кәбир, батып баручы кояшка карап, кинәт кенә суга чумды. Барысының күзләре елгага текәлде. Менә богыр-богыр килеп төссез куыклар күтәрелде...
Су өстенә буй-буй төшкән кояш нурларыннан ясалган тасмалар Вятканы юлбарыс тиресенә охшатып калдыралар иде. Сул яктагы озын-озын агачлар үскән тирәк урманыннан төшкән күләгә, елганың төбен төпсез, хәтта дөньяны йотарлык итеп күрсәтә.
Суык җил исеп куйды. Тал яфраклары, комга ышкылган арба тәгәрмәче тавышы чыгарып, леперди башладылар. Яр кырыендагы бер уч суга ташлап калдырылган корбан балыгы җан ачысы белән бәргәләнә, нәни койрыгы белән зуп-зур җирне кыйный. Чебен-черки халкы, бу тамашаны күрергә теләп, болыттай булып җыелган да бер күтәрелеп, бер төшеп, һавада биеп тора.
Шулчак Кәбир су өстенә башын калкытты да:
— Булышыгыз әле!— дип кычкырды.
Елга өсте чатнап-ватылып китте — ирләр дәррәү суга ташландылар...
Берничә минуттан Фәритнең җансыз гәүдәсе искереп беткән көймәнең яргаланган тупас борынында ята иде. Кочагында метр-метр ярымнар тирәсендәге агач түмрәне. Минвәлинең аяклары шул кочакка кергән икән...
Кәбир аның йөзен юып җибәрде, чөнки борын тишекләренә, колагына һәм бигрәк тә авызына ком тулган иде. Гүя елга төбенә ятып ком ашаган...

* * *

Авылга кайтканда һәркем үз уена чумды.
— Бәй! Миңа кереп сорасалар, бер шулпалык балык бирмәс идеммени!— дип көрсенде Кәбир.— Шуның аркасында кеше бетте...
— Әх! Мин генә гаепле! Мин генә...— дип уйлады Минвәли,— Кабәхәт! Дуңгыз! Сорыкорт! Ялагай!! Юк, кеше үтерүче син, зараза! Имеш, начальникка?! Җизни жист жизни, нәчәлник есть начальник, имеш?! Кайтам да барлык балыкларны тирескә атам... Бер кило балык җәлләдем бит! Өч калак шулпалык балык... Нинди егет әрәм булды... Минвәли абый дип өзгәләнеп тора иде... Гомерлек үкенеч бит бу... Обищәйткән, имеш... Сүзне эш итәм, имеш... Нәчәлник, имеш... Нәчәлдерик! Нә-чәлдерик!! Сүзне эш иттем!!! Ух...

— Фәрит белән Нәзидә өчен генә тарткалашып килдек. Хәтта сугыша язгаладык... Бер тапкыр аңа Фәритне яманлап сөйләдем... Эх! Нигә алай иттем инде? Нәзидәнең шуннан соң миңа күңеле суынды. Ә мин... Мин Фәритнең көчле һәм сабыр булуыннан көнләшә идем... Югыйсә дуслар үзебез... Бер партада ун ел утырдык... Әгәр Фәрит исән булса, Нәзидәне үземә каратырга тырыша идем әле. Ә хәзер... Хәзер, юк! Иптәшем хөрмәтенә янына да бармыйм,— диде үз алдына сары чәчле егет.

Исәннәрне һәм мәрхүмне төяп, машина алга чаба, арттан күтәрелгән тузан, аждаһаның галәмәт зур койрыгыдай, юлга бәргәләнә һәм сирәгәеп кичке салкынча һавага күтәрелә. Кемгәдер дулаган кебек, машина моторы улый...

Төньяк җиле көчәя төште.

Вятка артта калды. Ачудан йоннарын кабарткан алама эт кебек иде ул. Аксыл-соры дулкыннары чайкалышып, чәйнәп өзәм дигәндәй, яр буендагы ташларга ниндидер сыек чыпылдавык тавыш белән килеп бәреләләр. Бәреләләр һәм котлары очкан кебек чәчрәп китәләр...

Гүя Вятка эт булып, кешеләргә өрә иде...

* * *

Кичкырын Минвәли җизниләренә килде. Ул керел килгәндә Бәдәр түти елап шешенеп беткән, гаҗиз бер хәлдә иде.

— И, ходаем! Нинди каргышларың төште?!. Бәла өстенә бәла... Улымны алуың гына җитмәгән, инде менә монысы да... Нихәлләр итим!— дип ялвара иде карчык.

— Ни булды, апа?— диде сәерсенгән Минвәли.

— Соң, ни булды, дип... Көне буе тамагына берни капмады...Ниләр генә китермәдем, барысын кире кага, ә үзе һаман «балык шулпасы...», «балык шулпасы...» дип кабатлый...

— Ашый торган чагымыни, апа? Борчылма, зинһар!

— Соң, эш ашауда түгел ич... Гел бер сүз ич. Гел бер сүз... «Балык шулпасы...», «балык шулпасы»! Җиңеләеп китмәсен, дим... Их, башларыбызга кара кайгы булды бу балык шулпасы!

Бәдәр түти йөзен кытыршы уч төпләре белән каплап, кычкырып елап җибәрде. Минвәли түзмәде, карашын читкә борды: тәрәзәнең өске өлгесеннән күренеп торган күк йөзендәге кара ач болыт кинәт көмеш айны кабып йотты. Ул башын иеп чыгып китте.

* * *

Төнгә каршы Минвәли тагы җизниләренә килде.

Өй эчен куе караңгылык баскан. Стенадагы күкеле сәгать «келт-келт» килеп вакыт саный. Келт!— уң якка китә сәгать теле, келт!— сул якка. Келт!— уңай якларыңны билгеләп куя, келт!— кире якларыңны тамгалап ала... Әйтерсең шулай... Алгы яктагы Бәдәр түти һәм аның иптәш хатыннары түшәмдәге ялгыз лампочкадан сибелгән сап-сары нурларга коенып утыралар. Урталарында утырган саф йөзле ак чәчле карчык салмак һәм тыныч тавыш белән аларга нидер сөйли. Кызыклы һәм гыйбрәтле, тормышчан нәрсә турында булса кирәк, барысы да йотлыгып тыңлыйлар, бары Миңвәлинең апасы гына, әледән-әле почмак яктагы караватка күз төшереп, ирексездән килгән яшьләрен яулык очы белән сөрткәләп ала иде.

Йокы бүлмәсендә Якуб карт ята.

— Җизни...— дип эндәште әкрен генә Минвәли, гомерендә беренче тапкыр бу сүзгә гаҗәп тә якынлык мәгънәсен салып.

Карт эндәшмәде.

— Җизни!— диде ул кычкырыбрак.— Мин сиңа... балык шулпасы алып килгән идем. Корбан балыгыннан...

— Ә-ә? Нәрсә дисең?!

Картның тавышы зәгыйфь һәм ямьсез булып, хырылдап чыкты, әмма бу сүзләрен әйткәндә, күзләре кинәт кенә ялтырап китте, аларда тормышка ашмас ниндидер өмет чаткылары күренеп киталәр дә сүнәләр..

— Балык шулпасы... Корбан...— Минвәли соңгы сүзен әйтә алмыйча тукталып калды, гүя аны сихри көч бугазыннан буып алды, күз аллары караңгыланып китте.

— Балык шулпасы? Ә-ә-ә... Әйткән... идең шы... шу-ул, улым. Бер шу-улпалык... бал... ыйк!.. алып кайтам, дип. Рәхмәт, улым!

Якуб картның калтыранган авыр кулы Минвәлинең аш тәлинкәсе кадәр дәү уч төбен, ул әле моңарчы бервакытта да тоймаган туганлык, үз итү һәм чиксез ярату белән кысты.

Алар шул хәлдә шактый озак тордылар, шунәмы Минвәлинең күңеле тулып, күз яшьләре кырынмаган кара төкле яңагы буйлап агалар да тып! итеп соңгы көндә аларның тормыш-яшәешләренә язмыш фаҗигасе булып кергән балык шулпасына тамалар иде... Корбан балыгы шулпасына...

Бу вакытта таң атып килә иде инде. Көнчыгышта, офык кырында, тәрәзә челтәренең читеннән ачып караган оялчан чибәр кыз кебек, кояш кызарынып тора. Аның нигә оялганын, кем өчен оялганын Минвәли үзе генә белә...

## Өченче хикәяткә сүз башы

*Нишләрсең! Яшәү булган кебек, Үлем дә бар шул. Ул да безнең белән рәттән йөри. Хакыйкать — дөнья гел шатлыктан гына тормый: кайгысы китә телеп, синең белән ике куллап көрешер өчен сыкраулар чиратта тора, сызланулар, җан җәрәхәте гомернең караңгы куакларына оялап, һөҗүмгә күтәрелү өчен «җайлы вакыт» кына көтеп яталар. Тик шулай да кеше барешми, аның киләчәккә булган өмете һаман якты, һаман кояшлы, «бүген булмаса, иртәгә матур!»— ди ул һәм тигәнәк булып калкыган хәсрәтне нәни генә бер сөенечнең үткен балтасы бер чабуда кырт итеп өзеп ташлый...*

*Шөн авылына мин басынкы, әмма шат рух белән килдем. Ял итәргә кирәк иде. Ялсыз сыер гына яши, диганнәр. Мансур абый Вятка буенда «менә дигән балык тоту, күңел ачу, ял итү» оештырырга вәгъдә биргән иде бит. Үзе түгел, әлбәттә, улы Одик оештырачак!*

*Көне кояшлы. Тәнне мәлҗерәтеп, арганлыкмы ясә ялкаулыкмы, гәүдә буенча җәелгән. Якты нурлар күзне чага. Мин ял итәргә — тынычланырга карар бирдем. Дөньяның бар мәшәкатен син генә күтәрә алмассың, тынычлан, тынычлан!— дип, үз-үземне тиргәп ташладым. Гомер диңгезенең яртысына да җитмәдең — борчу-әрнү, җан ярасы... һәм шулар өстенә сәламәтлек ягыннан да какшап киттең, агайне! Күзләрең начар күрә башлады, йөрәгең тауга менеп баручы машинаның иске моторы кебек, үпкәң тишек гармун күреге кук. Онытт борчу-мәшәкатьне! Гамь шәп нәрсә, әмма анда ямь юк. Кемнәрдер яшиләр ич әле. Берни турында уйламыйлар...*

*Тынычлан!*

*Тынычлан!!*

*Тынычлан!!!*

Автобустан төшүгә, як-ягыма каранам. Шөн авылының шактый зур икәнен күрдем: зәңгәргә, сарыга, кызылга, көрәнгә һәм башка төсләргә буялган өч йөзләп йорт, үлән арасына чәчелеп яткан төрле төсләрдәге агач шакмаклар кебек, ямь-яшел агачларга күмелеп утыра иде. Авылның төньяк һәм көньяк яклары тау сыртлары белән капланган, көнбатышта зәңгәрсу-кара булып урман күренә, көнбатыш ягы биниһая зур капка кебек ачык һәм тигезлекле. Мин басып торган урыннан уң якта балалар бакчасы, сулда бер катлы кечерәк больница, тагы да арырак, тау башында кибет һәм шәһәр паркында утырган йортка охшаган зур гына мәктәп. Алар барысы да яңа гына таштан салынган булып, шуның өстәвенә бер урындарак торгач, авылга күпмедер шәһәрчә төс кертәләр иде. Күңелгә тия торган урыннары шунда: бер-берсенә тәрәзәләре, ишекләре, түбәләре һәм башка яклары белән бер тамчы су кебек охшаганнар һәм һәркайсысы аксыл-көрән төскә буялган булып, яшеллектә җәелеп яткан авыл йортлары янында хәтфә паластагы ватык кирпеч кисәген хәтерләтәләр һәм мондагы манзарага ябышып бетмиләр. Бигрәк тә мәктәп белән балалар бакчасы. Ябышмаганны төкерек кенә тотмый, диләр.

Колонка янына туктап тешләреңне сындырырдай салкын, чиста һәм гаҗәп тәмле (авылның шәһәрдән бер өстенлеге!) су эчкәч, Мансур абыйның өйрәтүе буенча, түбән очка киттем һәм башта агач, аннан соң таш күперне үтүгә, клубның сынык рәшәткәләрен кагып ятучы кешеләрдән: «Мансур абыйлар өе еракмы әле?»— дип сорар өчен, алар янына юнәлдем.

Бүген кояш иртәдән үк кыздыра башлады, тагы яңгырсыз көннәр китте. Җан ияләре бер мәлгә тынып калган чак, бары якындагы нәни елганың челтерәп агуы ишетелә дә берән-сәрән кошлар бер-берсенә аваз биргәлиләр. Инеш кырыендагы карт тупылдан ишелеп-ишелеп мамык коела, гүя җәйге кар.

Урам чатларында күренгән кешеләр ашыкмый һәм вәкарь белән генә (авылның шәһәрдән икенче өстенлеге!) эшкә яисә берәр йомыш-юлга баралар. Су ала торган урында берничә хатын-кыз артык кычкырмыйча гына сөйләшеп тора, өй алдындагы комда сабыйлар уйнап ята, йокыдан әле күзләре дә ачылып бетмәгән кыз бала болынга казлар куа, үсмер-малай, сумкасын велосипед мөгезенә элеп, кибеттән ипи алып кайта, ә кара чалбар, тезенә җиткән ак күлмәк, башына үзбәк түбәтәе кигән түгәрәк йөзле, түгәрәк ак сакаллы бабай боларның барысын күзәтеп, яшәеш хакында булса кирәк, уйланып, күзләрен йомгалап утыра һәм кулындагы матур таягы белән җиргә нидер сызгалый, гүя тормыш, исән-саулык, тазалык-байлык, яшәүнең картайгач та тәмле һәм ләззәтле булуын яза.

— Исәнмесез!— дип, шактый көр тавыш белән рәшәткә кагучыларга эндәштем мин.

— Бигәйбәт! Сәнмәсез!!— диде араларында зәңгәр халат кигән өлкәнрәге һәм шундук:

— Сез рәрсенә тыгызмы лә?— дип ифрат тиз сорады ул, сүзләрен сагыз белән ябыштыргандай бер-берсенә бәйләп һәм күп кенә сузык, хәтта тартык авазларны теленнән ычкынганчы ук, вак балыкка ташланган чуртан кебек, йотып.

— Ник асыгадыр, агас пулемет?— диде нечкә озын егет зәңгәр халатлыга, үзе дә «ш» һәм «ч» авазларын «с» белән алмаштырып.

— Тә-әрәҗмәсен я-асаргамы?— дип сорады миннән борылып, ябык йөзле, әмма атлетик гәүдәле тазасы чүкечен уйнатып кадак кага-кага. Рәшәткә төзәтәләр димәктән, такталарны монда ул гына кага иде, зәңгәр халат биреп тора, ә «нечкә озын», чиста ак күлмәген пычратудан куркып

булса кирәк, алардан ике-өч метр читтәге утыргычта, астына газета җәеп, матур рәсемле журнал караштыра иде.

— Тәрҗемәсе кирәк түгел,— дидем мин.— Минем мишәр дустым бар, тагы да кызурак сөйләшә. Ник ашыгасың дигәч, космик чор дип җавап бирә. Ә иптәш: «Сез берәрсенә кайттыгызмы әллә?»— дип сорады.

Алар кычкырып көлеп җибәрделәр һәм сары чәчлесе кадак кыйнавын дәвам итеп, җитди генә үз алдына сорап куйды:

— Чыннан да-а, ни-ик ашыга-адыр?

Шундук аңлап алдым: гадәти сөйләшкәндә ул сузыкларны болай ук сузып тормый, монда иптәшеннән шаярту йөзеннән шулай дип әйтте.

— Теп рәлмам дим,— диде зәңгәр халат тагы да кызурак итеп һәм көлә-көлә. Күренеп тора, ул да юри әйтә икән, сөйләшкәндә болай ук тиз булмаска тиеш.

— Әйтеп бетерәм алайса,— дидем мин һаман шаярту тонында.— Мансур абыйларның... Мансур Маракшин абыйларның өйләре еракмы моннан?

— Мансур Маракшин?— дип сорады кинәт сары егет, гәүдәсен турайта төшеп, аннан соң чиләктән иелеп бер уч кадак алды да:

— Ул минем әти, мин...— ди башлаган иде.

— Одикмы?— дип сорадым.

— Әйе, Одик...

Мин аны үзем белән таныштырдым һәм Мансур абыйның чакыруы буенча балык тотарга килүемне әйттем.

— Әти кичә дә сезне искә алды: «Рәхмәт инде, бер тиен акчам юк иде, сыйлады, юлга биш сум акча бирде, үзебезгә кунакка чакырган идем, күренми әле», ди!

Биш сум?? Йә Алла! Вәт, Мансур абый? Биш сум, ә...

— Таныш булыгыз,— диде Одик, зәңгәр халатлыга төртеп күрсәтеп,— бу — безнең Культура йорты директоры Хак Кәримов.

Мин Хакның, культура эшчесе булуына карамастан, физик хезмәттән кытыршыланып беткән шактый дәү кулын кыстым. Аның дустанә елмаеп торуы күңелгә җылылык һәм аңа карата шундук якынлык өстәде.

— Ә бесь... кино сь сәнгате кесесе булабысь,— диде ак күлмәк урыныннан торып башын иде һәм миңа чыбык бармакларын сузды.— Гафил!

Йөзенә текәлеп карагач, мин аның күзлек пыялалары астына яшеренгән саргылт-кара күзләрендә мыскыллы елмаю чаткылары күрдем.

— Киномеханик булып эшли,— диде Одик.

Шулвакыт юл уртасына мотоцикл туктады.

— Әй сез, өчлек союзы!— дип кычкырды аның өстендәге әзмәвердәй таза утыз биш яшьләрендәге ир.— Иртәгә барыгыз да печәнгә, кибән салырга чыгасыз!

Аннан соң, китеп барганда өстәп куйды:

— Үзегез белән кунакны алсагыз да була, бездә ничек печән җыйганнарын күрер...

— Ярар, ярар,— диештеләр өчлек союзы членнары.

— Шәһәр кешесенә файдалы ул!— дип, миңа төрттереп китеп тә барды әзмәвер ир.

— Кем ул?— дип сораган булдым мин алардан, кем икәнен чамаласам да:

— Бригадир Танир... дорфа кылана кеше белән,— диде Одик.

— Аның каравы халыкны тота белә!— дип каршы төште Хак.

— Тиранлык-деспотлык кирәкми!— дип куйды Одик.

— Җитәкче — тәвәккәл булырга тиеш, әйбәт башлык ул!— дип, Хак үз сүзен бирмәде.

— Современный кулак!— диде мыскыллы тавыш белән Гафил һәм черт! итеп төкерде дә журналын ябып, утыргычка ыргытты, чалбар балакларына төшкән көнбагыш кабыкларын бик озаклап каккач, кесәсеннән затлы сигарет алып кабызды.

— Ә «Өчлек союзы» нәрсә ул?— дип сорадым мин.

— Анысы — без!— диде алар миңа мәгънәле итеп.

Соңыннан белдем: бер-берсеннән аерылмый йөргәнгә авылда аларны «Өчлек союзы» дип йөртәләр икән.

* * *

Өйләренә кайтып барганда, Одик миңа туп-туры болай диде:

— Минемчә, сезгә дә берәр көн колхозга булышырга кирәк, кешедән оят югыйсә, уттай эш өстендә балык тотып йөрү... Әйдәгез, болай килешәбез: көндез — эш, кич — балык.

— Хуп!— дидем.— Авыл малае бит мин дә... Күптән кибән салган юк. Кул да кычытып тора.

Сәгать сигезләрдә Вятка буена төшсәк, Хак жиденәге паром белән чыгып киткән икән. Менә тынгысыз җан!

Тагы иртән иртүк кыздыра башлады, дөнья имән утыны ягып җылытылган эссе мунча кебек. Кинәт кенә исеп куйган тымызык җил тәнгә салкынча ләззәт китерсә дә, бу озакка бармый, тагы өскә кызган нурлар коела башлый.

Малай-шалайлар һәм кичтән мичкәләре аракы белән тулып, шунамы иртән йөзләре салып таптагандай чытык, кәефсез берничә ир су коена башладылар. Аргы якта ял итәргә килгән поселок кешеләре чиләк асып, учак якканнар, әрле-бирле йөрешәләр, коену киемнәреннән генә калган килеш туп уйныйлар, берничәсе, суеп ташланган дуңгыз түшкәсе кебек җансыз ятып, тере комда кызына.

«Аз гына булса да тагы җил иссен иде...»— дип уйлыйсың, әмма бер чәч бөртеген селкетерлек иң көчсез, ундүрт яшьлек арык үсмер кебек сыек җил кисәге дә исми, күптән түгел генә шаяргалап йөргән җилне әллә солдатка алганнар, әллә кияүгә биргәннәр шунда! Агачлар, төш турындагы эсселекне уйлапмы, башларын игәннәр, кош-кортлар күренми, берән-сәрән чебеннәр ялкау гына оча, бары әллә кайдан килеп чыккан ялгыз озынборын гына үзен әллә кемнәргә куеп, «Без-з-з!»— дип тавыш чыгарган була, ялгышып тимер атка — машина кабинасына яисә кызавына килеп куна, әмма аннан мазут белән бензин исе генә аңкыгач, аңгыраеп тора да, нәни вертолет кебек тиз генә күтәрелеп, тагы каядыр китеп югала.

Күперчеккә килеп тукталуга, халык паромга керү өчен умарта күчедәй бер җиргә өелеште, бары сабыр ир-атлар гына бер читтә тәмәке көйрәтүен дәвам иттеләр, ә су коенучы малайлар күлмәк-ыштаннарын тоткан килеш иртәнгә җылынып җитмәгән суык судан дер-дер килеп әти-әниләре, абый-апалары артыннан йөгерделәр, тик кайсынадыр ияреп төшкән алама йонлы дәү кара эт кенә, «нәрсәгә тыгылалар инде?» дигәндәй, кешеләр ягына сыңар күзен ачып, ком өстендә тыныч кына ятуын дәвам итте.

Паромның көньяк өлешенә хатын-кызлар өелгән, алар ике төркемгә бүленә: ир хатыннары һәм олырак яшьтәге түтәйләр бер почмакта ләчтит саталар, кыз-кыркын һәм көзге алмадай кызарып пешкән, йомры гәүдәле, барысы да диярлек чибәр кызлар икенче почмакта бертуктаусыз сөйләшәләр, көлешәләр һәм сирәк-мирәк булса да елт итеп егетләр ягына күз аталар. Ирләр халкы да икегә бүленгән: беренче төркемгә кергәннәр тәмәке суыра-суыра кем күпме эчкән, хатынын нигә үпкәләткән, ничә кибән салганнар — шул хакта гәпләшәләр, ә күбесе озын буйлы озын чәчле егетләр шау-гөр киләләр һәм минут саен диярлек кызлар ягына сынаулы һәм тикшеренүчән, әмма болай карап торырга игътибарсыз күренгән караш ташлыйлар. Ә бер егет белән бер кыз үзләре генә бер почмакка басканнар. Болары яңа гына өйләнешкәннәр, яисә, авыл кешеләре әйтмешли, «күптән йөриләр».

Одик белән без бензин мичкәсе, запас баулар яткан кешесез почмакка барып сыендык. Мин журнал караштырган булам, әмма бу болай гына, уку өчен түгел, үзем каш астыннан гына булса да кешеләрне күзәтәм һәм, ни хикмәттер, карашым кызлар тирәсендә (вәт карт ишәк!) озаграк туктала да тайгак юлда кузгала алмыйча буксовать иткән машина кебек китә алмыйча тора. Матурлыкка һәм яшьлеккә күбрәк карауның бер гөнаһы юк, әлбәттә! Нигәдер бу минутта миңа шушы кешеләргә кушылып китү сәер, кызык һәм ифрат та сөенечле иде, үземә-үзем якын тоелам, алар миңа якын кебекләр, күмәк яшәү-эшләүнең бөеклеген шактый вакытлар ялгызың гына гомер кичереп, адәм балалары арасына килеп кергән чакта бигрәк тә нык аңлыйсың икән.

Ул көнне без болында шактый эш майтардык. Чын күңелдән тырыштык дигәнне бригадир Танир үзе дә раслады:

— Эх, мат-малина!— диде ул,— сезнең кебек тагы бер партия кибәнчеләр булса, башкалары кирәк тә түгел. Колхоз эшен алып барыр идек без ул вакытта!!

— Рәхмәт, Танир, яхшы сүзеңә. Кичкә кадәр әле тагы берне салабыз!— диде кибән өстендә торучы Хак.

Дөресен генә әйткәндә Одик та, мин дә бик арган идек, монысы соңгы кибән булыр дип уйладык, әмма Хак бер сүзле икән, күзне дә ачтырмады.

— Әйттек — эшлибез. Аргансыз икән, әнә ял итегез, бер үзем салам... Ир сүзе — бер булыр!

Килештек, әлбәттә, әмма соңгы кибәнне очлап чыкканда, авылдан кешеләрне алырга килгән машина кайтып киткән булып чыкты.

— Бигрәк әйбәт, кунабыз...— диде Хак күз дә йоммыйча,— күптән печән өстендә болындагы куышта яшел печәнгә тәгәрәп йоклаган юк инде.

— Ә балык?— диде Одик.

— Балык иртәгә...— дидем мин, Хак белән ризалыгымны белдереп.

Кичке ашка кадәр Одик белән ике йөз метрлар читтә торган Батыш күлендә юынып килдек, Хак бармады — күл суыннан тәне чабыручан икән.

— Батышта батмагыз тагы,— дип шаяртып калды ул.

Көндез тимер мич кебек кызган табигать әкрен генә үзенә салкынлык җыя: агачлар йокымсырый башлаганнар, үләннәргә елтыр чык төшкән, күл өстенә ак җәймә булып куе томан яткан, көндез тавышларын да чыгармаган бихисап күп кошлар сайрый, кайдадыр таллыклар арасында тәкәрлек тавыш бирә, камышлар кочагыннан үрдәк кычкыра, уяу калган чикерткәләр черр-черр килеп җырлаган була, ерактагы урман янында ялгыз кәккүкнең «кәк-күк! бу көн узды күк!» дигән моңлы тавышы, аяк табаннарына кадәр төшеп, җанны сагышландырып, күңелгә бер минутлык моң оеткысы салып җибәрә.

Күл кырыена килеп җитүгә үк, чишенеп ташладык. Одикның төз таза аякларына утыртылган нечкә билле киң җилкәле гәүдәсе ак томанны ертып аксыл-кызгылт сын кебек тора иде, шуңа күрә мин дә алга таба җәелгән эчне тартып куйдым, тәнне катырып, сикерешкә әзерләнгән атлет кебек, бер хәлдә калдым.

Одик суга керүгә, күл өсте ватылып китте. Барлык арганны-алҗыганны югалтып, тәнгә салкынча рәхәт бирә торган ләззәткә чумдык...

Шактый гына юынганнан, йөзеп йөргәннән соң, яр читендә шадра сөлге белән чиратлашып сөртендек тә кайтыр юлга чыктык. Әллә көне буе эшләп күп көч куйганга, әллә салкын суда коенып чыкканга, үтереп ашыйсы килә башлады. Бер буханка ипине күл суына манып ашап бетерер дәрәҗәдә идем. Бу уйларымны оныттырып Одик миңа:

— Ә сездә жегәр бар икән!— дип куйды.

— Аллага шөкер!— дидем мин ярым шаярып, ярым чынлап, әмма аның сүзенә бик тә риза булып (кайсы ирнең үзен «көчсез» дип ишетәсе килә!)

— Шулай да,— дип дәвам итте Одик,— сезгә карап бу кадәр үк көч булыр дип уйламаган идем. Гафу итегез, тышкы кыяфәтегез сезнең җегәрле булуыгыз турында сөйләми.

— Ә мин егет чакта спорт белән дә шөгыльләндем, штанга һәм көрәш буенча минем беренче разряд иде.

— Хәй!— диде Одик бот чабып.— Минем дә штанга буенча беренче разряд бит! Армиядә тапшырган идем... Тренер «спорт мастеры ясыйм» дигән иде дә, икенче урынга күчерделәр, анда штанга юк иде, вакыт та булмады.

— Сиңа хәзер дә соң түгел әле,— дидем мин,— миңа гына...

— Нигә, сез дә карап торырга егетләрдәй әле, чын күңелемнән әйтәм: чыннан да куәтле кеше сез, кибән өйгәндә күрдем бит — көчегез күп.

— Рәхмәт!— дидем мин елмаеп, шул ук мизгелдә җаным буйлап үземнән канәгатьлек белән тулган сөенеч дулкыны узды. Моннан да зур мактау кирәк идемени миңа. Көчле-таза кешеләр сафына кертә бит мине Одик, ә мин үземне чирле кеше дип йөргән булам тагы... Менә әкәмәт!

Хәер, көчлеләр янында үзеңне көчле сизәрсең, диләр бит. Хикмәте шундадыр аның...

Әмма, ни генә булмасын, бу көннән соң үзеңне чирле димисең, елак бала кебек юкка да кәефсезләнмә, үзеңне көчле, мәгърур итеп тот!

Онытма — син көчле!

* * *

Салкын сулы чишмә чыккан җиргә салынган куышлар янына җитәрәк, озын ялгыз карамага кагылган фанерага эленгән «Яшен»не укырга туктадык — Хак чыгарган газета иде бу. Без дә макталып телгә алынганбыз — күңелгә рәхәт булып китте.

Куыш кырыендагы чирәмлеккә ятып, кичке ашка тотыныйк кына дигәндә, әллә кайдан йөгереп Хак килеп чыкты:

— Ах сезне! Озакладыгыз бит — әллә Су анасы алганмы, дип торам. Ә хәзер аз гына сабыр. Сабыр иткән — морадына җиткән. Одик, син икмәк кисә тор, ә сез суган кыягы турагыз,— дип, тагы каядыр китеп тә барды.

Аның кушкан эшләрен эшләп бетерергә вакыт та җитмәде — иптәшебез кайнап торган шулпа күтәреп килеп җитте дә, корымга буялып беткән кара чиләгеннән тантаналы рәвештә безнең алга куйды.

— Нәрсә бу?— диде Одик.

— Уха...

— Уха?

— Нинди уха??— дип сорадым мин дә.

— Чуртан ухасы.

— Чуртан?— дип сорадым, тагын да икеләнебрәк.

— Әйе... Кичә үк карап куйган кечкенә генә күлем бар иде. Анда һәр елны язгы су белән кергән чуртан мыж була. Сез коенырга китүгә ат тырмасы җиктем дәген өч малайны алып әйдә болгатырга. Их, күлне болгатып чуртан тотуны бала чактан бирле яратам инде мин! Яланаяк ерып каты чәй яисә дегет кебек булганчы болгатасың, менә берзаман миңгерәүләнгән чуртаннар кайсы крокодил, кайсы торпеда кебек башларын су өстенә тырпайта башлыйлар, ә син ике учыңны җәеп астан китерәсең дә — шап!— җайлап кына кысып аласың һәм ярга ыргытасың.

— Ә аяк нишли?— диде Одик көлемсерәп.

— Нинди аяк?— дип сорады берни аңламаган Хак.

— Чабырмыймыни?

— Ә-ә-ә! Аны әйтәсең икән, бүген мин ярда балык кына җыйдым, малайлар тотты.

— Болгатып тоткач, нәни балыклар да харап буладыр инде,— дидем мин.

— Әлбәттә,— диде Хак.— Әмма аларны җәлләүдән файда юк: табигать тарафыннан үлемгә хөкем ителгәннәр инде алар — йә каргалар чүпләп бетерә, йә еланнар ашый, йә берәр атнадан күл кибеп харап булалар. Кечкенә күл балыкларының язмышы шул.

— Кечкенә ил халыклары язмышы кебек,— диде Одик көрсенеп. Кайсын җәлли иде ул: күл балыкларынмы, әллә кечкенә ил халыкларынмы? Аңлый алмадым...

* * *

Чуртаннан пешкән балык шулпасы ифрат тәмле булып чыкты. Шуның өстенә аны тәлинкәләргә бүлеп торганда Хак сумкасыннан бер шешә ак чыгарды:

— Уха астына, кызурак булсын өчен!— диде ул елмаеп.

— Каян эләктердең, Хак абый?— диде Одик, үзеннән битәр мине сыйлый алуларына куанып.

— Мәйсәрә апаңа, безнең белән печәнгә кунак егете дә чыга дигән идем, запасыннан тиз генә тартып чыгарды.

— Ну, Мәйсәрә апаны, валлаһи, битеннән үбәр идем!— дип көлде Одик ята торган урыннарга хуш исле яңа чабылган печән түшәп.

— Йә-йә,— диде Хак.— Мине беләсең — көнләштерәсең ич!

Көлеп җибәрдек һәм өчебез дә бер булып алдыбыздагы сый-нигъмәткә ябырылдык. Юк, бу гурманлык түгел, таза итеп эшләүдән соң таза итеп ашау гына. Бары шул!

Ашап туйгач, иртәдән бирле мине борчып килгән соравымны бирдем:

— Нигә сезнең союзның өченче члены күренми бүген?

Иптәшләрем икесе дә эндәшмәделәр. Хак бер кочак яшел печән алып килеп, куыш эченә мендәр-ястык итеп түши башлады, ә Одик савыт-сабаларны алды да чишмә кырыена төшеп китте. Хак күрше куыштагылардан ябынырга ике одеял алып килде. Печән өстендә кунучылар аз иде.

Күпмедер вакыттан соң нәни куышыбызга кереп яттык. Борынга уннарча төрле үлән һәм чәчәкләрнең бергә катнашкан исерткеч исе ярып керә, кичке салкын белән суытылган һава саф һәм сулап туймаслык иде. Табигать тагы да тына төшеп, күл буе бакаларының йокылы кычкырып җибәрүләренә чикерткәләрнең чиратлап сузган скрипкалары гына кушыла. Алары да колакны иңрәтеп түгел, ә көне буе эшләп арган гәүдәне изрәтеп кенә.

Менә-менә йоклап китәм дигәндә генә, баш очында «бомбардировщиклар» пәйда булды, алар: «Энем, энем!»— дип сузынкы, нечкә һәм кызганыч тавышлар белән очалар да «абзыйларының» маңгайларына, кулларына, колак артларына безләп куна башлыйлар.

— «Истребительләр» килде!— дип көлде Одик.

— Борыннарын авызларына каптырыйм!— дип сукранды Хак, чалтчолт үз-үзен яңаклый башлап.— Иртәгә тагы кабармаган җир калмас инде. Минем тән бигрәк азгын бит, борынын тыккан бер төштә чикләвек төше кадәр кабарып чыга.

— Ярый әле карбыз кадәр түгел,— дип көлде Одик.— Ничек күтәреп йөрер идең?

Ни тыелсам да мин дә түзә алмыйм, кычкырып көлә башлыйм. Безгә ияреп, Хак үзе дә көлә.

— Әйдәгез, тартып алабыз,— дип тәкъдим кертәм.— Төтенгә тончыктырыйк әле үзләрен!

Өчәүләп (хәтта тартмый торган Одик та) икешәр сигарет тартып бетерүгә, төн уртасы узып та китте, шуңамы озынборыннар күренмәс, дөресрәге, ишетелмәс булдылар. Дөньяга авыр һәм сабыр салкынлык иңде.

— Гафил авырта ул, шуңа печәнгә чыкмады,— диде Хак одеалына төренә-төренә.

— Хай!— диде Одик одеал белән мине дә, үзен дә төреп.— Авырта пычак! Симулянт ул. Эш турында сүз чыктымы — чиргә сабыша. Ә сөйләшкәндә...

Шуннан соң сүз ялганмады, өчебез дә суеп ташлаган кебек каты йокыга талдык. Физик эш — изелеп йоклауны сорый.

* * *

Иртәгесен калтырап уянып китсәм, Хак чишмә буеннан юынып кайтып килә, ә Одик куыш кырыена парлары бөркелеп торган бәрәңге боламыгы һәм кайнар чәй алып килеп, тәлинкә һәм калай кружкаларга бүлеп маташа. Мине күргәч, елмаеп:

— Хәерле иртә!— диде ул.

— Хәерле иртә!

— Барыгыз, юынып килегез. Аннан соң кайнар чәй эчеп алырбыз.

Шадра сөлгене тотып чишмә кырыена йөгердем. Аш пешерүче чибәр кыз елмаеп кулыма су салып торды, мин рәхәтләнеп юынып алдым, рәхмәтемне әйтеп, иптәшләр янына киттем.

Бар җирдән сөт кебек ак һәм куе томан күтәрелә. Үләннәрдән күзгә күренеп зөбәрҗәт чыклар тама, тирә-юньдә дистәләгән кошларның иртәнге талгын-тыныч сайраулары ишетелә. Табигать акрын гына, авыр гына йокысыннан уянып килә.

Җирдән өшетерлек салкын һәм юеш дым бәреп, туфли табаннарын чылатып, тәнне җиңел генә дерелдәтеп тора. Берәр кружка баллы чәй эчеп, бәрәңге боламыгы белән тамак ялгагач, күңел тагы күтәрелеп китте, бу якларга килүемә, шушындый дуслар табуыма чиксез сөендем, үземне кыска гына бер мәлгә булса да ифрат та бәхетле сиздем. Адәм баласына бәхетле булу өчен күп кирәкмени! Саулык та күңел көрлеге!— ди торган иде минем мәрхүм бабай. Бүгенге матур иртәдә генә шуны аңладым: хак әйткән икән...

Төшкә таба күк йөзендә болытлар куерып йөрсә дә, яңгыр яумады, ә кичкырын эсселек тагы да арткандай булды.

Бүген кичәге кебек эшли алмадык. Сәбәбе: көйдереп ала торган кызу көн һәм...

Бүген печән өстенә ак күлмәк, үтүкләнгән модный чалбар киеп Гафил да чыккан иде. Иптәшләрен сагынгандыр, күрәсең. Ни генә димә, Өчлек союзы бит...

Одик, аның туйдагы кияү кебек киенеп чыгуын яратмыйча, чыраен сытып карады, ә Хак, күрмәмешкә салынып, кара күзлеген киеп куйды.

Гафил безнең партиягә кушылган иде. Аны кибән өстенә менгездек. Ул өстендәге кияү киемнәрен салып ташлап, су кырыена кызынырга төшкән кебек плавкидан калды. Шул килеш үзенең шыксыз озын нечкә һәм арык гәүдәсе белән кибән өстендә тору аңа һич тә килешми генә түгел, эчеңне тотып көләрлек, шуның өстенә ул чөйгән печән өемен эләктерә алмый азаплана, безне дә җәфалый иде.

— Вәт, шүрәле!— диде Одик, ачуы белән йөзендәге тирен сыпырып төшереп.— Эшләп үсмәсәң, шулай була ул. Ун яшьлек малай да моннан яхшырак тора.

— Әллә нәрсәгә өстен чишенгән булды!— диде Хак та йөзен сытып.— Шәрә килеш печән кылчыгы гына кадала бит. Әллә Маутхаузен тоткыны булып кинога төшәргә җыена.

Гафил, аркага кунып бимазалый торган бөгәҗгә һәм кигәвен кебек — иркенләп эшләргә ирек бирмәде:

— Давай, ял итеп алабысь!

— Эсьләп кем баеган?

— Бик кызыкса бригадир-кулак эсьләсен ана!— дип кычкыргалап, эшкә кәефне бозып торды.

— Син — анаң яламаган нәрсә!— дип сукранды Хак,— елавыннан туктыйсыңмы, юкмы. Чистый әшәке эт кебек...

— Нәрсә, каберенә алып бару өчен мал җыясыңмы әллә?— диде Гафил аңа өстән.

— Хай?— дип куйды Одик.— Валлаһи, сугып төшерәм бит, йә эшлә, йә юк — канны бозма!

Мин аларның сүз сугышына катнашмадым, күрәсең үзара әрепләшеп алырга һәм бер-берсенә каты сүз әйткәләргә Өчлек союзы күнеккән инде, уставларында бу тәртип бардыр. Чын дуслык — дөреслекне бәреп әйтү, диләр бит...

* * *

Соңгы кибәнне очлап бетергәч, корыган карама төбенә килеп хәл җыярга утырдык. Гафил авылдан алып чыккан транзисторын җибәрде. Болын киңлекләренә иркен музыка агыла башлады.

Безнең янга Мансур абый килеп утырды. Кесәсеннән шактый каралган яулыгын чыгарып, тирле маңгаен сөртте, кыршылып һәм мазутка буялып беткән иске фуражкасың үлән арасына куйды. Радиодан соңгы хәбәрләр бирәләр иде. Диктор дөнья хәлләре турында сөйли.

— Эс-се-е!— диде Мансур абый сузып кына.

— Дөньясы чаеры чырагачы кебек, дерт итеп кабынырга әзер,— диде Хак, уйчанланып.

— Шырпы сызсаң, һава да янып китәр кук,— дип куйды Одик үз алдына.

— Ә миңа салкын! Зил исә монда!— диде шунда Гафил. Барыбыз да күтәрелеп карадык: тавыш корыган караманың юан ботагыннан килә иде. Эссегә түзә алмагач, җилләү өчен ул шунда менеп утырган икән.

(Аннан соң Гафилне кайда гына күрсәм дә, нигәдер ул корыган карама ботагында утырган килеш күз алдыма баса торган булды. Үзе дә корыган — тире тарттырылган склет кыяфәтендә иде ул).

Кичкә таба көнбатыштан тагы болытлар куерып чыга башлады. Шулвакыт безнең янга Танир йөгереп килде:

— Егетләр, зинһар тыңлагыз, Озын бот болынында бер кечкенә кибәнлек печән бар, яңгыр яуса, харап булачак!

— Сәгать алты инде! Масьинага соңга калабыс,— диде Гафил.

— Соң, ярты сәгатьлек эш анда, мать-малина! Анаңны эт яламаган нәрсә!

— Үсең эсьлә алайса!— Гафил бирешми, һаман тарткалаша.— Үсең эсьлә, ярты сәгатьлелек булгась!

— Китер сәнәгеңне!

Танир уклау таягын тоткандай аның сәнәген эләктереп алды.

— Киттек!— диде Хак.

Сәгатькә карап куйган идем, егерме минут дигәндә, кибән өелеп тә бетте. Хәер, кибәне дә зурдан түгел иде...

Вәт эшләдек дисәк тә эшләдек! Әйтерсең, бу кибәнне салу — безнең алгы гомеребезгә юл салу иде. Бер минут, юк, бер секунд тын тору юк. Сәнәк сабы шартлап сынардай булып каерыла, муенга, чәчкә, аркаларга шыбырдап печән вагы коела, үзебездән гөжләп тир ага. Ул Танир! Бер күтәргәндә бер центнер күтәрәдер. Менә җегәрле дисәң дә җегәрле, куәтле дияргә була моны! Одик та, әлбәттә, аннан калышмый, Хак та тырыша, мин дә җан көчемне куям, хәтта берәзгәләп торган Гафил дә печәнне өлгеррәк каптырып алып кибәнне шактый гына матур очлап килә. Алайса тегеләре исерек агай кебек берсе — бер якка, икенчесе икенче

якка авышып беткәннәр иде — кичә безне мактаган Танир берничә мәртәбә яннан ыңгырашып һәм тамак кырып узды.

— Рәхмәт, егетләр,— диде бригадир, кибәнне очлап бастырыкларын элеп куйгач,— көндәлек эшне кем дә эшли, ә менә кинәт кенә кирәккәндә көч түгәсе булганда — күпләр сыкрап кала. Әнә шунда кемнең кем икәнен сынарга була инде. Рәхмәт, сынатмадыгыз, мать-малина!!

* * *

Иртәгесен коеп яңгыр яуды. Яңгыр кичтән үк сибәли башлаган иде, төне буе коеп чыкты. Ничә көннәр бер йотым суга интеккән үләннәр, агачлар, басудагы ашлык, бакчалардагы чөгендер, кыяр, помидор, бәрәңге туйганчы су эчтеләр. Урамда һәм бакча артларында гөрләвекләр акты, уйсу җирләргә бәләкәйрәк көймә белән йөзәрлек булып күлдәвекләр җыелды. Суны яратучы үрдәк-казлар барысы шунда ашыктылар. Дөнья мунча кергәндәй чистарынып калды, хәтта кояш та иртәгесен иртән яктырак һәм сафрак кебек тоелды. Күк йөзе гөнаһсыз унҗиде яшьлек гүзәл кыз тәне кебек чип-чиста, тигез, ниндидер илаһи иде. Офыкларга тикле күзне камаштырырлык зәңгәрлек иңгән, якты җылы нурлар хәтта күләгәле урыннарда да үзләрен сиздереп уйнапчагылып китәләр. Җирдән акрын гына җылы пар күтәрелә. Пешереп өстәлгә утырткан ярмалы бәрәңгенең буы кебек...

Иртәгесен печәнгә чыкмадылар. Табигать ничә көннәр эссе мич кебек һавада эшләтеп алҗыткан балаларына ял да бирә белә. Бүген — ял. Киленнәр су китерә, кер юа, мунча яга, агайлар ишек алдындагы вактөяк хуҗалык эшләрен карыйлар яисә берәр күршесе белән «ике башка оештырып», кибеткә бер яртыга йөгерәләр дә тынгылык бирмәүче хатыннарыннан бакча артына качып, бер чеметем тоз, ике телем ипи һәм суган кыягы белән зәм-зәм суын иплəп кенә гәпләшеп, суырып утыралар. Ачуыннан шартларга җиткән усал хатыннары: «Кая икән ул, каһәр сукканнар»,— дип эзләп карасалар да, таба алмыйлар. Җәй — җәй инде ул, теләсә кайсы җирдә ауна, җаның теләгән төшкә ят!

Без печәндә йөргән арада, идәннәрен буяганлыктан, кунак кешегә җайсыз булмасын дип, Одик белән печәнлектә бергә йоклыйбыз дигәнемә карамастан, Мансур абый мине хатыны Газзә ханымның әнисе Зөһрә әбиләргә урнаштырды.

— Курыкма, бик чиста, тәртипле ул минем әби,— диде Мансур абый миңа.

Карчык белән без бер көн эчендә дуслашып киттек. Чәченә чал кереп, алгы тешләре коелуына карамастан, сиксән дүрт яшьтәге бу әби ифрат житез һәм һәрнәрсәгә өлгер иде әле.

— Безнең саулык,— диде ул зарланып,— бернәрсәгә дә тормый, менәтерә. Минем әни йөз дә өчтә үлде, йөгереп йөри иде әле!

— Әби, унҗиде яшьлек кыз кебек әле сез,— дидем мин мәгънәсезлегемне сүземне әйткәч кенә аңлап.

— Хи-хи-хи,— дип көлде ул тешсез авызын җәмәйтеп.— Унҗиде яшемдә мин Зәйнигә кияүгә чыктым, улым, менәтерә. Моннан алтмыш җиде ел элек...

Авылның агач күпере кырыенда биек манарасында көмеш ай утырган иске, әмма әле нык сакланган мәчет бар иде. Мине шул мәчетнең ничек җимерелмичә яисә манарасы киселмичә бүгенге көннәргә кадәр торуы кызыксындыра иде. Әби менә нәрсәләр сөйләде:

— Ярлы идек, менәтерә, без ул вакытта. Элеккеге Зәки Мулла мәхәлләсе саналган сары мәчетнең манарасын вулыс, сөлсәвет кешеләре кушуы буенча Сәлах өч пот онга кисте. Әмма ул гына ачлыктан балаларын коткара алмады: икесе үлделәр, менәтерә, Сәлахның үзенең бер күзе сукырайды. Алла каргышы төшкән, диделәр. Бер көнне Зәйни өйгә

кайтып керде дәген, менәтерә, инешнең аръягында Фаяз мулла мәхәлләсе салган яшел мәчетнең манарасын өч пот онга кисеп төшерәм дип йөри, менәтерә. Сәлах: «Бер күзсез калдым, икенче күземнән язасым килми, кисмим мин ул манараны»,— дигән имеш. Мин дәген Зәйнигә әйтәм: «Маташа күрмә, карт, дим. Гөнаһы зур, саулыгыңа зыян килер»,— дим. Тыңламый бит, менәтерә. Елап та алдым, кеше алдында хур итмә гаиләбезне, йөзебезне ачырмаслар, дим. Тыңламый, менәтерә. Шуннан нишләдем, дисеңме? Иртә белән торгач, ашына сиздермичә генә бер чүмеч кайнамаган салкын чишмә суы салдым, и-и, мәрхүмемнең, урыны оҗмахта булгыры! Ашап та бетерә алмады, тышка чыгып йөгерде, мин сиңа әйтим, менәтерә. Ә мин үзем куркам, каты күңелле адәм иде бит, мәрхүм, белеп алса, кулыңны сындырып ташларга дагын күп сорамас, менәтерә, үзем яулык почмагы белән авызымны каплап пышык-пышык көләм. Картым өстенә киеп чыгып китәргә генә җыена, эчен тота дагын тагы абзар артына йөгерә. Икеме-өчме чыккач: «Хатын,— ди бу,— сүзең синең, валлаһи, дөрескә чыкты, эч тотмый башлады бит әле минем, ыштан төбен дә пычратып бетердем. Бармыйм болай булгач, өч пот онга кызыгып, саулыгымнан язасым килми. Шуның хикмәте бу, ди. Иртәгесен бу хәлне авыл кешеләренә сөйләгән. Шуннан соң ник берсе йөрсен мәчет манарасын кисәм дип, менәтерә. Шулай исән калды ул мәчет...

Без әби белән рәхәтләнеп көлдек, ә ул кәҗәсен саварга чыгып киткәч, мин үз уйларыма биреләдем...

Менә бит гади халыкның көче кайда! Начальствога жалоба белән район юлын таптап йөрми, чыр-чу килеп җыелышларда кычкырмый, үзенә кадерле булган әйберсен саклау өчен, кирәк икән, ашка бер чүмеч салкын су гына сала...

* * *

Әгәр тормыш юлын поезд юлына охшатсак, аның рельсләре мәхәббәт һәм нәфрәт булыр иде. Без кешеләргә карата гына түгел, үзебезгә карата да мәхәббәт һәм нәфрәт арасында яшибез, шуңа күрәдер инде мин үземне яратам һәм күрәлмыйм...

Икенче көнне үк Зөһрә карчык мине орышып ташлады. Ул болай булды...

Зөһрә әбинең ишек алдында былтырдан калган утын тумраннарын ярып ята идем, сугышып йөреп койрыгында ике каурые гына калган, бер канаты асылынып йөри торган, сыңар күзле, кара-кучкыллы алама әтәч (күршеләрнеке булса кирәк) урам як коймага сикереп менде дә: «Кәкре кук!» (Әллә минем балта сабын әйтә инде?) дип гөрселдәтеп кычкырып җибәрде һәм «Кот-коткып, алам кот-ын!»— дип бугай, ишек алдына сикереп төште. Аннан-моннан бер-ике ярманы, нидер табып кәкре борынлы авызына озаткач, әкрен, әмма вәкарь генә басып, ләгәннән он белән бутап бирелгән бәрәңге ашаучы тавыклар янына килде. Аңа комачау итүче юк, чөнки Зөһрә әбинең озын кикрикле, зәһәр һәм мәһабәт кызыл әтәче печәнлектә яраткан тавыгы белән иде. Аңа кушылып-кытаклашып күкәй салырга булыша.

Мин балтаны бүкәнгә чабып, тәмәке кабыздым. Сыңар күзле әтәч, сыңар тәрәзәсеннән карап, тавыкларга нидер сөйләнә, үзе купшыланып-шәпләнеп биеп ала, тирәләрендә әйләнеп йөри һәм бертуктаусыз: «Кот-кот-котын... алам котын!»— ди. Кемнең котын ала? Минекенме?? Әһә, әнә кемнеке икән — күз ачып йомган арада кызыл шар тәгәрәп килде дә кара-кучкыллы шарга ташланды. Һәм китте, мин сиңа әйтим, сугыш — каралар һәм кызыллар сугышы!

Адәм балаларына каян килгән гадәттер (ә бәлки борынгы инстинкт): хайваннар яисә кошлар сугышы башландымы, бар эшен ташлап, шуны

тамаша итәләр. Мин дә шул халәттә идем. Бигрәк тә әтәчләр сугышы, кызык!

— Ник сугыштырасың аларны, менәтерә?— дигән тавышка борылып карасам, Зөһрә әби кәҗәсен саварга баскычтан төшеп килә икән: бер кулында литрлы банка, бер кулында кәҗәсенә «мәмәй» (ул үзе шулай ди) — ике телем ипи. Әби әтәчләрне тиз генә аерды, күршенеке: «Кот-кот-котылыйк!» — дип, ачык капкадан чыгып шылды.

— Нишләп мин сугыштырыйм ди аларны. Үзләре бит, әби,— дидем мин, уңайсыз хәлдән тизрәк чыгарга тырышып һәм бер үк вакытта акланырга теләп.

— Үзләре дип... Менәтерә! Үзе укыган кеше, үзе кешеләрне сугыштыра.

Монысы аяз көнне яшен сугу белән бер иде. Нинди кешеләрне сугыштырыйм, ди, мин. Әби саташамы, әллә акыл ягының шулай зәгыйфьләнеп ала торган гадәте бармы? Булмас димә — сиксән дүрт яшьтә бит инде ул...

— Кеше түгел ич алар, әби, әтәчләр...

— Соң... Менәтерә, барыбер кеше кебек җанлы ла алар. Менәтерә! Укыган кешеләр кешеләрне сугыштыралар...— диде әби, һаман әлеге сүзләрне кабатлавы белән минем йөрәктә ачылган ярага (укыган кешеләргә барысын сылтау ярасы) бер уч тоз сибеп.

— Соң, әби җаным, укыган, укымаганның монда ни катнашы бар?

— Менәтерә, үзе укыган, үзе шуны аңламый!— диде ул,— маңгаенарак шуышкан бер тотам ап-ак чәчен яулыгы астына яшереп.— Укымаган надан кешеләр бервакытта да сугышмыйлар. Нәрсәгә аларга сугыш? Аларны укыган кешеләр сугыштыра. Алар башта әтәчләрне сугыштыралар, аннан соң — кешеләрне...

«Йә, Аллам, каян кергән аңа бу фикер?»

Мин нигәдер сәерсенеп, әбинең купшы һәм көяз әтәченә күз салдым:

— Кем алай диде сиңа, әби?

— Кем дип... Менәтерә! Үзе укыган, үзе шуны да белми. Кырык беренче елгы сугышны кем башлады? Иттер!

— Иттер?

— Әйе, Иттер...

«Йә инде, үзең шигырь язып йөргән буласың тагы!— дип сүктем шунда үз-үземне эчемнән генә, рифмасы ук кычкырып тора бит: Гитлер... Әби аны «Иттер» ди. Әби белән сүз никадәр җитди булуына карамастан, чак кына көлеп җибәрмәдем. Менә син аны, әй! Иттер... Ит-тер, ди бит.

Зөһрә карчык сүзен дәвам итте:

— Ә аны әллә укымаган кеше дип уйлыйсызмы? Безнең кебек әлифне таяк дип белми ди сиңа! Укымаган булыр, пычагым, укымаган булса, Ирмания җиренә патша итеп куймаслар иде. Ә сугышны шул патшалар башлый, ил башлыклары...

Әбинең күзләренә карагач, аның сүзләренә шулкадәр инанып-инанып сөйләвен күрдем ки, берсүзсез бу «ученый-карчык» белән килешергә мәҗбүр булдым һәм — һәр ачу чит нәрсәдән алына — укыган башымны хур иткәне өчен, авыр-авыр бүкәннәрне каз мамыгы тотырган мендәр урынына гына күтәреп, ачудан тагы утын яра башладым, ә әби кәҗәсе янына китте.

«Аңлатып кара син аңа! Әтәчләр сугышуын да күрә алмый — үз гомерендә күргән сугышлардан гарык булган, күрәсең...»

Дөрес, безнең буын сугыш күрмәде. Әмма без аны ишетеп тә гарык булдык. Без аның үзен түгел, күләгәсен кинодан күреп, шәүләсен китаптан укып та нәрсә икәненә төшенгән буын...

Мин утын ярам, сирәк эшләүдәнме, әллә кояш кыздыра башлагангамы, маңгайдан шабырдап тир ага. Аксын, тир агу сәламәтлек дигәннәр, кан гына акмасын, кан гына... Куллар, бигрәк тә кулбашы сулкылдап-сызлап куя. Сулкылдасын, сызласын, өзелмәсен генә, каерылмасын

гына... Лапаста әбинең литрлы банкасына безләп сөт ага: «Без-з-зк! Без-з-зк! Без-з-зк!»

Унлап кына бүкән калган иде, әби кәҗәсен савып бетергүгә мин дә эшне төгәлләдем: ярылган утын шактый зур өем булып ишек алды уртасында ята иде. Берәр сәгать ял иткәч, әрдәнәгә өеп ташламый булмас. Одик та мәктәптән кайтканда кереп житәрмен дигән иде. Бүген аның отпуск срогы бетте. Физкультура мәйданчыгын яңа уку елына әзерлисе бар, ди. Минем бер-ике көн аның белән мәктәпкә барырга да исәп бар. Аңа булышырга һәм мәктәпне карарга. Мәктәп искеме ул, яңамы — авылда иң хөрмәт ителә торган йорт. Кәҗәсен мактый-мактый миңа сөт эчергәндә, Зөһрә карчык тагы сүз башлады, күрәсең, әйтәсене эчтә калдыра торганнардан түгел:

— Ярый, улым, ачуланма инде, яме. Кызып киттем, менәтерә...

— Юк, юк, әби, үзегез миңа ачулана күрмәгез.

— Ачулана күрмәгез дип, кемнәргә әйтәсең?— Карчыкның тавышы тагын кырысланды.— Мин берәү генә бит, әллә кәҗәмне дә кертеп сөйләшәсеңме? Ул безнеңчә аңлаша белми...

Тагы бер кавемгә аптырап калдым. Билләһи дим, сак сөйләшергә кирәк бу карчык белән!

— Әби, жаным, кешегә олылап эндәшкәндә күплектә сез, диләр...

Ул монысына риза булмады:

— Күплектә? Менәтерә? Син күплектә эндәшүдән Зөһрә карчык артмый шул. Ул берәү генә. Аннан соң, әби жаным димә, минеке кадәр жаның булса, син сиксән дүрттә булыр идең инде!

Карчык кабаланып, сөт сөзә торган савытын алды һәм миңа карамый гына үз алдына сөйләгән күк:

— Әйтәм бит, укыган кешеләрнең сүзе дөрес түгел дип, сүзе белән эше туры килми аларның!— диде.

— Әби, жаным!— дидем мин ялварып (тагын «жаным» ычкынды).— Ничек инде туры килми? Укыган кешенең сүзе дөрес түгел, ә укымаган наданның дөресмени?

Карчык бу юлы чын-чынлап ачуланды:

— Менәтерә! Шуны да белмисең икән!! Без наданнарның эче — тышта, ә сезнең тышыгыз да эчкә бикләнгән. Без бәреп әйтәбез, усал сөйләшәбез. Ә сез — матур, боргалап. Һәрвакыт ни сөйләгәнегезне аңлап та булмый. Сезгә барысы да — әйбәт, ә без күбрәк начар якны күрәбез һәм шуны сүгәбез. Менә шулай, улым!

Соңгы сүзләрен әйткәндә әби миңа чыннан да улына акыл бирүче ана кебек күренде. Ул матурлыгын жуйса да, терелеген югалтмаган күзләре белән жемелдәп, кыска һәм кискен генә, әмма яратып әйтеп куйды:

— Менәтерә!

Шушы сүздә, безнең сөйләшүгә нокта куелып, дөреслек әби ягында, дигән ышаныч ярылып чыкты.

Мин чын-чынлап жиңелдем...

Нәрсә әйтим мин аңар?

Сиксән дүрт ел дөньяда яшәп, агын һәм карасын күреп, ачысын һәм төчесен татыган олы тәжрибәле, шулар өстенә иң мөһиме: һәр нәрсәгә үзенең туры хөкеме, катгый фикере булган яшәү өчен яшәгән карчыкка тагын ни әйтим ди мин...

* * *

Печән өстендә чуртан балыгыннан пешкән шулпа авыз иткәнгәме, Вятка буенда уха пешерү арткы планга кала башлаган иде, бер хәл бу эшне көне-сәгате белән тизләтте тагы. Бер-ике тапкыр Одик белән мәктәпкә чыкканнан соң, мин иртә белән торып, культура йортына Хак янына барып утыра башладым. Гәжит-журнал караштыра-

быз, бильярд уйныйбыз, берәр партия шахмат сугабыз һәм... һәрвакыт, пыскып яткан черек бүкән кебек, төтенлибез.

Зәңгәрсу йомшак материя тарттырган киң һәм зур өстәлдә антоновка алмалары кебек тәгәрәп яткан соргылт-яшел шарларны бер кырые каерылып чыккан өчпочмакка урнаштырып кына ята идек (дөресе: мин кий тотып торам, Хак тәмәке тарта, мәктәптән кайтып яңа гына килеп кергән Одик шарлар җыя) җил-җил атлап, борчылуы һәм ачуы йөзенә чыккан Мәйсәрә апа килеп керде:

— Хак, ике бәбкәбезнең башын борып алып киткәннәр. Минһаҗ малае күреп калган, кара Жигулида килделәр, ди. Казларны таба алмадым. Идел буйлап аска, Кәримулла утравына акмадылармы, дим...

— Фу!— дип, бик тиз генә сүгенеп куйды Хак (ни дип сүгенде: Одик та, мин да аңламадык)— Былтыр Зөһрә әбинең җиде баш казын харап иттеләр, быел...

Мәсьәләгә якын килергә тырышып, мин үземнең наив соравымны куйдым:

— Ә кемнәр соң алар?

— Кемнәр булсын...— диде, Хак урынына, Одик,— каз караклары!

— Жигулига утырып киләләр дә — әзер ит! Кемнең каз боты кимерәсе килми. Хәзер җәй базарда аны шәм яндырып та таба алмыйлар,— дип куйды Хак һәм шарларны кулы белән чәчеп җибәрде:

— Моңа чик куярга кирәк, Хак! Казларга погром ясап йөрмәсеннәр. Бүген — синеке, иртәгә — безнеке, берсекөнгә — барыбызныкын ашап бетерерләр алар, ачкорсаклар!

— Үзләренә погром оештырыргамы?!— дидем мин, ярым чын, ярым юри.

— Куып җибәрергә аларны моннан... Тагы да оятсызланалар икән, Америкадагыча шәрә тәннәренә бал яисә солидол сөртеп каз мамыгына батырырга кирәк!

Одик бу сүзенең чын күңелдән түгел, болай гына әйтелүен раслапмы, көлеп җибәрде. Аңа без дә кушылдык.

Каз каракларын табарга кирәк иде. Хак шулай уйлады. Каяндыр килеп чыккан Гафилгә хәлне сөйләп бирдек.

— Да-да!— диде ул, әче әйбер капкандай чыраен сытып,— вакланды кесьсе: элек ат караклары булган, хәсьер кась караклары. Бүгенге Сәкурлар... Вак-ла-на ха-лык!

Одик башка бер сүз әйтмәде, тиз генә өенә җилдертте һәм ун минут та узмагандыр бер кулына бензин багы, икенчесенә бәрәңге, ипи, суган кыяклары һәм тагыниләрдер салынган сетка тотып, килеп тә җитте.

— Вятка ухасы ашыйбыз бүген!— диде ул, миңа карап.

Гафил, үзе әйтмешли, бу «экспедициягә» бик катнашырга теләсә дә... никтер күренмәде. Югыйсә, «мин дә барам», дип, чынлап әйткән иде. Одик белән Хак аны көтеп тормаска, кузгалырга дигәннәр иде, мин каршы төштем:

— Барам, диде бит ул!

— Ул әйтер, әмма эшләмәс!— диде Одик, кечкенә балтасының бушая башлаган сабын тыгызлау өчен тимер чөй суга-суга.

— Килми ул, аның сүзенә ышану — суга таяну,— дип куйды Хак.— Аңа ышанма, Иделгә таянма!

Шуннан соң өчәү генә кузгалдык.

Одикның әйтүе буенча, узган төшкәнендә ул көймәсен колхозның яшелчә бакчасындагы парниклар турысында калдырган икән. Юл — шулайга таба.

Инеш яры сукмагы буйлап барабыз. Көн кичәгедән дә матуррак булып, ялкау гына тымызык җил исеп тора. Инеш буенда котырып үскән әрем-кычытканнар, куе таллар, зифа тупыллар, кызыклы кино караган тамашачылар кебек, тып-тын калганнар, судагы казлар канатлары белән гәүдәләрен суккалап мунча чабына, үрдәкләр, сай җылы куеннарга кер-

гән маймычларны эзләп, болай да яшькелт күрән суны пычратып богырдаталар. Инә караклары, төклетуралар һәм сирәк генә бал кортлары үзләренең дөньяда икәнлекләрен белдереп, очып торалар, сырышкы вак чебеннәр янакка, чәчкә яисә маңгайга кунып, ваемсыз гына барган чакта сискәндереп куялар, буш кулны эшкә җигәргә һәм үз битеңә үзең чәп иттереп сугарга мәҗбүр итәләр дә шуннан кызык тапкан төсле баш очында тавышсыз гына көләләр. Чирәмлектә казыкка бәйләнгән эреле-ваклы төрле төстәге бозаулар һәм берьеллык баһадир үгез безне битараф кына каршы алсалар да, Одик кулындагы әйберләрен тиз генә җиргә куеп, бер-икесенең казыгын ныгытты, берничәсенең алдына сыер тизәгендә аунап яткан чиләкләрне сөрткәләп инешнең чиста урыныннан су алып килеп эчертте.

— Барысы да сезнекеме әллә?— дидем мин аптырабрак.

— Юк, барысы да түгел...

— Монда синеке-минеке юк,— диде Хак,— кемнең вакыты бар, шул караштыра. Сараеңа кайткач кына синеке ул. Монда җәй ул — бисмилла, абзарыңа көз кайткач — аллаһы әкбәр!

Баһадирга да су эчерештеләр.

Бу церемония тәмам булгач, юлны дәвам иттек. Күпмедер үткәч, инешнең чәй чынаягы кадәр ак ташлары төптә ялтырап яткан урыныннан аргы якка чыктык һәм тупыл урманына кердек. Монда җиләс һәм күләгәле иде. Бары озынборыннар гына борчып маташа, алары да күп түгел, дөньяның тоташ оҗмах түгеллеген искә төшерү өчен генә...

Аяк астында корыган агачларның скелетлары — ботак-чатак шартлап сына да яшел яфраклар кочагында утырган кошлар пырлап очып китәләр. Без барган бу сукмак буйлап күптән йөрмиләр булса кирәк, аның кырыйларын тигәнәк һәм зәһәр уклы яшел кычыткан баскан, чамалабрак бармасаң, читкә тайпылсаң, алар язгы усал ата каз кебек каптырып-тешләп алалар. Тигәнәк киемгә кадала, кычыткан — тәнгә...

Инеш ярында ук үскән, биек һәм юан, тирә-якка йомшак мамыклардан мендәр түшәгән карт тупыл янына җиткәч, Хак кинәт туктады:

— Монда бик тәмле сулы чишмә булырга тиеш, Гайнул чишмәсе... Туктап суын эчик әле,— диде.

— Хай! Ис шул,— дип җөпләде аның сүзен Одик, кулындагы әйберләрен люцернага охшаган куе үлән өстенә куеп.— Хәзер аны ел саен Әхмәтнур чистарта. Балаларга суны мәктәптә шушыннан ташыйлар. Эчәр өчен... Билләһи, минем бу чишмәнең үзеннән су эчкән юк иде әле. Хай!

Чишмә суы чыннан да тәмле иде, туйганчы эчтек. Аннан соң Хак белән яр буена утырып, сигарет кабызып җибәрдек. Мин тирә-ягыма карандым. Дөнья матур, һава үпкәләргә үзе бәреп керә, йөрәк сәгать кебек текелдәп, үзеңдә куәт сизеп эшли, җанның бер генә минутка булса да каядыр еракка, зәңгәр күккә, җиңеллеккә күтәреләсе килә. Нинди хозур! Әйбәт тә нәрсә соң дөньяда яшәве!!

— Эх!— диде Хак.— Кайчандыр бу чишмәгә әбиләр-җиңгиләр, бигрәк тә кызлар! Хе-хе-хе!.. Кызлар суга төшә иде. Мәйсәрәне беренче тапкыр шушында тупыллар арасында үптем мин, кичке уенга чакырдым, йөрергә сүз куштым. Эх-Эх-Эх!! Ә хәзер? Ерак, имеш! Өч йөз метр ара килер өчен ерак, имеш. Өйдә ялкауланып ятасы бар бит... Телевизор карыйсы бар! Шуңа күрә хәзер кызлар, унбиш-уналтыга житми, симерә башлый. Тутырган тавык кебек! Мин әлбәттә, манекен кебек булсыннар димим. Хатын-кыз йомшак тәнле, кем әйтмешли, тотып карарлык ите булсын инде аның... Киптерелгән балык кебекләрен сөймим...

Аннан соң ул ярым борылып, Одикка карады:

— Ул яктан синең Әдилә хәтәр, ә?

— Әдиләнең исеменнән чәчәк исе килә!— диде Одик уйчан гына.— Минем өйдә Әдилә гөлем бар...

Хак тиешсез сүзгә кергәнен аңлап, элекке уена кайтты:

— Спорт-физкультура, диләр... Элеккеге кешеләр бу турыда сөйләмәгәннәр, ә эшләгәннәр: ярты километрдагы чишмәгә суга барганнар — менә сиңа спорт! Егетләр унар чакрымдагы авылга кызын күрер өчен җәяү йөргәннәр — менә сиңа физкультура! Ә хәзер? Тьфу! Кран борасы — су ага, аяк тибәсе — матай чаба... Кешене ялкаулыкка, селкенмәскә өйрәтеп бетердек. Аңларбыз соңыннан — соң булыр! Пешкән — шешә!

— Әхмәтнурга рәхмәт! Чишмәне үтермәгән, терелтеп җибәргән...— диде Одик.

Без тынып калдык. Одик чишмәгә төшә торган сукмак кырыендагы тигәнәкләрне балтасы белән чабып атты, Хак белән без икәү эт эчәгесе үләннәре йолкыдык. Өч-дүрт минут узуга сукмак ялтырап матураеп калды. Гүя монда көн дә, сәгать саен, минут саен су эчәләр. Кеше кулы гына орынганын сизсен, табигать көяз кыз кебек шундук үзгәрә, гүзәлләнә ул. Табигать белән тәңгәл килгән кеше генә аның кочагында яшәргә тиеш!

Ары киттек...

Инешнең төньяк яры шактый текә һәм биек (25—30 метрлар чамасы) тау булып, без шуның өстенә күтәрелдек. Каян килеп кергәндер андый уй: нигәдер миңа бу минутта шушы тау-ярдан атлау гигант динозаврның өстеннән бару кебек тоелды. Бәс, бер уйласаң, без үткәннәр өстендә яшибез дә ич! Уйлар тагы бик борынгы заманнарга сәяхәткә чыгарга җыенганнар иде, аларны Хакның усал һәм нигәдер калынаеп киткән тавышы бүлде:

— Әнә, каз ите яратучыларның учак төтене күренә!

Чыннан да, Вятка уртасында ташбака кебек яткан Бәләкин утравының тәбәнәк таллы һәм сирәк-мирәк чирәмле көньяк борынында сыек кына зәңгәр төтен туры багана булып фирүзәдәй күккә барып тоташкан иде. Учак тирәсендә икеме-өчме гәүдә селкенә, тагы икесе яр буенда артык эчкә керми генә бала-чага кебек чыр-чу килеп, көлешә-көлешә су коенып яталар.

— Алда дошман гаскәре — бер взвод!— дип шаярткан булдым мин.

— Әйе,— дип куйды Хак.— Өерләре белән килгәннәр, бер-ике кисәк кенә йөрергә куркалар, дуңгызлар!

Одик дәшмәде, йөгереп яр астына төшеп китте дә моторы белән булыша башлады. Ашыкмый гына свечаларын алып чистартты, чүпрәк белән мазут-саз сыланган корпусны (хәтта ул ялтырап торса да!) сөртте. Аннан соң артык көчәнми генә шнур бауңы тартып җибәрүгә, елга өсте тынлыгын беркадәр бозып, мотор гөрелди башлады: калаклар болгатып чыгарган судагы йөзләгән күбекләр мотор тавышы белән кушылып, шул көйгә дерелдәргә һәм биергә тотындылар.

Одик рульне туп-туры каз каракларына төбәп тотты. Безнең алда гына очып баручы җитез акчарлак кинәт таштай суга атылды һәм җиңү тавышы белән зур гына балыкны эләктереп өскә күтәрелде.

Каз караклары учак тирәсенә җыелдылар һәм сәерсенеп безгә карап тора башладылар. Читтән караган кешегә дә ачык күренә: аларны каушау катыш аптырау һәм нидәндер шөбһәләнү биләп алган иде.

Моторлы көймәнең очлы борыны үткен кылыч кебек кытыршы һәм дымлы комны ярып керүгә, без ярга сикердек. Хак нигәдер кулына балта алды, Одик штанга күтәрергә әзерләнгән спортсмен кебек билендәге киң каешын кысыбрак куйды, ә мин ике кулны да кесәгә тыктым, әмма үз-үземә бик тә ышанган кыяфәт чыгарып, тегеләр янына атладым.

— Каз ите тәмлеме?— дип сорады Хак, юри баналь сорау биреп.

Җавап юк.

— Бәлки безне дә сыйларсыз?— дидем мин, гайрәтле генә.

Эндәшмәделәр.

— Югалыгыз күземнән, дуңгызлар!— дип кычкырып җибәрде кинәт үзен шактый сабыр тоткан Хак, балтасы белән кизәнеп.

Мин аңа күз салдым: Хакның ачуы яман иде.
— Алайса бер-икегезне чабып үтерәм!
— Киттек, егетләр...— диде каракларның өлкәне, кырык яшьләрдәге симез йөзле, кыска аяклы адәм. Аның күз төбе кара көйгән иде, күптән түгел генә аңа «төшергәннәр» булса кирәк.
— Ә нәрсә алардан куркырга?! Кирәк икән — үзләрен...— дип, әтәчләнә башлады озын буйлы, күкрәгенә тәре-медальон таккан пумала чәчле чандыр егет.
Шулвакыт Одик тыныч, әмма гаҗәеп бер өлгерлек белән аның янына килде һәм биленнән тотып кәҗә бәтие урынына күтәреп алды:
— Улым, үтенеп сорыйм, өеңә кайт!— диде ул, аңа астан өскә караган килеш һәм кинәт кенә тегене тып! итеп җиргә бастырды.
— Тыңлагыз әле, егетләр,— дидем мин, киеренке хәлне йомшарту теләге белән.— Яхшы чакта, китеп югалыгыз. Үз гаебегезне үзегез беләсез — ычкыныгыз кызурак, моннан соң бу эшегез тагы бер кабатланса...
Одик каз бәбкәләре йолкынган җирдән берничә мамык алды да әлеге озын егетнең маңгаена төкерекләп ябыштырды:
— Икенче тотылсагыз — дегет сөртеп, мамыкка батырып җибәрәбез. Америка тарихында шундый хәл булган, беләсезме? Факт бу — әкият түгел!
Каз караклары (су коенганнары чыннан да ике кечкенә малай булып чыкты!) тиз-тиз генә әйберләрен җыйдылар да, эчендәге пычрак суы да түгелмәгән иске көймәгә утырып, чайкала-чайкала теге якка чыгып киттеләр. Мин зур тавыш кубар, хәтта сугышуга кадәр барып җитәр дип уйлаган идем — намусын бөтенләй югалткан кешеләр түгел икән — ояла белделәр.
Көймәгә утырганда өлкәне, симез йөзлесе:
— Гафу итегез, башка кабатланмас...— диде.
Учакта богырдап шулпа кайный. Караклар ике бәбкәне түгел, бер ата казның гына муенын борганнар икән. Ул хәзер ике ботын һавага чөеп, кайнар суда пешеп ята. Аңа хәзер нәрсә: яшәү ни дә, үлем ни... Беткән инде ул... Кайтмаска киткән...
Трофей шулпаны ашап тормадык, тамакка инә булып кадалыр, ашказанын көйдерер кебек иде ул. Ашның да намус белән пешкәне яхшы! Шундые гына тамактан шәп үтә һәм тәмле дә була...
Каз караклары пешергән каз шулпасын Бәләкин комы эчте...

* * *

Без балык тотып ятканда, Гафил килеп төште: гадәттәге модный чалбар, киң каеш, ак күлмәк. Авызында затлы сигарет «Космос». Үзе — Одик мотоциклында.
Одик белән Хак чөгә балыгы турында бәхәсләшеп яталар. Кармакка эләккән чөгәне Хак:
— Ухага шәп ул, алыйк,— ди.
Одик:
— Соң, карандаш кадәрле генә бит ул. Җибәрик, чөгәне тотарга ярамый. Шуны да белми, хай!— дип аптырый.
Ахырда җибәрделәр — тәмле итле балык елан кебек боргаланып үз стихиясенә кереп китте, әмма үч иткәндәй тагы берәү, нәкъ шундый ук, килеп капты.
Бу юлы өстенлекне Хак алды:
— Безнең ухага... тәм өчен генә... бер экземпляр... Гөнаһ дисәң, гөнаһтан пәйгамбәрләр дә читтә йөрмәгән, диләр.
Уңлап балык кабуга, уха хәстәрен күрә башладык. Беребез утын ташырга, икенчебез балык чистартырга, өченчебез бәрәңге әрчергә, дүртенчебез чишмәдән су алып килергә тиеш булдык. Чишмә ерак иде —

Одик китте, Хак — балыклар янында, Гафил якын-тирәдә аунап-өелеп яткан чыбык-чабык җыя башлады, миңа — бәрәңге.

Эшләрне төгәлләп, Вятка ярына кул юарга төшкәч, Гафил ни ултара, ни пултара дигәндәй, миннән сорап куйды:

— Карагысь әле сеф, сес үсегес үгесь кебек таса адәм, ә кулыгысь кысьларныкы кебек нәфис. Нидән ул?

— Ручкадан битәр әйбер күтәрмәгәнгә...— диде минем өчен Одик, сумкадан суган кыягы ала-ала.

Хак көлеп куйды:

— Үзеңнеке ичмасам көрәк кадәр булсын иде...

— Ә шулай да,— диде Одик сумкасын кага-кага.— Аның нәфис кулы синең нәзек кулыңны тотса...

— Әйдә, кул көрәштерәбез!— дип ярып салды, әтәчләнә башлаган Гафил, күзләреннән ачу бөркеп.

Мин үзалдыма елмаеп куйдым. Аны егачагыма ышана идем. Аны гына түгел, бармак юанлыгы сеңерләре — кан тамырлары уйнап торган Хакны да, хәтта (бәлки???) Одикны да... Кул көрәштергәндә таза-таза ирләрне эх тә димичә өстәл тактасына сылаганым бер генә булмады. Кечкенәдән үк каты куллы идем, бу бер яктан баржа төягәндә унбиш катлы молотилканы җилкәсенә салып траптан алып менгән әтидән иңгән көч булса, икенче яктан егет чакта ук штанга, гер, көрәш белән ныгытылган мускуллар (мыскыллар түгел!) нәтиҗәсе иде.

Чытырдап ябышкан Гафилне мин, әлбәттә, бик тиз җиңдем. Ул бәхәсләшеп-әрепләшеп, тагы ике тапкыр тотынса да, берни тожыра алмады.

— Бөркет белән карганың кайчан көч сынашканы бар?— диде Одик үзалдына. Ул аны көлүен сиздермәс өченме, юри уйчанланып әйтте һәм учак кабызып җибәрде. Гафил ачуыннан сикереп торды да ак күлмәген салып җиргә ыргытты һәм кызу-кызу адымнар белән яр буена китте.

— Зерә рәнҗеттегез кешене,— диде Хак.— Кеше күңеле — пыяла, ватыла да уала...

Әмма аның тавышында Гафилне түгел, гомумән, кешеләрне рәнҗетмәскә кирәк дигән аваз бар иде.

— Юри егыласы калган икән...— дидем мин чын күңелдән.

— Юри егылмыйлар!— дип кырт кисте Одик.— Аның кебекләр дөньяда юри егылганнарны көтеп яшиләр дә...

Гафил ярдан ерак түгел тездән суда коенып ята иде.

— Тирәнгә керергә курка!— дип көлде Одик, мотоциклының бензин багын чүпрәк белән ыхтыматлап сөртә-сөртә. Мотоциклын ул алдагы көнне Гафилләрдә калдырган булган икән.

— Йөрәк ялкынын басарга кайвакыт бер стакан су да җитә,— диде Хак.

...Чишмә суы белән чиләкне асып куюга, Одик мотоциклын кабызып «зәм-зәм» суына кайтып китте. Хак аңа этеңә атарсың дип, юньләп йолкынмаган, арык ата казны тоттырды. Чүпрәк белән төреп, арткы утыргычка бәйләп куйдылар.

...Гаҗәп иде бу балык шулпасы. Ашаган саен ашыйсыны китерә. Чишмә яныннан тотып алып килгән банкага тутырып эчеп җибәрәсең — бөтен тәнеңә дәрт-көч, тыгызлык иңгәндәй була.

Берәм-берәм барыбыз да чиләк тирәсеннән кузгалдык, бары Одик бер үзе генә калган көе нәсел үгезедәй мыш-мыш килеп, аякларын төрекчә бөкләде дә калган шулпаны тамчысына кадәр сугып куйды. Вәт аппетит дисәң дә аппетит! Бүре аппетиты, бүре ашказаны! Чыннан да, эшләгән кебек ашый икән...

— Кая бара ул сьсинең, әллә Сомбай эсьләпәсе кебек тисек урыныннан зиргә агып торамы?— диде Гафил, мыскыллы көлеп. Аш яныннан иң беренче ул кузгалган иде. Әмма аның көлүендә мыскыл түгел, ә шушы

аттай эшләүче, сыердай ашаучы, үгездәй таза-куәтле егеттән көнләшү төсмере бар иде.

— Арык атның ашавы да арык, ашар иде — тагарагы ярык! — диде Одик, кашык-тәлинкәләрне юар өчен чиләккә тотырып.

Гафил көлүне миңа күчерде:

— Сеснең дә корсак сәрифләре алга таба сактый сөрлеккән, әмма ихлас әйтәм: асау ягы...

— Эш корсакта түгел, тештә... — дидем мин.

— Ә теш — эштә! — дип көлде Одик, урыныннан кузгалып.

— Әйе! — дип килеште Гафил.

Ул урынсыз сүз кузгатып, тагы кәефне боза башлавын төшенгән иде. Әллә җиңелгәнен аңладымы...

Ашап туйгач, таллар арасына кереп югалган Хак безнең янга килеп җитте дә:

— Тагы бәхәсме? — дип сорады.

Нигәдер аңа беркем дә җавап бирмәде.

Одик кара корым ялаган чиләген алды да салмак һәм нык адымнар белән басып, каршыга искән сыек җилне куәтле һәм таза гәүдәсе белән җиңел генә икегә ярып, чишмәгә китте. Менә ичмаса кеше! — аз сөйләшә, күп эшли...

* * *

Кичкә тагы уха пешерергә сүз куешкан идек. Одикның әйтүенчә:

— Монысы баласы гына иде, хәзер булыр анасы!

Ул балыкны да шулай, ди. Әгәр кармакка бармак буе бәләкәй нәрсә эләгә икән:

— Монысы баласы гына, хәзер анасы кабар, — ди.

Йә булмаса, бармак буйлысына әйтеп җибәрә:

— Бар, чум, атаң-анаңа әйт: синең урыныңа алар капсыннар. Әйтерсең, яме, бармак буй!

Одик мотоцикл белән җиде метрлы ау алып төшкән иде. Инеш кырыендагы Вятка куенында кич корбан балыклары (табак кадәрләре бар!) уйный икән, шуларны ятьмәгә футбол тубы урынына җыеп кына аласы ди. Дөрес, алар үзләре туп кебек очып керергә риза түгелләр икән, шуңа күрә монда туп капканы эзләми, ә капка (ау) кыр буйлап (судан) тупларны (ягъни корбан балыкларын) куарга тиеш ди. Капка-ауның як-ягында ике кеше: Одик һәм мин булачакмын. Хакның суда аяк чабыручан, ә Гафилгә килгәндә, аның ак күлмәге буялырга мөмкин...

Аңарчы бераз ял итеп алабыз. Көн озын, кояш әле күкнең сыртында диярлек үк утыра.

— Әйдә, Вяткада куна калабыз! — ди Одик кинәт кенә, ауга таяклар бәйләп ятканда.

— Мин риза, — ди Хак. — Әмма сәгать унбер-уникеләр тирәсендә авылга кайтып киләм. Хатын янына шыпырт кына...

— Хатын янына имесь, — ди Гафил, мыскыллы көләп. — Туймадыңмыни әле сул юан Мәйсәрәңнән?

— Туймадым, туячагым да юк, — ди Хак, ихлас күңелдән. — Эх, егетләр, ифрат та куркам: картайгач, хатынны тиешенчә назлый алмау — сәер бит, ә? Минемчә, ирләрнең хатыннар алдында бердәнбер көчсезлеге шул...

— Ә син, бәлки, бөтенләй картаймассың? — диде Гафил.

— Ничек?

— Картайгансы үлеп китсәң?!

Кинәт авыр тынлык урнашты.

Сүзне икенчегә бору теләге белән мин Гафилнең үзенә сорау бирәм:

— Син үзең нишләп өйләнмисең, Гафил?

— Минме?— дип, кинәт ялкынланып китте ул.

Икенче тапкыр күрүем инде: үзе турында сөйли башласа, ул бөтенләй икенче кешегә әйләнә, күзләрендә ниндидер әкәмәт очкыннар йөзә башлый, тавышы дәртле, әйтеп бетерим дигәндәй, сөйләве кызу, хәтта маңгаена энҗе бөртекләр кебек вак-вак тир бәреп чыга. Үз-үзеңне бик нык ярату тире. Сирәк чыга торгандыр ул тир кешеләрдә.

— Ну, ата эгоист бу!— дип, хәтта сокланып куям мин, шундый вакытта. Кире характерларның да иң көчлесе игътибарга лаек!

— Айе!— диде Гафил тәкәббер генә.— Айе, айе!!

— Уйлап карыйк — ни әйтер бу бась!— дип куйды аннан соң.

— Монда уйласы юк,— диде Одик сүзгә тыгылып.

— Йә, ни әйтәсең бась?— дип, Гафил маңгаена төртеп алды һәм сөйләп китте:

— Мин өйләнмәскә уйладым. Өйләнми дә ясәп була.

— Ә нигә өйләнмәскә?— дидем мин.

— Бу саф, баналь хәл. Райүсәктә сибәр яхсы киенгән бер кысь белән таныстым. Укыган, өсьтәвенә тыйнак курена. Бер сүсь белән әйткәндә — суперкысь. Феномен! Өйләнергә дип карар кылдым. Беркөн үсьләренә сакыра бу. Килдем. Мин дә — сын кавалер! Карыйм: өстәлдә яхсы вино, суперсакуськалар. Өйләре — гөлт итеп тора. Зиһась — соңгы модада. Ськафьлар, сервант, тахта... Сервись! Во! Ныклабрак карыйм: өйдә беркем юк. Вино эсьтек, эксьтрасигаретлар тарттык, ә аннан соң утны сүндереп тансевать итә башладык. Сул вакыт ботын капсаган идем, мине үзенә таба өсьтерәп урынга-тахтага ятты бу. Бер үпкән идем — сисенеп тасьлады. Калганы безнең көсьтә түгел иде, сеф. Һәрбер ир эсьләргә тиесьне мин дә баськардым. Вообсе, моны миңа кадәр күпләр... капсаган икән... Суннан соң өйләнмәськә булдым. Хатын-кысь болай да дөнья тулы! Ә өйләнеп сундые эләксә?!

Хак һаман үз уенда утыра икән:

— Го-мер үтә...— диде ул нигәдер моң һәм сагыш катыш.

Гафил аңа борылып карады һәм сүзен бүлдергәнгә ачуы килеп:

— Гомер үтә дибесь, әгәр ул усьмаса, ник гомер бер урында таптана дияр идек!— дип куйды.

— Эш андамыни!— диде Хак уйчан йөз белән. Ул нигәдер уң кулы белән күкрәгенең сул турысын тоткан, ә тавышы калтыранып, хәтта кемгәдер рәнҗегән кебек чыкты:

— Күп кешеләргә хас нәрсә: яшьлектә без тазалык-сәламәтлекне дан-шөһрәт, акча-мал өчен корбан итәргә әзер, ә картайгачтын барлык даныңны, акчаларыңны саулык хакына бирергә әзер. Кеше шул корбаннар арасында яши бугай. Бу аның беркем дә сизми, белми, күрми, үзе генә аңлый торган фаҗигасе.

* * *

Инеш кырыендагы куенны бер сөзеп алуга биш-алты яртышар килолы корбан балыгы һәм унлап чабак, бәртәс, алабуга, һәм юрша (шыртлака) эләкте. Чыннан да, бай куен икән. Килолы корбан балыгының саңагыннан күтәреп, Хак аның эре сары тәңкәләрен һич тә җирәнмичә үбеп алды:

— Менә бу корбан ичмасам. Балыкчы Кәбир моның өчен иманын сата!

— Иманын ук сатмас,— диде Одик, ялангач тәнен су белән юып.— Әмма синең кебек үбә-үбә бөтен сазын юып бетерер.

Без дәррәү көлеп җибәрәбез, Хак балыкны кадерләп кенә чирәмгә сала.

Көн шактый гына кичкә авышты, әмма шуңа карамастан, күк йөзендә чиста һәм күзне ардырмый торган сихри зәңгәрлек. Еракта ялгыз акчар-

лакның нокта булып тирбәлүе күренә. Көн үзенең мичен томалады бугай, күләгәле агач итәкләренә салкын оеша башлады, әлсерәгән эт кебек яфрак-телләрен асылындырып утырган усак һәм чикләвек агачлары ярым йокыларыннан уянып, лепердәшә башладылар, аннан соң гына салкынча төньяк-көнчыгыш җиле исеп куюга, батып барган кояшка карап баш иделәр.

Елганы икегә кисеп, моторлы көймә узды. Ак күбекле калын яллы дулкын-атлар бер-бер артлы томырылып килеп, ярларга төртелделәр һәм сискәнеп китеп, кире елгага сикерделәр. Күп тә үтмәде, Вятка өсте, бинидһая зур өстәл кебек шома һәм тигез булып, ялтырап калды.

Каршы як ярда, Бәләкин утравында, өч кеше ау белән балык сөзәләр иде. Икесе — нечкә озыннары — судан бара, ә кыяр бүчкәсе кебек юан һәм тәбәнәге капчык тотып, ярдан атлый.

«Менә кемне эчкә кертергә кирәк. Сөзсен шунда!— дип уйладым мин — бөке кебек, юк, кармак җебенә тагылган калкавыч кебек барыр иде. Тирән җирдә калкавыч чиртә дә бата-калка — тегеләре тартып ала».

Үзалдыма елмаеп куйдым: «Каян килде бу ахмак уйлар?»

— Корсак Минһаҗ тагы ярда балык җыеп кына йөри,— диде шул якка карап торучы Одик.— Мин белә-белгәннән бирле бер тапкыр суга кергәне юк, ә балыкны ике кешелек ашый. Гаҗәп адәмнәр бар: эшләмиләр, ә ашыйлар!

— Алай дисәң, дөньяда һәр ике кешенең берсе эшләмичә ашый,— диде Гафил, ауны таратып киптерергә элеп ятучы Одикка.— Моны белү өчен хәреф тану да җитә.

— Һәр нәрсәне белеп бетереп булмый. Бу — бер. Икенчедән, син әйткән әлеге «бөек яңалыкны!» минем дә ишеткәнем дә, укыганым да юк,— дидем мин, Одик ягында торуымны белдереп.

— Гәҗит укырга кирәк!— дигән булды, ауны элеп куйгач, кулын юа башлаган Одик. Аннан соң бераз торды да чыраен сытып өстәп куйды:— Әмма анда да кайбер «журналист-корреспондентлар» шыттырып язалар!

Одикның кемгә суктырганын мин дә белә идем. Элегрәк Гафил район газетасында булмаган эшләрне бар итеп һәм шулар өстенә колхоз рәисен дә бик мактап мәкалә бастырган. Соңыннан райком моның өчен әйбәт кенә «пешергән» Гафилне дә, рәисне дә...

— Гәҗит — мөһим эш!— дигән булды Хак, Наполеон сүзләре белән. Ул да Гафилгә төрттерә иде...

— Әмма Гегель аны каторга дип атаган,— диде Гафил көлемсерәп һәм усал итеп.— Тик шулай да синең алма бакчаңны шул каторга коткарды түгелме?

Алма бакчасы да миңа таныш хәл иде. Мәктәп артында Аю күле дигән үзән-кырда колхоз берничә мең төп алмагач утырткан булган. Әмма соңыннан доход бирми дип, ун-унбиш яшьлек алмагачларны бульдозер белән эттерә, казып ала башлыйлар. Әлбәттә, моңа колхозчыларның ачуы килә. Мәктәп укытучылары аптырый: «Без балаларга табигатьне сакларга, агач утыртырга, дибез, ә монда күз алдында меңнәрчә алмагачларны кыралар. Китә тавыш, шау-шу. Рәиснең үз туксаны туксан: «Доход бирмәгәч, ниемә ул?! Лутчы арыш йә бодай чәчәм мин анда. Сарык та исән, бүре дә тук». Әмма Хак, Одик һәм тагы берничә кеше эшне зурга җибәрәләр — үзәк газеталарның берсенә язалар. Күп тә үтми, килеп төшә корреспондент. Агачларны кыру туктатыла, әмма бүгенгә көнгә кадәр бу мәсьәлә чынлап чишелмәгән әле. Рәис үз сүзен сүз итәргә тели, югары оешмалар алдында күз буяп маташа.

— Бу юлда йөреп харап буласың бит!— ди Гафил.— Аңлыйсыңмы? Нәрсә ясереп торырга. Колхозь председателе элеккеге алпавыт кебек, аның кулында сикләнмәгән Власть. Сине кысасаклар, изәсәкләр. Алар күп, син бер генә...

— Хакыйкать тә бер генә!— ди Хак.

— Райком нәрсә ди?— дип сорадым мин.

— Бардым. Шул ук сүз: алма бакчасы доход бирми.

— Обком бар!— ди Одик, ышаныч белән.

— Кирәк икән, иң югары ноктага — башкалага барып җитәрмен, әмма намусыма каршы килмәм: алма бакчасы калырга тиеш, хет бакча булган өчен булса да. Доход-табышны башка җирдән алабыз без. Колхоз аңа гына калмаган.

— Барып зитәрсең дә...— дип каршы төшә тагы Гафил.— Мәскәү күзь ясьләренә ысанмый ул!

Гафилның ике ел Мәскәүдә институтта укып, соңыннан куылганын белә идем. Ул турыда сорагач:

— Әлбәттә, политика өчен кумадылар инде!— дип ачы көлеп җавап биргән иде.

Хак учакка бер-ике уч чыбык ыргытканнан соң, сүзен дәвам итте:

— Безнең иң зур хаталарның берсе — әзергә бәзер тору. Кияргә — кием, ашарга — ризык, хәтта эшләргә эш әзер булсын безгә, сүзнең дә әзерен генә чыгып сөйлибез...

— Ягъни җөплибез,— дип куйды тагы Одик, уханы болгатып.

— Менә шул нәрсә инициативаны, яңалыкка омтылышны, дөреслеккә тартылуны үтерә. Барысы өзер, нигә юкка интегергә, дибез. Бүген булмаса иртәгә булыр, дибез. Битарафлык туны киябез. Миңа гына тимәсеннәр, ник шунда дөньясын аркылыга бөгеп салмыйлар, диябез...

— Беләсеңме, Хак,— диде Гафил.— Синең кебек кеселәр — куркынысь алар. Зәмгыять өсен дә файдалы түгел... Систа суны болгатып йөрисең син. Йә, ни эсең бар синең кеселәрдә?! Ясәсеннәр сунда үзләренсә. Кесегә син дөньяда ике нәрсә генә бир: икмәк һәм эсь, эсь һәм икмәк!

* * *

Одик, үгез канына охшаган курткасын салып атты да, таулар артына бөгәрләнеп төшеп барган аш табагы кадәр кызыл йөзле кояшка карап, көрсенеп куйды һәм джунглидагы лианалар кебек чуалып беткән кармак җепләрен, аңа гына хас иплелек, пөхтәлек белән ашыкмыйча, борын астыннан бер моң көйләп, сүтә башлады.

Кошларның бүгенге соңгы сайраулары, әллә инде төн җитә дип аваз салулары, агачларның шома кәүсәләренә бәрелеп, үләннәр арасына егылып төште һәм шундук йокыга талды, чөнки иртәгә иртүк торасылары бар, сәгать өч яисә дүртенче яртыларда аткан таңны каршылыйсы — җыр сибәсе бар, шуңа кыска төннең йокысы ифрат кадерле!

Вятканың аръягында, Ямул суы тамагында, яңа гына килеп урнашкан балыкчыларның озын һәм куе төтенле учагы кабынды. Коры-сары таба алмаганнардыр, яисә чебен-черки куар өченме бу төтен?.. Ни сәбәптәндер табигатьнең бу комсыз һәм гөнаһлы җаннары бүген безнең тирәдә очмыйлар иде. Әллә без иянәнеп беттек инде, әллә алар безнең тәннеканны сынап карагач, яңа төрле ризык теләп икенче якка очып киттеләр.

Иске маякчы йорты тирәсендә ял итәргә төшкән яшьләрнең транзисторлары акыра, аңа сирәк-мирәк ялкау гына чиртелгән гитара тавышы кушыла да егетләр һәм кызларның ишелеп көлүләре ишетелә. Гүя алар өчен барысы кызык, барысы көлке. Әй, беркатлы һәм бөек оптимист яшьлек! Вакытлар узгач, шушы якларың искә төшә, гел сагындырасың, кайчак уйландырасың...

Кәримулла утравы тирәсендәрәк кемдер өздереп-өздереп вараксин гармонында уйный. Күрәсең, авылда берәрсенең шахтадан яисә ерак җирдән берәр туганы кайткан. Боларның көе-моңы үзләренчә, утырулары үзләренчә. Кызып алган абзый аракы бүләдер, ә хатыны, черки кагылмаса да, ялангач балтырларын аяк йөзенә кадәр каплап куйган чуар күлмәкле, татарча яулык япкан апа: «Гайфетдин, күбрәк була бит, исерә күрмәгез, калганын кайткач маташтырырсыз»,— ди. Йөзе комач кебек

кызарган кәкре аяклы, кунаклар хөрмәтенә бизәкле үзбәк түбәтәе киеп, хәтта галстук та бәйләп куйган Гайфетдин моңа гына бирешми: «Ә соң, әнисе, былтыр килен белән малай кайткач, болай гына җибәрдекме?— дигән соравы белән кыбырсынып утырган тулы битле, тулы гәүдәле, гомере буе эш күреп үскәнгә, кытыршы куллы, юан бармаклы хатынын үз ягына аудара. Кунак хатыны үзен ифрат культуралы, ягъни шәһәрчә тотарга тели, түшенә кадалган алтын брошканы ничә сумга, танышбелешләре аркылы тапканын, авыл хатынына бераз мактанып, ярым серле итеп сөйләп тора һәм ирләр кыстый башласа: «Фу, яратмыйм шуның исен!»— дигән булса да, йөз грамм ак аракыны эх! дә димичә, сабантуй йомыркасы кебек кызартылган ireннәрен үзенчә бик матур ачып, авызына коя. Бу вакытта кунакка кайткан «шахтур абзый» шулай ук мәлҗерәгән була, сүз саен «Теге вакытларны хәтерлисеңме? Үгез җигеп, колхозны үгезгә тагын аппарган чакларны, ә? Не забывается, брат, не забывается!» — ди һәм яшьлеген искә төшереп, чирәмгә каплана да тавыш-тынсыз, әмма гаҗәп зур сагыш белән елап ала. «Борис,— ди аңа хатыны турсаеп,— хватит тебе, Борис. Ну и что? Расплакался, хватит. На, выпей, немножечко!» Борис, ә татарча исеме Рәис булган абзый, рюмканы читкә этә һәм үзенчә, әмма моң белән җырлап та җибәрә:

Телеграмм баганасы
Олы юлга маяк ул.
Сагынасыңмы, дип сорыйсыз,
Сагынмаган кая ул?!

Колхоз агае Вараксин гармунын күрекләре аерылырдай итеп тарта да җырны дәвам итә:

Телеграмм баганасын
Саныйсым калган икән.
Күз керфекләрем талганчы
Карыйсым калган икән.

Җыр-моңга бирелгән, кинәт кенә яшьлек хатирәләренә чумган авылапа элеп ала:

Ага сулар, ага сулар,
Ага сулар ник болай?
Аккан сулар кире кайтмый,
Яшь гомерләр дә шулай.

Җырны хәзер Вятка суларына карап, шәһәр-апа гына тыңлый. Ә сулар чыннан да ага да ага. Аны кире борыр, кире кайтарыр бер көч тә юк. Гомер сулары бу, вакыт бу! Карасаң, яшь гомерләр әллә кайчан узып киткән икән. Менә шушы суда коенып үстеләр ич алар! Шушы Кәримулла утравына бөрлегәнгә килә иделәр. Бармак башы кадәр зәңгәрсукызгылт бөрлегәннәр хәзер дә исендә әле. Кинәт ул үзен бер минутка онытa да әз генә чәрелдек һәм нечкә тавыш белән җырлап җибәрә:

Бакчадагы чәчәкләрнең
Өзәм тик берен генә.
Яшь гомерләр ике килми,
Белик кадерен генә...

Бу җырдан соң дүрт йөрәк, дүрт баш, дүрт авыз, сигез күз, сигез кул һәм сигез аяк бер җан булып утыралар. Төнгә чаклы... Күп еллар узгач та алар бу утрауны онытмаячаклар. Бүген — иртәгә юк ул...

Нигәдер минем хәтеремә Панки авылындагы җизни килде. Озынча борынлы, ябык озын гәүдәле, азрак кычкырыбрак сөйләшә торган ачык күңелле бу кеше белән гармун тартып, җыр җырлап утырасы иде. Болай

гына... Күңелдәге авыр юшкыннарны юып җибәрү өчен генә... Хәтта аның өчен дә түгел... Янында җыр-гармун яратучы әйбәт кеше булган өчен генә... Алайса калдым берүзем... Хак хатыны янына кайтып китте, Гафил җиңелчә киенгән икән, суык тидерүем бар, дип, җылы киемгә авылга юнәлде, ә Одик иң беренче булып мотоциклына утырып чапты — Әдилә янына, исеменнән дә чәчәк исе, һушыңны яздыра торган чәчәк исе килә торган Әдилә янына. Дөрес, Хак кузгалганда Гафилгә: «Минем төшкәнне көт, кайтам дисәң, аннан соң кайтырсың»,— дигән иде. Гафил-егет төнге чык төшүгә дерелдәп үк башлады — үзем җибәрдем.

Караңгылыкны фонарь яктысы ертты — Одик гөрелдәп, мотоциклы белән килеп туктады.

— Кайда егетләр?— диде ул килә-килешкә.

— Хак — Мәйсәрә апа янында, Гафил — туңды...

— Хәй! Соң берәмтеклэп китәргә иде инде, кешене ялгыз калдырганнар! Хак абый — ярый инде, ә Гафил катып үлмәс иде бит, хәй!

— Зыян юк... Миңа үз уйларыма чумып утырырга әйбәтрәк тә әле ул.

— Әйдә, башта җылынып алабыз!

Одик куеныннан «Российская» чыгарып яртышар кружка итеп бүлде. Эчеп җибәрдек һәм ул алып төшкән йодрык кадәрле кып-кызыл помидорлар белән «зәм-зәм»не урынында ятсын дип бастырып куйдык». Эчкә җылы кереп китте. Одик кырык яшьлек интеллигент башы кебек сирәкләнгән (XX гасыр — пеләшләр чоры әле ул!) таллыктан бер кочак коры чыбыкны сүнәр-сүнмәс пыскып яткан учак өстенә салуга, уч төбе зурлыгында гына калган ялкын, чая ач бүредәй, корбанына сикерде һәм сөякләрен шатыр-шотыр китереп, бик тәмләп чәйни-ашый башлады. Төннең куе кара шәленә кинәт ут кабынды — бер читтән карап торучыга, бу якты төн кызының чәчләренә кунган алтын күбәләк яисә җанлы зөбәрҗәт кебек күренер иде.

Учак җылысы төнге салкынны бөтенләй куып җибәрә алмады, суык, сырышкан көчек баласы кебек, резина итек эчендә зәңгәрләнә башлаган аякларга урала һәм чәнечке үләнедәй кулга, тәннең ачык җирләренә чәнчеп-чәнчеп кадала. Ләкин... ни хикмәттер! Вятка буенда балык сөзсәм дә, ничә сәгатьләр буе салкын чирәмдә йөрүемә карамастан, ревматизм җәфалаган уң аяк ыңгырашып та карамый. Гүя аңа берни булмаган. Әллә Вятка суының берәр шифасы бар инде? Кулларымны угалап, учакка елыша төштем һәм шырпы кабы кадәрле турыпочмаклы утлы күмер алып тәмәке кабызгач, тәмләп бер суырдым да кибәргә куелган ыштырларны таяктан алып, аякка чолгадым.

— Мин төнгә салган кармакларны карап киләм әле...— диде Одик.

Ул әле генә су коенып килде һәм плавкидан гына калган килеш кибенә иде. Саргылт төкләр белән капланган филнекедәй калын бот-аяклары һәм баз капкачыдай киң күкрәге учак ялкынында алтын төскә кереп җемелди һәм... (миңа шулай тоелды) селкенеп торалар иде. Ул да суыктан аз гына дерелди икән...

— Бергә барыйкмы?— дидем мин иренеп кенә, ә үземнең учак җылысыннан суык төн кочагына керәсем килми иде.

— Юк, кирәкми, хәзер әйләнеп киләм...

Ул китүгә, тагы ялгызым гына калдым. Учактагы чыбыклар арысланнан калган куян скелеты кебек кенә, әмма ялкын көчле әле, аның җылысы оятын югалткан фәхишә кебек назлап-назланып кына минем бөрешеп-корышып утырган тәнгә елыша. Күз кабакларына өч гөрәнкәле гер асканнармыни — шап итеп ябылалар, һич кенә күтәреп булмый. Күз кабаклары — дөньяның гүзәллеген һәм ямьсезлеген ачып һәм каплап торучы пәрдәләр. Ул пәрдәләргә йокы асылынган, алар ябылырга гына тора. Нигәдер үземне тагы гигант динозавр өстеннән барган кебек хис итәм... Җиңел һәм йомшак адымнар белән. Ә күз кабаклары ябылалар... ябы-ла-лар... ябы... ла... ла....

Кинәт кенә минем каршыма караңгылыктан кемдер килеп чыкты. Карыйм: таныйм да кебек үзен, танымыйм да. Чү, кем әле бу?..

Авыр күз кабакларымны көч-хәл белән күтәреп, әлеге адәмне ныклап танырга тырышам: куллары тезләренә җиткән, авыр йөк күтәреп йөргәнгәме яисә яшәгән еллар саны гәүдәсен ватканга мы, яртылаш бөкрәйгән, шәрә тәнен саргылт-күксел төк баскан, маңгае тар һәм сөзәк, шуның өстенә җыерчыклы, күзләре кызгылт һәм кечкенә, әмма аларның төбендә акыл уты елтырый, өске ирене «Беломорканал» пачкасы кадәр, ияге туры түгел, киресенчә муенына таба кырык-кырык биш градус чамасында авыш, буе — шактый кечкенә, өстәвенә үзе шактый йонлач...

Таныш миңа бу кеше, бик таныш. Кайда күргәнем бар соң әле мондый әкәмәтне? Кайсыдыр журналдамы, әллә китаптамы шунда, аның рәсеме дә бар бит. Бар шул!

— Нишләп утырасың?— диде ул, минем яныма әлпән-тилпән килеп.

— Туңдым, җылынам...

— Куыш ясарга кирәк иде!

— Нигә? Без бер төнгә генә...

— Без барыбыз да бер төнгә генә!

Шул арада аңа охшаган тагы бер шыксызы килеп чыкты:

— Утны сүндерә күрмә!— диде ул шактый усал кычкырып.

— Юк, нишләп сүндерим ди, чыбык өстәп торам...

Аларга тагы да шыксызрагы-килбәтсезе өстәлде:

— Әйдә балык тотабыз! Иптәше балык тота, ә бу, җебегән, тик утыра. Үзе бит балык ашын я-ра-та! Ха! Ха-ха! Ха-ха-ха! Оста син! Ашарга барыбыз да оста безнең. Эшләргә кирәк, эшләргә!— дип фәлсәфә корды ул.

Мин урынымнан кузгалмак булам, ләкин нигәдер тора алмыйм, гүя тәнемне җиргә сумала белән ябыштырып куйганнар.

Шулвакыт дүртенчесе, араларында иң матуры, каяндыр килеп чыкты да минем янга килеп, маңгаема чиртә башлады. Үзе чиртә, үзе сөйли:

— Утырып торма! Тик ятма! Алайса үләрсең... ү-ләр-сең... ү... ләр... сең... Кемнәрдер сиңа пычак кайрый...

Мин бөтен җегәремне җыеп, урынымнан тора башлыйм һәм... кинәт кенә күзләремне ачып җибәрәм.

Шабыр тиргә төшкән маңгаемны Хак тоткан да:

— Син авырмыйсыңдыр ич? Салкын тидеме әллә?— дип сорый. Мин йоклап утырганда, ул безнең янга төшеп тә җиткән.

— Юк!— дим тиз-тиз генә.— Юк, авырмыйм. Менә утыра торгач, оеп киткәнмен.

— Ярый алайса,— ди Хак.— Одик йокласын, уятма дигән иде.

— Мин тагы берәр кочак чыбык алып киләм әле,— дип, Одик тыгыз стенадай торган куе караңгылыкка кереп югалды.

Мин һаман да төшемдәге төнге очрашудан айный алмый утырам. Хак калган шулпаны җылытырга элде дә бөркәнеп ятты.

Утыра торгач, уйлар шигырь юлларына күчте. Гадәттә, ялгыз калганда, шулай көндәлдән шигырь язу белән мәшгуль булучан мин. Бу бигрәк тә трамвайда, поездда барганда, пароход-теплоходта йөзгәндә яисә самолетта очканда. Күбрәк, әлбәттә, табигать кочагында йөргәндә: урман-кырларда, елга-инеш-күл буйларында җәяү йөргәндә...

Одик учакны тергезгәч, артыны калган шулпа белән җылынып өчен каплап куйдык та, уңайлап кына учак кырыена сузылып яттык. Одик нидер көй сызгырып кармак таягы юна, Хак үз уйларына чумган, ә мин көндәлдән язам:

...Вятка өсте, купец амбары күк,
Кара ишек белән бикләнгән.
Утын өстим учагыма. Ялкын
Чыбыкларны ашый бик тәмләп.
Учак... һич китәсе килми аннан,
Ялгыз башта уйлар тилерә.

Шулвакытны килде бабаларым
Минем янга хәлне белергә.
«Утың сүнмәсен!...—ди алар миңа —
Куыш яса, әйдә, бик тунсаң.
Сез — егерменче гасыр имгәкләре,
Өшеп үләрсез дә... чик куйсаң!»
Йонлач бабай никтер гел кисәтә,
Маңгаема минем чиртә дә:
— Йөз мең еллар элек без яшәдек,
Сез яшәсен өчен иртәгә!..

* * *

Адәм баласын яраткан нәрсәсенә ияләштер генә, ул аңа сагыз кебек чат ябыша. Балык тоту белән дә шулай булды. Без дә Вяткага күлмәккә тегелгән сәдәпләр кебек ябышып калдык. Авылга азык-төлеккә һәм йокларга гына кайтабыз.

Шул ук Вяткада Одикның туган көнен уздырдык. Әдилә дә килергә тиеш иде, әмма аны райкомга җыелышка чакырганнар. Бүген генә белдем: Әдилә күрше кечкенә генә колхозның председателе булып эшли икән! Менә сиңа мә! Болай булгач аннан чәчәк исе түгел, арыш-бодай, клевер-люцерна исе килергә тиештер... Шәп ис, яшәү исе... эшләү исе...

Иң матур тостны Хак әйтте:

— Һәркемнең иң зур шәхси бәйрәме бар, ул — туган көн. Кешенең нинди зур җиңүе ул туу дигән нәрсә! Уйланып караганыгыз бармы, без бит җиргә миллионнарга бер конкурс белән киләбез. Чыннан да, зур җиңү, зур бәхет бу. Шулай булгач, бернинди шатлыгы калмаган чагында да кеше үзенең туганына сөенергә тиеш. Менә без дә бүген синең туганыңа сөенәбез, Одик. Туган көнең мөбарәк булсын!

Нигәдер, соңгы көннәрдә Хак миңа ошый башлады әле. Мин аның йөзенә текәлдем... Андый кешеләрнең йөзе матурлыкка дәгъва кылмый, ләкин аларны ямьсез дип тә булмый. (Гомумән, кеше кадәр кешене ямьсез дип әйтү үзе ямьсезлек яки мәнсезлек ул, халык бервакытта да «аның ире яисә хатыны ямьсез икән дими, матур түгел ди — матур түгел!) Әмма андый кешеләр белән дөнья тулган, статистларга хас саннар телендә әйтсәк: йөз кешенең, әлбәттә, туксаны, ягъни ун кешенең тугызы матур түгелләр, икенче сүз белән әйткәндә ярыйсы (русча — ничево!) билгесе куя торган адәм балалары.

Әгәр портретын ясау максаты белән Хакның йөзенә күз төшерсәк... Өч рәт буразна салынган җыерчыклы маңгай, артка таба сыпырсаң, күңелне «шытырдата» торган кытыршы кара чәчләре, кашлары куе һәм калын (мондый кешеләрне «чабата каш» диләр), борыны кыска һәм аз гына кәкрерәк, сул яфрагында әллә пычак, әллә пыяла кискәннән калган ак җөй беленеп тора, күзләре кечкенә, әмма ташны да тишәрлек итеп карыйлар, аларда акыл нуры уйный сыман, ияк чокыры мөлаемлык чишмәсе кебек һәркемне үзенә тартып тора, аз гына турсайган калын иреннәрендә яшәүгә омтылыш, тормыш ләззәтен белү чагыла...

Бүген иртә белән без аның белән кычкырыштык.

— Мин ял итәргә кайттым,— дидем мин аңа,— беләсеңме, ял итәргә!

— Ял? Гел ял буламыни?! Ял эш арасында ул. Сау-сәламәт, исән кеше мәңгелек ял турында уйламыйдыр!

— Вяткага мин ялга килдем,— дидем үзсүзләнеп.

— Вятка ял итү урыны түгел, яшәү урыны ул. Ә яшәү урынын һәркем көрәшеп яуларга тиеш!

— Күпертмәсәнә! — дидем мин, ачуым килә башлап, нигәдер ул миңа юри шулай «матурлап» сөйли кебек тоелды.

— Алайса, эшләп яуларга тиеш! Эш — шул көрәш инде ул,— диде Хак та үзсүзләнеп.

Бу кычкырышуның башы болай иде.

— Тыңла әле,— дигән иде бервакыт миңа Хак.— Син миңа алма бакчасы эшендә булыша аласың. Төгәлрәк әйткәндә, язу эшендә. Бу мәсьәләне төбеннән куптарып өлкә оешмасына язмакчы идем, орфография ягы шәп булса да, урынына җиткереп язу ягыннан үземдә йомшаклык сизәм. Ярдәм итмәссеңме?

— Көчемнән килгәнчә...— дидем мин.

Ул вакыт Хак шатланган иде:

— Рәхмәт! Ышандырдың... Җирдә нык басып тору өчен кешегә ике аягы гына җитми әле, таянырга кешеләр кирәк: көчле дуслар, акыллы иптәшләр, ярдәмчел туганнар...

Иртә белән шул хатны языйк әле, дип, минем янга керде. Әмма яза башлауга, үземнең бу урында көчсез икәнлегемне аңладым. Хатта колхоз председателен тәнкыйтьләп язган сүзләр күп, ә мин ул кешене белми торып (хәтта кыяфәтен дә күргәнем юк!) ничек аның турында... Аннан соң кунак кеше бит мин дип уйладым. Халык: «Кунак булсаң, тыйнак бул!»— ди. Гомумән, «икеләнеп» калдым... Ә кеше икеләнсә, өчкә әйләнә: аккошка, чуртанга, кыслага...

* * *

Хак, кайда хакыйкать? Синдә аның беренче өсь хәрефе генә...— дигән сүзләргә уйларымны туктатып, башым күтәрсәм, Гафил белән алар тагы бәхәскә кергәннәр икән.

— Сүз белән эшнең тәңгәл килүе!— диде Хак.

— Менә-менә! Уйлап карыйк, ни әйтер бу бәсь!— Гафил тар уч төбе белән үз маңгаена сугып алды да бер мәлгә сүзсез торды.

— Айе!— дип куйды аннан тәкәббер генә, аның соргылт-кара күзләрендә ниндидер мыскыллы һәм кыю ут кабынды, бу утны күзлек пыялалары астында гына яшереп булмый иде.

— Сүсь-эсьнең тәңгәл килүе, ягъни, икенсе төрле итеп әйткәндә, грамот-лы итеп әйткәндә... (ул бу сүзләргә зур басым ясады һәм, бик акыллы фикер әйтәсен сиздерепме, тагы беравык туктап безне көттереп торды) сүсь белән эсьнең дөресьлегенә иресү өсен кесегә сын ирек... сын мәгънәсендә ирек кирәк, сөнки кеселәр бер-берсенә бәйле булганда, бу турыда борынгы философ Сократ та әйткән: «Икенсе кесегә бәйле кесене ирекле дип булмый», дигән...

— Сократ: «Икенче бер халыкны изеп торучы милләтне ирекле дип булмый дигән...»— мин аның сүзләренә тиз генә төзәтмә ясадым.

Гафил мине бөтенләй ишетмәгәндәй дәвам итте:

— Сүсь белән эсьнең дөресьлегенә абсолют иресеп булмый.

Шушы сүзләрдән соң укучыларына караган укытучы шикелле барыбызны өстен һәм горур караш белән сөзеп чыкты: «Аңладыгызмы инде, тинтәкләр?» янәсе... Күпмедер вакытка тынып калдык. Шунда күрдем: Гафилнең чыраена үз-үзен ярату галәмәтләре чыккан. Ул хәзер фикерен дәвам итү өчен, шаккатырырдай, саллы сүзләр эзли иде. Ул шактый көттергәч, дәвам итте:

— Сулай булгась, кесе иң беренсе сын ирекка иресьсен, ә моның өсен, дөньяда бер генә кесегә дә бәйле булырга тиес түгел!

Менә кая бора үгез тәртәне— җылы абзарга, яшел печәнгә! Кайдан анда бу фикерләр? Чынлап әйтәме ул, әллә юри генә безне шаккатыризм белән утыртырга телиме?

— Чын ирек— максатыңа, инанган эшеңә хезмәт итү ул!— дидем мин, үз-үземә ышанып. Бу фикер миндә егерме яшьлек егет чакта ук сеңеп калган иде инде, бүгенге көнгә кадәр аның үзгәргәне юк.

— Марксь!— диде Гафил.

— Ленин: «Җәмгыятьтә яшәп, аннан ирекле булып булмый»,— дигән.

— Аннан соң...—дип өстәде моңарчы бер сүз дә эндәшмәгән Хак.— Дөньяда яшәгән һәркемнең патриотлык дигән хисе бар. Кешеләрнең күмәкләшүен, бер уйга килүен, бер эш өчен януын, син әйткәнчә, берберсенә бәйлелекләрен шушы бер сүз — патриотлык төшенчәсе белән дә аңлатырга мөмкин. Ансыз ил-җир юк, ил-җирсез җүн юк!

— Чын патриот үз иленә каршы килмәүче түгел, ә үз Ватанын кире кайтару өчен барлык көчен куючы кеше! — диде Гафил, кирәкле сүзләрне табуына сөенеп һәм безгә җиңүле карап.

Кайда ишеттем, юк, укыдым соң әле мин мондыйрак сүзләрне. Әйе, әйе... Борынгы Греция... Безнең эрага кадәр бишенче гасыр. Тарихчы Фукидид язып калдырган. Полководец Алкивиад шундыйрак сүзләр әйткән бугай... Әмма Алкивиад илен, Афинаны саткан кеше. Үз иленә каршы поход белән килгән һәм бер генә тапкыр түгел... Менә кая кергән сезнең уйлар. Еракка качып котылмакчымы? Фикерләрне ерак тарихтан — бик тирән коедан алмакчы? Безгә ярыймы соң ул кое?

— Үзең белмәгән коедан суны эчкәнче, аның чисталыгын тикшерергә кирәк...— дидем мин аңа карап һәм «коедан» сүзенә аерым басым ясап. Аннан соң өстәп куйдым:

— Пычрак су эчүдән ашказаны бозыла...

Аңлады Гафил кое белән кая төрттергәнне:

— Тарих — бүген әйтергә ярамаганнарны үткәннәрдән сөйләтү ул,— диде.

— Әмма тарих — Наполеон, Һитлер табуты да ул...— Моны Хак әйтте.

— Ә икенче Һитлерны Җир шары күтәрә алмаячак! — диде Одик кинәт кенә һәм пәкесен кискен генә лезвиягә чумарлык итеп былтыргы корган яфраклар яткан җиргә кадады.

— ...Пычрак су ашказанын бозып кына калмый, үлемгә алып бара...— дидем мин, әүвәлге фикеремне дәвам итеп.

— Бесьнең ясәү сул көн саен үлемгә бару инде ул...— диде Гафил ярсу гына, аңа үзен тыныч тоту авыр иде, күрәсең.

— Ник туганга үкенгән кеше сүзе бу. Ә андый кеше мәрхүмнән йөз мәртәбә көчсез!

Минем сүзгә Хак тагы өстәмә кертте:

— Тере мәет! Яшәү белән җан асраучылар арасында аерма күп шул.

Шунда ул сүзне икенчегә борып, ифрат зур сагыш белән әйтеп куйды:

— Ә шулай да, егетләр, мин быел үлемнән курка башладым әле...

Өчебез дә аңа борылып карадык, Хак уң кулы белән йөрәген тоткан, йөзе кәгазь бите кебек ап-ак, маңгаена тир бәреп чыккан.

Гафил сүзнең икенче якка кереп китүенәме, әллә бәхәс тагы аның җиңелүе белән тәмамлангангамы, корт чаккандай сикереп торды һәм чәбәләнеп, нечкә тавыш белән кычкырып ук җибәрде:

— Әй, сез тинтәкләр белән утырганчы, бер ялгызым...

Һәм ул читкә борылып ятты.

— Характерны да шәрәтән күрсәтергә ярамый! — диде Хак, Гафилга ачуы килеп.— Бигрәк тә ят кеше, яки кунак булганда... Холкыңа да күлмәк кидерергә кирәк!

Чистартылган нәни балыкларны Одик бер урынга җыйды һәм чишмәгә суга барырга җыенгач, нигәдер безгә карамый гына, үз алдына сөйләнгәндәй, әйтеп куйды:

— Белем белән... у-кыган-лык белән щеголять итү яхшы нәрсәдер бәлки. Ни әйтсәң дә, миро-воз-зрение! Әмма кеше фикерен сөйләп, нигә философ булып кыланырга. Философлар түгел сез, ә сөйләсофлар! Хәзер, уйлый торган түгел, эшли торган замана. Безнең өчен башкалар уйлыйлар яисә уйлаганнар инде...— Аннан соң миңа карап: — Катырак кагылсам, гафу итегез! — диде.

Утыртты! Кем уйлаган? Ай, Одик! Ай, егет!! Ай, философ-сөйләсоф!..

Беренче тапкыр озын һәм озак итеп җөмлә әйтте — югыйсә, сөйләшмичә эшли генә иде, сүзеннән эше күп иде. Кем ди бит — сөйләсофлар! Уйлап-уйлап та башка килми торган сүз. Ә шулай да, шалишь, брат. Уйлый торган түгел, эшли торган замана, дисең. Уйлый торган түгел, дисең. Уйлый торган! Уйлана торган замана. Алдама — син дә уйлыйсың! Уйлаганыңны сөйләмисең генә...

Кем дип атады бит безне — сөйләсофлар. Шәп сүз!

Шул көннән соң артык сүз куерта башласак, бер-беребезне бер сүз белән генә тыя башладык:

— Йә, йә, сөйләсоф булма әле!

* * *

Гафил табигать тарафыннан нәзберек күбәләкнең нәфис һәм кулга тотсаң уалып китә торган канаты кебек ясалган иде: акбур төсендәге кояш күрмәгән аксыл йөзендә зәңгәрсу кан тамырлары беленер-беленмәс кенә сузылганнар, гүя рәссам каләмен зәңгәргә манып, берничә тамга сызган, аз гына бөтеркәрәк кара чәчләрен ишле рәвештә кавык сарган, алар аның күлмәк якасына да шактый коелганнар, озын нечкә борынының сул як тишегеннән ике бөртек кара төк төртеп чыккан, үзсүзлеген күрсәтеп торган нечкә һәм кызгылт корган иреннәренә ирония кысылган, зур матур кара күзләре кешене өнәмичәрәк карый, вакыт-вакыт аларда мыскыл — алдында басып торучы кешедән үзенең өстенлеген сиздерүче хыянәтчел яшерен сары ут ялтырап китә; бугаз тирәре шактый алга чыгып торган нечкә муены биек маңгайлы кечкенә башын шактый туры һәм тәкәббер тота, озынча матур ияге һәрвакыт бетмәс-төкәнмәс горурлык белән югары чөелгән була. Атлавын да ул җиңел, әмма чайкалыбрак, җилдәге мамык сыман җилфердәп атлый. Җилфердәп диюем шуннан: кигән костюмы ике үлчәмгә зур булып, халык әйтмешли, «казыкка элгән капчык кебек» тора, күзәтүем буенча, Гафил үзенең нечкәлегеннән оялып, зуррак үлчәмгә костюм астыннан җәй көне дә ике кат күлмәк яисә свитер кия, әмма бу гына аның арыклыгын яшерә алмый иде: уч төбе кадәрле калак сөякләре шыксыз булып тырпаеп торалар. Ни генә димә, Гафил авылда эшләп, арыш ипиен тозга манып ашап үскән егет түгел шул! Әтисе Урал шахталарында күмер чапканда, бу Губаха урамнарында трай типкән. Ун классны тәмамлагач, киномеханиклыкка укыган, аннан соң институт... Анысы да ярты-йорты гына...

Каян йоккандыр ул аңа андый чир — физик эшкә карата нәфрәт һәм йөз чөереп карау. Шуның белән ул, күрәсең, яшәүдәге иң зур бәхетләрнең берсеннән мәхрүм булган. «Мәхрүм — мәрхүм була»,— ди торган иде минем бабай.

Ул китапка чумган. Әмма Мансур абый сүзләренә караганда, «коры китап кына уку — сукыр бер тиенгә дә тормый...» Печән чабуның асылын укып түгел, эшләп беләләр. Йорт салуның да шулай... Утын яруның да...

Балыкларны юып салгач, Одик мотоциклына атланып, авылга Әдиләне алырга элдертте. Узган көнне ул да берәр сәгатькә безнең белән утырырга ризалык биргән булган. Одикның әйтүенә караганда, Әдилә балык ярата икән.

Күрәбез болай булгач Әдиләне — исеменнән дә чәчәк исе килә торган кызны! Тәненнән — арыш-бодай, люцерна-клевер исе килә торган рәисне, колхоз башлыгын!

Одикның уена башта Гафил генә каршы төште:

— Таптың сүсь. Ирләр зәмәгатен хатын-кыз белән пычратырга димени! Ул кыска аяклар сулкадәр хәйләкәр: егетләре алдында матур күренер өчен үксә-платформа кияләр.

— Теләге бар икән, төшсен,— диде Хак бәрәңге әрчегән җиреннән кузгалып килеп.

— Һәркем үсенең теләкләренә кирәкле урын табарга тиесь! — диде Гафил. — Менә минем теләк: мин карсы! Хатын-кысьсысь утырыйк.

Шактыйдан бирле бер-берсенә үпкәләшкән ир белән хатын кебек сүзсез утырабыз, шуңа мин аның белән сөйләшү өчен:

— Йә, иптәш сөйләсоф, фикерегез ачыклана башлады, дәвам итегез, — дидем.

— Асылырсың сезнең янда, асылмас борын ябарлар! — диде Гафил һәм кинәт кенә сүзеннән туктап, стенадагы кадакка бәрелеп шартлаган уенчык шар кебек шиңеп калды. Нинди дер гаебе булган кеше кебек...

— Ачылуы ябылуга охшый! — диде Хак көлемсерәп.

Гафил ни өчендер ярсып китте:

— Минем бабай — Фаясь мулла, заманында өсь ат тоткан, тегермәне булган, әмма хезмәтсе тотмаган. Дөбер-сатыр эсьләгән, мәхәлләсен дә алып барган. Сабантуйларында батыр калган. Ә мин кем? Адәм имгәгемени? Мин кемнән ким, ә?! Минем дә горурлыгым бар. Ул горурлык өсьнекеннән дә көсьле! Минем кемсек (кемчек) түгел, ә кемдер! буласьсым килә...

— Чү-чү! — диде Хак. — Әллә кемгә охшый башладың әле син.

— Мин кемгәдер охсыйм икән — минем кебек кесьеләр бар дигән сүсь, әгәр мин кемгәдер осыйм икән — димәк ки, бесьнең кебекләр дөньяда күп!

Хак ухага бер кашык тоз салды һәм калагын сумкага салып сөйләп китте:

— Теләк дигәннән... Кешеләрдәге һәр нәрсә теләк туганга барлыкка килә... хәтта кешеләр үзләре дә... әмма — теләк туу — сүз, ә барлыкка килү — эш...

Хак, нинди дер тирән сагыш кичергән кеше кебек моңланып, сүзсез калды. Аннан соң тагы дәвам итте:

— Теләк дигәннән... Эх, егетләр, ифрат зур бер теләгем бар минем...

Нәрсә әйтер диеп без аңа карап каттык. Гафил (каян килгән гадәттер) иренеп кенә үлән сабагы чәйни иде. Әллә витамин җитми инде аңа? Менә аның селәгәе-төкерегә белән нечкә иренле авыз кырыена яшел масса җыела башлады, шуннан соң ул лыч итеп җиргә төкерде.

— Зур теләгем бар минем, егетләр. Өч кыз миндә, ә малай юк. Малай тусын иде, малай. Аның белән менә сезнең белән утырган кебек Вятка буенда балык каптырыр идек, сөйләшеп йөрер идек. Кызларымны барысын да яратам мин... Тик шулай да ир кешегә малай кирәк!

— Мәсьәлә Мәйсәрә апада тора, — диде Гафил, нигәдер оятсыз көлеп. — Ул рисьа булса?..

— Үземдә мәсьәлә, үземдә... — диде Хак акрын гына.

Мотоцикл тавышына борылып карасак, ифрат зур тизлектә килгән Одик күренде.

— Бер-бер хәл булганмы әллә? — диде Хак, кинәт борчылып.

— Әдилә дә күренми... — дидем мин.

Одик моторын сүндереп тә тормастан, әллә ничек сәер генә итеп «Иж-спорт» мотоциклы өстеннән сикереп төште дә (әллә егылды шунда) йөгереп килеп, чирәмдә үлән сабагы чәйнәп яткан Гафилны көчек баласы урынына күтәреп алды:

— Бәреп үтерәм, кабәхәт!

— Үтер! — диде тегесе аптырамый гына һәм аның күзләренә битараф карап.

Одик үләксә күргән кебек җирәнү һәм тирән нәфрәт белән аңа карады, кинәт кенә җыерчыклар барлыкка килгән маңгаена төшкән юеш чәчләрен сулышы белән өф! итеп өреп, янга җибәрде, аннан соң ачы алма капкан кеше кебек йөзен чытты, корбанын, буялырга чиркангандай, кинәт кенә этеп җибәрде. Гафил һаман да битараф һәм салкын йөз белән бер адым артка чигенде һәм чирәмдә калкып торган ташка абынып, җиргә егылды.

Торып өстен-башын каккалагач, берни булмаган кыяфәт белән шым гына минем янга килеп утырды.

— У-у-у! — дип улап җибәрде Одик өзгәләнеп, гүя аның тәненә генә түгел, җанына учлап-учлап тоз салалар иде. Ул беравык яшькә томаланган рәнҗүле күзләре белән безгә карап торды һәм, бу халәтенә оялган төсле, кинәт кенә читкә борылды. Аның үгез каны төсендәге курткасы аркылы беленеп торган рельефлы иңбашлары, амбардагы ашлык суыргыч кебек, калтырый башладылар. Менә ул безгә таба борылды һәм безнең эчебезне, тышыбызны берьюлы күрергә теләгәндәй, яшь тулган зәңгәр күзләрен зур итеп ачып (хәтта күз агының зәңгәрсу тамырлары да күренде) Гафилгә, өзелгән ботак ялгана дигән өмет белән, эндәште:

— Дөресме??

— Дөрес...— диде тегесе, тагы да битарафрак итеп.

Одик җиргә ауды һәм башы белән кадалып тора башлады.— Дөресме? — дип кабатлап сорады ул.— Бәлки... Беләсеңме, минем өчен бу — үлем белән бер...

— Дөрес...— дип, өметне кисте әлеге битараф тавыш.

Одик тавыш-тынсыз гына коймакка ошаган чуерташка башын тык-тык! итеп бәрә-бәрә елады.

— Тык-тык! — Гүя тамчы тама...

— Тык-тык-тык! — Гүя яңгыр ява...

Хак сүзсез иде. Мин дә эндәшмәдем. Күңелнең кайсыдыр сизгер һәм тиз әләктереп ала торган өлгер кылы сүзнең Әдилә турында барганын белә иде... Одик йокыдан уянган лунатик кебек авыр гына урыныннан торды һәм ышанычсыз адымнар белән агачлар арасына кереп югалды.

Хак әйберләрне җыештырды, бездә уха кайгысы юк иде инде, чиләкне шулпасы ние белән кире Вяткага түктек. Ашагыз, балыклар, үзегезнең чиләктә кайнаган туганнарыгыз, иптәш-дусларыгызның башын, йөрәген... җанын, бәгырен ашагыз... Кешеләр дә кайчак шулай бер-берсен ашыйлар. Чиләктә пешереп түгел, сату, алдау казанында пешереп, бер-берсенең җаннарын ашыйлар.

Одикка нәрсә әйтергә? Юатыргамы? Юк, юк, ул аңа мохтаҗ түгел. Кирәкмәс вакытта юату — кайгыны тирәнәйтү генә ул.

Хак Одик артыннан агачлар арасына кереп китте, миңа Гафилны алып китәргә ымлады.

Кайтырга чыккач, түзмәдем сорап куйдым:

— Нәрсә булды сезнең арада?

— Әдилә...

— Әдилә икәнен үзем дә аңлыйм!

— Кыз түгел ул...

— Ә!..

— Бесь аның белән Одик күрмәгәндә ирле-хатынлы уйнадык.

— Ну! Ышанып бетмим...

Чыннан да мин аңа ышанмадым. Күңел: «Ышанма!» — диде.

— Мин вәгасьсе түгел... Ысанмасаң көсләмим. Одикка кадәр ул минем кысьым иде. Мин институтта укыган сакта...

— Ни намусың белән! Мин бит Одик белән сине дуслар дип йөри идем.

— Дуслар? Бесь икебесь тә бер класста укыдык, икебеськә дә егерме тугысар ясь. Менә бесьнең дусьлык! Ә мәхәббәттә дусьлык катнашмый...

Шулвакыт ул иелеп җирдән таш алды һәм өненнән чыгып, безне карап торган йомранга атып җибәрде. Йомран шундук, суга чумган күк, юкка чыкты. Моннан кызык тапкан Гафил шаркылдап көлде, аннан соң кулындагы таштан калган тузанны сөртеп сүзен дәвам итте:

— Беләсеңме, сеф! Бүген генә сөйләсьтек. Дөньяда теләк дигән бөек көсь бар. Теләк туды — үсеңне тотам димә, чөнки ул турыда уйлый басьлыйсың, ә уйга кергән нәрсә пысьрак түгел.

Минем күптәннән аның кеше кайгысына, күз яшенә булган битарафлыгы, дус дип йөргән (дуслыкны белмәсә дә) кешесен сатып та, юктан,

таштан куркып качкан йомранны күреп, шаркылдап көлүе йөрәгемә ачу давылы кузгаткан иде...

— Шушы сүзләрең өчен генә дә мин синең авызыңа сугып, утыз ике тешеңне кояр идем! — диде мин, ачуымнан шартларга җитеп.

Гафил кинәт туктап калды һәм битараф кына:

— Сук соң, сук! — диде.

— Җәллим...

— Минеме?

— Юк...

— Ә кемне?!

— Өстеңдәге костюмыңны... үзең әйттең бит: 170 сум тора дип. Пычратырмын... Ә синең бәяң — 170 тиенгә дә тормый...

— Һәркемнең үсь бәясе!

Мин кинәт кенә борылып, икенче сукмакка кереп киттем, Гафил инеш ярындагы язгы ташу вакытында чүпләр эленеп калган куе талларга күмелеп калды.

Күз алдыма Вятка ярындагы коймакка охшаган уч төбе зурлыгындагы чуерташка маңгаен бәреп елаган Одик килде.

Тык-тык... — гүя тамчы тама.

Тык-тык-тык... — гүя яңгыр ява.

Тык-тык-тык-тык... — Одикның мәхәббәттә алданган, хыянәт угы кадалган ат башы кадәр яралы йөрәгеннән кан тама...

Әй, бу кеше дигәннең Җаны! Шушындый пошмас, бер караганда, күп нәрсәгә битараф егеттә һәр сүзнең әйтелешен тоемлый, һәрбер эшнең иң кечкенә төсмерләрен күрә һәм кешедәге аз гына үзгәрешне дә сизеп ала торган шундый нечкә күңел булсын әле!

Менә бүген Вятка ярында ул күңелнең бер кылы тартылды да өзелде. Мәхәббәт кылы...

* * *

Шул сөйләшүдән соң Гафил белән башка очрашмабыз дигән идем, әмма алай булып чыкмады.

Ул үзе килде. Кесәсенә бер коньяк тыккан. Мин аларны Вятка буенда коньяк белән сыйлаган идем. Күзләре әйтеп тора: «Без дә мондый нәрсәләр белән таныш, янәсе...»

Минем тозлы-борычлы җимерек чыраемны күреп, сүзне үзе башлады:

— Усак янында сүсьне басьладык кына, дәвам итәргә мөмкинме? Юлдагысын да сөйләп бетермәдек сикелле...

— Юньсез сүзне дәвам иткәнче, башламавың хәерлерәк!

— Дөресьлек хакына! Басьлаган сүсьдән касу — зиңелү дигән сүсь...

Зөһрә карчык кызы Газзә ханымнарга киткән иде. Өйдә бер үзем генә. Ризалаштым:

— Йә нәрсә әйтербез?

— Әдә асыктан асык!

— Мин ачык сөйләшәм...

— Соң сулай булгась, хоть утырырга урындык бир!

— Рәхим итәсең! Әмма онытмыйк — бу минем өй түгел...

— Зөһрә карчык өе. Стаканнар алып кил әле!

Әбинең шкафында өч-дүрт рюмка да бар иде, аларның икесе өстәлгә килеп кунаклады. Гафил аларны келтерәтеп коньяк койды. Мин Одик биргән кипкән балыкны турадым. Шул вакыт Гафил кесәсеннән ике пачка шоколад һәм «Петушок» конфеты чыгарды, аннан соң миңа үтергеч итеп карап куйды да моңсу гына итеп мыскыллы елмайды. Коньякны нәрсә белән эчәргә икәнен белмисең, эх, шәһәр аламасы, ди иде бу елмаю. Аптыраш, мин аннан көләсе урынга, ул миннән көлә.

Коньяк белән кипкән иреннәрне юешләткәч һәм шуның белән телне ачыктан-ачык сайратырлык иткәч, сүзне янә мин башладым:

— Йә, нидә калдык?

— Теләк турында...

Шул вакыт Зөһрә әбинең базда калган соры мәчесе «мияу!» дип кызганыч рәвештә кычкырып куйды. Барып баз капкачын ачкан идем, чыкмый, ә үзе һаман мияү! мияу! ди. Гүя: «Сөйләшегез-сөйләшегез әйдә, мин уяу, мин уяу!» — ди...

Гафил киерелебрәк утырды, әллә урындык аяклары, әллә аның сөякләре бер-берсенә бәрелеп шыгыр-шыгыр килде. Ул, нәрсә әйтергә соң дигәндәй, бераз вакыт күзен йомып торды, ач яңакларындагы сеңерләр уйнаклап алды, иренә кәгазь калынлыгы гына калып кысылды, шома биек маңгаена хыянәтчел тир бөртекләре бәреп чыкты. Мин шулвакытта аның йөзенә ныклабрак күз төшердем: моңарчы күрми йөргәнмен икән — матур иде, каһәр, бу егет, ирләрчә тупас кыяфәтле, көче йөзенә чыккан аю кебек салмак һәм җегәрле Одик белән чагыштырганда хатын-кызларча матур иде. Хәтта кызларча матур, сабыйларча матур. Кыяфәтендә инфантиль чалымнар да бар. Табигать аны нәзберек, нәзакать иясе итеп яраткан, ләкин җанына сагыш-моң катыш оятсызларча үз-үзеңне ярату, башкаларны түбәнсетеп карау рухы өргән...

— Менә сесь, — дип сөйләп китте ул, — минем Әдилә белән ирлехатынлы ... мөн... мөнәсәбәтне Одикка карата хыянәт дип саныйсысь...

— Әйе! — дидем мин.

— Әмма теләк дигән бөек көсь бар! Миңа егерме тугысь, Әдиләгә егерме дүрт. Бесь... фисик яктан бер-беребесьне теләдек... Одик моны аңламый, аңа рухи сөесү кирәк...

— Нигә сез нәкъ Әдиләгә күз аттыгыз?

— Ә нигә сесь каз боты урынына сөяк кенә кимермисесь? Коньяк урынына сасы самогон гына эсмисесь?

— Аңламадым? — Мин, әлбәттә, боргаландым гына. Аңлатты бу! — Сез — русчалап әйткәндә — сволочь, татарча — хәсис! — дидем мин, аның йөзенә бәреп.

— Сүсьләрегесьне үзегеськә кайтарам: минемчә, алар сесьгә дә ябысырга мөмкин. Аннан соң, онытмагысь: мин — сесьтә кунак!

Мин аның йөзенә текәлеп уйга баттым...

Соң, бу адәм баласына бернинди сүз дә тәэсир итми микәнни соң? Нинди авыр сүз ишеткәч тә, кымшанмады. Ә син, абзый, кызасың. Көчсезлегеңне күрсәтәсең. Сүзләрең үзеңә ябышырга мөмкин дип шәп сылады бит бу үзеңә. Йә, ходаем! Каян килгән аңа мондый ихтыяр көче. Югыйсә, тәрбиясе дә ташка үлчим кебегрәк... Ә үзен ничек тота? Принцмыни! Ә коньяк, шоколад һәм «Петушок»? Ә ни өчен сөйләшеп утырам соң әле мин аның белән? Ни өчен?! Дөреслек хакына! Ә... Ярый алайса!

— Беләсезме нәрсә? — дидем мин аңа шактый сабыр гына һәм житди тон белән. — Сез бервакытта да үз хыялыгызга ирешмәячәксез...

— Ә нинди хыял ул?

— Әдилә!

— Әдилә?! — дип куркынып сорады ул.

— Әйе, Әдилә. Ант итеп әйтәм, Әдилә бервакытта да сезнеке булмаячак!

— Ничек булмаячак?

Мин кинәт кенә торып бастым һәм аның йөзенә үк якын килеп, күзләренә текәлдем:

— Ни өчен Одикка алдап мыгырдандың? Әдилә аңа хыянәт итмәде ич! — дидем мин, пышылдап кына, әмма зур пафос белән һәм сүзләремә яшерен сер мәгънәсе салып.

— Каян беләсең?! — диде ул да астан без белән чәнечкәндәй сикереп торды, кара күзләренә тагы курку йөгерде.

— Күпме ышанырга теләсәң дә, күзләрең әйтеп тора, егетем!

Миңа ифрат рәхәт булып китте. Гүя бүлмәгә саф һава тулды, сулыш иркенәеп, гәүдә җиңеләеп китте.

«Шалишь, брат! — дидем мин эчемнән генә.— Яхшылык барыбер җиңәргә тиеш, чөнки ул — кешенең яшәве!»

Гафилгә сөйләргә ирек бирмичә сүзне дәвам иттем:

— Менә бүген син минем янга ник кердең? Кичәге Әдилә белән без ирле-хатынлы... дигән сүзләреңә мине тагы да ныграк ышандыру өчен бит. Син минем кичә ышанмавымны күрдең. Ә мин ышансам, Одик һәм Хак та ышана, имеш... Шулай берәм-берәм безне алдарга теләдең, ә?

— Каптым! — диде ул, бөтеркә чәчләрен йомарлап тотып.

— Уйный алмадың ролеңне, хәсрәт артист!

— Сөенәсең?

Аның ни сабыр ак йөзенә тимгел-тимгел кызыл иңә башлады. «Оялудanмы, әллә бик ачуы килүдәнме?» — дип уйлап алдым.

— Яхшылык җиңүенә сөенергә кирәк, әлбәттә! Әмма мин сине аңладым: балыкка йөрүләрең, фәлсәфә сатып маташуларың — барысы да кыланулар гына булган, шулаймы?

— Әдилә кирәк иде миңа, Әдилә...— диде ул ишетелер-ишетелмәс кенә.— Яратам мин аны, мин унынсыда, ул зиденседә укыган вакыттан бирле яратам...

— Ә ул?

— Ә ул юк... Ул О...дик... ны... Сул зыкны ярата!

— Нишләрсең... Яратуны көчләп алып булмый!!

— Одик беркатлы егет... бу сүсьгә ышанасак һәм... Әдиләне тасьлаясак... Ул барыбер минеке булаясьсак...

— Сүзнең ахырын уйлап сөйләргә кирәк, энекәш! — дидем мин аңа, акыл өйрәтүче тоны белән.

— Сүсь? Нәрсә у сүсь?

Кинәт ул кыргыйларча шаркылдап көлеп җибәрде:

— Ха-ха-ха! Ха-ха-ха-ха! Сусь, имес...

Менә ул ярсып китте, кашлары җыерылды, авызы чалшайды, күзенә зәһәр очкыннар йөгерде:

— Сүсь... Сүсьләр... Теләсә кайда сүсьләр! Ә эсь кая? Сүсь белән эсь аермасы тау кадәр. Кая алар арасында Хак әйткән тәңгәллек?! Ә? Кая гына карама, бер төрле сөйлиләр, икенсе төрле эсьлиләр. Үсенең мәнфәгате өсен һәркем алдарга тырыса. Мин кем? Аңардан киммени, ә? Үсем теләгән яраткан кысьымны...

Шулвакыт ишек ачылып китте, бүлмәгә эре бөдрә кара чәчле, озынча зифа буйлы чибәр кыз керде дә Гафил янына тиз-тиз генә атлап килде һәм:

— Кабахәт! Ни йөзең белән минем чиста исемемә пычрак атырга батырчылык иттең? — дип, чалт итеп яңагына сугып җибәрде. Әдилә (әйе, бу Әдилә иде) кергәндәге кебек кызу-кызу атлап чыгып та китте.

Өстәл өстендәге «Петушок» конфетлары идәнгә чәчелде, Гафилнең уң яңагында малларга суккан тамга кебек биш бармак эзе янып калды.

— Әдилә! — дип өзгәләнеп кычкырып җибәрде ул. Җавапка кузгалып китеп барган «Уазик»ның» «оныт-ты-рр!» дигән тавышы гына ишетелде.

Гафил бөкрәя төште, озын буе ничектер кечерәеп калган күк булды. Кай ягы беләндер бозлы су белән коендырылган шәбәргән-койрыксыз әтәчкә охшый иде ул... Идәндә ялтыравыклы кәгазьгә төрелгән «Петушок» конфетлары чәчрәп ватылган мәхәббәт кисәкләре кебек ята иде...

— Әдилә! — дип кычкырды ул тагы.— Их, заным, белмисең сьсине ничек яратканымны!..

— Менәтерә, нигә шулкадәр кычкырасың, тәрәзә пыяласын ертасың бит! — диде ишектән килеп кергән ачулы йөзле Зөһрә карчык.

— Тәрәсьсә пыяласьы, әби, ертылмый, ватыла гына... Ә монда минем йөрәк пәрдәсен ерттылар...

Шул сүзләрдән соң Гафил капылт кына торып чыгып китте.

Тәрәзәгә күз төшкән иде: төн пәрдәсе дөньяны томалап килә икән...

— Тегендә баргач та карангыдан туярбыз әле! — дип, Зөһрә карчык кабаланып ут кабызды. Өй эченә кинәт кенә якты нурлар коелды.

Ә шулай да Гафил жәл иде... Нигә шулай? Кайсы ягы белән күңелгә үкенеч һәм сызлану булып керә ул?! Һич җавап бирә алмыйм. Чөнки... Бу турыда белмим. Белмим шул... Белмим...

* * *

Арып кайтылган иде. Колхоз печәнен җыюны тәмамладык. Ул халык! Кырмыска урынына кайнады, бал корты урынына йөреп торды. Кая барсаң да шау-гөр, көлү, шат йөз, ерык авыз. Моның ике сәбәбе бар: берден, бүген колхоз болынындагы эшне бетерәләр. Эш бетүгә күп итеп ит пешереләчәк, аланда сабан туендагы кебек матур бер күмәк утыру булачак. Икенчедән, иртәгәдән башлап һәр йорт өч көн буе үз әрчүләреннән мал-туарга кышлык печән әзерләячәк. Бу якта моны август җыены дип, шаяртып әйтәләр. Шуңа күбесенең күңеле — көр, йөзе — кояш.

Хак, Одик һәм мин көне буе алты кибән куйдык. Талчыктырды. Икенче партия кибәнчеләр — бишне, өченче партия дүртне генә куя алды.

Зөһрә карчыкның кызгылт-кара плюш җәелгән йомшак диванында китап укып утырам. Хемингуэйны... Минем идолны... Кумирны... Кичә генә Мәһдиевне кабат укып чыккан идем... «Без — кырык беренче ел балалары»н». Мәһдиев тә — ихтирам казанган каләм иясе, булганны — бер итеп язучы...

Шулчак Мансур абый килеп керде. Әйбәт үк эчеп алган (колхоз сыена шактый өстәгән): озынча борыны тимгел-тимгел, күз кабаклары күгәрчен күкәе кадәр булып шешенгән, өске иренен шешә бөкесе ачканда ялгыш кискән булса кирәк: бармак бите кадәр җирдә кан оешып каткан. Ул тыңлаусыз сирәк чәчләрен артка сыпырды. Аннан соң пычак кайрарлык булып ялтырап-шомарып беткән кепкасын салып, йодрык кадәр сөякләре тырпаеп торган тез башына элде һәм куенынннан бер «пыяла самавыр» алып өстәлгә куйды. Зөһрә карчык лапаста кәҗәсен сава иде — сөт көткән кешегә ширбәт! Хм! Нишләргә? Маташыргамы, юкмы? Кырт киссәң — үпкәләячәк... Йотам дисәм — ул нәрсәне авызга капмыйча, бер атна-унбиш көн ураза тотып, баш миендә чәчелеп яткан уй-фикерләрне бер җепкә җыеп, кәгазьгә төшерәм дигән план бар иде бит!..

Мансур абый кайчандыр зәп-зәңгәр, хәзер өстендәге күлмәге кебек таушала башлаган, төсе уңган күзләрен миңа төбәде дә:

— Яшьтәш, сез Одик белән дуслармы? — дип сорады.

— Дуслар!

Мин җәһәт кенә урынымнан сикереп тордым, олы кеше белән ятып сөйләшү — күперенке мәнсезлекләренең берсе!

— Хай! Соң дуслар булгач, ананны (фәлән-фәсмәтән!) нигә өйләндермисең аны?!

Ул кыска гына җөмләсенә ике этажлы тозлы-борычлы сүз өстәп, соравының никадәр житди икәнен аңлатырга теләде, бугай.

— Мансур абый...

— Туганнан бирле Мансур мин, яшьтәш! Кая синең дуслыгың, аны өйләндерә дә алмагач?

Миңа ул кинәт башын иде, әмма мин күреп калдым: күзләреннән атылып чыккан хыянәтчел ике яшь бөртеге тәк баскан бите буйлап тиз генә аска тәгәрәделәр дә берсе кепка өстенә, берсе бозау башы зурлыгындагы кытыршы кызгылт йодрыгына төште. Бер сүз эндәшмәдем.

— Утыз тула бит инде аңа... Миңа бер елдан пенсиягә... Хай! Нужәли, мин аның өйләнгәнен дә күрми үләрмен инде... Әй Одик, Одик! Бала, бала... Хай... Улым!!

Ул шактый гына вакыт борынын тарта-тарта әнисенә үпкәләгән сабый бала кебек тавышсыз гына елады.

Белоруссия урманнарын айкап йөргән әзмәвер Мансур абый! Командирларының иң яраткан партизаны булган, отрядны ничә мәртәбәләр үлемнән коткарган элемтәче Мансур абый! Сугыш башында, артиллерист чагында, бер үзе өч кешелек снаряд ташучы Мансур абый... Кем уйлаган сине, сугыш бетеп дистәләрчә еллар узгач, менә шулай елап утырыр дип? Ни өчен диң әле? Улы, бердәнбер улы, утызга җитә язган улы өйләнмәгән өчен... Эх, шулаен шулай да! Дөнья үзенекен итә... Теге чактагы Мансур юк инде хәзер... Яшьлек еллары узып китте аның... Бәлки шуңа елый ул. Егерме яшендә туп кебек тупырдап торган кызы рак белән үлеп китте. Шуңа елый ул. Одикның яраткан кызы, күрше колхоз председателе, чибәр һәм таза, шуның өстенә зифа гәүдәле Әдилә турында әллә нинди килбәтсез сүзләр йөри... Имеш тә мимеш... Шуңа елый ул. Аның яшьтәшләре оныкларын мәктәпкә укырга озатып калалар. Капка төбендә... Ә аның оныгы юк. Шулай булгач, Маракшиннарны дәвам итүче сары чәчле түгәрәк малай җитми әле бу дөньяда! Шуңа елый ул... Дөнья дөнья инде ул! Һәрнәрсәне үз вакытында сорый... Нәсел агачы корымасын, нәсел агачы!

— Йә, нигә дәшмисең? — диде ул, башын күтәреп тупас кына.

Аннан соң өстәлдәге чәкиле-сырлы стаканны тутырып аракы салды һәм, бер тын белән эчеп бетергәч, кепкасын авызына каплап торды. Авыр гына урыныннан кузгалды һәм саубуллашмый-нитми чыгып китте.

Нәрсәдер әйтим дип ачкан авызым, кош оясы кебек, ачык калды.

Нәрсә әйтим мин аңа? Тукталып аңлатыргамы? Юк, әлбәттә. Бүген аның хәле шундый — бу сөйләшүне онытачак ул. Күңеле чишелеп китте аның бүген, күңел күлмәгенең сәдәпләре өзелгәндер, күрәсең...

Ул хәзер өенә дә кермәячәк, Одикның сөйләве буенча, инеш буендагы кычытканнар арасында утырган ярым җимерек кара мунчаның ләүкәсенә менеп йоклаячак. Одик бу мунчаны быелдан калдырмыйм, утынга сүтәм, ди. Югыйсә, ияләнде бит, аз гына салдымы, мунча пәрие кебек ләүкәгә ятып йоклый.

Аңламый аны улы! Белоруссия урманында шушындый мунчалар — партизаннарның гүзәл сарайлары иде. Җылы, иркен! Унар кеше бергә йоклаган чаклары булды. Шуларны сагынып йоклыймы ул?

Юк, юк инде! Аны шайтан сагынсын! Исерек килеш хатынына, улына һәм салып йөрүне яратмый торган кызына — Илсөягә күренәсе килми Мансур абзагызның. Шуңа күрә мунча ташы — мендәр кук йомшак, ләүкә — сиртмәле карават кук! Ә иртә белән...

Сәгать дүртләрдә кайтып, бер бөтен ипи белән ярты казан ашны чөмерәчәк. Аннан соңмы? Аннан соң, баш авыртасы искә төшә. Верандада йоклап ятучы Одик янына аяк очларына гына басып чыгачак һәм... (йә, Ходай, гөнаһлы бәндәләреңне ярлыка!) аның «парадный» костюмының түш кесәсеннән бер шешәлек акча эзләячәк. (Өч өй аркылы торучы күрше карчыгы сәгать унбергә кадәр, берәр эшеңә булышырмын дип вәгъдә бирсәң, яисә акча төртсәң, теләсә кайсы вакытта бер ак табып бирә, әллә кайдан эзләми ул аны — идән асты запасы бар! Җае барның — мае бар! Төшемле генә кәсеп. Шуның өстенә һәр шешә саен бер-ике тәңкәгә алдаса да, шешенке йөзле калтырау куллы ирләр халкы аны «во карчык!» дип мактап торалар. Үз кеше, янәсе! Безнең хәлгә керә белә...) Акча эзләячәк дигәч тә, Мансур абзагызга акчаны эзләп торасы түгел, әнә шул түш кесәгә ике бармакны гына төшерәсе. Анда һәрвакыт ким дигәндә ун-унбиш тәңкә булыр. Шундый касса ул Одикның түш кесәсе, акчасыз тормый. Әмма монда бер яман нәрсә бар — әнә шул кыйммәтле костюмның акчалы түш кесәсенә Мансур абзагызның берсе-берсе урындык аягыннан юан бармаклары сыймый шул... Менә бәла! Берсен генә төшерер идең, аңа шома акча ябышып менә алмый, шул бал сылап төшерсәң генә инде. Алай итсәң, костюмны пычратуың бар. Менә шулай

интеккән чагында, Одикның сыңар күзен генә ачып: «Әти, костюмны пычратасың ич, бар әле, кулыңны юып кил!» — дигәне ишетелә. Идән ярыгына сыйса, Мансур абзагыз бик төшеп китәр иде, юк шул, табигать аңа гәүдәне жәлләп бирмәгән, идән ярыгына түгел, тар-тәбәнәк ишеккә дә сыймый әле ул. Нәрсә дисен «Ә, улым, син мондамыни?» — дигән сорау җөмләне сүз булсын өчен генә бирә дә, андый вакытта башын аска иеп, таю ягын карый ул.

Ул вакытта Газзә ханым уянып, ит өчен димәктән генә түгел, соңгы елларда иялэнгән гадәт буенча «утыз тавык, илле чеби, һәм егерме каз, кырык үрдәк арасында» кайнаша башлар. Иренең таптап ташлагандай чыраена, калтыранып торган кулына һәм эттәй турылыклы мэюс күзләренә карап аны жәлләгәнен белдереп уфылдап куяр һәм кызганып, үз запасыннан йөз илле грамм аракы салып бирер. Тегесе шуны күрүгә, чөгендер йөзен кояш итәр, кечәге хәлләрне сөйли башлар һәм, утыз биш ел бергә торган гомер иптәшенә беренче мәртәбәдәге кебек бүгеннән соң эчүен ташлаячагын, «лутчы» умарта карау яисә куян үрчетү белән шөгыльләнәчәген әйтер. Аннан соң аклы-кызыллы сыерга башак бирергә сарайга кереп китәр.

Бу сыерга Мансур абзагызның телевизор да караткны бар. Аларның бер иске телевизорлары верандада иде. Одик кайвакыт төнге тапшыруларны карап ята. Әлеге аклы-кызыллы сыерны алган еллары иде. Бозавы гәүдәле булса да, сөткә чамалы иде ул үзе беренче елны. Ә Мансур абзагыз, сөтне савып бетерүгә, чиләге белән күтәреп эчәргә ярата. Газзә ханым көлеп әйтмешли: «Сөт еланы!» Бер салган баш белән верандада телевизор карап ятканда, көтү кайткан чак була. Телевизорда да сыерлар мөгри. Үзләре нәселле, сөтләре потлап, имчәкләре каз чуманы кадәр. Ә бу аклы-кызыллы сыер кәҗә сөте биреп җәфалый. Мансур абзагызга пүхмиллек сөте юк! Әле Газзә ханым, Илсөя дә сөтләп чәй эчәргә яраталар бит. Шуннан бу телевизорны тәрәзәгә борып куя да сыерны мөгезеннән тотып, нәселле сыерлар белән очрашуга алып килә. «Менә кара,— ди,— кәҗә токымы, әнә алар көнгә унбиш-егерме литр сөт бирәләр! Ә син? Кәҗә токымы! Ике-өч литр, хай... Син дә начар тормыш итмисең бит. Ашавын да артыңнан гына тыкмыйбыз, хай? Оялмыйсыңмы әзрәк, ә?»

Әлбәттә, бу агитация-пропагандадан соң аклы-кызыллы сыер оялган. Бер елдан соң сөтне ике мәртәбә артык бирә башлаган, алдагы елны тагы икеләтә арттырган... Бу хәл Мансур абыйларның ишек тупсасыннан ерак таралмады, гомумән, алар семьясында күп сөйләшү дигән нәрсә юк иде. Марак карт элек-электән әйтеп калдырган: «Өеңнән чыкканда сүзеңне тупсага салып калдыр!»

Олы кеше бит! Озатыйм дип чыксам, Мансур абыйдан җилләр искән, әллә палас-самолетка утыртып алып киткәннәр инде үзен.

Шулвакыт ниндидер тавыш ишетелде. Зөһрә карчыкның күрше малае әнисенә кычкыра икән:

— Ани! Ани, дим! Адыйк абый өйләнгән. Прсидател Адила апага!

Шулай итеп, Одик та өйләнде. Күп сөйләшеп йөрмәде. Мыштым гына өйләнде дә куйды. Яратканына...

Әгәр кыз кеше булсам мин дә һичшиксез, аңа кияүгә чыгар идем. Алай дисәң, мин кыз булып тусам, аны болай якыннан белмәс идем, чөнки Вятка буенда минем урынга икенче кеше Одик белән балык тотып йөрер иде.

Һәркемнең гомере — тормыш юлында бер сукмак... Бу сукмак олы юлдан барса да, очрашу кебек үк, очрашмый калулар да мөмкин хәл... Рәхимле дөнья мине Одик белән очраштырган икән, рәхмәт аңа! Тормыш яхшы кешеләрдән тора! дигән уемны раслаучы бер җанлы дәлил — чын кеше белән очраштырды бит ул мине. Одикның минем өчен кадере менә нәрсәдә. Мондый кешеләр югалырга, кимергә тиеш түгел, киресенчә артырга, барлыкка килергә тиеш. Дөньяда яхшылык шулар җилкәсендә...

Бүген Одик өйләнде, шулай булгач, киләчәктә (бәлки бер-ике елдан, бәлки тугыз ай үтүгә үк!) дөньяда тагы бер кеше артачак. Яхшы кеше баласы! «Алма агачыннан ерак төшми»,— ди халык...

* * *

Мин китәргә җыенып йөри идем инде — Одикның соравы буенча кичектерергә туры килде, чөнки туйны озакка сузмаска булдылар. Яшь ир белән яшь хатын минем анда катнашуымны теләделәр. Гафил туйга килмәде. Килсә дә утыра алмас иде. Одик белән Әдиләнең ак бәхетенә кара челтәр кирәкми! Кара челтәрләрне аннан башка да язмыш яшертен тегүчән ул!

Мин бүген аларга кергәндә Газзә ханым үзе генә иде.

— Исәнмесез, Газзә ханым! Хәерле кич!

— Исәнмесез! Түрдән узыгыз!

Ул иске открыткалар карап утыра икән.

— Укучыларыгызныкымы?

— Әйе... Элек: «Укытучының эше — көндезе һәм киче!» — ди торган идек. Менә пенсиягә чыккач та, шул «көндезе һәм киче эшкә» күңел тартып тора.

— Эш эшләгәндә авыр, беткәч — җиңел, диләр.

— Бик дөрес әйтем! Менә тагы берничә ел укытыр идем әле... Әмма классны Илсөягә бирдем... Яшьләр өйрәнсен, алар барыбер безне алыштырачак бит, шулай булгач, ник сузып торырга? Һәрнәрсә вакытында алыштыруны ярата...

Газзә ханымга минем күптән бирергә теләп тә, мәнсезлек санап, үз эчемдә йөрткән бер соравым бар иде, чөнки ул минем күңелдә оешып килгән әйбер өчен ифрат та әһәмиятле иде. Шуңа бүген битемә әрсезлек битлеге кидем дә гади генә итеп сорап куйдым:

— Газзә ханым, әгәр сер булмаса әйтегез әле: сез Мансур абыйга ничек кияүгә чыктыгыз?

Ул беркавым сүзсез торды, аннан соң миңа үткен күзләрен текәп, үзе сорау бирде:

— Бу турыда сезгә Мансур сөйләгән идеме?

— Әйе... Беренче тапкыр тимер юл станциясендә очрашкан чагында...

— Ярый алайса... Минем ул нәрсәләрне кузгатасы килми иде. Шулай да сөйләп китим...

Ул тагы тынып калды, шул вакытны хәтерләргә теләгәндәй, маңгаен җыерды һәм аз гына хәсрәтле тавыш белән акрын гына сөйләп китте:

— Мансур безне беренче ирем белән автобуста очратканнан соң, мин аның белән аерылыштым. Күп тә үтмәде, Мансур белән тагы шул ук автобуста очраштык. «Ирең кайда?» — ди бу. Башта: «Миндә ни эшең бар синең?» — дип карлы-бозлы сөйләшсәм дә, соңыннан хәлне аңлатып-төшендереп бирдем. Мансур бөтенләй үзгәрде: «Гафу итегез, мин сезнең семьягызны, тормышыгызны боздым»,— ди. «Сезнең бер гаебегез юк. Мин ялгыш эшләдем» — ди. Шуннан соң очраштыргалап йөри бу миңа һәм беркөнне әйтте дә салды: «Мин,— ди,— сезнең тормышыгызны боздым, рөхсәт итегез, ди, мин аны төзәтим! Чыгыгыз миңа кияүгә, кайтыйк безнең туган авылга. Анда менә дигән мәктәп бар, ди. Сез укытучы булып эшләрсез, ә мин — тракторчы. Әмма,— ди бу,— теге сволочьны мин барыбер бугазыннан алам. Кырык тугыз кешелек отрядны саткан өчен костыртам мин аны, ди. Башта әйбәтләп үзен тукмыйм, кулларым авыртканчы тукмыйм. Аннан соң хөкем кулына тапшырам, ди».

Газзә ханым тагын беравык тынып калды. Бәс кебек чәчләре өстендә яткан ярымтүгәрәк тарагын рәтләп куйды да дәвам итте:

— Әмма бик соң тапты ул аны. Бик соң...

— Сез беренче ирегезне...— дидем мин, кыюсыз гына.

— Жәлли идем мин аны, жәлли идем...
— Жәлли идегез? Ә хәзер?!
— Әйе! Сатлык икәнен белгән чакта ачуымнан үтерердәй булган идем. Бер генә төн түгелдер елап мендәр чылатканым. Бер уйласаң, яшь-яшь кыз килеш кешегә — иргә ышанып чыгасың бит, ә ул? Иптәшләрен саткан, сине дә сатачак! Әмма!..
Ул тагы тарагын рәтләп куйды.
— Картайган саен күңел йомшара төшә. Минем аны кызгану хисе туды. Жәлли идем мин аны, жәлли идем...
Ул торып басты:
— Әмма жәлләргә калган — кеше түгел инде ул! Әле быел гына бергә үскән дус кызымның армиядән кайткан улы, Вяткага балыкка төшкәч, батып үлде...
— Фәритме әллә? — дип ычкындыра яздым.
— Миндә укыган егет иде. Ипле, акыллы, төп кебек егет. Менә шул Бәдәр дустымның...
Йә, Алла! Минем туганнан туган энем Фәрит турында сүз бара икән шул!..
— Малае батып үлгәч, мин аны жәлләүдән туктадым. Ул сатлык яшәгәнче менә кем яшәсен иде. Ул сатлык менә нинди егетнең гомеренә кул сузган. Миңа шулай тоела: әгәр ул сатлык үз вакытында сугышта үлгән булса, хәзерге көнне Бәдәрнең малае Фәрит исән булыр иде. Белмим кайдан килгән миңа бу уй. Әмма миңа шулай тоела. Ул кырык тугыз партизанның гына гомеренә кул сузмаган, бүгенге көндә яшәүчеләрнең дә гомеренә кул сузган. Шулай булгач, андыйларны жәлләү юк!..
Газзә ханымның тавышы калтырап чакса да, үз сүзләренең хаклыгына нык ышанып сөйли иде ул.
Шунысы истә калган: күз төбендә мин аның нәни генә елтыр тамчы яшь бөртекләре күрдем.
Бу яшь бөртекләре үкенеч сулышы булудан битәр, ничә еллар газапланып килеп тә үткәненә дөрес хөкем юлы табу шатлыгыннан иде булса кирәк.
Бәлки башка нәрсәдер... Кем белә? Кеше күңеле — төпсез упкын бит ул...

* * *

Өч тиенлек унсигез битле гади дәфтәрләрне яратам. Аларны язмасызма белән тутырам...
Шөн авылында да шул ук хәл: менә өченче дәфтәр тулып килә инде. Хак белән Одикка мин аны көндәлек дигән булам, әмма бу көндәлек түгел...
Шулай да көндәлек дип исем тагабыз икән, менә аңа язганнар:
1. Еш кына миңа бу авылга иртә белән яисә кичкырын капка төпләрендә утыручы сиксән яшьтәге хәтта аннан да картрак әби-бабайлар күренде. Гадәттә, авыл яисә шәһәрнең матурлыгын, күңеллелеген яшьләрнең күп булуы белән билгелиләр. Ә менә сиксән-туксан яшьлек картларның күп булуы теге яки бу якның таза-нык тормышлы, көр күңелле булуы турында сөйләүче иң беренче билгеләр. Димәк, авылның бүгенгесе генә түгел, үткәне дә матур һәм нык нигезләргә корылган. Шуның дәлиле: Шөн. Кавказга барып йөрисе дә юк!
2. Ил никадәр зур булса, аның белән идарә итүе дә шулкадәр авыр. Моның ачык мисалы: биредәге колхоз, Район җирләренең алтыдан бере аның өлешенә туры килә (ә районда 16 колхоз!) Шулай да ул районда иң беренче урыннарда бара. Моны каты куллы, «демократияне кесәсенә тыгып йөри» торган председательнең «заслугасы» диләр. Аннан алдагы-

сы колхозны кабалага төшергән булган. Бирәсе әҗәтләре генә миллионлап саналган...

3. Хайваннар бер-берсен телсез дә аңлый. Ә кешеләр бөек аралашу чарасы булган тел ярдәмендә дә кайвакыт аңлаша алмыйлар. Аралашу чарасы — аңлашу чарасы гына була алмый икән. Бу — коточкыч хәл! Без Гафил белән аңлаша алмыйча гафил булдык бугай...

Дәфтәргә соңгы сүзләрне язам да саф һава суларга дип урамга чыгам. Зәһрә карчык күптән йоклый инде.

Дөнья тып-тын... Ефәк караңгылык. Мәче баласы кебек иркә һәм йомшак җәйге җылы җил биткә кагылып уза. Агач яфраклары төшләнеп йә саташып, нидер турында әкрен генә сөйләшеп алалар. Ләкин бу сөйләшү тынлыкны боза алмый. Тып-тын... Инешкә коя торган Мәтә елгасының челтерәп акканына кадәр ап-ачык ишетелә. Гүя чикерткә тавышы... Айлы күктә бер болыт әсәре юк. Зәп-зәңгәр аз гына карасу күк. Учлап-учлап йолдыз сибелгән аңа. Инеш буена таба, мәктәп бакчасына киттем. Бакчадагы тәбәнәк утыргычка утырып сигарет кабызырга уйлавым булды, якында гына сөйләшә башладылар.

— Син, кешеләр барында хатының икәнне оныт. Мин эш кешесе, ләбаса — председатель...

— Хәй! Шуннан...

— Кешеләр миңа: «Әдилә Галимовна, керергә мөмкинме? — дип рөхсәт сорыйлар, ә син: «Әдилә, минем янга чыгып кер әле!» — дип чакырасың...

— Син минем өчен хатын, яраткан хатыным, кешеләр барында да, югында да...

— Йә инде... — тавыш назлы иде. — Кешеләр барында әз генә официально, ә?

— Ярый, ярый... Кешеләр барында син дигәнчә, ә кешеләр югында мин сине...

— Одик, юләрләнмә! Кара син, аю... Йә ин-де, җа-ны-ем... бә... гы... рем...

Соңгы сүзләре белән Әдилә, хәлсезләнгән күбәләк кебек, Одикның куәтле кочагына сеңә башлады.

Алар мине күрмәсәләр дә, үз йөземә кызыллык китермәс өчен, карашымны тагы йолдызлы күккә күчердем һәм... шундук сискәнеп киттем.

Йә хода!

Мәчет манарасындагы көмеш ай белән күк йөзендәге бронза ай кочаклашканнар иде.

* * *

Шуннан соң мин бу яклардан китеп бардым. Зәһрә карчыкка бирәсене түләп, ачык йөзе, киң күңеле өчен егерме биш тәңкә акча бүләк итмәкче идем:

— Юк, юк, кирәкми, менәтерә! — диде. — Акчаның кадерен бел, улым. Болай булса, синдә аның ботаклысы да тормас. Кесәдәге акчаның ботаклы булуы яхшы! Менәтерә! — диде ул чәбәләнә-чәбәләнә каршы килеп.

— Соң, әби, бүләк итеп...

— Акча бүләк булмый!

«Әй, надан! — дип сүктем үземне... Ачык йөзне, киң күңеллелекне 25 сумга сатып алып буламыни! Ахмак! Кырдың инде... Икенче кайтканда күчтәнәч, Казан күчтәнәче алып кайт син аңа. Менә булыр бүләк... Зур бүләк!»

— Тагы кайта калсаң, менәтерә, — диде Зәһрә карчык. — Туры үземә кайт, сиңа бик нык иялә штем инде мин. Синнән башка!..

Карчык күзен ак яулыгы очы белән каплап, читкә борылды.

Аннан соң күз яшьләрен сөртеп:

— Син, улым, минем Газизә кызым әйтмешли, пәри-умный улым булырсың, менәтерә!

Әй әбекәй! Пәриумный улы! Йә, кемнең бар мондый пәри умный улы? Сүз тәртибен әзрәк үзгәртсәк: акыллы пәри улы! Менә бит ул ничек... Йә, ярый, ярый... Рәхмәт сиңа, Зөһрә әби! Рәхмәт сиңа, изге карчык!!

Кайтып, күп тә үтмәде, Хактан кыска гына хат килеп төште: «Синең ярдәмең кирәк. Тиз генә кайтып кит әле».

Колхозның еллык уңышлары өчен унбиш мең сум премия бирелгән, әмма премияне бүлешү гадел түгел икән. Колхоз җитәкчеләре үзләренә бишәр йөз сум алганнар, ә гади колхозчыга Хак язганча, «бишәр йөз тиен». Үзләренә — сум, колхозчыга — тиен. Анда да һәрбер кешегә эләкмәгән. Дөрес анысы, ун сум да зур бүләк. Әмма тигезләү кирәк. Тигезлек кирәк! Мең сум белән мең тиен арасы — зур аерма!

Әмма мин кайта алмадым. Санаторийга киттем. Санаторий ял өчен түгел, дәвалану өчен кирәк иде миңа. Өлгерербез әле Хакның хаты белән дип уйладым...

Санаторийдан кайтып керсәм — үтерелгән ак күгәрчен кебек телеграмма ята. Одик җибәргән. Хак үлгән! Иртәгә күмәчәкләр...

* * *

Автобус шоферыннан үтенгәч, ул мине зират янына төшереп калдырды. Тәки өлгердем! Мин зиратка кергәндә, кешеләр шунда иде әле. Дөрес, каберен күмеп, кырыйларына тартма-тартма яшел чирәмле кәсләр тезелгән иде инде.

Халык бер сүз эндәшми, үле тынлык белән зираттан чыкты.

Урам башына килеп кергәч, кешеләр сөйләшә-гәпләшә, елмая-көлешә башладылар.

— Өлкәдә чәчүне беренче бетердек быел, мать-малина! Шәп эшләдегез, егетләр! — диде бригадир Танир.

— Премиясе кайчан, нәчәлник?

— Җиңү көне алдыннан...

— Вәт рәхмәт! Двуйной празник алайса!!

Тукталып, уртадарак кайтучылар янына калдым...

— Хәерен әйбәт бирделәр... Икешәр таңкә! — дип куйды берсе.

— Картлар кайтып киткәч, ике кара башка бер акбаш! Мәрхүмне юмый булмас... Шәп малай иде! — диде кабарынкы күз кабаклы, күбенке йөзле икенчесе, пычрак кулы белән яшь ага торган күзен сөртеп.

Арткы рәткә калдым...

— Әйбәт егет иде... Шунсы яман — бишектә чакта, сабый чакта ук үлде... Әмма дә ләкин шәп малай иде!..

Әлеге карт түбәтәен салып, сакалы кебек ап-ак кульяулыгы белән тирле маңгаен сөртеп алды. Таныдым: авылның иң карт кешесе — йөзне дә узган Йозмөхәммәт бабай бу.

— Тынгысыз бала иде... Җаны тынычланыр инде... — диде түгәрәк сакаллы икенчесе, алга таба сөртенеп атлый-атлый — шулай шул: иртәрәк китте... Иртә тынычланды.

— Яшен биектәге әйберләрне суга...

Моны җыерчыклы киң һәм биек маңгайлы, борынгы философларга охшаган уйчан карт әйтте.

* * *

Кичкырын Одик миңа менә ниләр сөйләде.

Соңгы көнен Хак, үләсен сизгәндәй, тыз-быз килеп, эшлисе күп эшләрен эшләп, үтәсе сүзләрен үтәп йөргән.

Иртүк Мәскәүгә хат язып җибәргән.

Зөһрә карчыкка биргән вәгъдәсе буенча, сарай тәрәзәсенә пыяла куйган. Одикка машинасы өчен яңа кабина биргән.

Культура йортына районнан яңа бильярд алып кайтып куйганнар.

Төштән соң председатель янына кереп, әлеге премия мәсьәләсендә хаксызлык турында яңадан сөйләшеп караган. Рәис дулаган, әлбәттә. «Авылдан куам мин сине!» — дигән. Хак: «Хаклыкны барыбер тапканчы йөрим! Тигез бүлегез! — дигән. «Тигезлек — зиратта»,— дип җавап биргән председатель. Әнә анда гына һәркемгә ике метр җир, дигән. Артык та, ким дә түгел. Кем булуыңа карамастан... Кич белән кайткач, өйләнешкәннән соң беренче тапкыр диярлек хатынының маңгаеннан үпкән. Аннан соң: «Мәйсәрә, ардым мин бүген, җаным, үз гомеремдә беренче тапкыр шулкадәр ардым, сөякләрем-гәүдәм менә-менә таралып китәр сыман»,— дигән. Шул сүзләрдән соң олы якка чыгып, телевизор кабызган. Ярты сәгатьтән соң кичке ашка чакырсалар, утырган килеш кенә үлеп киткән. Башына кан савып...

* * *

Күктә ак эз сызып, бик биектә булганга көмеш матур уенчыкка охшаган реактив самолет очып бара иде. Аның саңгырау һәм йомшак гүләү тавышы җир өстенә килеп орынгач, үлән һәм агачлар арасына тәгәрәп юкка чыкты. Арыш-бодай басулары, бәрәңге кырлары, алма бакчалары йотты ул тавышны.

Гаҗәп! Ничә тапкыр инде күктәге шушы нәни уенчыкны тотып аласы килә... Тотып карыйсы иде! Каян килә мондый уй? Имештер, кулыңны зәңгәр чиксезлеккә тык та, мичтән бәрәңге алган кебек, көмеш самолетны учларыңа ал! Ботактан алма өзүмени! Каян килгән шундый хыял... Тормышка мәңге ашмаслык хыял! Ә бит күккә карасаң, әлеге көмеш уенчык бик кечкенә, аны тотасы килә, тотасы...

Хак-дөреслекне табу да шулай...

* * *

Одик белән инеш буенда йөрибез.

— Әдилә белән тормышлар ничек? — дип сорыйм.

— Үз семьяң-тормышың белән генә бикләнеп калмаска иде...— ди ул. Аңлыйм: гаилә тормышы белән мактанасы килми, чөнки әле яңа гына өйләнештеләр ич.

Белмим нигәдер, фәлсәфә саттым:

— Уннарча кешеләр тормышы белән кызыксынасың икән — яңа дуслар тап, йөзләрчә тормыш дисәң — сәяхәт ит, театр-кино юлында бул, меңнәрчә тормыш кызыксындырса — әдәбият укы!

— Килешерлек сүзләр,— диде Одик ботинкасына кунган тузанны фил колагына охшаган әрекмән яфрагы белән сөртеп.

— Әмма мин,— диде ул авыл ягына карап,— йөзләрчә реаль кешеләр белән кызыксынам. Авылым... Шөн кешеләре белән... Премияне тигез бүлү турында сүзне дәвам итәргә кирәк. Югыйсә Хакның рухы рәнҗер...

Ул кинәт миңа таба борылды да йөземә текәлеп карап, кискен генә сорап куйды:

— Сез ничек уйлыйсыз?

— Риза! Килешәм. Әмма дөреслекне табу — авыр булыр.

— Рәхмәт... Мин ялгышмаганмын икән...

Аерылышканда Одик:

— Кайтып йөр! Хак абый үлгәч, миңа һаман нидер җитмәячәк...— диде.

* * *

...Кичкә таба яңгыр яуды. Калай түбәләрдә берөзлексез моңлы итеп биегән яңгыр тамчыларына шомлы итеп күк дөбердәве кушылып китә. Нигәдер бу янгыр миңа матәм маршы булып тоелды.

Матәм маршы — мәңгегә хушлашуның кайгылы көе генә түгел, буыннар алышынуын раслаучы катгый һәм тантаналы аваз бугай. «Без китәбез — сез каласыз...» — Яшәешнең мәңгелеге, тормышның хикмәте шушы сүзләрдә.

Иртә белән дөнья яңа туган сабый кыяфәтендә: чиста, якты, тыныч һәм беркадәр хәлсез иде.

Авылдан китәр алдыннан гына ишеттем: «Хакның бер ел элек кенә кияүгә чыккан кара кашлы, көләч йөзле Рәзилә исемле кызы малай тапкан...»

## Соңгы сүз

Бу кайтуда мин Зөһрә әбидә онытып калдырган яшел тышлы блокнотымны таптым. Блокнот үзе әллә нинди кыйммәтле нәрсә түгел, әмма анда миңа кирәк бер сүз бар иде. Бер сүз... Мин ул сүзне язып куйдым да, соңыннан оныттым...

Бу болай булды. Вятка буенда алма бакчасы турында бәхәс кузгалгач, Гафил Хакка ташланды.

— Нәрсә тапмаксы буласың син? Кеселәрне борсыйсың, урыннарыннан кусьгатып йөрисең... Нәрсә иресьмәксе буласың син?! Нәрсьсә кирәк сиңа?

— Исабәт,— диде Хак.

— Нәрсь-сьә???

Гафил аңа чит ил кешесенә караган кебек итеп бакты.

— Нәрсә шул менә! — дип сөйләп китте Хак.— Нәрсә? — дибез... Ә үзебез кирәкле бер сүзне белмибез. Тирән мәгънәле иске сүзне оныттык. Ә үзебез бу турыда көн-төн, көн-төн сөйлибез...

Шуннан соң ул миңа бу сүзне без икебез генә беләбез дигәндәй күз кысты, яратып карады.

Кызганычка каршы... дөресен әйткәндә, оятыма каршы, йөз меңләгән сүзләр диңгезендә бер иске көймә булып йөзгән ул сүзне белми идем шул мин. Ә Хакның әйтүенә караганда, үзебез шул турыда көн-төн... көн-төн сөйлибез икән.

Алар кармакларын карарга киткәч, мин урлап яшерелгән бер пачка акча чыгарган кебек, читләре юешләнә башлаган яшел тышлы блокнотымны тартып алып, як-ягыма карангач, әлеге сүзне язып куйдым һәм астына өч сызык сызып, сүзлектән карарга дип билге ясадым.

«Ярый-ярый! — диде миңа ул вакыт эчке бер горур һәм кырыс тавыш.— Бу сүз — барыбер минеке булачак!»

Менә хәзер шул яшел блокнотымны (анда язылган әлеге сүзне!) табуыма чиксез сөенеп, үземне бәхетле саный идем...

Бәхет дигәч тә...

— Сеф, сесь үсегесне бәхетле дип саныйсызмы? — дип сораган иде Гафил миннән. Ник алай сорады ул, аңлый алмадым. Бәхет дигән төшенчәгә минем ничек каравымны беләсе килде микән. Бәлки ул үзен бәхетсез, бик бәхетсез итеп сизгәндер. Ни генә димә, билетсыз акча җыеп кино күрсәткәне өчен, аны эшеннән алдылар. (Соңыннан ул Үзбәкстанга китеп барды). Ул: «Чыннан да билетлар сатылып бетте, ә кино Һиндстанныкы — халык ташу урынына агыла, саттым инде...» — дип акланды. Әмма районнан шул көнне контролерлар килеп төшкән.

Нәрсә соң ул бәхет? Иң зур шатлыкмы? Шатлыклар җыелмасымы?

Хак әйтмешли, без дөньяга тууыбыз белән дә бәхетле! Туган кеше — бер тапкыр бәхетле инде ул. Мин дөньяга тудым — шулай булгач, бәхетле! Мин сау-сәламәт, таза булуым белән дә бәхетле...

Якты кояш нурларына коенып, күкрәкләрне тутырып саф һава сулап, җир өстендә атлап йөрибез икән;

Гүзәл төсләргә кергән салават күперен һәм нәфис чәчәкләрне күрәбез икән;

Дусларыбызның һәм яраткан кешебезнең якын һәм назлы тавышларын ишетәбез икән —

Бәхетле без! Ифрат бәхетле!!

Бер уйлаганда, бәхетле булу өчен күп тә кирәк түгел... Әмма... аз кирәк дип тә булмый...

Эштән ләззәт табу — бәхет! Бу инде иске сүз...

Өстән яңгыр коймасынга, кышын-көзен суык тимәсенгә, кайтып керергә, арыгач яисә кич булгач, ятып йоклар бүлмәм яисә йортым (баш өстемдә түбәм!) бар икән — бәхетле мин!

— «Әти!» дип яратыр балаларым, «Ирем!» дип сөеп дәшер хатыным бар икән — бәхетле мин!

Мин яшәвем белән дә бәхетле! Үлгән әйбәт кешедән исән алама кеше яшәве белән бәхетлерәк... Шулай дигән бугай борынгылар...

Вятка буенда балык тотып, яр буенда учак яккан килеш, чиләктә уха пешүен көтеп ятканда, бәхетсез идеммени мин?!.

Йөз иллешәр грамм «Российская»ны «под уху салып куеп», бер кулда агач кашык, икенчесендә икмәк тотып капкалап алырга үрелгәндә һәм пешкән ризыкка — «Шәп! Бик шәп!» билгесе белдергәндә бәхетсез идеммени мин?!..

Адәм баласына күпме кирәк соң?!.

Гомумән, кешене бәхетле итәргә дә, бәхетсез итәргә дә күп кирәкми.

Кешене кеше егет итә, кирәк — егып китә һәм эт итә. Бигрәк тә хәзерге чорда...

Якын дусларымны югалту, ышанып йөргән кешемнең сатуы — бәхетсез иттеләр мине... Берничә елга картайттылар...

Дөньяң бер кителә башламасын, китек кителүне сорый. Эшеңдә туган бәхетсезлек семьяда чатаклык тудыра, семья чатаклыгы сәламәтлеккә бәрә, ә начар сәламәтлекнең кая алып баруы һәркемгә мәгълүм, аның юлы бер генә...

Ә бит тугач — яшисе килә! Озак итеп, яшьлекне күргән кебек, ир уртасы чоры — гомер җәеңне, шатлык димәсәләр дә, картлыкны — гомер кышын күрәсе килә. Килсеннәр — без аңарга да әзер. Яшәргә без — һәрвакыт әзер! Бәлки туйганчы яшәп тә булмас, барыбер озаграк һәм... матуррак!.. яшисе килә... Чөнки мәңгелеккә киткәннәр кайтмый, ул юлның капкасы безнең якка таба ачылмый. Моны тагы бер мәртәбә Хак раслады...

Чакырып хат язса да, вакытында — ул исән чагында кайта алмадым!..

Гаепләме мин? Нәрсәдә минем гаебем?..

Җавап таба алмыйм... Күрәсең, күңелгә мәңгелек яра, гомерлек әрнүгазап булыр инде бу... Якты дөньяда күзем йомганчы тынычлану булмас инде миңа хәзер...

Алай дисәң, яшәгәндә кем генә тынычланып калды икән... һәм... калыр микән?!

Ә нигә үкенү? Ник үземне җәзалыйм әле мин?!

Бүген мин яшимен икән, димәк, кичә начар яшәмәгәнмен, әгәр иртәгә дә яшим икән, димәк бүген яхшы яшәгәнмен... Ә инде киләчәктә дә яшәргә теләсәм, иртәгә тагы да яхшырак яшәргә кирәк булыр! Диалектика законы: кичә бүген өчен, бүген иртәгә өчен искерә, чөнки дөньяда бер генә нәрсә дә мәңгелек түгел, хәтта вакыт үзе дә картая, ягъни алга барган саен, аны үлчәү берәмлеге булган секундлар, минутлар, көннәр, атналар, айлар, еллар, гасырлар саны арта бара.

Кешеләр киләләр дә китәләр... Кемдер алдан... Кемдер соңрак... Кемнәрдер озак тора... Кемнәрдер тиз китә...

Кемдер вакытсыз үлгән, кайгы кичергән, авырлыклар күргән икән...

Без — исәннәр, бәхетлеләр, җиңел һәм рәхәт яшәүчеләр аның алдында гаепле...

Чөнки безнең яшәү аның үлеме өстендә, бәхет — аның өлешенә кергән, җиңел һәм рәхәт тормыш дигән тәти сарай аның газаплары нигезенә салынган...

...Без кешеләр киләбез дә китәбез... Безнең арттан шул ук елгалар агып кала, шул ук болытлар яңгыр булып ява. Шул ук эссе яисә салкын җилләр исә. Шул ук кырлар-болыннар, таулар-үзәннәр. Шул ук Җир, шул ук Кояш, йолдызлар...

Дөнья шулай булган һәм булачак та!—

Шулай дигән акыл иясе.

Һәр нәрсәне тигезләп була, әмма кеше белән кешене тигезләү өчен үлчәү юк һәм булмас та!—

Шулай дигән кемдер...

Хикмәт аларның дөресме, түгелме икәнлегендә түгел, хакыйкать — алар икесе дә кешеләргә тормыштагы һәр нәрсә белән ризалашырга, ягъни тынычланырга... чакыралар. Бернишләп булмый! диләр. Тынычланырга... Тынычланырга кирәк... диләр.

Әмма кешенең бөеклеге дә шунда яши икән, ул тынычлана белми, нәрсәдер эзли, ә ул нәрсәдер дигәннәре бер сүз белән атаганда: **Исабәт — Сүз белән Эш тәңгәллеге! Сүздә һәм Эштә дөреслеккә ирешү. Хакыйкатькә омтылу...** Гадирәк әйткәндә — Кыекны Турылау...

Миллион еллар элек адәм баласы җанына менә нинди орлык салынган. Шул орлык аны маймылдан кеше итеп үстергән, көлдән гөл иткән! Әмма ул гөл чәнечкеле! Ул гөл кара чәчәк тә ата...

Кыекны турылау авыр, хакыйкатькә ирешү — булмастай күк. Бу юлда меңнәрчә газаплар, корбаннар һәм җинаятьләр.

Юлыбыз — кыек... Сүзебез — кыек... Эшебез — кыек икән... Шулай булгач — турыларга кирәк...

Инде килеп, барысына күз йомып, колагыңны томалап тынычланырга да була.

Әмма якты дөньяда яшәгәндә тынычланырга мөмкинме соң?

Тынычлану — үлем бит ул...

Ә без яшибез әле!

Без — яшибез...

*Түбән Шөн — Казан,*
*1978—1980.*

# ДАҺИЛЫК ДӘГЪВАЛАМЫЙЧА ГЫНА



*Шамил Маннапов — инде күптән танылган шагыйрь. Аның иҗатын беренче чорыннан ук күзәтә барырга тырыштым. Телдән фикерләремне әйтә дә килдем. Ә менә матбугат аша моңарчы сүз әйтергә туры килмәгән икән.*

*Дистәләрчә китаплары басылган. Алар хакында мәкаләләр эзләдем. Ләкин алар, иҗаты белән чагыштырганда, шактый аз булып чыкты. Шуның сәбәпләре хакында уйлана калдым.*

*Еш кына шулай була бит, бер нәрсә укыйсың, икенче нәрсә хакында уйлыйсың. Менә тагын шулай килеп чыкты, Ш. Маннапов китапларын укыганда, еракта калган хәлләр искә төште. Алар, гүяки, яңадан кабатлана. Һәй-лә, әз үзгәрә икән бу тормыш. Югыйсә, илдә, дәверебездә нинди генә үзгәртеп корулар булмаган бит инде!*

*1950 еллар башы иде. Безне — яшь авторларны — Язучылар союзы идарәсенә «Үсү юлы» альманахын тикшерүгә багышланган утырышка чакырдылар. Ул чактагы әйдәп баручы, олы әдипләр белән сөйләшеп утырабыз. М. Әмир, Ш. Маннур, С. Хәким, Ә. Фәйзи шунда. Г. Иделле, Ә. Давыдов шунда. Һәркайсы альманахка бәйләп, үз сүзен әйтә. Минем өчен иң гыйбрәтлесе һәм онытылмый торганы Әхмәт ага Фәйзи сүзләре булды. Шигырьләр хакында гомумән сөйләгәндә, ул үзенә карата:*

*— Минем лирик шигырьләрем тәнкыйть тарафыннан яклау тапмады. Шуңа күрә иҗатымда лирика үсә алмады,— дип, сәеррәк сүз әйтеп куйды.*

*Чынлап та гаҗәпләнмәслек түгел бит. Бу — Ә. Фәйзинең әдәбиятта иң зур популярлыкка ирешкән чагы. Шигырьләре, поэмалары сәхнәдән дә, радио аша да гел яңгырап тора. Тукайга багышланган пьесасы һәм бигрәк тә романы телдән төшми. Ә ул әнә үзенең эшләреннән канәгать түгел. Аның лирикасына игътибар җитмәгән. Әгәр җиткән булса, бу жанрда да уңышлар зуррак буласы икән.*

*Гаҗәеп нәрсә икән бит ул игътибар дигән нәмәрсә. Нинди зур әдипләргә карата җитмәгән ул. Элек шулай булган. Һәм хәзер дә шулай дәвам итә икән. Бу хәлне мин, гомер буе дигәндәй, тоеп, белеп яшәдем. Ш. Маннапов китапларын кулга алгач, шул хакта тагын уйланмыйча булдыра алмадым.*

*Шамил Маннапов шигырьләре матбугатта 1960 еллар башында күренә башлый. Беренче шигырьләре «Дуслык» исемле күмәк китапта басылган. Басмада урын алган авторларга хәерле юл теләп, яшьләргә ихлас ярдәм итүчеләрнең берсе булган Зыя Мансур сүз башы язган.*

*Шуннан соң яшь шагыйрьнең «Яшьтәшләрем» исемле беренче мөстәкыйль җыентыгы дөнья күргән. Нигездә, якты хисләр уята торган лирик шигырьләр. Арадан берсе — «Солдатта булган, диләр» исемле.*

*«Хәят көндәлеге» дип аталган чираттагы китап. Хисам Камалов үзенең сүз башында яшь авторның сабыр холыклы, киң күңелле кеше булуына игътибар иткән, тормышта артык кайнарланып китмәвен һәм шигырьләрдә дә шул холкы саклануын күрсәтеп үткән. Шагыйрьнең бөтен иҗатында дәвам итәчәк үзенчәлеген аның беренче әсәрләреннән үк күрә алган сүз башы авторы. «Әдәбиятта һәр әсәрнең тормыш фактларына нигезләнгән булуы мәҗбүри нәрсә»,— ди Х. Камалов һәм,— «Яшь шагыйрь бу кагыйдәне бозмый»,— дип өсти.*

*Китап арты китаплар чыга, дистәләрчә җыентыклар. Күләмнәре арта, сыйфатлары камилләшә, жанрлары байый бара. Шигырьләргә «Әти урманы» дип аталган проза китабы өстәлә. Гади, җир кешеләре турындагы уйланулары, туган*

*җир, икмәк кадере һәм әлбәттә инде, дуслык, мәхәббәт кичерешләре. Болар кешелеклелек, тугрылык төшенчәләре белән бәйле рәвештә тасвир ителәләр.*

*Хикәяләрнең исемнәрен генә кара син: «Тәмле куллы апа», «Су тәме», «Моң», «Суга ыргытылган ташлар», «Ике гашыйк һәм убырлы карчык» һ. б. һ. б. Әсәрләрнең барысы да авторның, шагыйрь җанлы булуы белән бергә, җентекле прозаик карашына да ия икәнлеген күрсәтәләр. Һәм, табигый булганча, аның иҗаты, шушыннан соң киңәеп, ике юнәлештә үсә, тирәнәя бара.*

*Шигъри әсәрләр һаман активрак языла һәм басылып чыга тора. Арада минем игътибарны ныграк җәлеп иткәне «Тамырлар» җыентыгы булды. Монда инде шагыйрьнең язу рәвеше, күзгә күренерлек дәрәҗәдә ачыклана, формалашып җитә һәм тематикасы киңәя. Төзүчеләр, игенчеләр, солдатлар турындагы лирик һәм фәлсәфи уйланулар, тәгаен тормыш вакыйгалары аша сурәткә күчә. Лирик кичерешләр белән эпик тасвирлар чиратлашуы шагыйрьнең төп үзенчәлеге булып әверелә. Аларны үз вакытында күрү дәлиле буларак, китапның бер данәсенең минем искәрмәләр белән чуарланган булуын әйтәсем килә. Хәзер, шул искәрмәләрне яңадан карап чыккач, моннан чирек гасыр элек ясалган тамгалар үзем өчен кызыклы тоелды.*

*Китап өч төрле мәзһәптә язылган әсәрләрдән — лирик, эпик, публицистик шигырьләрдән тора.*

*Җыентыкка исем биргән «Тамырлар» дигән шигырь лирик әсәрләрнең төп яңгырашын билгеләгән. Шул хакта карандаш белән минем искәрмәләр теркәлгән. Хәзер шуларны кабатлыйм.*

*Лирик уйлану. Дөньяны тирәнрәк аңларга кирәклеге турында. Тормышның барлык мәгънәләре күзгә күренеп бетә алмый бит. Аларның тирәнгәрәк яшеренгәннәре дә байтак. Шигырь күңелнең һәм тормышның шундый тирән мәгънәләрен тоярга, күрергә, уйланырга кирәклеген искә төшерә.*

Күзем төште бүген
Давылдан соң
Актарылып чыккан тамырларга...

*Актарылып чыкканчы, нишләптер, игътибар ителмәгән. Хәзер алар, шуңа күрә, рәнҗиләрдер кебек. Чөнки өскә генә карап, илтифатсыз йөргәч, аларга абынып тәпиләр канаган. Күккә талпынсалар да, агачларның ныклыгы — аста, тамырларда.*

Җилләр өзгән яфрак бер моңланса,
Һәрбер яфрак өчен сыкрый тамыр.
Ул җир белән серен уртаклаша,
Шуның өчен Җирдәй сабыр дадыр.

*Алдарак без телгә алган сабырлык үзен сиздерә килә. Янәшәлек кануны буенча баштa төрле уйлар туа. Күренеш кенә түгел, бу — фикер, тоем, кичереш. Дөрес рәвешләрдә ачылган тоемлаулар туган туфракка нигезләнгән, шул җирлектә шытып үскән. Икенче бер шигырьдә сагыну дигән төшенчә авылның үзе төсле булып күз алдына китерелә.*

*Күпме шагыйрьләр тарафыннан күпме тапкырлар кабатланган яшьлек темасы. Инде яңа сүз табылмас та кебек. Ләкин Шамил тапкан андый сүзне.*

Яшьлек нәрсә? —
Дәрт очкыны кабынган чак,
Таңре итеп бер рәсемгә табынган чак,
Гомереңдә тәүге тапкыр абынган чак,
Ә шулай да гомер буе сагынган чак.

*Табышлар. Мәгълүм хәлләрдә шагыйрь үзе генә күргән ачышлар. Алар бу китапта шактый күп.*

*Эпик шигырьләр арасында уңышларны тагын да күбрәк күргәнмен. Шуларның берсендә гаилә яңа фатирга күчкәч булган кызыклы хәл тасвир ителә. Хуҗаларның монда бер танышы да юк һәм тиз генә таныша да алмыйлар икән. Әмма аларның кечкенә кызлары бар — Миләүшә исемле. Ул урамга уйнарга чыга һәм тиз арада, үзе кебек үк балалар белән танышып, шуларны өйгә ияртеп керә. Озак та үтмәстән, ул балалар үзләренең әти-әниләре белән дә таныштыралар. Шигырь шулай тәмамлана:*

Ял иттеме, хәзер бездә
Кеше өзелми көнозын.
И, күпме дусны арттырдың,
Бик рәхмәт инде, кызым.

*Балачак белән өлкәнлек, яшәү белән үлем — бер тирәдә. Әнә бит, «Каберлектә» исемле шигырьдә чардуганнар бала караваты төсле булып күренә. Моны күз алдына китергәч, ямансу булып китә. Ләкин якында гына яңа сурәт. Төзүчеләр сала башлаган йортның күршесендә, иске өй түбәсендә, краннан күз алмыйча, песи карап тора. Кран астан кирпеч күтәреп менгезгән мәлдә, песи, чалкан ятып, авыз ачып, тәпиләре белән шуңа үрелә. Ә кранчы кыз, җепкә бәйләп песи уйнаткан чагын хәтерләп, елмая...*

*Китапта авыл тормышын күз алдына китерә алырлык, халыкчан сурәтләр күп. Авыл кешеләренең үз сүзләре, үз уйлары тасвирлана аларда. Гади дә, кызыклы да. Кайбер очракларда, афористик фикерләр булып формалашалар.*

*Публицистик шигырьләр арасында мин мондый кызыклы фикерләрне күп таба алмаганмын. Бу төр әсәрләрне бик өнәп бетерә алмавым сәбәпледер. Гәрчә аларны да инкарь итеп булмый, алары да озак димәсәк тә, яшәргә хаклыдыр.*

*Ул чакларда эпик шигырьләрнең дә дәрәҗәсе әллә ни югары түгел иде. Эпик сурәтне тасвирчылык чире белән бутау таралган иде. Лирик шигырьдә тасвирламалар, табигыйдер ки, күп була алмый. Ләкин икенче чиккә тайпылу, тасвирны гел тискәре билге белән генә тамгалауны да тулысынча яклау кыен. Ә тәнкыйтьтә тасвирчылык төшенчәсе әйбәт сурәтләрне инкарь итергә дә җай калдыра иде. Без монысын да күрә килдек.*

*Ләкин чынлыкта эпик шигырь тасвирсыз була димени? Бит күп очракларда нәкъ менә шул тасвир әсәрне озын гомерле итә. Фикер (лирик фикер) искерсә дә, сурәт үзгәрми. Әгәр дөрес сурәт булса. Тагын шунысы бар, хәтта лирик шигырь дә бит сурәтсез һәм бөтенләй үк сюжетсыз була алмый. Фикер һәм хис үсеше тасвир аша матдиләшә. Шушы хәлне танымау шигъри практикада шактый гына зыян китерә килде. Нәтиҗә буларак, декларатив фикерләүләр, ә күп очракларда сәбәпсез хыялланулар өстенлек итә башлады. Бу чирнең әле дә узганы юк, дияр идем.*

*Җыйнап әйткәндә, «Тамырлар» китабында сиземләнгән өч юнәлеш — лирик, эпик, публицистик юнәлешләр берлеге алдагы иҗат барышында автор стилен, сурәтләү үзенчәлеген һәм шигъри мохитен барлыкка китерде. Әмма әлеге дә баягы, тәнкыйть моны күрә алмаган. Минем күргәннәрем дә китап битләренә карандаш белән ясалган аерым тамгалар рәвешендә генә калган. Хәзер кулдан ычкынган форсатны кире кайтарырга тырышып каравым...*

*Игътибар җитмәүгә карамастан, иҗат барыбер үсә. Күтәрелеп бәрелмәгән Шамил, сабырлыгын җуймаган. Үз көченә ышанган кешеләр шулай һәр хәлдә дә үзе булып кала ала.*

*1987 елда чыккан «Апрель авазы» җыентыгын шагыйрьнең күпъеллык иҗатына йомгак ясау дип карарга мөмкин. Анда да искә алынган өч юнәлеш дәвам итә. Яңача ачылган күренеш дип, юмор рухында язылган шигырьләрне санарга була. Җыр текстлары булып әверелгән шигырьләрнең күбәя төшүен дә искә алырга кирәк, әлбәттә.*

*Эфирда беренче булып яңгыраган «Солдатта булган, диләр» исемле шигырь әүвәл яшьләр газетасында басыла. Аңа композитор шуннан күреп музыка яза. Беренче уңыш башкаларына рухландыра. Моннан соң Сара апа Садыйкова язган «Керфегеңә тамармын мин», Җ. Фәйзинең «Яшьлек дусларыма», Б. Мөлековның «Кичермәсләр» исемле җырларын ишеттек. Ә Р. Яхинның «Рәхмәт сиңа» җырын Зөһрә Сәхәбиева композитордан үзе сорап яздырган икән. Соңгы вакытта Ш. Маннапов «Алпарым» дигән шигырь язды.*

Үзе җырлап тора сыман
Алпарым ла, Алпарым.
Чирмешәнең болынында
Көткән идем атларың.
Алпарым ла, Алпарым,
Бик сагынган чакларым.
Синең атың белән кичтем
Тормышның сиратларын.

*Шигырьгә Луиза Батыр-Болгари музыка язып, аны Әлки егете Мирсәет Сөнгатуллин башкарды. Кайчандыр мәктәбендә укыган авылны зурлау — үзе бер зур бәхеттер ул.*

*Ш. Маннапов әдәби иҗатын журналистлык эше белән, гомер буе дигәндәй, бергә алып барды. Йөзләрчә мәкаләләре басыла килде һәм басыла тора.*

*Күренгәнчә, аның мәкаләләренә шигърият нык ярдәм итә. Мәсәлән, дисәк, С. Хәкимнең «Гел кояшка карый тәрәзәләрең» исемле шигырен искә алырга мөмкин. Арча яклары турындагы очеркка журналист «Тәрәзәләр кояшка карый» дигән баш куйган һәм эчтәлегендә шул образдан файдаланган.*

*Мәгълүм чорда бер хуҗалыкның комсомол оешмасы эшчәнлеген күрсәтеп, «Юлдагы борчаклар» исемле мәкалә язганда да, шигъри фикер ярдәмгә килә. Ошбу комсомол оешмасы башкарган «эшләр» борчак сибү генә булып (ягъни буш сүз булып) кына калганлыгы шигъри детальләр аша бик ачык күзаллана.*

*Блокнотларга журналист язмалары буларак теркәлгән детальләрнең кайберләре шигырьгә әверелә.*

*Шагыйрьнең журналист сыйфатында язылган публицистик хезмәтләре «Ачы какылар» дигән шактый зур күләмле китапка тупланган. Андагы очерклар, мәкаләләр һәм истәлекләр язучының җәмәгать эшлеклесе икәнлеген дә күрсәтеп, аның иҗади офыкларын тагын да киңәйтеп җибәрә.*

*Проза жанрындагы тәҗрибәләре уңышлы дәвам итә. Вакытлы матбугатта чыга килгән кечкенә лирик хикәяләрен, шулай ук мәзәкләрен яратып укый идем. Әмма соңгы вакытта «Казан» китапханәсе сериясендә басылган «Шамил Маннап (Шаман) мәзәкләре» минем өчен яшен яктысы кебек ялтырап киткән күңелле бер ачыш булды.*

*Китапның «Зыялыларыбыз турында мәзәкләр» дигән бүлегендә башлыча язучылар хакындагы кызыклы хәлләр урын алган. Елмаймыйча уку мөмкин түгел. Бәлки кемнәрнеңдер чырае бозылып та куйгалыйдыр. Әмма нишлисең, көзгегә үпкәләү акыллылык галәмәте була алмый. Булганны яза Шамил, дөресен яза.*

*«Хуҗа Насретдинның яңа мәзәкләре» миңа бигрәк тә әйбәт тәэсир итте. Халык телендә кабатлана торган мәзәкләрне үзенчә (һәм, бәлки, Гомәр ага Бәшировча) эшкәртеп, халыкның үзенә кайтарып бирә Шамил. Халык мәзәкләрен гомере буе җыйный, туплый килгән Гомәр ага күзенә чалынды микән бу мәзәкләр? Әгәр күргән булса, өлкән язучыбыз моның өчен Шамилгә рәхмәт әйтми калмас иде, диясе килә. Моңа ышанычым шуның өчен нык ки, чөнки остазыбыз шушындыйрак рәхмәтне башка очракта әйткән икән инде. Быел гына «Сабантуй газетендә Ш. Маннаповның «Мәхәббәт имән кебек» исемле мәкаләсендә шундый хәбәр басылган. «Тукайлык яки даһилык дәгъвә итмичә, «мыштым» гына бик һәйбәт шигырьләр язып ятасың бит, әй! Һәммәсе дә бик кирәк, һәммәсендә дә үз фикерең бар, барысы да рәхмәткә лаек»,— ди Гомәр агабыз Шамил Маннаповка.*

*Мин дә, бу сүзләргә: «һәм Тукташлыкка дәгъва белдермичә»,— дип өстәгәч, булган хезмәтләрен тәкъдир кылып һәм булачак яңа уңышларына ышанып, шагыйрь һәм прозаик Шамил Маннаповка, түгәрәк юбилее уңае белән, ихлас котлавымны җиткерәм.*

**Әхсән БАЯНОВ.**

## Шамил Маннап

### ДӘРЬЯ ЙӨРӘГЕ

* * *

*Дәрья дулкыннары Әлмисактан бирле*
*Килә һаман ярга табынып.*
*Кыя-ярга мәңге кагалырлык*
*Дулкыннарда нинди сабырлык?!.*

Әй, кыяга кага дулкыннар!
Кагыла да кире чигенә.
Горур тора кыя, кымшанмый,
Исе китмәгәндәй һичнигә.

Ник кымшансын,
Йомшак урыннар
Инде күптән юып алынган.
Хәзер аңа куркыныч түгел
Хәтта тугыз баллы давыллар.

Чал кыяга кага дулкыннар,
Кагыла да кире чигенә.
Кыя бит ул — дәрья йөрәге,
Кагылуларга, йөрәк, түз генә...

* * *

Дулкынланмый тормый дәрья,
Иделемдә дулкын купкан.
Ишелеп килә дә чигенә...
Ярда ятып кала чүп-чар.

Чүп-чар гына түгел, ярда
Суы кала, көче кала.
Үз дәрьясын пакьләндергән
Дулкыннарның эзе кала.

Дулкынланмый тормый дәрья,
Дулкынлана Иделем дә.
Каккан саен дулкыннарның
Көче кими... күңелемдә.

* * *

Истәлеккә диеп, һәркөн килеп,
Ташлар җыям дәрья ярыннан.
Ул ташларны дулкын-кулы белән,
«Ал!» — дигәндәй, сибә алдыма.
Чуерташлар төрле,
Кайберләре
Йөрәк кебек. Гаҗәп: таш йөрәк...
Каян килгән, кайсы төпкелләрдән?
Инде ята ярда ялтырап.

Әллә диңгез шулай кемнәрнеңдер
Таш йөрәген аткан чыгарып?
Таш бәгырьле була күрмәгез, дип,
Әйтүеме әллә бу аның?
Әллә озак еллар яр-кыяның
Хисләренә җавап бирмәве
Кимсеткән дә, аны илерткән дә,—
Таш иткәнме дәрья йөрәген?

Нидер булган, булган...
Тик сүнмәсә,
Сүнми икән өмет-теләкләр.
Учка алган идем, әй пешерә! —
Кайнар икән әле йөрәкләр...

## Янган саен өмет яңара...

* * *

Мин сөйгәннәр мине сөймәделәр,
Нинди язмыш, нинди хикмәттер:
Җаным кебек күрдем бер матурны,
Ә ул... күрмәгәнем күрсәтте...
Көнләшүләр белән җаным кыйнап,
Балалардан соңра аерды,
Мәхәббәтнең күкләрендә очкан
Канатымны минем каерды.

Яратуы кыен, тик кыенрак
Үзең яратылмау хәлләре.
Моңа карап ләкин сакламадым
Күңелемдә үчлек хәнҗәре.

Мине сөйгән әнием, туган ягым,
Сезне уйлап һаман юанам.
Сабырлык вә киң холкыгыз миңа
Ваз кичәргә бирми дөньядан...
Сезнең кебек мин дә
Ташлап киткәннәргә
Хәерле юл теләп каламын,
Кинә тотмыйм,
Килгән чакларында
Каш җимерми каршы аламын.

Корыган агачларга сайрар кошлар
Кунмаганын беләм, шуңарга
Мин Ходайга сыенам,
Җанымны шул
Иман нуры белән сугара...
Шулай булмаганда,
Көтмә дә син
Җәбраилдән вәхи килерен.

Сөймәсәләр мине сөймәсеннәр,
Өмет тамырымны өзмәсеннәр,—
Гашыйк булып узсын гомерем...

* * *

Яшьлегемдә күзем нурландырып,
И Мәхәббәт, миңа килгән идең,
Икебезгә уртак булсын диеп,
Бер матурга сине биргән идем.

Кичермәдең шуннанниләр генә,
Хассынмады сиңа кемнәр генә,
Бирешмәдең, кыю көрәштең син
Шик, Ялганнар, Салкын сүзләр белән.

Үги итте сине кырыс Тормыш,
Син гакылсыз, син хыялый имеш!
Яшәү өчен миңа булыштың гел,
Үзеңә дә бик-бик кыен килеш.

Йөрәгемә килеп сыендың да,
Алга очтык икәү хыял-атта...
Ә бер төндә кинәт юлыктык без
Агулы ук тоткан Хыянәткә.

Ул юлбасар җәясен нык тартты,
Агулы угын сиңа төбәп атты.
Аһ, капларга өлгералмый калдым —
Күкрәгеңнән кайнар каның акты.

Каһкаһәләп көлде Хыянәт һәм
Юкка чыкты төннең карасында!
Елый-елый яраң бәйләдем дә
Салдым сине җаным парәсенә.

Син терелдең янә,
Нинди бәхет!
Нурландырып моңсу күзләремне.
Мәхәббәтем, сине моннан ары
Ышанычсыз кулга бирмәм инде.

* * *

Авыл очына гына төшкән кебек
күренә иде чите офыкның,
Яшьлегемдә шуңа житәргә, дип,
Орынып карарга, дип кызыктым.

Бәхетем дә
синең зәңгәр күзләреңә генә
торган кебек иде сыенып.
Шулай якын тоелганга микән,
юл чыгарга житте кыюлык.

Ләкин барган саен офыкның да
ерагая барды чикләре.
Инде беләм: анда ирешү өчен
адәм гомеренең житмәвен.

Алдансам да, бизеп-суынмадым,
яратуым калды тормышка.
Әле дә сихри зәңгәр күзләр нуры
чакыра төсле ерак офыктан...

Шул хыялый нурлар миңа — канат,
Сират күперләрен узганда.
Рәхмәт сиңа, чиксез зәңгәр офык,
Рәхмәт, зәңгәр күзле кыз бала...

* * *

Хәрәмләштең, Тормыш, хәрәмләштең,—
Бар мөлкәтем синең кулыңда.
Миңа һаман вак-төякне биреп,
Күбрәк алу булды уеңда.
«Болар шиңмәс!..» — диеп, ясалмага
Алыштырдың
Күңлемдәге күпме гөлемне.
Аh, ул гөлләр табигыйләр иде,
Булмаса да озын гомерле.

Мин Зөһрәмне эзләп барган чакта
Очраттың да Маһи кызыңа,
Тышаулаттың атым болыныңа,
Көрәш кылычым калды кынында.

«Һәрбер бәндә — каршылыклар иле,
Чикне бозма, кертмә һәм үзең!..» —
Атыңны да болай онытырсың,—
Уйлар белән калсаң ялгызың...

Хәрәмләштең, Тормыш!
Күрәсеңме,
Ни бирдең дә, үзең ни алдың?

«Иң мөһимен саклап калдың, бала,
Кешеләргә булган ышанычың,
Бабаңнардан калган иманың...»

## Көзгә кергәндә

Эндәшмисең,
Арадагы тынлык
Озыная-ерагая кебек.
Җылы якка оча, әнә кошлар,
Шулар белән китә җәйге өмет.

Син карыйсың миңа,
Күзләреңдә
Сызылып киткән киек казлар юлы.
Син телисең бугай китеп барган
Шул кошларны юлдан туктатуны.

Җылы җәйләребез узып бара,
Алар миңа бик кадерле, иркәм.—
Кошлар белән узган гомеркәйне
Җибәрмәскә мөмкин булса икән!

Җылы җәйләремне яраттың да,
Яратырсың микән көзләремне?

Эндәшмисең...
Ә мин күрәм — шул ук
Сорау тулы яшьле күзләреңне...

* * *

Көзләр моңсу никтер,
күзләр дымсу,—
Син карыйсың миңа борчылып.
«Көз шикелле хисең суынудан
Түгелме, дип, синең моңсулык?»

Көзләр җиткәч, мин сагындым әле
Артта калган матур язларны,
Язда калган яшьлек дусларымны,
Сандугачлы алсу таңнарны.

Гомер җәйләремдә күз нурларым
Түгеп үстерелгән уңышның
Көткәнемчә булмавыннан микән,
Кырларыма карап боектым.

Уңыш җыю болай күңелле дә,
Моңландыра гомер узуы.
«Нинди булыр алда кышлар?..» — диеп,
Уйга батып, уелып торуым.

Көзләр моңсу шуңа,
Күзләр дымсу...
Тик борчылма, дустым, моңарга.
Саксыз сүзең, хаксыз үпкә белән
Кагыла күрмә ялгыш кылларга.

Борчылма син, хисем суынудан
Түгел минем көзгә моңсулык.
Көзгә кырда яшел уҗым шыткан,
Күңелемдә килә җыр туып...

* * *

Гөнаһлылар өчен ахирәттә
була, диләр, тәмуг газабы.
Ә мин ул газапның нindилеген
бу дөньяда татып аңладым.

Нинди генә гөнаһларым өчен
салдың икән мондый ялкынга?
Гыйшык утларында януларым
аз тоелды микәнни сиңа?

Янам-янам, гаҗәп: үлмим үзем,
янган йөрәк кабат яңара,
кабат яна...

Сиңа булган яратуым гына
янган саен һаман азая.
Яратуым кими барган саен,
кими сыман көче ялкынның.
Ялкын кимегән саен,
йөрәгемә
иңә сыман гүрләр салкыны...

Сөюемне яшерәм тирәнгәрәк,—
мин янарга инде өйрәндем!
Ялкыныңа күнеккән дә идем,
салкыныңа ничек түзәрмен?!

Янып бетмә, гыйшкым!
Ризамын мин
тәмугыңда мәңге янарга.
Ни дисәң дә, мин бит яшим әле,—
янган саен
Өмет яңара...

* * *

Бер җылы сүз кешегә җитә, диләр,—
Җылы сүз ул кешегә күп кирәк.

Бер йотым су кешегә җитә, диләр,—
Кешегә чишмә, елга, күл кирәк.

Бер аршын җир кешегә җитә, диләр,—
Юк, кешегә бөтен Җир кирәк.

Күпсенмәгез,
Аңа — башкаларга
Дәрья ясау өчен күл кирәк,
Кешелеккә Галәм яулау өчен
Кешегә бит бөтен Җир кирәк.

Шул эшләрне башкарганда, кешегә
Җылы сүз — бер түгел,
Гел кирәк.





**Альберт Хәсәнов**

# БАЛЫКЧЫ МАҖАРАЛАРЫ

хикәя

Елга портына Фаяз иртәнге сәгать өчкә үк төшеп җитте. Ул дусты Гомәр өйрәткәнчә эш итте. Башта Казан белән Шеланга арасында йөри торган су трамваеның беренче рейсына билет алды. Аннары, аның бәхетеннәндер инде, таң тишегеннән ачылган киоскка кереп, йөри-йөри таушала төшкән күн портфеленә дүрт шешә хәмер алып тыкты. Фаяз, күбрәк булмагае, дип уйлаган иде дә, соңрак таман гына булыр әле, дигән карарга килде. Ахирәте, Кутыр Борын Гомәр, аңа алларына «Пшеничная» дигән ак алъяпкыч япкан «Бөгелмә киленнәрен» җитәрлек итеп алырга кушкан иде. Майсыз кашык авызны ерта, дигәндәй, «нәкъ менә шул «Бөгелмә киленнәре» эшне җайга салырга» тиешләр дә иде инде.

Дөрес, сәфәренең уңасына, Бохар сәүдәгәре кебек баеп кайтасына Фаяз күңеленнән бик үк ышанып та җитми җитүен. Әмма, өметсез — шайтан, диләр бит. Бәлки Ходайның амин дигән чагына туры килер әле...

Су трамваена утырган чакта Фаяз, әллә йокысы ачылып җитмәгәнгәме, әллә тумыштан төс-кыяфәте шулай идеме — кысык күзле, усал йөзле бөтен килеш-килбәте белән карт диңгез бүресенә тартым трап төбендә билетләр тикшереп торучы егеткә игътибар итте. Әллә вакыт тапмаганга, әллә башка берәр сәбәптән, кимендә ике-өч көн рәттән кырынмаган бу матрос, әллә кай җире, әллә нинди килеш-килбәте белән, Фаязның күңелендә өмет уятты. Аңа шушы трамвай белән Шеланга пристанена кадәр төшеп, артельчеләр башлыгы Чингачгукны табарга кирәк иде. Гомәр шулай өйрәтте. Ярар, менеп тә җитте, ди. Парольне дә белә, портфеле дә буш түгел. Ләкин Чингачгук — Идел апачилары башлыгы — аны гына көтеп утырмаска да мөмкин ич. Ә менә бу матрос егет биредәге обстановканы белә булыр. Алар бу калага көненә ничәмә-ничә менеп төшәләр ләбаса. Бу карсак белән ничек тә сөйләшеп китәргә иде. Ләкин ничек? Каян сүз башларга? «О-о, Фаязетдин, бу синмени әле, ни йомышлар белән йөреш, сиңа Чингачгукның үзе кирәк иде мени?», — дип каршыңа килеп утырмас ич инде гомердә беренче тапкыр күргән кеше. Ул да булмады, матрос калын табанлы ботинкалары белән трамвайның тимер идәненә тыпыр-тыпыр ике такт чечетка бәреп, аска, машина бүлегенә төшеп китте. Болай булгач, сөйләштең инде, тот капчыгын-

ны, бодаен читкә акмасын, дип Фаяз үзен орышып алды. «Кыюлык юк синдә, энем. Егет холкында бик тә кирәкле бу сыйфатны үзеңдә булдырырга җыенмыйсың да».

Матрос егет аста озак югалып тормады. Бу юлы ул кояшта шактый уңа төшкән җиңсез тельняшкадан иде. Фаяз ирексездән аның чуендай янган тәненә, беләк һәм күкрәгендәге татуировкаларга игътибар итте. Бу карсак матрос бик «фырт» егет булырга охшый, ахрысы, порт-пристань тирәләрендә аларны күпләп очратырга була, Муромда хәрби хезмәттә булып, туган якларына ялга кайткан вакытларында Фаязга андый гайяр егетләр белән шактый якыннан танышырга туры килде.

Күңелләренә үтеп керә белсәң, алар сине рәнҗетмиләр, җәберләмиләр. Ач булсаң, туендыралар. Ялангач булсаң, киендерәләр. Милиция эзләсә, яшерәләр. Юлыңа акчаң булмаса да курыкма: әллә нинди юлларын табып, сине парахутка алып керәләр, капитаннан яшереп булса да барасы җиреңә дә илтеп җиткерәләр. Әмма тәртибе шундый — син үзең дә егет була белергә тиешсең. Кирәк икән, ышанычыңны югалтсаң, алар синең арт ягыңа тибәргә дә күп сорап тормыйлар.

Үзенә карата кызыксынучан, игътибарлы карашны матрос та сизенде, ахрысы, «Йомыш-гозереңбулса, тот та әйт, озынга сузма», дигәндәй Фаязга табан мәгънәле генә карап куйды. Сүзгә алай артык җор телле булмаса да, Фаяз да төшеп калганнардан түгел — үзәктән куу насосларын ремонтлау цехында аны юкка гына «академик» дип йөртмиләр ләбаса. Аннары ир-атны таныштыра торган бер шәп ысул да бар бит әле.

— Яшьти, карале, синең берәр савыт-мазарың юкмы, бераздан кайтарырмын,— диде ул күптәнге танышына эндәшкәндәй итеп.— Әллә нәрсә шунда, тамак кипшенеп тора...

Матрос шуны гына көтеп торгандай, бердән телгә килде:

— Найдем!!! Табабыз аны!!! — дип, эшлекле кыяфәт белән тимер баскычтан аскы палубага төшеп китте һәм, башы белән ишарәләп, Фаязга үзе артыннан ияреpгә кушты.

Алар кечерәк кенә бер кубрикка килеп керделәр. Ул, канәгатьләнү хисе белән:

— Минем апартамент шушы була инде. Рәхим итегез,— дип көтелмәгән кунагын түргә узырга чакырды.

Матрос егет аңа утыргычы да, таянычлары да тимер рәшәткәдән эшләнгән тимер эскәмиядән урын күрсәтте, аннары стенага уеп эшләнгән тимер капкачлы бер шкафтан шактый ук дөнья күргән алюмин кружка чыгарды. Фаяз да югалып калмады, портфелендәге бер «Бөгелмә киленe»нең муеныннан гына эләктереп алды да өстәлгә китереп утыртты. Шул ук тимер шкафтан кипкән балык башы да килеп чыккач, Фаяз шешә бөкесен теше белән генә ачып, кружкага кул яссуы кадәр аракы агызды. Бүлүче башлап эчәргә тиеш, дигән гадәт буенча, кружканы кулына алды.

— Әйдә, туган, танышу хөрмәтенә тотып куйыйк булмаса. Минем исемем Фаяз була.

Аннары чират хуҗа кешегә җитте һәм ул шешәгә үрелде:

— Тотасыңдыр ич, бераз гына!

— Ярамый да инде аңсы. Эштә бит. Начальство күрсә...

— Чүт кенә.

— Бик кыстасаң... Сал алайса... Күп тамызма...

Тулыр-тулмас кружканы түмен белеп кенә кабып куйганнан соң, карсак матрос кул аркасы белән авызын сөртеп куйды. Шифа суының сихәте тәнгә таралсын дигәндәй, киерелеп алды. Сигарет кабызды.

— Өстимме? — диде Фаяз.— Тагын чүт кенә...

— Не-не!

Матрос, нидер исенә төшкәндәй кинәт кенә урыныннан кузгалып, әлеге дә баягы теге тимер шкафны ачты һәм вәкарь белән генә сөйләп китте:

— Ошаткан кешеңә бит аңа җаның да җәл түгел... Иделдә балык тотуның самай тыелган чагы, югыйсә... Балыклар уылдык чәчә...

Ул бераз тын торды.

— Әйдә, угощайся әле. Ошаса, тагын табарбыз. Ахирәт гамәле түгел.

— Монымы?! Яратмаска соң,— дип, Фаязның күңеленә җылы йөгерде. Ул чөлкә хәтле балык кисәген кулына алды, башта, телен тидергәнче, озаклап иснәп торды, аннары гына:— Үзеннән бигрәк исе тәмле, каһәрнең,— дип тәмләп ашарга кереште.

Менә хәзер, шушы рәвешчә бер-береңә «верительный грамота»лар тапшырганнан соң, бер-береңә карата ышаныч тугач, йола буенча сүзне матрос башларга тиеш иде һәм алар, адәм балаларына хас булганча, стандарттан читкә чыкмадылар. Төбенә өч-дүрт йотым хәмер салынган кружканы кулына алгач, матрос:

— Рәхмәт туган!—диде.— Бажай телевизор алгание. Кичә шуны куеп маташкан идек. Иртән торсам, башко бобо! Әйбәт булып китте әле. Үзең соң, кай таба китеп барыш соң?

— Анысын әле... тәгаен генә үзем дә белмим...

Фаяз елмаеп куйды.

— Сәфәр кыласың, ызначит.

— Сәфәр дип. Чингачгукны күрәсе барие.

Әллә «Бөгелмә килене»нең тәэсире тиде, әллә матросыбыз үз халәтенә кайтып төште — ул урысчага күчте:

— А-а, знаю я Чингачгука, Фазылку Гараева! Мировой парень. Кто его на Волге не знает! — Матрос канәгатьләнү хисе белән бармакларын шартлатып куйды:— Ничек инде белмәскә! Да, свой парень, в доску! А тебе он зачем? Вовла кирәк что-ли?

— Әйе шул, бер-өч килограммнар чамасы кирәгие шул. Туй төшерергә җыена идек. «Өстәл бизәргә дә ярап куя, закускага да әйбәт. Теләсәң каян табып кайт», дип хатын чыгарды мине бу сәфәргә. Дусишләр Чингачгук дигән бер егетнең координатларын да биргәннәрие.

— Ул чакта, сиңа Чингачгук нигә хаҗәт? Анда хәтле тагын ике сәгать менәсе бар. Ә балык әнә, Иске Морквашта да навалом.

— Наваломдыр да бит. Адресын белмәгәч, аны сиңа кем табып бирә?

— Нигә бирмәскә дә, нигә белмәскә! Мин үзем җибәрәм сине аңа,— дип, матрос йонлач күкрәгенә сугып куйды.— Анда бит... дебаркадерщик булып... минем служак Кеннеди Второй эшли...

— Кем дисең?

— Сашка Зверевны әйтәм. Фамилиясе генә Зверев аның, үзе болай поп песие ул. Юаш егет. Танышкач күрерсең әле, Кеннединың төгәл копиясе. Бер анадан тусалар да алай ук охшамаслар. Шуңа күрә аны Иделдә барсы да Кеннеди Второй дип йөртәләр. Менә аңа үзеңне миннән — Мишка Богатыревтан, диярсең. Шул җиткән. Бар гозереңне дә үтәр.

— Тыңлармы соң? Вакыты бит, әнә, нинди. Үзегез әйтмешли, балыкның уылдык чәчкән чагы!

— Мин әйткәчме?! Тыңламый карасын. Если что, аның белән будет другой разговор; разговор по душам будет, раз по шею, два по ушам.— Богатырев канәгатьләнү белән кеткелдәп көлеп алды, Фаязның иңбашына кулын салды.— Борчылма! Эшләр. Балыгы бар аның. Теге балыкны да ул биргәние. Кичә генәсе. Бүген дә табар. Бер дә шикләнмә. Ә Чингачгук янына төшеп тә торма. Без төшеп менеп җиткәнче, син инде кипкән балык тулы капчыгыңны җилкәңә салып, астан менә торган трамвайга эләгеп, күптән Казанда булырсың. Мин бит сиңа чынлап торып әйтәм.

— Күндерден,— диде Фаяз.— Калам, алай булгач.

Ул арада трамвай Иске Морквашка килеп тә җитте. Мишка Богатырев аркан сүтәргә кереште:— Әзерлән! — дип ымлады. Төшәргә булды Фаяз. Карсак матрос Мишка Богатырев бик ышанырлык итеп сөйли бит.

Әгәр Кеннеди Второйда балык булмаса да, ул соң нәрсә югалта? Әле бит Чингачгук варианты кала. Шушы ук трамвай белән ул сәфәрен дәвам итә ала. Дубльләрнең булуы космоска очканда гына түгел, көндәлек тормышта да комачау итми ул.

Юлчыларның байтагы төенчек-янчыкларын элэктереп, трап төбенә килеп басты. Алар артыннан ашыкмый гына Фаяз да дебаркадерга чыкты. Аларны башына колакчынсыз бүрек-кубанка, өстенә җилдә-кояшта уңган брезент җилән кигән зур гына гәүдәле ир уртасы каршы алды. Кеннеди Второй шушы булырга тиеш инде. Әмма бу ирнең Кеннеди Первый белән мыскал да охшашлыгы юк. Фаяз аның белән шулай аяк өсте генә сөйләшеп китәргә кыймады. Трамвайдан төшкән халыкның бераз тарала төшкәнен көтте. Дебаркадерщик янына аннары гына килеп һәм бик серле итеп:

— Мин — Мишка Богатыревтан, сез Кеннеди Второй буласыздыр инде? — диде.

— Мин — Челкаш, — диде дебаркадерщик бер дә исе китмәгәндәй. — Ә Кеннеди Второй беренче трамвай белән үк Казанга тешен алдырырга китте. Аның урынына мин калдым.

— Абау?!! Каһәр генә төшсен! Ничек инде? Мин бит...

Фаяз һушына килеп, кире трамвайга таба йөгерде. Ул инде кузгалып маташа, дебаркадердан бер адым чамасы аерылган иде. Шунда йөгереп килгән хутка сикерәсе генә иде. Юк, курыкты. Яшь чагы түгел бит.

Шопыр-шупыр тизлеген арттырып, трамвай бөтенләй ерагайды. Ә Богатырев ике кулын колакларына куеп, мин ишетмим, берни дә аңламыйм, дигән сымак ишарә генә ясады.

Аһ, каһәр! Аһ, шайтан! Инде нишләргә? Фаяз читлеккә эләккән җанвар төсле, дебаркадер буйлап әрле-бирле йөренергә кереште. Бу Челкашы кем инде тагын? Берсе — Чингачгук, икенчесе — Кеннеди Второй. Монысы тагын Челкаш. Бер җүнле кеше юк ахыры монда. Җыен жулик оясы бу Идел. Фаязның чын ачуы купты, астына ут яккан казан кебек кайный башлады. Дебаркадерның көтү залында берьюлы егерме-утыз кешегә аш пешерерлек зур плитә көйләнгән, мич дөрләп тора. Хәзер исә тын гына пристань хезмәтен үтәгән бу дебаркадер, заманында зур гына баржа булгандыр, күрәсең. Хезмәт «срогын» тутыргач, ягъни «пенсиягә чыккач», елгачылар аннан пристань ясап, чын мәгънәсендә комга утырткаnнар. Менә шушы мич тә әнә шул заманнардан калган булырга тиеш. Ә Челкаш үз мәшәкатьләре беләнме, бер ара югалып торды. Тыштан бер кочак такта-токта кисәкләре күтәреп керде, мичкә утын өстәде. Зур алюминий бак алдына тезләнеп, изүләренә агыза-агыза су эчте. Тагын да дәрт белән дөрләп киткән мичтән күмер алып, тәмәке кабызды. Эченә суырган төтеннең мыскалын да әрәм-шәрәм итәргә теләмәгәндәй, тирән итеп махрасын суырырга кереште.

Фаяз тагын бер мәртәбә тәвәккәллек кылып, аның каршына килеп басты.

— Сез шәт, шаяртмагансыздыр бит инде?

— Башка белән шаяртсалар да, теш сызлау белән белмим кем генә шаяртыр икән?

— Аһ, каһәр! Ничек кенә кире килеп тора бит. Ярык тагарак алдында утырдым да калдым.

Дебаркадерщик, калсаң, калгансың инде, ә мин монда причем дигән кыяфәттә, бастырык юанлыгы махрасын көйрәтә бирде.

— Безнең Кеннеди Второй, Сашка Зверевны әйтәм, сиңа нәрсәгә кирәк иде соң? Сер булмаса?

— Нәрсәгә дип? — Фаяз бу сорауга җавап табалмагандай дәшми торды. — Дөресен генә әйткәндә, миңа сезнең ул Кеннедиегезнең пычагыма да кирәге юк. Минем аны, күргәнем дә юк. Шулай да...

Әлеге дебаркадерщик үз гомерендә байтак кеше күргән булырга тиеш. Фаязны башта сабыр гына тыңлап торды. Аннары гына:

— Нигә инде шулай кырт кисәсез? Сашка Зверев мировой егет. Күрсәгез, исегез китәр иде. Ул бит баритон тавышлы. Шушы дебаркадерга басып җырлап җибәрсә, аны бөтен Моркваш, Ослан таулары тын калып тыңлый. Аның матур тавышы, үзе җырлаудан туктагач та, әнә теге тау битләрендә озак вакыт яңгырап тора.

— Анысы шулаен шулайдыр,— дип бүлдерде Фаяз хуҗаны.— Мине бу очракта аның җырчы булуы кызыксындырмый иде шул.

— Теләсә, бүген алалар аны Казанга, театрда җырларга. Үзе бармый.

— Нигә бармый соң? Алкашмыни?

— Нигә алкаш булсын? Синнән-миннән әзрәк эчә ул. По семейным и сердечным обстоятельствам бармый.

Челкаш төпчеген мичкә ташлады, җилән җиңен өскә сыпырып сәгатенә карады.

Аннары әдәп саклап кына:

— Үзегез соң кем буласыз? — диде.

— Минме? Мин Кулибин! Ишеткәнең барыемы?

— Екатерина патша заманында яшәгән, каз күкәе эченә сәгать ясаган оста турында укыган бар ансы. Аны бит мәктәптә үк укыталар. Ә мин тарихтан гел яхшы билгеләргә генә укыдым. Тарихи китапларны хәзер дә яратам. Ял йортының китапханәсе бай. Тарихи китапларны шуннан алып, монда дежурга да алып киләм.

— Ә мин Кулибин Второй. Үзәктән куу насослары буенча белгеч. Үз гомеремдә барлыгы сигез ачыш ясадым. Шуларның җидесенә хәтта уйлап табучы таныклыгым бар.

— Зур кеше икәнсез! — диде Челкаш, бу сүзләренә ихтирам мәгънәсе салып.— Безнең авылда да бер Кулибин бар. Кулибин Өченче була инде алайса. Электр үтүгеннән алып, тегү машинасы, мотоцикл, суыткыч, телефон, телевизор дисеңме — барын ул төзәтә.

— Әмма минем кем булуымның монда мыскал да әһәмияте юк. Минем бик зур җитешсезлегем бар. Мин патологик төстә балык яратучы. Мин, шикләнә күрмә, шпик та, ОБХСС агенты да түгел, балык ашарга ярату белән чирләгән бер авыру. Менә паспортым, менә рационализаторлык таныклыгым. Болар өстенә мин түм-түгәрәк ахмак та әле. Богатырев дигән лилипутыгызның сүзенә ышанып, әйбәт кенә барган трамваемнан төшеп калдым. Хәзер менә кая барырга инде?

— Тагын ике сәгать ярымнарсыз булмас әле. Бүген бит дүшәмбе. Якшәмбе көнне эшләгән күп экипажлар бүген ялда.

— Чәнчелеп кенә киткән икән! Йә, Ходай, нишләргә хәзер миңа? Мин бит кыргыйлар утравына эләккән Робинзон хәлендә.

Фаяз тагын бер кат дебаркадерны әйләнеп килде. Шунда кырт итеп исенә портфелендәге хәзинәсе төште.

— Стаканың, яисә берәр кружкаң юкмы?

— Табарбыз.

Янган йөрәккә тагын да ут өстәп башта үзе тотып куйды.

— Бераз гына тотасыңмы?

— Ярамый. Эш урыны бит.

— Чүт кенә. Авыз чылатырлык кына.

— Сал алайса. Берүк күп тамызма. Өстән төшеп килүче трамвай унбиш минуттан монда булачак. Миңа тәртиптә булырга кирәк.

— Һәй, таптың шүрләр нәрсә! Бу бит үгез каны гына.

— Үгез каны да, ә борынны барыбер кызарта. Борының кызыл булса, йөзеңне кызартырга күп буяу кирәкми аннары...

— Тыңлап торам, философ син,— диде Фаяз.

— Урыны шул бит. Саф һава, Идел киңлеге. Күне буена башка күптәрле гыйбрәтле уйлар килә. Кайчак үземә үзем хәйран калам.

Шул рәвешчә әңгәмә корып, араларны якынайтып җибәргәч, Челкаш кунагы алдына тәмле исләр таратып буы күтәрелеп торган бер кәстрүл балык шулпасы китереп куйды. Шулпасыннан түгел, исеннән үк башың

әйләнеп, һуштан язып китешле. Хуҗа җилән итәге белән генә себереп, өстәлгә ике агач кашык, ике телем ипи куйды. Ә кәстрүлдә эре кисәкле судак калҗалары йөзә. Кыстаганны да көтмәде Фаяз, балык шулпасын чөмерергә кереште. Челкаш аны кызыксынып күзәтеп торды да:

— Балык шулпасына мин үзем дә тәкатьсез,— дип куйды.— Су буенда яшәгәч, яшерен-батырын түгел, беребез дә балыксыз тормыйбыз. Тыйсалар да, кисәтсәләр дә, тик тормыйбыз инде.

— Шулай булгач соң! Зинһар, бераз өлеш чыгара алмыйсыңмы? Акчасыннан тормабыз, килешербез, дип уйлыйм.

— Эш акчада түгел лә. Күрәм ич инде нинди егет икәнеңне.

— Әллә мин әйтәм, тагын бераз авыз чылатып куябызмы?

— Юк, юк, туган, син мине бөтенләй дөрес аңламадың. Син минем болай да тупой башка шешә белән бәрергә тырышма. Эш башкада. Миңа постны бер минутка да калдырырга ярамый. Ә безнең поселок моннан алты чакрымнар чамасында, урман эчендә.

— Табам мин аны! — дип бүлдерде аны Фаяз, ашыгып.— Өйрәт кенә. Алты чакрым җир минем өчен ярты сәгатьлек юл ул. Армиядә чакта, маршка чыксак, взвод командиры мине, солдатларның эченә кату чыгарасың, дип иң артка бастыра иде.

— Бәлки өен табарсың да, ышанам,— дип килеште Челкаш.— Ләкин балыгын табалмассың.— Өйдә кеше юк минем. Хатын иртән иртүк, ике баланы да алып, әнисе янына өен сыларга төшеп китте.

— Аһ, чурт! — диде Фаяз.— Һаман аркылыга урталай килеп тора.

— Чурт шул! Хатын авырга узып йөри. Бу икесе кыз минем. Өченчесе малай, картлык көндә безне карарлык терәк булмасмы, дигән идек. Тегеләрен ничек күтәргәнен сизми дә калган иде. Ә бу юлы ризык талымлый. Сорамаган нәрсәсе калмады инде. Татып кына карый да, барып укшый. Аннары кинәттән генә, кипкән балык ашыйсым килә, диде. Тыелган чагы булса да булыр, әнә теге якка чыгып җәтмә салып карадым. Шунда аларның оялары. Бик хәсиятләп кенә киптердем. Телеңне йотышлы чыкты. Хуш исле үләннәргә төреп киптердем мин аларны.

— Сөйләмә бүтән! — дип туктатты аны Фаяз — Барысы да кыпкызыл уылдыклымы?

— Уылдыклы булмыйча! Алар әле уылдык чәчәргә керештеләр генә. Кипкән балыкка мин үзем дә тәкатьсез, дип әйттем бит инде. Аңлыйм мин сине. Шушы портфелеңне тутырып биргән булыр идем дә бит.

Кешенең хәленә керешле, ипле генә егет булырга ошый бу Челкаш, дип уйлап алды Фаяз. Каян китереп такканнар диген үзенә бу кушаматны. Горькийның хикәясендәге таныш образ — «Челкаш» бит!

— Кушаматыңны әйтәм, матур бит — диде Фаяз, балык турында урынсызга фантазия куертудан туеп.

— Ә безнең монда кушаматсыз бер матрос та юк. Әллә каян гына табып, маңгаена пәч иттереп ябып куялар. Аннары, кушаматсыз да булмый. Сашка-Пашкаларыңны әйтим, алар Идел уртасында утырган маяклар төсле, атлаган саен, поди разберись.

— Максим Горькийның «Челкаш» исемле хикәясе бик шәп бит.

— Минем укыганым юк. Мин «Человек и закон» журналын гына алам.

Юк, теләсә нинди әтрәк-әләм булмаска тиеш бу Челкаш дигәнең. Шуны раслагандай, ул тирән уйга чумып утырган Фаяз җилкәсенә кулын салды.

— Годок! — Әйе, алар яшьләре буенча бер тирә булырга тиешләр.— Сине бит никак буш кул белән кайтарып җибәреп булмый. Шулай ич?

— Әлбәттә инде. Күкне тартып төшерепме, әллә җирне урталай ярыпмы.

— Моннан өч чакырымнар гына аста маякчы Архип дигән берәү яши,— диде Челкаш зур сер чишкәндәй.— Балык анда да бар. Капчыгы белән. Ләкин, белмим, телен таба алырсыңмы. Хәйләкәр, шома койрык-

лы кеше. Алай да менеп кара. Әле синең вакытың бар. Соңгы трамвай Казанга кичке дүртләрдә генә була. Аңарчы син анда әле ике менеп төшәргә өлгерәсең. Мин әйтте дип, телеңнән ычкындыра күрмә. Бик нәфесле, әйтәм ич, хәйләкәр карт.

— Минме?! — дип сукты күкрәгенә Фаяз. — Син белмисең әле мине, мин бит чын дипломат. Бәхәс чыкканда мине генә дәшсеннәр, чынлап торып керешсәмме, бер-берсенә каршы ут ачкан ике дәүләтне мамикт татулаштыра алам. Һәй-й, Челкаш дускай, годок, мине белмисең әле син!

Фаяз портфелен кулына алды.

— Ярар, кузгалдым алайса. Теге маякчы картны аскы якта диденме әле? Кушаматы ничек дидең каһәрнең?

— Винни Пух. Бәләкәй генә, чатан аяклы булыр. Стоп! Стоп! — дип туктатты аны Челкаш. — Болай гына булмый. Ул синнән шикләнәчәк. ОБХСС кешесе дип уйлар. Балык тотуның тыелган чагы бит. Мондый чорда Идел ярында кем йөрмәс тә, ишегеңне кем шакымас.

— Ә нишләргә соң? Шикләнә-нитә калса, паспортымны күрсәтермен. Балык дигәндә тәмам тәкатен җуйган бер фәкыйрьмен, диярмен.

— Хәзер, хәзер! Бер генә минут, — дип Челкаш дебаркадерның бирге башындагы кечерәк кенә чоланны ачты. Аннан матрос бушлаты, козырегы бераз янчелә төшкән, елгачылар кия торган фуражка алып чыкты.

— Эшләпәңне, җиләнеңне сал да, менә шуларны ки. Штиблетларыңны калдыр. Бераз зуррак булса да менә кирза итекне ки. Галстугыңны да сал, изү төймәләреңне ычкындыр. Безнең Иделдә изүне кышкы кырык градуслы суыкларда да төймәләмиләр. Юкса, авторитетың төшәр.

Челкаш аны тагын бер кат күзеннән кичерде. Үзенчә канәгать калды, ахры — бармак буыннарын шартлатып куйды.

— Менә хәзер син нәфесе чыннан да кипкән балыкка төшкән кешегә ошый төшәсең. Алай да Винни Пухның күзе бик җитә аның. Сөйләшкәндә сак бул, итәгеңне җыеп сөйләш.

Челкаш аның кулына бер брезент капчык кисәге тоттырды.

— Ә менә монысы инде миннән, — дип, бушлат кесәсенә бер акбаш тыкты. — Бик кирәк булуы бар. Шушы зәхмәтне күрсәтми торып, бездә берәүнең дә теле ачылмый. Ләкин өстәлгә чыгарып куярга ашыкма. Бәясен түләгәч, авызын чылатмасаң да түзәр. Әмма күзен яндырып торсын.

Болар өстенә Челкаш ике кап «Астра» сигареты да сузды.

— Винни Пух Идел буендагы сараннарның берсе. Тартырына беркайчан булмас. Көймәң комга терәлә башласа, киерелеп берне пыскытып җибәрерсең. Сигаретыңа шундук кулын сузачак. Һәр йозакның, годок, үз ачкычы! — Челкаш Фаяз җилкәсенә шап итеп сугып куйды. — Әйдә, смело атлый тор. Сәгать дүртләргә әйләнергә тырыш. Соңгы «Москвич»ка өлгермәсәң, бүген башка транспорт юк.

— Тагын шуны хәтерлә, — дип туктатты ул Фаязны. — Пристаньнән төшкәч, урман эченә таба чокырлы-чакырлы бер юл булыр. Анысы белән китмә, шул юлдан уңга таба кечерәк кенә бер сукмак керә. Аны табуы җиңел. Сукмак башында квартал баганасы булыр. «Урман эчендә ут белән сак булыгыз!» дигән кисәтүле такта да күрерсең. Һич тә икеләнмичә менә шул сукмак белән атла. Карт каенлыктан берәр чакрым атлагач, асылмалы күпер аша чыгарсың. Димәк, годок, Винни Пухның өенә таба атлыйсың.

Фаяз Челкаш өйрәткәнчә атлады. Тиздән биек яр башына килеп чыкты. Аста, күз күреме хәтле җирдә, Идел чайкала. Ниндидер бер серле бию башкаргандай акчарлаклар тирбәлә. Бик еракта, су өсте күзгесе зәңгәр күк белән кушылган чиктә, томан пәрдәсен ертып ап-пак парахутлар күренә. Аста, шау чәчәккә күмелеп утырган култыкта маякчы өне — субайлар өстенә утыртып салынган матур гына йорт күренде. «Һи-и, иренмәгән кешегә кытлык юк икән» дип уйлады Фаяз. Аның моңа кадәр дә печән төяп Иделне урталай ярып баручы көймәләрне күргәне бар иде.

Каян чаптылар икән бу тикле печәнне дип аптырый торган иде ул. Сыер-бозау тоткан хуҗалар печәнне менә шушындый култыклардан чабып хәстәрли торганнардыр инде.

Ярдан түбән таба ун адым да атларга өлгермәгәндер, Фаязны эт көтүе чорнап алды. Шунда әллә каян гына этләргә:

— Пушал, пушал! — дип, кулындагы таягы белән кизәнеп, башына бүрек, өстенә сырган куфайка кигән, йөзен-битен сакал-мыек баскан чатан аяклы бер агай килеп чыкты. — Пушал, әрәмтамаклар!.. Шуннан, ни йомыш?

Фаяз да югалып калмады.

— Бу кай тирәләр соң, хөрмәтлем? — диде.

— Ә сиңа кай тирәләр кирәк?

— Минем Дубровкадан Морквашка төшеп барышым иде.

— Ялгышкансың бит. Бу Галимнәр дачасы.

— Менә сиңа мә! Кая килеп чыкканмын бит. Ә Морквaш моннан еракмы соң?

— Елга яры буйлап кына төшәсең, ерак түгел. Күп булса, ике чакырымнар булыр.

— Алай да әллә ни ерак китмәгәнмен икән әле.

Фаяз кесәсеннән сигарет чыгарды. Каршында яткан каен бүрәнәсе өстенә чүгеп тартып җибәрде. Сигарет кабын бүрәнә өстенә куйды. Карт та, рөхсәт сорап, сигарет кабына үрелде. Фаяз аңа сынаулы караш ташлады, әмма дәшмәде. Шулай шактый тын утырганнан соң гына:

— Сез соң үзегез монда кем буласыз? — дигән булды Фаяз, гәрчә хуҗаның кем булуын бер карауда таныса да. — Каравылчы-мазармы?

— Каравылчы да, маякларны да карап торам, — диде карт горурлык белән. Янәсе, бел, без алай төшеп калганнардан түгел.

— Әнә теге дачаларны әйтәм әле, ай-һай купшыдан, җәһәт корганнар.

— Аларның хуҗалары кемнәр икәнен беләсеңме соң? Кәттә егетләр. Сузарлык хутың булганда, аягыңны нигә бөтен буеңа сузып яшәмәскә? Фани дөньяда бер генә яшибез бит!

— Анысы шулай-й, хак сүз сөйлисең, — диде Фаяз, агайның фәлсәфәсе белән килешеп. Ләкин аның уе башкада иде.

— Дубровка кибетеннән кыстырганыем. Юлда кирәге чыгар әле дип. Дәртең булса, тотыйк бирәрне.

— Нигә монда. Өйгә керик, кыяр яки суган кисәге дә табылыр, — диде агай, кинәттән генә ачылып китеп. Ул бер аягына әз генә аксаклап, балык җәтмәләре элгән читән кырыеннан, җыйнак кына өйгә таба атлады. Фаяз да аның артыннан иярде. Балта-пычкыны кайсы башыннан тотарга икәнен бик яхшы белгән кул белән ясалган җыйнак кына баскычтан күтәрелеп өйгә үттеләр.

— Дача йортларының барын да субайлар өстенә куйганнар. Әллә су кергәлиме?

— Елына карап.

— Йортларны, дачаларны әз генә өскәрәк, тау башына күтәребрәк салсалар соң?

— Дача биләмәсе гектар ярым гына. Калганы урман хуҗалыгына керә. Аларның өлешенә бер түтәл дә керә алмыйсың.

Өй эче яккан мунча кебек җылы иде. Керә керешкә Фаязның борынына кипкән балык исе бәрелде. «Балык бар картта!» — дип уйлап алды ул.

— Теләсәң, чәй дә әзер. Түлке гаеп итештән түгел, үлән чәе белән генә сыйлый алам, — диде хуҗа. — Хатын Дубровкага ничә мендe, кибетнең ачык чагын туры китерә алмады.

— Пойдет! Үлән чәе ул, абзыкаем, синең булыр-булмас кибет чәеңне орып бирә. Әйдә, башта чүт кенә тотыйк әле.

Фаяз теләмичә генә, хуҗа исә йотлыгып тоттылар. Тотып куйганнан соң, һәркем үз уй-хисапларын тәртипкә китерә торган тынлык булып алды. Бераздан агай үзе:

— Ә син Дубровкага ни дип төшкәниең соң? — дип сорады.

Фаяз булмады бит анда. Ни дип җавап бирсен! Авыздан хата ычкынмасын тагын. Фаязның анда эз дә басканы юк. Челкаш әйтүе буенча гына ишетеп белә.

— Йомыш төшкәние. Дөнья булгач, була бит инде. — Фаяз кеткелдәп алды. Карт килештерде аның серне ачмавын. Күз кысып, бармак янап алды. Янәсе, шулай кирәк.

— Бөкесен бер ачкач, калганын җиргә түкмәссең ич инде. Тамыз тагын бераз, — диде карт.

— Дубровкага ни дип барып чыгуым билгеле инде, — диде Фаяз үзе дә чүт кенә тотып куйгач. — Бераз гына кипкән балык табып булмасмы дип менгән идем. Гришка Соловьев-разбойникның адресын биргәннәрие. Мендем, ишекләре бикле. Иртән иртүк ат җигеп, бала-чагасын төяп, Шелангага китте, диделәр. Әбисенә китсә, бүген генә кайтмый инде ул, диделәр. Менә йөрим шулай корыны бушка алыштырып. — Фаяз капрон чәшкәләргә тагын бераз тамызды. — Үзегездә юкмы бераз кипкән балык? Миңа күп тә кирәкми. Ике-өч кило инде.

— Тоткан балыгым юк. Тотмыйбыз, — дип кырт кисте хуҗа. — Тыелган чакта! Шуның белән эләгеп Себер китәсебез генә калгание. Без закон кушканча яшәүчеләр. Тотмыйбыз да, кирәге дә юк.

Шул чак ярга, нәкъ өй каршына ук моторлы көймә килеп туктады. Хуҗа сикереп торып тәрәзәне ябып куйды. Ләкин соң иде инде. Моторкадан бер хатын сикереп төште дә, яртылаш суга батырып куйган кәрҗиннәргә балык бушата башлады. Хәрәкәтләре — каракларныкыча. Ялт та йолт як-ягына карана.

— Кәнишне, елгада, дәрья эчендә яшә дә, балыксыз тор, — дип аңлатма бирде хуҗа хатынның гамәленә. — Монысы аның булмаган хәл. Кайда да тоталар. Без тотып кына Иделдә балык кими димени. Балык шундый җан иясе ул, син аны күбрәк тоткан саен ныграк үрчи. Чөнки аңа үрчергә иркен дәрья кирәк... Бушатып бетерсен дә, сиңа да берәр кыздырырлык өлеш чыгарырбыз. Буш җибәрмәбез.

— Миңа тереләре кирәкми. Ни эшлим мин алар белән?

— Кипкәне юк, туган, юк. Киптермибез. Үзебез өчен дип кенә киптергәне барые, кичә күрше лесник сугылды. Малаен армиягә озатам диме шунда, бар булганын кырып-себереп алып китте. Бирмичә дә булмый, гозерең төшүе бар. Аннан алда гына Ялан тау колхозы председателе кеше җибәргәние. Туй төшерә, кызын кияүгә бирә икән. Менә шулай, туган, үзебезгә дип киптергән дүрт-биш корбан балыгы да үзебезгә тәтеми. Канат куйгандай оча баралар...

Картның күзгә карап алдашуына Фаязның ачуы килде.

— Шулай ук бөтенләй юкмыни? Мин бит бушка сорамыйм.

— Юк. Юк булгач, юк инде. Кара, кешегә ышанмый ничек.

Әле яртысы да эчелмәгән шешәне бөкеләп, Фаяз кесәсенә тыгарга җыенды. Калганнары исәннәрме, дигән төсле, портфелен капшап карады. Карт исә ач борча тешләгәндәй кыбырсынып алды. Каядыр барып та килмәкче иде бугай, кире утырды.

— Ярар, юлдагы кешенең юлда булуы хәерле. Юл уңаена берәр уймак кына тамызыйм да кузгалыйм булмаса, — диде Фаяз.

— Соң, утыр әле бераз, сине куган кеше юк бит. Берәрне көйрәтеп алыйк, — диде хуҗа, үзе сул ягына ярыйсы аксаклап мич арасына кереп китте.

— Бай кешенең бит аның иң ярлы чагында ботыннан тотып селексәң, бер уч алтын коелыр, дигәннәр, — хуҗа кет-кет кеткелдәп, өстәлгә үтә күренмәле булып кипкән кызыл канатлар китереп салды. Ачның күзе киштәдә дигәндәй, Фаяз балыкның башын каерып ташлап, аны кабаланып кимерергә әзерләнде. Шулчак өйгә әле генә көймәдән балык бушаткан хатын килеп кермәсенме! Боларга аждаһа төсле усал караш ташлап:

— Тагын алкашлар җыеп утырасыңмы, аксак шайтан! Мич артына тагын бер генә атлап кара, икенче аягыңны да тибеп сындырырмын — дип дуларга керешә.

— Кызма әле син, кызма, сиңайтәм. Алкашлар җыеп утырган кеше юк. Кунагым Гришка Соловьевка балыкка килгән булган. Өйдә туры китерә алмаган. Күп сорамый ул. Әллә, минәйтәм, ике-өч кило гына табабызмы. Акчасы да кирәк бит.

— Грамм да юк. Тотмыйбыз! — өстәлгә яны белән утырган Фаяз күз кырые белән күреп алды: хуҗа хатын иренә бик усал итеп йодрык янады, телеңне тый, янәсе.

Мич башы тулы җепкә тезгән балык булырга тиеш. Тышка элсәң, чебен куна, киптерү технологиясе бозыла, кеше күрә. Әмма хуҗа хатынның шулай күзгә карап алдашуына Фаязның ачуы купты.

— Моннан барын да күреп тордык. М-м, — диде ул, — яр буендагы кәрҗиннәргә күпме балык бушаттың. Бәлки...

— Бушатса соң! Икәүләшеп елга саклап, әллә ач торырбызмы?

— Кхм, кхм! Сезнең монда уңга да сулга балык сатып, спекуляция ясап ятуыгызны тиешле урынга җиткерү берни тормый анысы, — диде. Янәдән күп мәгънәле итеп тамагын кырды: — Әле менә кәрҗиннәргә центнерга якын балык бушаттыгыз. Әнә теге утраулар артында салынган күпме җәтмәләрегез бардыр? Алары әллә кичке ашкамы? Тамак ялгау өчен генә күбрәк түгелме икән?

Боларын ул чамалап кына әйткән иде, әмма юкка атып туры тидергән булып чыкты.

— Бер безнеке генә түгел. Анда, саный башласаң, җәтмәләр җитәрлек. Дегетне юып, балыкны тотып бетерә алмыйсың аны. Балык бет кебек бит ул. Бет сыткан саен, балык тоткан саен үрчи, — диде хуҗа хатын, бу юлы инде мөмкин кадәр йомшаграк тавыш белән. — Инде дөресен әйтим әйтсәм, балыкның самый уйный торган җиренә переметрларны рыбнадзор үзе куя. Безнең ишеләргә балык шулпасының шулпасы гына эләгә.

Фаяз үтемле ым белән:

— Анысын инде следовательгә сөйләрсез, — дип куйды. Ул арада күкне болыт каплап, вак кына яңгыр сибә башлады. Фаязга кузгалырга вакыт иде. Сәгатенә күз салып алды, көрсенеп утырган җиреннән күтәрелде. Әмма аның уйнап-шаярып кына әйткән сүзләре дә хуҗаларны пошаманга салды, күрәсең. Алар мич арасына кереп пышын-пышын килеп алдылар.

— Ипи тотып ант итсәк тә сез ышанмассыз инде, — дип сөйләнә-сөйләнә хуҗа хатын иренең артыннан ияре чыкты. — Балыгыбыз, чыннан да, юк. Була ул, булып тора, ә менә бүген сез нәкъ юк чагына туры килдегез. Бензинның гына бәясен күрегез, чүпрә кебек күперә. Моторларның да бәясе артыннан куып җитешле түгел. Былтыр берне алганыек, тартмый, каһәр, юктан да кыза. Печән өстенә яңасын алырга кирәк. Ә акчасын каян табарга? Әз-мәз тотабыз инде. Киптерәбез. Саткалыйбыз да. Аннан гына Рәсәйнең бүсере асылынып төшмәс.

Хуҗа хатын Фаязга берәр кило чамасы тартышлы төргәк сузды:

— Монысы бездән сезгә күчтәнәч булыр. — Фаяз кулында кәгазь акчалар күргәч, болай дип өстәде: — Юк, юк, нинди сүз ди ул, акчага түгел. Сезгә дә сатмыйбыз. Әйтәм бит, саткан чакларны да шул яңа мотор юнәтү өчен генә тырмашабыз. Идел бит ул очсыз-кырыйсыз. Ишкәк белән генә монда әллә ни майтара алмыйсың. Яңа моторны безгә влачлар бирергә тиеш тә, хәзер бит влачларга да бик ышаныч юк.

Фаязның күчтәнәчне алмый чарасы калмады. Чөнки аны янәдән кысынкы божра белән чорнап алган маэмайлар, «безнең хуҗабикәнең кушканын тыңламасаң, без сине җибәрмәскә дә можем», дигән төсле аңа карап бик усал итеп өреп алдылар. Яңгыр шыбырдарга керешә. Хуҗа да төпчек кабызып, баскыч төбенә чыкты.

— Син хәзер елгадан аерылмаска тырыш,— диде ул корык-карык йөткереп.— Әгәр сукмак сүзен тыңлап эчкә кереп китсәң, адашасың. Елганы сул якта тотып, смело атла. Әнә теге, су эченә кереп торган «әрмән борыны» артында «Авиаторлар» дачасы. Аннан сиңа күп калмый инде. Хәзер төшеп җитәрсең. Мин аксак аяк белән дә бер сәгатьтә кире әйләнеп кайтам.

Фаяз хуҗаларның кунакчыллыгыннан ихлас күңелдән канәгать калуын сиздереп, алар белән җылы саубуллашты. Иделнең бу як яры коточкыч текә иде. Кайбер урыннардан аска карарга куркыныч, аста башың әйләнешле упкын. Күп тә бармады, елга борылышын узуга, аның алдында җәннәт почмагыдай матур култык пәйда булды. Биредә текә яр ышыгына сыендырып, биш-алтылап дача өе бастырып куйганнар. Аскы икесе биек субайлар өстендә. Бер уйласаң, тар, кысынкы шәһәр фатирларыннан соң оҗмахның үзе инде бу. Икенче уйласаң, ни пычагыма кирәк болар. Биредә бит кишер түтәле ясарлык та җир юк. Хәер, бәлкем бу дачаларның хуҗалары кишергә бөтенләй мохтаҗ түгелләрдер.

Әлеге дачаларга сокланып карап торган арада, Фаяз каршына, өстенә башлыклы брезент җилән бөркәнгән бер агай килеп басты.

— Иске Морквашка шушы сукмак җитәклидер инде?— диде Фаяз.

— Шушы, шушы. Итәгеннән эләктерсәң, шап төшеп басарсың. Син үзең кем буласың соң? Мин Алексей Платонович Грознов булам. Җәйге навигация чорында маякчы, ә кышын, бу тирәләрне кар баскач, шушы дачаларны саклыйм.

Платоныч агай ачык йөз белән танышырга кулын сузды.

— Грознов?— дип сорады Фаяз.

— Булмыйча! Безнең бөтен авыл Грознов фамилиясе йөртә. Иван Грозный Казанны алганчы, башта Свияжск каласын төзеткән. Әйләнә тирәдәге авыл мужикларына да үз фамилиясен бирдерткән. Бу турыда сез гомердә ишетмәгән кызык хәлләр сөйли алам. Әйдәгез, өйгә төшик, анда безнең аш та өлгергән, чәй дә кайнап утыра. Мин бит сезне әллә кайчаннан бирле көтәм.

Фаяз бу агайга бик сәерсенеп карап алды. Карт, шуны гына көткәндәй:

— Әйе, әйе, иптәш өлкән следователь. Әйдәгез, әйдә, сез безгә бик тансык, бик кадерле кунак. Безнең сый-хөрмәтне татымыйча торып, мин сезне аяк та атлатмыйм,— диде.

Колакларына ышанмый тора Фаяз: каян килеп ул өлкән следователь булды әле?

— Сез көткән кеше мин түгел, сез ялгышасыз. Мин бернинди следователь түгел.

— Шаяртмагыз, пожалуста. Минем бит сезне беренче генә күрүем түгел. Менә хәзер дә шундук таныдым.

«Монысы үзенә бер сәхифә, маякчы Грознов аны өлкән следователь итеп кабул итте. Әйдә, чурт с ним, бәхәсләшеп торудан ни файда. Ни булса, шул булыр» дип, Фаяз аның артыннан атлады. Хуҗаның пөхтә генә итеп җыештырылган өенә керде.

— Сез, иптәш өлкән следователь, гаеп итмәгез инде. Сезне бик мулдан кубып каршылый алмадым. Үзем генә бит. Без ашау-эчү кирәк-яракларын Иделнең теге ягындагы затонга чыгып алабыз. Хатын иртән иртүк моторка белән шунда чыгып киткән иде, нигәдер соңлады. Бәлкем склад бикледер. Склад мөдире шулай ук Грознов, безнең авылныкы, бер тотынса, атнасы буе эчә. Маякчылар нәрсә ашар дими, амбарын атналар буе ачмый. Әйдәгез, бар булганы өстәлдә, якынрак утырыгыз әле. Үземчә, кулдан килгәнчә тырыштым. Сездәй олы кунаклар бездә сирәк була.

«Хуҗа юкка борчыла»,— дип уйлап алды Фаяз.— Өстәле ризыклардан сыгылып утыра. Балыкның да ниндиен генә куймаган. Нәкъ уртада, кукыраеп, җиде йөз граммлы «Сибирская водка» утыра.

Иртәдән бирле тәгам юньле ризык капмыйча, Фаяз бүре кебек ачыккан иде. Хужага үзенең следователь түгел икәнлеген дә исбатлап торуны кирәксенмәде. Танышу хөрмәтенә, мул сый-нигъмәтле өстәлне зурлап йөз иллешәр грамм каптылар да, ул умырып ашарга кереште. Ә кунакчыл хуҗа аны:

— Менә монысына үрелегез әле, монысын татып карагыз, монысы заливной судак, монысы кабыклы бәрәңге шулпасы парында гына пешерелгән чуртан, ә монысы шыртлака дерелдәвеге,— дип кыстады.

— Ә бит мин сезне инде күптәннән беләм,— дип куйды хуҗа. Фаяз серле елмаеп куюны кирәк тапты. Белә икән белсен, ни дип бәхәсләшеп утырырга. Шушындый бай өстәл артында.

— Теге чакта, поши атучы браконьерларны хөкем иткәндә, судта мин дә катнаштым. Юу-ук, хөкем ителүчеләр арасында түгел, шаһит буларак. Шунда допроска йөргәндә еш күргәләдем мин сезне. Дәрәҗәгез майор төсле хәтерлим. Шулай ич? Кабинетыгызны да хәтерлим, икенче катка менеп, коридор буенча баргач, беренче ишек — миннән сорау алган тикшерүченеке. Ә сезнеке шуннан арысымы, әллә янәшә үкме инде. Тәк ышту, кадерле кунагым, үзегезнең кем булуыгызны миннән яшереп маташмагыз инде.

Фаязның бераз башына да китте.

— Аны нигә яшереп торыйм. Кирәк тә санамыйм. Ләкин белмәгән, күрмәгән кеше алдында мин фәлән кеше дип шапырынырга да яратмыйм,— диде.

Хуҗа үзе дә кызмачаланып килә иде:

— Беләм мин тикшерүчеләрнең бик хәйләкәр булуларын, беләм,— дип дустанә бармак янады.— Без, маякчылар да төшеп калганнардан түгел. Өс-башны дебаркадерда алыштыргансыз да, маякчыларны күзәтеп кайтыйм әле, балыкны артык урламыйлармы, сатып ятмыйлармы, дип белеп, үз күзегез белән күреп кайтырга булгансыз. Һай, хәйләкәр дә кешеләр инде үзегез. Әмма хәйләгез тиз ачылды. Өстегездәге бушлат Челкашныкы бит! Фуражка да аныкы. Бу кыргый култыкта ятып үзебез дә тикшерүчегә әйләнеп бетәбез. Бер күрүдә сиздем хәйләгезне.

Маякчы агай эчкерсез, күңелле генә кеше күренә. Табын бай, күңелле гәп корып утырырга булыр иде. Тагын берәр рюмка капкач, Фаяз кузгалырга кирәк икәнен әйтте. Юкса, ул соңгы трамвайга да өлгермәячәк.

— Аһ, каһәр, аһ каһәр! — дип сукты тезенә кунакчыл хуҗа.— Мариям һаман да кайтып җитми. Юкса, мин сезне моторка белән генә илтеп куйган булыр идем. Теләсәгез, әйдә, ишкәкле көймә белән төшерәм. Әмма алай озаграк булачак. Җитмәсә, Иделдә көчле дулкын, ишкәкле көймәне йомычка урынына уйнатачак.

Маякчы аны озата чыкты. Ни арада тутырып өлгергән: кулында — бер кәгазь капчык кипкән балык:

— Монысы миннән күчтәнәч.

— Алексей Платонович, рәхмәт! Сездә зур кунак булдым. Мин зур бурычлы сезнең алда,— диде Фаяз.

— Нинди сүз ул! — дип бүлдерде аны маякчы.— Шушында көн иткәч, балыксыз торган юк. Үзебез саклагач, үзебез урлаштырабыз да. Йомышың төшкәндә, моннан соң туры үземә кил. Җәйге чорга дача да алырга була. Менә бу хан сараеның хуҗасы бик башлы конструктор икән. Ике җәй күренми инде. Чит илгә киткәнме, диләр. Ә дачасы буш тора. Гаиләгез белән килегез, рәхәтләнеп ял итәрсез. Балыкка да бергә йөрербез.

Алай да бик сәер килеп чыкты әле бу. Шулай итеп, Фаяз прокуратура тикшерүчесе, майор булып китте бит. Ләкин аның бу затонга киләсен маякчы каян белде икән? Шуңа җавап әйткәндәй Алексей Платонович әйтә куйды:

— Бездән өстәге маякчы артыгыздан ук шалтыратты миңа. Миндә Казаннан тикшерүче булды. Бик хәйләкәр, астыртын кеше,— диде.— Яхшы кабул ит, матри аны. Кешечә озат, дип кисәтте.

— Аһ, картлач! — дип елмайды Фаяз.— Үзе әнә нинди хәйләкәр.

Ә яңгыр сибәләвен белә. Аяк аслары чыланып, тайгакланып бара. Фаяз ашыкты. Маякчының монысы да мөмкин хәтле ярга елышырга, сукмакларга алданып урман эченә кермәскә, дип кисәтте. Әмма таулашлары, шунда үсеп утырган каен-имәннәре белән Идел өстенә менә ишеләм, менә ишеләм дип, торган кәҗә сукмагыннан мондый тайгакта түгел, аяк асты коп-коры чакта да бик сак атларга кирәк иде шул.

Яңгыр тагын да көчәйде, тау битенә таба кистереп сибәли генә. Фаяз суга төшкән тавыктай чыланды. Үз гомерендә күпне күргән матрос бушлаты күтәрә алмастай авырайды. Итекләрнең борчак булып бүртүен сөйләп бирешле дә түгел. Әмма Фаязга ашыгырга кирәк. Юкса, трамвайга соңара. Шулчак ул ничек таеп киткәнен дә, кат-кат мәтәлеп аска очканын да сизми калды. Шушы хәлендә ул күпме яткандыр, аңына килсә, билдән су эчендә ята. Терсәк-тез башларына утлы кисәүләр басканнармыни, кызышуларына түзәр хәл юк. Ләкин сынган, имгәнгән җире юк төсле. Башын менә ярыйсы гына бәргән, ахры, ярылырдай булып даң-даң килә. Шунда ул үзеннән ике-өч адым гына суда тирбәлгән капчыгын күреп алды. Әмма үрелеп кенә алышлы түгел. Фаяз ыңгырашып булса да, аякларына басты, таяк кисәге табып алды. Ләкин аның кирәге калмады. Дулкыннар аның белән шаярган төсле капчыкны тагын да эчкәрәк өстерәделәр. Юеш капчык су өстендә озак тирбәлмәде. Фаяз күз алдында әкрен генә төпкә китте.

«Асфальт чире» белән чирләүчеләр төсле йөзен канатып, әс-башын ерттырып, пычракка батып, Фаяз, ниһаять, дебаркадерга кайтып егылды.

— Шулай килеп чыгар әле, шулай булып чыгар, дигән идем аны. Сезне ник кенә ялгыз җибәрүемә үкенә-үкенә яртылаш картайдым,— дип каршылады аны Челкаш. Фаязның чебеш кебек чылануына, шушындый бәлаләргә дучар булуына әйтерсең лә гаепле. Башта җылы су белән юып, аннары кат-кат йод сөртеп, аның кан саркыган җирләрен бәйләде. Коры киемнәр бирде. Аннары уңайсызланып кына:

— Трамвайга да соңардыгыз бит. Соңгысы да үтте. Бүген Казанга бүтән транспорт булмас,— диде.

Фаязның халәтен аңлау кыен түгел иде. Дебаркадердан утыз-кырык адымнар гына астарак, аунап яткан «Беларусь» тракторы хәтле агач тамырына карап уйга калды. Ике тезен кочаклап, тезләре өстенә ияген атландырып байтак утырды ул. Җәйге көн гаҗәп бит. Иртән нинди матур иде. Аннары кинәттән генә бөтен күк йөзен болыт каплап, ничә сәгать рәттән яңгыр сибәләде, кичке якта янәдән ачылып китте. Болытларның әсәре дә калмады, балкып кояш чыкты.

Шушы тирәдә аунап яткан коры-сарыны җыеп, Фаяз учак кабызып җибәрде. Аның янына Челкаш төшеп җитте.

— Шул кипкән балык дисез дә, үләсез дә китәсез,— диде ул бая өзелгән сүзне дәвам итеп. Төкерәсе генә иде дә, югыйсә.

— Өеңдә капчыгы белән утырса, әлбәттә, төкерерсең.

— Бер сез генә түгел, язга чыксаң, ярты Казан килеп аптырата. Кибетләрдә дә бар бит. Алары гына ярамый, күрәсең.

— Кибеттәге ширпотреб. Ә монда һәркем үзенчә киптерә.

— Анысы да дөрес,— дип килеште Челкаш.— Ә син, годок, борчылма. Урамда калмассың. Сине генә сыйдырырлык берәр җылы урын табылыр, шәт.— Челкаш аңа күз кысып алды да ял йорты корпусларына таба менеп китте.— Качуым түгел, разведка ясап төшим дип атлавым.

Черт-черт янган учакка карап, Фаяз янә уйга калды. Бу сәфәргә ул дусты Гомәрнең киңәше, дөресрәге, котыртуы буенча чыккан иде. Кичә аның ял көне иде. Үзләренә каршы гастрономнан сигез шешә сыра алып, 39 нчы маршрут автобусына утырды. Нахальный поселогына китте.

Алпаут утарыдай каралты корып, анда аның дусты Гомәр яши. Моннан егерме еллар элек алар һөнәр училищесында бергә укыганнар иде. Фаязны «Механика» заводына эшкә билгеләделәр. Шунда эшләп иң югары разрядка ия булды, өлкән мастер дәрәҗәсен алды. Заводның баш инженеры аны еш кына үзенә киңәшкә дәшә. Ә Гомәр училищега килгәндә тыңкыш борынлы шым гына авыл малае иде. Бер аягын күтәреп атлаганчы, икенчесен бүре ашый. Өч ел уку дәверендә шушы тыңкыш борын дөньяга дифференциаль күзлек белән карарга өйрәнде. Укуын яхшы укыды ул. Ә диплом алгач, беренче карашка бик перспективалы күренгән эшләргә чакыруларның күбесеннән баш тартып, чукраклар мәктәбенә металл эшкәртү буенча мастер булып урнашты. Анда, чукраклар арасында, ни дәрәҗәсе, ни акчасы, дигәндәй. Группа егетләре үз артында баштарак аны кызганып та сөйләгәннәр иде. Ә Гомәр алар уйлаганнан күп хәйләкәррәк булып чыкты.

Аның җиле дә Гомәргә гел арттан булды, дөньясы да йөзе белән басты. Казан байлары әвәрә килеп борынгы җиһазлар җыярга керешкәч, кинәттән генә Гомәр калкып чыкты. Тегесеннән сорашып, монысыннан белешеп дигәндәй, агач белән эш итү серләрен үзләштерде. Үзе белән ике-өч чукрак малайны да ияртеп, баштарак Опера театрында, филармониядә, Офицерлар йортында сакланып калган бизәкле урындыкларны, диван-көзгеләрне яңартып йөрде. Аннары эш сорашып-белешеп йөргән дәрвишне машина белән эзләп килә башладылар.

Әмма «һай, син техник училище тәмамлагансың икән», дип аңа фатир бирергә ашыкмадылар. Казан хәтле Казанда бер ул гынамы соң баш өстендә түбәсезләр. Хәер, тормышка теше-тырнагы белән ябышкан Гомәрнең моңа исе дә китмәде. Аның белән училище тәмамлаган егетләр тулай торакларда, малосемейкаларда көн күреп азапланганда, Гомәр Сәвин бистәсендә урын табып, «сыпушка» куыш корды. Аннары Нахальный поселогында күченеп, ташландык кына бер йорт сатып алды. Торабара шул урынга ак кирпечтән, түбәсен күгәрми торган ак калай белән ябып, ике катлы йорт бастырды, ак мунча, гараж салып куйды. Телефон керттерде. Теләсәң, бу телефон белән Канадага яки Австралиягә шалтыратып була, дип сөйли Гомәр. Башта заказлар үтәргә бер сүнсә мәңге кабынмый торган кәҗә бәтие, ягъни «Восход» матае белән чаба иде Гомәр. Хәзер ишек алдында өр-яңа кара төстәге «Волга» тора. Фаяз шуңа инанды, ничу язмышка зарланырга, яши белсәң, дөнья үзе төпсез диңгез ул!

Әйе, шушы хәлләрнең барсы да Фаяз күз алдында булды. Чөнки алар шушы еллар эчендә атна саен ук булмаса да, айга бер күрешеп, аралашып яшәделәр. Чөнки аларны шулай еш очраштырып, күрештереп тора торган бер хикмәт бар: сабакташлар икесе дә патологик дәрәҗәдә, ягъни чиргә сабышырлык булып балык яраталар. Әле училищедә укыган чакларыннан ук. Казанның берәр почмагында тозлы селедка, яисә йөз граммга мең данә керешле «шат күңелле егетләр», ягъни әлеге дә баягы кильки сатканны ишетсәләр дә, иренмиләр, дәрестән качып булса да бер җамыяк алып кайтырлар иде. Балык ярату әле бер нәрсә, ә һәркемнең мөмкинлекләре икенче. Агач остасы буларак даны Казанга таралган Гомәрнең мөмкинлекләре чиксез иде һәм ул балыксыз яшәмәде.

Дөрес, балыкны шулай яраткач, аны Фаяз да табар иде. Ул да алай чуттан төшеп калганнардан түгел. Үз заводларында ул да ихтирам, пачут казанган егет. «Үзәктән куу насослары» дигәч тә, ул сиңа ат дагасы яисә шырпы кабы гына түгел. Хикмәтләре чиксез аның. Өлкән мастер Фаяз белән чал чәчле инженерлар, конструкторлар да кул биреп күрешә. Теләсә, аның өстәленә дә балыкның иң майлыларын китереп салырга әзер торучылар бар. Хикмәт шунда, Фаязга хатынлыкка алтын таңкаләрне яратмау гына түгел, аның исен дә сөймәүче җан туры килде. Аның Мәйсәрәсе, ике йөзле җан, өйләнешкәнче бу турыда сиздермәде дә. Мәйсәрәсе артыннан чапканда ул аңа, күчтәнәч итеп, бер-ике кипкән

балык кыстырып та килгәли иде. Аны Болак елгасының Кабан күленә караган күпере өстенә басып, көлешә-көлешә кимерәләр иде. Кылчык канатларына тикле суырып торырлар иде. Инде ашханәгә-мазар керсәләр дә, Фаяз гомерлек яры итәргә җыенган назлысын, ихлас күңелдән сыйларга теләп, гел балыклы ашлар гына ала иде. Селедкалы закускаларны икене-өчне китертә. Ә Мәйсәрә, эчкерле нәрсә, балыкны яратмавын шунда ник бер генә сиздерсен. Өйләнгәч, инде балалары аякка баса башлагач кына ача башлады ул йөзенә каплаган хәйләкәрлек пәрәнҗәсен. Хатын-кыз дигән затта менә бит нинди серләр ята икән. Балыкны Мәйсәрә кыз чагында да сөймәгәндер, әмма түзгән. Ә хәзер кая ул өйгә балык кертү, исемен ишетсә дә укшый башлый.

— Миндә балыкның үзенә генә түгел, исеменә карата да аллергия,— ди Мәйсәрәсе. Әмма соңрак сиздерде шул аны. Хатыннар шулай алар, аллергияләрен ирләренә йөгәнне тәмам кидереп бетергәч, авызлыклап алгач кына сиздерәләр. Балык яратмый дип, аерып кына җибәреп тә булмый бит әле аларны. Җайлашырга туры килә инде. Җайлашуы шул: Фаяз балык ашамыйча түзә-түзә дә, бүтән чыдарлыгы калмагач, дусты Гомәргә китә. Күтәрә алганчы «Кызыл шәрекъ» сырасы ала. Күп кичләрне куна ук кала. Сабакташларның гәбе килә. Башта Гомәр аны балык шулпасы белән сыйлый. Телеңне йотарлык итеп пешерә ул шулпаны. Икенчегә уган бәрәңге, сыек йомырка, сөт өсте һәм сарымсак согында пешкән судак китереп куя. Кыскасы, өстәл өстендә балыкның кипкәне, каклаганы, маринадланганы, тозлысы — ни телисең, шул бар. Бер бәхетле гел бәхетле бит ул. Гомәр хатыннан да уңды. Аның Тәслиясе балыкны Гомәрнең үзеннән дә ныграк ярата. Шуңа күрә ире ни кушса, шуны йөгереп үтәп тора.

Гомәр бераз төшереп тә алса, мактанып җибәрергә ярата. Әмма зыянлы итеп түгел, гәп куерту өчен генә. Аннары, кулыңнан эш килгәч, кеше арасында абруй-дәрәҗәң булгач, сүз уңаенда гына мактанып куюда гаеп түгел ич. Гомәр хәзер Казанның кызыл агач белән эш итүче иң кадерле осталарыннан санала. Әле шушы арада гына бер күренекле министрның гозерен хуплап, дачасын кызыл агач белән бизәп бирде.

Фаяз үзе дә Гомәрнең мактанганын гына тыңлап утырмый. Дустын ярты юлда бүлдереп, «Үзәктән куу насосларының бүгенгесе һәм киләчәге» турында сөйләп җибәрә. Бу насосларның әһәмияте бүгенге көндә дә югалмый. Чөнки космик кораблар төзегәндә дә беренче чиратта үзәктән куу көчләрен исәпкә алырга туры килә. Димәк, техник прогресс фронтында Фаязның да урыны түрдән.

Запаста ял көне бар иде Фаязның. Заводка тиз арада башкарылырга тиешле заказ килгән иде. Фаяз үз бригадасы белән өч көн, өч төн цехтан чыкмады. Аннары атна башында аңа ял бирделәр. Фаяз сигез шешә сыра алды да дусты Гомәргә барып чыкты.

Хуҗаның кәефе бик күтәренке чакка туры килде. Чөнки ул яңа заказ алган икән.

— Күп булса ярты ел кирәк миңа. «Форд» машинасы алырлык акча шалт Мөхәммәтҗан минем кесәгә,— дип сөйләп китте Кутыр Борын. Заманча дигәнең үзе белән адәм баласын да үзгәртә икән. Әле кайчан гына бер тиен өчен үлеп китәргә әзер Гомәр, хәзер әнә ничек бөеренә таянып сөйләшә.

— Акчасы минем өчен пүчтәк, кәнишне. Эшен эшләгәч, анысын бирерләр. Минем өчен аның икенчесе важный. Исемем тарихта калырлык булсын. Бу залны кем шулай матур итеп бизәде, дигәндә: «Гомәр Яримов!» — диярлек булсын.

Вәт бит, каһәр, Гомәр ничек сөйләшә хәзер. Моны берәрсе өйрәтеп куйганмы әллә, диярсең, валлаһи. Юк, юк, гөнаһысына керешле түгел. Бик күңелле итеп утырдылар алар. Фаяз килеп керүгә, Гомәр өстәлгә бер көлтә чехонь китереп салды. Кысыбрак тотсаң, мае тамарга тора. Фаязның уйларын укыгандай, Гомәр:

— Кичә генә балыкчыларның үз кулларыннан алып кайттым,— диде.

— Ә мин барып чыксам? Миңа да табарлар микән?

— Ышту син! Мин дә аларның бик ышанычлы кешеләре аша гына таптым.

— Ә син ул адресны миңа да бир. Әллә ышанмыйсыңмы?

— Мин бирермен дә...— дип куйды Гомәр башын кашып.— Ләкин алар синең белән сөйләшергә теләрме? Хәтәр бит. Балык тоту тыелган чор. Эләктерә калсалар — таш капчык. Законнар каттый хәзер.

— Алай да барып карыйм, бир адресларын. Әгәренки берни дә барып чыкмаса, күңелне тынычландырып кайтырмын.

Гомәр дусты Фаязның тәвәккәллеген белә. Артык вакланып маташмады.

— Иртәнге беренче трамвай белән үк юлга чык диде ул.— Шелангада трамвайдан төшкәч үк Чингачгукны сора. Пристаньнән әз генә читтә, ярга чыгарып каплаган көймә булыр, бер егет утырыр. Җәтмә үрер. Киндер ыштан — джинсыдан булыр. Беләкләре — айгыр боты, җилкәсе футбол кыры хәтле аның. Америка һиндлыларың апачилар кабиләсе башлыгы Чингачгукның нәкъ үзе. Озын кара чәчләрен җыеп кызыл косынка астына тыккан булыр. Чингачгук менә шушы егет инде. Ләкин ул сиңа:

— Чингачгук юк бит әле бирeдә, ни йомыш иде? — дияр. Менә шунда Ходай сиңа тел ачкычлары биреп, матур гына сөйләшеп китә алсаң, эшең пешәр. Чингачгук сине ошата калса, уртак тел тапсагыз, иренен киереп ачы итеп бер сызгырып куяр. Анда җәтмәләр элгән колгалардан әз генә өстәрәк, амбарлар бар. Шуннан бер малай йөгереп төшәр. Алар анда шартлы билгеләр белән генә сөйләшәләр. Әгәр шушы малай:

— О, кей, шеф! Эшлибез аны,— дисә, бераз көтәрсең. Балыкны сиңа төргәккә төреп төшерәләр. Алар акча алмыйлар. Шунда шешәләреңне сузарсың. Ачы итеп сызгырмаса, үзеңә үпкәлә. Йә син алар белән уртак тел таба алмагансың, йә алар синнән шикләнгәннәр булып чыга.

Идел ярына Фаяз менә шулай килеп чыккан иде. Әмма Шелангага ук төшеп җитә алмады. Чингачгукны да күрү бәхетенә ирешмәде. Ләкин ул үкенми. Күргәненнән, татыганыннан да бик канәгать. Учак яна гына. Өстәгән бер чыбыкны ялап кына ала. Фаяз кочагына яссы ташлар җыйды. Аларны, малай чагындагы төсле, чәпчетеп-чәпчетеп су өстенә ыргыта башлады. Бер ташы биш тапкыр чәпчеде. Икенчесе җиде тапкыр. Рекордны унбер тапкыр чәпчетеп куйды. Шулай итеп, кичке җиделәр дә җитте. Идел өсте бу чорда аеруча матур икән. Еракта-еракта, томан эченнән чак кына беленеп, баржалар кәрваны күренә. Кичке якта Идел өсте янә җанланып китте.

Дебаркадердан өскә күтәрелгән яр буе кичке уңайда саф һава суларга чыккан ял итүчеләр белән тулды.

Парлашып-парлашып та, төркемнәргә берләшеп тә, ял итеп торган шушы халык еракта, су эчендә нидер күреп алды, ахры, башларын изәп тә, куллары белән төртеп-төртеп тә шунда таба күрсәтергә тотындылар. Фаяз да кызыксынып өскәрәк, яр башынарак менде. Хикмәт менә нәрсәдә икән:

Ярдан байтак эчтәрәк бирегә таба ак җаймәгә төргәндәй бүрәнәме шунда, әллә башка берәр нәрсәме йөзеп килә иде. Дөресрәге аны дулкыннар ярга таба куа иде. Бер бата, бер калка килгәнлектән аның нәрсә булуын әлегә аерырлык түгел. Нәрсә булыр соң бу?

— Балык! Балык бит бу, егетләр! Белуга, валлаһи! — диештеләр ярдагы дөнья күргәнрәкләр.

«Нигә соң ул шулай җансыз? Исергәнме әллә? Шик юк, белуга бу!»

Дулкыннар әлеге «ак бүрәнәне» ярга тагын да якынайтты. Ул хәзер ярдан нибарысы егерме биш-утыз адым гына эчтә тирбәлә. Белугамы-севрюгамы, китмы-акуламы дигәндәй, анысы соңыннан ачыкланыр, әмма шунысы бәхәссез, дулкыннар ярга куалаган нәрсә гаҗәеп зур балык иде. Менә сиңа мә!

Шундый чакта кирәк бит, яр буена әллә кайдан гына өс-башлары пычракка баткан, бит-йөзләрен сакал-мыек баскан ике кеше килеп чыкты. Алар су читенә үк басып, дулкыннарның балыкны ярга бәргәнен көтә башладылар. Икесенең дә кулларында тимер ыргаклары да бар. Аякларын да чылатмый гына балыкка хуҗа булырга боларның исәпләре. Кыяфәтләре майлы калҗа каравыллаган козгыннардан бер дә ким түгел. Челкаш кая олагып йөри соң, атың коргыры. Дулкыннар балыкны нәкъ теге егетләр басып торган җиргә куып чыгарырга тиеш. Фаяз күп уйлап тормады, кулына колга алды да, киемен дә салып тормыйча су эченә кереп китте. Ул агып барган балыкны колгасы белән үзе янына тартып китерә башлады.

— Әй, әй! Нишлисең син! Ул бит... Ул бит безнең балык! — дип ярдан кычкыручыларга йодрык кына күрсәтте.

Әйтергә генә ансат, балык ике метрлар чамасы булыр. Фаяз югалып калмады, ап-ак тәнле бу балыкны саңак астыннан эләктереп алды да ярга өстери башлады. Ул арада кунар урын эзләп киткән җиреннән югалып торган Челкаш та аңа ярдәмгә килеп җитте. Балыкны көч-хәл белән ярга өстерәп чыгардылар. Һәм күрделәр, бу гөнаһсыз җанның сырты кырт итеп кыеп алынган иде.

— Уылдык чәчкән чаклары бит. Кая сикергәннәрен белми уйныйлар. Вак балык артыннан куып уйнаганда «Метеор» винтына эләккән, — дип аңлатты Челкаш. — Әмма син бәхетле мужик, годок. Мондый очраклар бездә көн саен булып тормый.

Битләрен сакал баскан әлеге егетләр дә алар тирәсендә чуалалар. Балыкны ярга чыгарырга булыштылар. Аның берсе бик тәвәккәл кыяфәттә:

— Ашыкмагыз, мин тиз генә йә үлчәү, йә бизмән табып төшәм, — диде.

— Анысы тагын нәрсәгә хаҗәт? — диде Фаяз.

— Ничек нәрсәгә? — диештеләр тегеләр аптыраган кыяфәттә. — Монда бит миллион тәңкәлек балык түшкәсе ята. Безгә күп кирәкми. Авызмыекны чылатырлык өлеш чыгарсаң, шул җиткән. Ә без сиңа аны күз ачып-йомганчы ял итүчеләргә сатып та бирербез.

— Балыкны судан мин тотып алдым, — диде Фаяз. — Ярга да мин өстерәп чыгардым. Димәк, ул минеке! Аның белән нишләргә икәнен дә, давайте, егетләр, үзем хәл итим.

Аның бу сүзләрен Челкаш та хупламады.

— Бу хәтле балыкны син бит барыбер өеңә алып кайтып китә алмыйсың, годок, — диде ул.

— Ә мин җыенмыйм да.

— Ул чакта?..

— Ул чактамы? Дебаркадерыңда плитәң бармы? Биредә ял итүчеләр өчен күмәк кичке аш пешерәбез. Дәшегез, барсы да чистартырга төшсеннәр.

Фаязның шушы сүзен ишетүгә чибәр-чибәр ханымнар, яулыкларын артка бәйләп җиңнәрен беләктән югары сызганып, шаян сүзләр, такмаклар әйтешеп, балыкны эшкәртергә дә керештеләр. Челкаш аны читкәрәк дәшеп:

— Однако, годок, күңеленә авыр алма, чын тиле син. Шушы сәгатькә кадәр синең ОБХСС кешесе түгеллегеңә бик үк ышанып җитмәгән идем. Хәзер тәмам ышандым. Анда синең кебек ахмаклар эшләмәс, — дип орышырга керешге. — Сатып бирсәк соң, кимендә миллион тәңкә эчеңне тишәр идеме. Бу бит белуга! Аның килограммы күпме торганын син бит башыңа да китерә алмыйсың. Шыр тиле син! Күз алдында сыпырып алып бетерәләр иде бит.

— Мөмкин иде, — дип килеште Фаяз. — Ләкин бит балык минеке түгел. Балык дәүләтнеке. Ә дәүләт халыкныкы. Ә халыкка мондый нәрсәләр еш татымый. Хәзер җае чыкты, сыйлансыннар бер.

Ул арада дебаркадерның миче дөрләп китте. Халык андый чакта күмәк хуҗалык итүнең иң алдынгы үрнәкләрен күрсәтә икән. Калҗаларны бүрек-бүрек кадәр салып шулпа куйдылар. Баяннарын күтәреп ике баянчы да төшеп җитте. Берәүләр вальска әйләнеп, икенчеләре җырлыйлар. Дебаркадерның пассажирлар залында балык шулпасы өлгергәнче үк чын бәйрәм башланып китте.

«Трагик» төстә һәлак булган бу бичара балыкның уылдыгы гына да чиләк ярымнар чыкты. Белуганы эшкәртүчеләр белән җитәкчелек иткән Челкаш:

— Однако, годоклар, монысына тимибез. Монысы хуҗа өлеше. Аның да гаиләсе, бала-чагасы, дус-ишләре бардыр. Монысын өенә алып кайтсын,— дип, уылдыкның күп өлешен целлофан капчыкка салып, бер читкәрәк алып куйды.

Бөтен Идел ярына башыңны әйләндерердәй тәмле исләр таратып, балык шулпасы өлгерде генә дигәндә, ашарга утыргач кына, озын итеп кычкырткан гудок тавышы ишетелде. Карасалар, эңгер-меңгер кунып килгән Идел өстендә бөтен утларын балкытып өч палубалы ап-ак пароход күренде.

— Ә-ә, «Михаил Шолохов» бу! Су өстендә йөзә торган ял йорты,— диде Челкаш.— Әчтерханнан Мәскәүгә менеп баруы.

Теплоход озын гудоклар бирә-бирә дебаркадерга якынлашты. Туктарга исәбе бар, ахры. Штурман рупор аша кычкырып, Челкашка әзер булырга кушты.

— Алар, гадәттә, бездә туктамыйлар иде. Туктасалар, годок, синең бәхеттән. Алар белән озатам мин сине,— дип, Челкаш аңа шушы тирәләрдә генә булырга кушты.

Теплоход туктау белән, дебаркадерга зур-зур чемоданнарын көчкә күтәреп, хатыннары, бала-чагалары белән ике офицер гаиләсе төште. Берсе майор, икенчесе капитан. Икесе дә летчиклар, татарлар, иде.

— Ялыбызның бер өлешен шушы теплоходта уздырдык. Инде калганын туган якларда уздырырга иде исәп. Машина булырмы икән, юкмы? Югыйсә, безгә моннан унике чакырым гына бит — дип, офицерларның өлкәннәре, Фаязны җирле кешегә санап, үз хәлләрен аңлатып бирде.

— Инде монда аяк баскач, кайгырмагыз, ничек тә кайтып җитәрсез. Машина булмаса, ат сорарсыз. Ил иминлеге сагында торган үзебезнең егетләргә мондый гына ярдәмнән берәү дә баш тартмас,— дип, Фаяз аларны үзенчә тынычландырырга тырышты.

Челкаш шул арада штурман белән сөйләшеп, Фаязны теплоходка кертеп утыртты. Юкса, бу бит ял пароходы, монда пассажирлар алмыйлар. Шушы бер көн, кыска гына вакыт эчендә алар ничектер якынаеп, бер-берсен ошатып өлгерделәр. Инде аерылыр чак җиткәч, икесенә дә ямансу булып китте.

— Однако, годок, Фаяз, яхшы егет син,— диде аңа Челкаш.— Синең белән танышуыма мин бик шатмын. Киләсе елларда ничек тә бер килеп чыгарга тырыш әле син. Балыкның иң тәмлесен мин сиңа үзем тотып куярмын.

— Танышларым-дусларым хәзер минем монда атлаган саен. Киләм әле, иркенләп киләм,— дип ышандырды Фаяз.

Саубуллашкан чакта Челкаш аны ике иңбашыннан тотып кочаклады.

— Ә син юкка шулай ашыгасың, годок. Мин сиңа монда кунарга домна миче кебек кайнар куен табып куйган идем,— дип аңа каш сикертеп күз кысты.

Безнең татар ни күрсә дә шул теленнән күрә. Игелекне дә, михнәтне дә. Күбрәк михнәтне, әлбәттә. Фаязга да шым гына кайтып китәсе иде дә. Әллә дебаркадерда сыйлаганнан, әллә инде бер көн эчендә үзе белән булган вакыйгалар тәэсиреннән бераз гына исерә дә төшкән иде. Түзмәде шул, үзе белән булган хәлләрне теплоходтагыларга да сөйләп ташлады.

Ә тегеләр ышанмыйлар, чын фантазер бу, диләр. Шунда ул портфелен ачып, целлофан капчыктагы уылдыкны чыгарып салмасынмы...

— Бу нәрсә соң, уылдык булмыйча! Шул мин тоткан биш потлы белуга уылдыгы ич инде! Һәр бөртеге киндер орлыгыннан бермә-бер зуррак!


Кич җитте. Идел өстенә тәмам бастырып караңгы төште. Ә Казанга менеп җитәргә байтак бар әле. Ял итүчеләр Фаязны да үзләре белән ияртеп кичке ашка ресторанга дәштеләр. Чөнки ул монда да бик тиз арада үз кеше булып киткән иде. Аны өстәлнең түр башына утырттылар. Ә егетнең кыланышлары Казан байларыныкыннан бер дә ким түгел иде.

— Анда пешекчегә кисәтеп әйтегез, тозын да, серкәсен дә, борычын да чама белән генә салып, башта безгә кыздырган кызыл уылдык китерсен, калганын соңыннан карарбыз, дип күрсәтмәләр генә биреп утырды. Әлбәттә, Фаязның «Үзәктән куу насослары» буенча өлкән мастер, аның белән инженер-конструкторларның да кул биреп күрешүе, аның Кутыр Борын дусты Гомәрнең Казанда бер краснодеревщик булуы турында теплоходта ял итүчеләрнең барысы да күптән белә иде. Инде Казанга җиткәч, Фаяз утырган салонга теплоход штурманы килеп керде.

— Монысы безнең теплоходта ял итүчеләрдән сезнең гаиләгезгә күчтәнәч,—дип аның кулына бер көлтә кипкән балык тоттырды.

**Каләмдәшебез Альберт Хәсәновны 60 еллык юбилее белән котлыйбыз һәм иҗади уңышлар теләп калабыз.**

*«Казан утлары» журналы редакциясе.*



# САЛАВАТ ЙӨРГӘН СУКМАКТАН...



*Сафуан Әлибай — танылган башкорт шагыйре; Г. Сәләм исемендәге республика яшьләр премиясе, Һ. Х. Андерсен исемендәге Халыкара бүләк иясе; Татарстан язучыларының күптәнге дусты — безнең яшьтәш, замандаш әдип. Ул Казаныбызга күп тапкырлар килде: Шигърият бәйрәмнәрендә, Башкортстан әдәбияты һәм мәдәнияте көннәрендә күрдек без аны. Ул йә Равил Фәйзуллин, йә Роберт Миңнуллин һәм Марсель Гали тирәсендә була; йә «Сабантуй» газетасы, «Сөембикә» журналы мөхәррирләренә килә. Һәркайда — шигырьләре, җырлары, һәм елмаюлы йөзе белән балкып күренә. Үзе дә бик үзенчәлекле моңга, тавыш-сәләткә ия булган, һәр күрешүдә безне озын башкорт көйләре белән әсәрләндергән Сафуан — бик күп популяр җырлар авторы да: алар Татарстан җырчыларының да репертуарында. Балалар әдәбиятында да уңышлары зур аның — әлеге Андерсен премиясе шуның билгесе. Әмма, барыннан да бигрәк, Әлибай — лирик шагыйрь, туган җиренә, атайсалына — изге тиягенә бөтен җаны белән береккән, Урал моңыннан яралган башкорт баласы. Ул — атаклы Салават Юлай туган яктан, Салават районыннан. Бу — үзе генә дә күпне сөйли, күпне таләп итә. Өстәвенә, ул — З. Вәлиди-Туган исемле Башкорт милли китапханәсе директоры да... Сафуанны күреп белә башлаганыма тиздән кырык ел тула. Әмма ул минем карашка һич тә үзгәрмәде кебек: гел яшь, алчак, ягымлы йөз, серле тембрлы, таулар моңын саклаучы тавыш, аз гына хәйләкәр дә кебек шат, җете күзләр... Ә иҗатында — ул үзгәрә, һаман эзләнә, үсә, югарыга омтыла. Бүгенге көндә бик күп кызыклы исемнәре булган, үзенчәлекле, олуг башкорт шигыреннә — Сафуанның үз урыны, үз биеклеге. Без бу санда тәкъдим итә торган шигырьләре — алар тиздән Казанда татар телендә дөнья күрәчәк «Язлар көтәм» исемле сайланма китабыннан алынды, — әнә шуны сөйли, шуны раслый, безнеңчә. Әйе, Салаватлар сукмагыннан табарсыз аны, кадерле укучыларыбыз!*

**Рәдиф ГАТАШ.**

## Сафуан Әлибай,

башкорт шагыйре

### Сөенче!

Яңа елда
 таңнан
 җир шарының
Түбәсенә баскан көенчә,
Кычкырасым килә
 бар тарафка:

Сөен-че!
Сөен-че!!
Сөен-че!!!
Сөенчемә күкләр
чыңлап китсен,
Сипкән чакта
энҗе карларын,
Яңгырап шул сүз,
Җирне урап чыгып,
Онытырса икән
аһ-зарын.
Сөенче! — дип,
шул сүз чыңгыратып
Зинданнарның ачсын ишеген,
Зынҗырлары
челпәрәмә килсен
Тәүбәсенә кайткан кешенең.
Алып кайтсын юллар
төягенә
Илкәеннән бизгән бәндәне.
Сөенче! — дип
битлек кигәндә дә
Үз йөзендә калсын җан-тәне!
Сөенче! — дип юрап
киләчәкне,
Һәр өрлеккә
бишек асылсын;
Туган телендә тик
һәр сабыйның
«Әнкәй!» — диеп
теле ачылсын.
Сөенче! — дип сугар
бүген кояш —
Җиһанымның алтын сәгате;
Шушы таңнан күчсен
һәр көненә
Сөенчеләп
туу гадәте.
Шатлык килсә ташып,
күңелемдә
Сөенче! — дип чыңлар
мең кылым;
Эндәшми дә түзәм,
кайгы килсә,
Сөенче! — дип тусын
һәр елым!

## Куян елы

*(1987)*

Өйрәнелеп киткән
йөрүләре
Горур гына
Барыс юлыннан.
Аяк басарга да кыймый тордым
Җилеп килгән

Куян елына.
Алай дисәң,
килгән,
киткән еллар
Бер-беренә игез,
охшашлар:
Күперелеп ята юлларымда
Ак куяндай ап-ак
йомшак кар.
Куян елы
ап-ак кар сафлыгын
Уй-хисләргә сипсен
кадерләп;
Күперелеп яткан ак мамыкның
Йомшаклыгы күчсен бәгырьгә.
Шушы елда безгә сеңеп калсын
Ак куяннан
нәфис җитезлек;
Шул җитезлек җитсен
иң-иң изге
Хыялларга барып җитәрлек!
Аякларга
Куян
ныклык бирсен,—
Җиңел түгел юллар каршыда:
Бер типкәндә,
башы чәчрәп калсын,
Ташланганда
Кайгы-карчыга.
Куян елы,
сизгер тойсак иде.
Дөнья шавын,
вакыт очканны;
Үткерлеген бирче
күзләреңнең
Аерырга
дусны,
дошманны.
Булсак иде
Куян елында да
Барыс сыман
олы теләкле.
Тик дошманнар гына
калсын, булып
Элеккечә,
куян йөрәкле!..

## Елан елы

*«Җылыга елан ияләшә»*
Халык әйтеме

Әйләндереп йолдыз төркемнәрен,
Балкып кына ята Җиһан Юлы[1].

[1] Җиһан Юлы — Киек Каз Юлы.

...Аждаһадан кәтмәс сынауларны
Китерәсең безгә, Елан елы.

Абайласаң, афәт елдамыни,
Син бит бары чират үткәрүче;
Ә соң сине сихерләүче кем ул,
Агу чәчеп, коткы җиткерүче?

Аз булдымы дулап Европада
Шуа-шуа каннар эчкәннәрең.
Илкәемне чагып, син кырык бердә
Асыл гомерләрне кискәннәрең?..

Утлар чәчәр аждаһамы әллә
Ярты илне китте күмер итеп...
Нәкъ шул елны мине әнкәм тапкан,
Дәвам итәр токым гомере, дип.

Дәвам итәр! Елан әлдән-әле
Уралса да аяк асларында;
Куенында елан йөрткәннәрнең
Ниләр барын беләм башларында.

Атылса да вакыт йолдыз булып,
Балкып кына ята Җиһан Юлы...
Аждаһадан яман казаларны
Китерәсең икән, Елан елы.

Җиркәемнең тәнен ермачлаган
Азмы торба кара елан булып,
Йә ут бөркер, яки агу чәчәр
Кайсы җирдә кайсы ялан тулып?..

89, июнь, Елан елы.
(Уем түгел елляр яманлауда).
Ике яктан ике поезд шуа,
Очрашырга тиеш Елантауда,

Һәм каһәрле шартлау... олы юлда
Аймылышлы итте гомерләрне,
Вагон-вагон килгән сабыйларның
Ятып калды көле, күмерләре.

Крематорийларың кирәк түгел,
Чамалардан, җирем, ашты даның;
Иләштерден җылы куенына
Азмы елан, азмы аждаһаны?!

Елан елы, дисәм, котлар оча,
Гаепмени еллар агышында.
Елан агуларын дару итеп
Кала күрче, кешем, язмышыңда.

## Куй елы

Этеш-төртеш, ыгы-зыгы,
Диңкеде халык арып...
Мәңгелекнең тугаенда
Тын гына утлый сарык.

Аңлый малкай: берни кылып
Булмыйдыр тамак ярып;
Коры сүз бит тамак ерта,
Сарык түгел — ил арык.

Ә көтүдә мал уңмаса,
Гаепле тиз табыла:
Көтүчене биетәләр
Кыздырылган табада.

Көтү түгел, ил диңкесә,
Эзләп кара сәбәпне! —
Ничәнче кат соң кирегә
Борыла тарих сәгате?!

Халыкларны сарык итеп,
Әйдәкләмик кабергә.—
Каберләрдә биеп кенә
Кем коенган кадергә?!

Имеш, гаеп бездә түгел,
Бөтен каза — үткәннән,
Мал артырмы,
Дан кайтырмы
Илне кат-кат сүткәннән?!

...Мәңгелекнең тугаенда
Тын гына утлый сарык.
Берүк, ходай ярлыкасын,—
Сарык булмасын халык!

Яңа елга аяк баса
Җангынам, арып-талып.
Сарык — арык, дигәннәрне
Онытса икән халык!..

## Ничәнче көн сине күргәнем юк

Ничәнче көн сине күргәнем юк,
Югалттым да кебек саннарын.
Өметләрем өзеп көн сүнсә дә,
Өмет булып туды таңнарым.

Ничәнче көн сине күргәнем юк,
Юлларымда һаман юлдашсыз,—
Көпә-көндез адашырга мөмкин,
Күңелләрең калса кояшсыз.

Ничәнче көн сине күргәнем юк,
Офыклардан ашып тилмердем.
Җитәр микән сине табар өчен
Көннәр түгел, бөтен гомерем?

* * *

Гомерләрнең ике мизгеле бар:
Тәүгесендә — җилү яшьлеккә,
Ә яшьлегең булмый мәхәббәтсез,
Сөюеңне эзләр яшь җитсә.

Мәхәббәтең җирдән балкып туа,
Айкасаң да күзләп күкләрне;
Әллә еллар, әллә юллар гына
Аймылышлы итә күпләрне.

Гомерләрнең ике мизгеле бар:
Яшьлегеңдә канат кагыну,
Эзләп табу тәүге мәхәббәтне,
Калган гомер — аны сагыну.

## Яфрак ява

Синең яктан җылы хәбәрләр юк...
Яфракларга сары сарыла,
Бирешмиләр иде хәтта алар
Вакытсыз ла яуган карына.

Сукмакларга иртә яфрак ява,
Син киләсе якка үрелеп;
Учак булып янган тирәгемнән
Һәр бөресе төшә өрелеп.

Тирәгемнән соңгы яфрак очты,
Сукмак ята көйрәп, яктырып.
Син кайттың да... Менә тирәгемә
Яфракларын кара кайтарып.

## Дәва

Тормыш-диңгез тәмам әлсерәтеп,
Бәреп китте берчак ярына.
Күзләремне ачып көнгә бактым,
Аягүрә бастым яңадан.

Утлар гына йотып көйрәгәндә,
Иреннәрем тиде чишмәгә.
Мин үземдә кабат гайрәт тоям,
Дәрьяларны әзер кичмәгә.

Еракларга очтым канат кагып,
Әле талгын, әле еш сыман;
Егылып ла төштем мин кансырап,
Канатлары сынган кош сыман.

Кайгы-уклар тетте канатларны,
Ә мин очтым, очтым кабаттан.
...Дәвалары каян туа, димә,—
Синең генә, синең караштан.

### Вәгъдә итмә...

Миңа йолдыз вәгъдә итмә,
Талпынып ла зәңгәр күккә,—
Атылыр да сүнәр йолдыз
Эзсез калыр мәңгелеккә.

Миңа ташкын вәгъдә итмә,
Дулкыннарың чайкый-чайкый,—
Күбек чәчеп, боз актаргач,
Ул да тынар, кабат чапмый.

Миңа таулар вәгъдә итмә,—
Янар таулар җирдә сирәк.
Юлдаш булсын — тау күтәрер
Синең генә тугры йөрәк.



Әхсән Баянов

# СУ ӨСЛӘРЕНДӘ ПАРОХОД

ИСТӘЛЕКЛӘР КИТАБЫННАН

Сугыш чыгу белән апабыз Галимәне Аятка дигән җиргә торф чыгарырга җибәрделәр. Һәм шул рәвешле, мин өйдә иң олы малай булып калдым. Хуҗалык минем җилкәгә менде. Бурычның иң зурысы — малларга кышлык азык әзерләү, печән чабып җыю. Көн-төн дигәндәй, муеннан эшкә чумарга, нужада йөзәргә тиешсең һәм йөзәсең. Кырда ашлык сугучыларга яки кибәннәргә салу өчен көлтә ташыйсың. Төшкелеккә кайткач, аз-маз капкалагач та, йорт өчен печән чабарга ашыгасың. Печәнлек һәркемгә җитәрлек булса, зарланмый гына чабар идең дә, анысы да юк дәрәҗәсендә шул. Бөтен авылга кирәк, бөтен авыл чаба. Хәтта безнең ындыр янындагы уйсулыкны да Гомәр карт чабып өлгергән. Ә синерактанрак эзлә. Көн саен эзлисең. Тапкан кадәр чабасың да, тагын көлтә ташырга китәсең. Монда бер генә юаныч: кулда мажар (печән-салам ташый торган арба бездә шулай атала) һәм ат булгач, эштән кайтышлый әзер печәнне өйгә кайтарырга мөмкинлек бар. Җәйләр, көзләр буе шулай этләнә торгач печән ярыйсы гына җыйнала.

Җилкәгә төялгән шундый мәшәкатьләрдән тыш, миңа яшәү хисе биргән ике әйбер бар. Беренчесе, әлбәттә, гармун, икенчесе — берданка дигән мылтык. Гармун, белүебезчә, Әсгать абый истәлеге, ә берданка — Миргасим абзыйныкы. Мылтык һәм гармун — капма-каршы көчләр — янәшә... Икесе дә минем кулда...

Көзге салкыннар башлангач, кырлар иркенәя, үзенчә матурая бит. Бигрәк тә уҗым басулары тантана итә. Анда маллар йөрсә дә сүз әйтмиләр. Терлек игенгә зыян китерми, киресенчә, ашлама гына өсти. Терлек кенә түгел, куяннар да була анда. Кеше бик якынайса гына торып чабалар. Элек зурлар йөргән кебек, җилкәгә мылтык асып, хәзер анда мин йөрим. Кайдадыр посып, куян ята. Кайдалыгын чамалап, мылтыкны кулбаштан төшергән буласың. Аткан буласың. Тик әллә кора белү җитмәгән, рәтләп шартламыйча, мылтык чыжт кына итә дә, куян бу тавышны колагына да элми.

Ул елларда бүре ишәйде. Кич җиттеме, авылны кырдан аера торган сазлык артында җыйнаулашып уларга тотыналар. Мескен этләр, шыңшый-шыңшый, чиный-чиный, күтәрмә асларына кереп кача. Ә син бүреләрне куркытмакчы, янәсе. Мылтыкны ныклабрак корып, күтәрмә өстенә чыгып баскан килеш, чакманы тартасың. Мылтык тавышы бу юлы каты чыга. Бөтен авыл калтырап куядыр кебек. Берничә минутка бүре тавышлары тына. Мәгәр озакка түгел. Минем мылтык тавышларына аларның

---

Ахыры. Башы 11 санда.

бик исе китми иде шул. Киресенчә, мылтык үземә тән җәрәхәте китермәсә дә, күңелдә тәзәлеп бетә алмаслык дәрәҗәдәге хатирә калдырды.

Физкультура дәресләре хәрби дәресләргә әйләнгән иде. Агачтан мылтык ясап килергә куштылар. Мин дә ясадым. Хәрби хезмәтнең нәрсә икәнен белмәгән апа безне шул эшкә өйрәтә. Классны бер рәткә тезә дә: «Направо равняйсь, налево равняйсь»,— дип команда бирә. Болары безгә таныш. Моңарчы ишетелмәгәннәре шулар: «К ноге, на плечо, к бою!» Дәрес саен шулар кабатлана. Туймый хәлен дә юк.

Гел бер төрле булмасын дип микән, кайсыбер көннәрдә мин мәктәпкә берданка белән киләм. Ничә мәртәбә кабатлангандыр бу хәл, әйтә алмыйм. Ләкин бер көнне моңа чик куелды. Нинди генә чик бит!

Агач мылтыклар классның алгы почмагында сөяп куела. Шулар арасында — минем берданка.

Тәнәфескә чыгабыз. Урамда йөреп керүемә, коридорда әллә нинди шомлы тынлык. Коридор тулы кеше, үзе тынлык. Һәркемнең күзе миңа текәлә: «Әнә үзе!»

«Үзе» ни уйларга белмичә, класска узмакчы да, тик туктап тор. Күземә мылтык шәйләнә. Ул, нишләптер, директор Кәримә апа Шәрипова кулында. Апабыз чәрелдәп мине тиргәргә дә керешә. Сүзләрен рәтләп аңлар хәлдә булмаганмындыр, берсе дә истә калмаган. Йөрәктә уелып калган бердәнбер нәрсә — ул идәндәге ямьсез тишек... Мин тышта йөргәндә, Муллакаев Мәгъсүм дигән малай, мылтыкны алган да, шуның белән башка укучыларны куркытып уйный ди. Кешләрнең күзләренә төбәп, чакманы тартып та куя. Ләкин мылтык атылмый. Шуңа күрәдер, балалар көлә генә. Мылтыклы кеше яныннан көлә-көлә узалар. Әмма бервакыт мәктәп өнсез кала. Гөрселдәп мылтык атыла. Ходайның хикмәте, ярый әле идәнгә таба атыла. Очраклы рәвештә. Мин кергәндә һәркемнең карашы ядрәләр тишеп узган кара тишеккә төбәлгән иде.

Һушны җыя алмыйча басып торам. Класска ничек кергәнемне, нинди дәрес икәнне хәтерләмим. Дәрес тәгәлләнүгә, милиционер килгән — Шәйдулла исемле. Үзем белән сөйләшеп тә тормады, мылтыкны элэктерде дә, чыгып та китте. Кәримә апа һаман тиргәнүен белә. Әмма бер сүзе дә колакка керми. Тавышы ачы булса да, мәгънәләре андый ук була алмагандыр инде. Колакка кереп кире чыкмый торган сүзне Нәйрә исемле карт укытучы апа әйтте:

— Баяновлар тота ул, незаконный мылтык тоталар, дәүләт гармунын да тоталар.— Менә ичмасам онытылмас сүзләр!

Сугыш вакытында «утлы корал» — ягъни мылтык буладыр — беркемдә дә калырга тиеш түгел икән һәм шул хакта хөкүмәт карары бар, имеш. Шулай икән, шулай. Мылтыкны һич дә җәлләмәдем. Ләкин Нәйрә апа сүзләрен ишеткәндә, күзләремә тагын яшь тулды. Коридордамы, әллә класска яңадан керепме, еларга керештем. Сулыгып-сулыгып еладым. Кемнеңдер була язган фаҗигасеннән куркып, кемнеңдер җирдә яткан канлы гәүдәсен күргән кебек тоеп еладым. Коточкыч караңгы бу минутларда ярдәмгә килүче күренмәде...

Дөрес, елаклыгым бүген генә сизелгән нәрсә түгел иде. Мәктәп диварлары мондый хәлемә бернична тапкыр шаһит булдылар. Хәтерлим, бик тә нык хәтерлим...

Беренче очрак — бишенче класста укый башлаган чак. Рус теле дәресе. Укытучы Алферова апа — бик чибәр, затлы, олы абруйлы. Әсгать абыйларны да укыткан иде. Телдән минем әйбәт җаваплар бирүемә күнеккән, кайбер сорауларга җавап бирә алучы табылмаганда, башка укытучылар кебек үк, миннән сорый. Ә менә язма эшләремә игътибар итмәгән икән. Ниндидер күнегүләр язып утырганда, парта араларыннан узышлый, минем дәфтәремә карап иелде дә:

— Бигүк әйбәт язмыйсың икән. Әсгать абыең бик матур яза иде бит синең,— дип куйды.

Яраткан апаның шул сүзе житә калды, күңелем тулды да, чыжык-пыжык елап җибәрдем. Аптырый апа.

— И-и, бигрәк йомшак күңелле икәнсең,— дип, аркамнан сөя.

Йомшаклык бардыр анысы. Шулай да сәбәбе дә юк түгел бит. Матур язу мәсьәләсе мәктәптә укый башлаганнан ук килә. Күңелнең шешле урыны: «Апа, карале, монау малай гел басма хәрефләр белән яза!» — дигән әләк әле булса колак төбемдә яңгырый кебек. Әләккә каршы тора алмау, көчсезлегеңне тану гарьлеге, хәзергечә әйтсәк, комплекс. Алферова апа минем күңелдәге әнә шул шешле төшкә кагылган иде.

Икенче юлы күргәзелгән йомшаклыгым өчен үземне озак вакыт кичерә алмадым. Гөрләвекле апрель ае. Кырлар диңгезгә әверелгән — ап-ак су җәйрәп ята. Үзе күңелле, үзе әрнешле. Оек-чабата белән тездән су ярып бардык. Мәктәп алдына җиткәч, ни күрик, бер төркем балалар белән укытучылар безне каршы алырга чыккан. Геройларны каршылыйлармыни!

— Молодцы, курыкмагансыз! Булдыргансыз.

Класска кергәч, аякларны чишенергә куштылар. Ике кыз һәм мин, өчебезгә ап-ак йон оек бирделәр. Миңа тигәне кечкенәрәк булганга, көчкә сыйдырдым. Оекчан килеш парта арасына утыргач, башымны яшереп, чыжык-пыжык килеп, күзләрне уа башладым. Аяк әрнегәннән елый дип белделәр, мөгаен. Шунлыктандыр, Акчурина фамилияле укытучы апа, кырыс кына:

— Йәле, елап утырма, әнә кызлар да еламый,— дип куйды.

Тиз үк акылга килдем килүен, мәгәр оятка калган идем инде. Мөгаен, апа хаклы, шулай кискен сүз тиеш булгандыр. Ләкин апа йомшаруның сәбәбен белми. Ә бит сәбәп бүтән — кайгыртулы мөнәсәбәткә, җылы игътибарга күнекмәгән мин. Көндәлек тормышта син бармы, юкмы, барыбер. Булмасаң да беркем юксынмас иде. Ә менә бүген! Нинди ихтирам! Күңел тулмый нишләсен!

Шулай да бу ике очракта тамган күз яшьләре белән әлегесе җир белән күк төсле аерыла иде шул. Әлеге яшьләр әллә нинди үкенечле, бөтен гәүдәне сызлатып, яндырып саркыйлар иде.

Класска кергәнмен, берүзем утырам икән. Тамар яшьләр калмагач кына урынымнан кузгалдым. Коридорда беркем калмаган. Укытучылар бүлмәсе яныннан узганда гына, кемнеңдер барлыгы сизелде. Ишектән Нурҗиһан исемле укытучы, завуч апа чыгып, мине туктатты да, шул бүлмәгә чакырды. Анда да беркем дә юк иде. Апа артык борчылмаска кирәген аңлатырга тырышты. Кәримә апа кебек кычкырмады, янамады. Киресенчә, укуларның нәкъ элеккечә дәвам итәчәген искә төшерде. Миңа бүтән җәза бирелмәячәк. Киресенчә, мине укучылар комитеты председателе итеп сайлаячаклар. Гадәттә бу эшне соңгы җиденче класста укыган отличникка тапшыралар. Ә бу юлы алтынчы класс укучысын куялар учком председателе итеп. Моңарчы староста итеп кенә куялар иде.

Апа аркамнан сыйпап озатты. Һәм мин, өйгә кайтып кергәндә, тынычлана ук язган идем инде. Була язган фаҗига турында, мылтыкны милиционер алып киткәне хакында сүз булдымы, юкмы, хәтерләмим дә. Әнкәйнең үз хәле үзенә җиткән бит. Бәлки, әлеге хәлләр аның өчен бик кечкенә нәрсә булгандыр.

Тынычландым дисәм дә, билгеле инде, тынычлык безнең өлешкә тигән нәрсә түгел ул. Монысыннан да ныграк кайгыга салган вакыйга якында гына булып чыкты. Нәйрә апаның: «Дәүләт гармуны... Баяновлар тота ул!» — дип ысылдавы пошаманга салды мине. Кем әйткәндәй, үз эчемә кереп бикләндем. Гармун тавышы кешеләргә ишетелмәсен өчен, аны кич, караңгы төшкәч кенә уйный башладым. Уйныйм-уйныйм да кире футлярына салам. Ә көн яктысында күренми гармун, яшел сандык эчендә тавыш-тын чыгармыйча ята. Шулай итеп, музыканы сандык эченә салдык... Озаккамы?

* * *

Кәримә апа бишенче класста арифметикадан укыта иде. Озынлыгы чиксез диярлек мисаллар бирелә. Кәримә апа бер көнне шундый мисалларның берсен тактага язды да, безгә шуны чишәргә кушты. Эшем озакка сузылмады. Хәзер башкаларны күзәтеп кенә утырам. Янымдагы малай миннән күчерде. Башкалар күчерә алмый. Арттагы кыз муены озынайганчы сузылса да, дилбегә буе мисалны күчерү мөмкин түгел. Күрәм, класс чишә алмый мисалны. Шуңа ышангач, укытучыбыз такта янына бер укучыны чакырып чыгарды. Эшли алмый бала. Берничә буын язгач та шып туктала. Икенче, өченче, дүртенче кеше чыккач та, юк, мисал бирешми, ярты юлда калган хәлдә тик тора. Аптырагач, апа үзе күпмедер саннар өстәп караса да, юк, алай да барып чыкмый. Сизә апа, хәзер ул тиз арада оятлы булачак. Болай һич тә ярамый, аңа хәлдән чиста йөз белән чыгарга кирәк. Нишләсен, класска сорау:

— Кем эшләп бетерергә тели?

Кул күтәрүче бердәнбер мин булгач, мине чакыра апа. Чыккач, балалар язганны гына түгел, апа язганны да сөртеп ташлыйм да, үземчә дәвам итәм. Дөресен әйткәндә, кыскарак юл белән чишү мөмкин иде. Болай исә саннар бөтен тактаны тутырды. Ләкин чишелеш дөрес. Җавабы китаптагысы белән туры килә. Димәк, апа җайсыз хәлдән котылды. Мин, соңгы санны язып класска карагач, бераз сүзсез торды да, соңыннан сүренке генә:

— Ярый, бар утыр,— диде.

Нинди дә булса уңай фикер әйтерлек хәлдә түгел иде ул. Билге кую хакында, әлбәттә, сүз дә булу мөмкин түгел! Ләкин эченнән генә рәхмәтне барыбер әйткәндер, дип уйладым.

Мылтык вакыйгасыннан соң, алтынчы класс көйле генә узды, дияргә була. Кризис дип аталырлык хәлләр җиденче класста җыйналды. Беренче кыенлык, әле мин искә алган мисал төслерәк булып, укытучыларга кайтып кала. Чын укытучылар сугышка китеп беткәч, калганнарының кеше буларак та, белгеч буларак та үз укучыларыннан әлләни аерыла алмавы безне мөшкел хәлгә куйса, икенче сәбәп — безне колхоз эшенә йөртү. Әйтерсең, без — колхоз әгъзасы. Көн тудымы, олылар белән беррәттән кырга җибәрәләр. Ул елларда көз көне болай да укулар октябрьдән генә башлана иде. Анысы җитмәгән, укулар башлангач та бригадир искечә дәвам итә — һәр кич саен иртәгә нинди эшкә барырга кирәклеген килеп әйтә. Әнкәй, нишләптер, каршы түгел.

— Әнә яшьтәшләрең дүрт кенә ел укыды, бер дә үлмиләр,— дип кенә куя иде.

Мин моның сәбәбен аңламыйм, әлбәттә. Ул ни өчен нәкъ менә мине укытуга каршы булды икән? Әсгать абый үзе туктамаса, аны туктатырга җыенмады. Энекәшләр дә укый, аларны тыярга да нияте сизелми. Нәкъ менә мине тыя. Ник? Бит әткәй үлгән чакта: «Мөмкин булса, балаларны укытырга тырыш»,— дип, гозер калдырган иде. Ярый эштән файда килә торган булса. Ә бит эшләгән өчен хезмәт көненә бер генә грамм да ашлык бирелми. Шулай булгач, ник мине үземнең төп эшемнән, укудан аерырга тырышалар? Һәм максатларына ирешәләр дә. Инде җир каткан. Саламны Ишкарга чана белән ташыйбыз. Кичке якта Ишкар малайлары атларга: «Каерып ал» — дип, гаярь егетләрчә кычкыруымнан көлеп, читтән генә карап тордылар. Аларны укудан тыймыйлар икән.

Шушы көннән соң аларны сагынганымны, укуга тәмам сусаганымны тоеп, әнкәйнең дә, бригадирның да ай-ваена карамыйча, мәктәпкә киттем.

Тиз үк ачыкланганча, анда инде мин — элекке мин түгел. Югалган бер ай вакытны кайтару мөмкинлеге калмаган. Бигрәк тә — алгебрадан. Бу предметны былтыр гына унынчыны бетергән бездән ике генә яшькә олырак Гатуф Нәҗметдинов дигән малай алып бара. Үзе дә рәтләп

белмәгән фәнне. Мин исә, мисалларны аның өчен чишеп бирә алырлык түгел инде. Киресенчә, язга чаклы шактый интегә-интегә генә адәм рәтенә керә алдым. Башка фәннәр әүвәлгечә җиңел бирелсә дә, математикадан дәрәҗәмне кайтарырга мөмкинлек тәки тумады.

Яз җитте, каһәрле яз... Мине тагын басуга, сабан сөрергә күндерделәр.

Шундый матур көннәр бит югыйсә. Тургайлар, күкнең түбәсенә үк менеп, дөньяда кояш төсле сөенечләр барлыгы хакында җырлыйлар. Бөтен кырга сибелә бәхетләре. Син дә шулай шатланырга тиеш, сабанчы дус. Әмма сөенү кыен. Синең аягыңда ат башы хәтле чабата һәм аңа бер потлы ләпек ябышкан. Син шуны өстерә. Авыр уйларыңны өстерә. Алар чабатадан авыррак һәм киндерәләрдән ныграк чәбәләнгәннәр. «Ник мин ризалаштым бу эшкә? Берничә көннән — имтиханнар, ник шуларга әзерләнмим?»

Моның өчен — төп эшең өчен — сиңа вакыт бирелмәгән. Сабанны ташлап китсәң, сине алмаштырыр кеше юк. Димәк, сукранма, сызланма. Тизрәк атла. Атларыңны ашыктыр, селтә чыбыркы.

— На-а! Малкайлар, бирешмәгез. Сынатмагыз, әй!

Атларга ял биреп, биш чакрымны йөгерә-атлый гына узып, бер-ике имтиханны тапшырсам да, калган икесен: «Аның фәнне яхшы белгәнен беләбез, болай да яхшы билге куярга мөмкин»,— дип, бәхиллек бирделәр...

Хәзер ни, алда ни көтә?

Киләчәк белән бүгенге арасында — куе томан. Караңгы. Алда бернинди ут, яктылык җемелдәми. Җәй матурлыгы да күзне иркәләми хәтта. Күзләрне тир әчеттерә, арганлык буыннарны йомшарта. Хатыннар белән печән чабасың. Син һәм Хәмит исемле иптәш малай. Чалгыларны Самат дигән сиксән яшьлек бабай чүки, үткерләп бирә. Чалгыларны көйле генә селтәгәндә дә сүз таба үзе:

— Әй, сез, кием калыплары, ник тураеп каттыгыз, иелебрәк, бөгелебрәк чабыгыз!

Тәнәфескә тукталганда, хатыннар да төрлечә шаярткан була, егетләргә санамакчылар безне. Бөтен шатлык шуның белән бетә.

Төшке ялга кайткач, ике-өч сәгать тагын үз йортың өчен чабасың печәнне — көндәгечә, еллар буена дияргә кирәк.

Көзгә таба егерме биш чакрымдагы Дүртөйле авылыннан, нефтебазадан керосин ташырга куштылар. Ничә мәртәбә барылгандыр, сан бутალмыш. Ишкардан бер олы агай белән йөрибез. Минем ат начаррак булганлыктан, ул мине еш кына ташлап китә, үзем генә интегәм. Бер көнне ачудан ярсынып, атымны (Казый аты дигән бик тә үшән ат иде) катырак кыйнадым бугай. Колхоз председателе Килмит рәнҗегәндәй шелтәләде. Ат өчен дә, үзем өчен дә әрнүдән, үкенүдән башка чара булса икән лә! Юк шул. Хәлләрнең җиңеләер чамасы күренми. Икенче юлы авылга караңгы төшкәч кенә кайтып җителде. Ике-өч өй узгач арбаның кендеге сынды. Хәзер нишләмәк кирәк? Шул инде, атны тугарасың да кайтып мендәргә авасың. Иртән иртүк Сафуан абзый килеп җитә. Мичкәдә керосин шактый кимегән, имеш...

— Мин бер грамм да керосин алмадым, теләсәң, тентү керт,— димен.

Абзый — ык-мык. Нишләтә ала ул мине? Кайсы да булса үз колхозчысына бик тә керосин кирәк булган, димәк...

Шундый-шундый хәлләр менә. Бит әле болары гына җитмәгән, алда тагын да хәтәррәкләре көткән. ФЗУ дигән мәктәпкә укучылар кирәк икән. Авылдан мине һәм миннән бер яшькә олырак Әзһәр исемле малайны җибәрмәкчеләр.

Хәбәрне ишеткәч, ындыр ягындагы саз буенда елап торганымны күргән Талиба апа:

— Егет кеше еламый инде,— дип оялткач кына, көчкә-көчкә генә тыйдым үземне.

Китәргә туры килде. Районнан егерме-утыз малайны Дүртөйле пристанена алып килделәр.

Агыйделнең сихерле матурлыгын пароходлар бермә-бер арттыра. Ерактан ишетелгән гудоклары җанның әллә нинди тирәнлекләренә үтеп, сокландыра һәм шомландыра. Алар күпме кешеләрне алып киткән дә кай җирләргәдер илтеп ташлаган, олактырган. Безнең күрше туганнарыбызны ике-өч ел элек кенә Себер дигән җирләргә алып киткән иде ул. Йорт хуҗасы булган абзыебызның шул чакта башыннан кепкасы суга очып төшкән. Яман фал. Абзый, Себергә барып җиткәч, озак та яшәмичә, дөнья куйган.

Менә без дә пароходка утырачакбыз. Ниләр көтә безне, нинди хәлләр? Җитмәсә әле, чын пароход та туры килмәде, буксир дигәннәренә төяделәр безне. Анысы угата да[1] яман кычкыра, колакларыңны куш куллап капла... Менә шулай, юлда барабыз. Буксир төтене төсле булып, арттан кара уйлар иярә. Күңелгә ямансу җыр килә:

Су өсләрендә пароход,
Ямансу тавышлары...

Халыкта бу җырның дәвамы юк. Ул минем шул чактагы хисләрдә дәвам итә.

Утырдым пароходларга,
Утырдым ал таңнарда.
Ул безнең газиз башларны
Илтеп ташлар кайларга?!

Су өсләрендә пароход,
Ямансу тавышлары.
Ямансу тавышларында
Аерылу сагышлары.

Уфаның затон дигән җиренә китерде безне буксирыбыз. Монда да эшләр пароход белән бәйләнгән булып чыкты. ФЗУ дигән мәктәп пароходта йөзәргә өйрәтә икән. Безгә шул мәктәптә укып чыккан «кадрларны» күрсәтәләр: якын киләчәктә менә сез дә шушындый матур кешеләргә әйләнәчәксез, янәсе. Ә мине, ни өчендер, мондый матурлык кызыксындырмый. Миңа Әшмәнем, туган авылым кирәк. Монда иртәләрен әтәч кычкырып уятмый, тавыклар кытакламый, басу капкалары ягында тузан күтәреп, кичке якларда көтү кайтмый, атлар кешнәми... Кала шау-шуы — миңа ят. Мин — имчәк баласы, туган җирем сабые, аннан аерыла алмыйм мин. Җан әрни, әрни, елап аргач, хәзер яшьсез елыйм инде.

Безне озата килгән абыйлар китеп өлгермәгән әле. Алар белән очраклы рәвештә, базар сыманрак җирдә күрештек. Нindидер сатучы шунда перцовка дигән бер ярты эчемлек сузды да: «Менә бик очсызга гына бирәм»,— дип аны кулыма ук тоттырды. Тегене-моны уйламастан (тиле булгач тиле инде), күпмедер акча биргәнне якташларым күреп торды. Елап кып-кызыл төскә кергән күзләремә карап, берсе:

— Бик кайтасың киләме? — дип сорады.

— Барыбер кайтам. Кайтмасам, суга төшеп үләм,— дигәнемне сизми дә калдым.

Сүз әйтелгәч, нишләмәк кирәк. Агыйделгә таба атлый да башлыйм. Ярый әле, яшьрәге куып җитте дә кулымнан эләктерде. Юлыма аркылы төште. Әгәр тоткарламаса, мин үземне беләм, батып үлмәсәм дә, барыбер шул бозлы суга сикергән булыр идем.

— Җитте, юләрләнмә, иртәгә бергә кайтырбыз.

---

[1] Ягъни үтә каты, нык мәгънәсендә. *Диалект.*

Сүзләрендә тордылар да. Пароход белән юлга чыктык. Ярты юлны узгач, өске каттан төшеп, яшьрәк абый мине үз кабиналарына чакырды.

— «Перцовканы» алып мен.

Мин ул шешәне өйгә кайткач урман каравылчысына диебрәк алсам да, боларга җәл түгел, кире алып кайталар лабаса. Һич икеләнүсез үтәдем сүзләрен. Өлкәнрәк абый, шешәне ачар алдыннан: «Авырып китүе сәбәпле, училищедан кире кайтарылды»,— дигән язу бирде дә, пәке белән сургыч бөкене кырып төшерде.

Ярты стаканнан кимрәк итеп, миңа да бирделәр. Аннары аскы катта, мичкәләр арасында идәнгә яткан килеш, йоклап киткәнмен. Уянуыма, аяктагы кунычсыз галушның сыңары юкка чыккан. Бер генә галуш киеп, оекчан килеш ничек кайтырмын? Инде җирдә кырпак кар ята. Озакламый — пристань. Ничек, ничек кайтырга? Әмма ничек кайтканым хәтердә калмаган. Димәк, нинди дә булса чарасы табылган булып чыга. Оекчан кайткан булсам, онытыласы нәрсә булмас иде.

Мин кайтканнан соң бер ай чамасы вакыт узгач ук, Әзһәр дә качып кайтты. Кышны бергә уздырдык, дус булдык. Әмма табигать яңара, үсә, чәчәк ата торган чакта, ул септик ангина дигән кан чиреннән вафат булды. Әгәр Уфада, училищеда калган булса, әлбәттә, исән калыр иде. Безгә күргәзелгән шәп кешеләрчә, пароходларның берсендә Агыйдел буйлата дөнья гизгән булыр иде. Их мин, их Әзһәр! Авылдан аерыла алмыйча, шәһәрне ташлап кайттык. Туган җиргә булган сукыр мәхәббәт алып кайтты безне кара язмышка.

Мәхәббәт һәлакәткә китерә... Нишләп? Нишләп болай? Кешеләрнең иң изге хисе, мәхәббәте нишләп һәлакәтле булырга тиеш соң? Аңламыйм, аңлата да алмыйм.

Әзһәр үлгәч, мин тәмам өмет җуйганмын, үзем дә үлемгә әзерләнгәнмен. Соңыннан әни әйткәнчә: «Барыбер үләбез, бәрәңгене утыртып та тормыйк»,— дигәнмен. Бу хәтлесе истә юк. Мәгәр әнкәй минем чаклы ук бирешмәгән, бергәләп, бәрәңгене утырткан быз. Һәм... исән калганбыз.

* * *

Тагын җәй, тагын печән өсте.

Кичке караңгыда (лампа яндырмыйча) гармун уйный идем, Сафуан абзый пәйда булды. Котым очып, тиз генә гармунны футлярга салмакчымын.

— Тукта әле, ашыкма,— дип боерды абзый.— Бир әле, мин дә уйнап карыйм.

Караватка утырып, аннары миндәргә авып, элек үзе белгән, сугышка хәтле яңгыраган шатлыклы көйләрне яңартмакчы, бичара. Мәгәр кая ул, бармаклары буйсынмый үзенә. Гармунны биш-ун минут интектергәннән соң, кире бирде. Ялындырмыйча уйнадым. Сафуан абзый — кырыс холыклы кеше. Шулай да әсәрләнеп китте.

— Булды, шәп. Булмый болай, иртәгә үк — болынга. Гармунны ал да... Иртәгә үк. Алырга ат килер.

Гармунны кешеләргә күрсәтергә ярамаганны әйтеп карасам да, айвайга карамады:

— Юкны сөйләмә, беркем дә сүз әйтә алмас. Үзең өчен генә түгел бит, бөтен колхоз өчен...

Шушы сүзләрне вәгъдәгә исәпләп, ризалаштым. Икенче көнне урамнарны, юлларны, әрәмәләрне шатлыклы моңнар белән тутырып, без утырган атлы арбалар келтерәп узды. Болында, әйтерсең, элеккеге тыныч дөнья терелде.

Нәкъ тыныч чактагыча: уен-көлке, җыр-бию... Чалгы янугычлаган тавышлар. Уртак мул табын. Арулар исәпкә керми. Олылар арасында — без, өч малай. Зурлардан һич калышмыйча, печән чаптык.

Кичләрен, инде әйтелгәнчә, бөтен тирә-як безнең куышлар янына җыела, гармун янына, без яккан учаклар янына. Кичке уеннар, җыр-биюләр таң сызылганчы дәвам итә. Печән өсте җырсыз, мәхәббәтсез буламы инде? Әйе, барысы да булды. Хәзер ышану да кыенрак инде. Әнә бит, унбиш яшь тулып ярты гына ел узган булса да, син дә үзеңне зур кеше итеп тоясың. Ник дигәндә, бүтәннәр сине шулай кабул итә. Алар сине мәхәббәт иленә чакыралар, алып китәләр. Һәм син иярәсең. Иярәсең дә... Тик бервакыт авылга, туган өйгә, әниең янына кайтасың килә башлый. Яшьлеккә хас мәхәббәт авылга, өйгә, әнигә булган мәхәббәт хисләре белән каршылыкка керә. Дусларыңны ташлап авылга кайтырга җыенгач, аларның сиңа хәтерләре кала...

Һәммә нәрсәне, хәтта мәхәббәтне дә вакыт үзенчә хәл итә. Болында гомерлеккә кала алмыйсың. Печәннәрне чабып-җыеп кибәннәргә салгач, барыбер таралышырга туры килә.

— Сау булыгыз инде, Агыйдел буйлары! Хушыгыз, әрәмәләр! Су өсләрендә йөзгән пароходларыгыз безне инде чакырмасын, әсәрләндермәсен! Тыныч кына үз авылларыбызда гомерләрне дәвам итик!

Әйе, калды болын, кайчанга чаклыдыр, ямансулап Агыйдел калды, дулкыннарын тыя алмыйча, һаман алга атлыгып калды...

Кышка таба яңа шөгыльләр кирәклеге алга килеп басты. Сафуан абзый мине Ишкардагы терлек фермасына хисапчы итеп куймакчы иде, болын-кыр киңлекләренә күнеккәнгәме, тирес исе күңелемә ярап бетмәс сыман тоелды. Аннары: «Кибетче булмыйсыңмы?» — дип карады. Анысына: «Мин бер айда ук растрата ясап харап булачакмын бит»,— дигәч, кыстап азапланмады.

* * *

Гармун кыйссасын башладым да, ташладым бугай. Шуны дәвам итик әле.

Мине беркайчан да укытмаганга күрә, якынлыгы булмаган Нәйрә апа: «Дәүләт гармуны» дип куркытканчы, гармун белән бик иркен йөри идем. Кышларның берсендә укытучы абый-апалар, клубта концерт күрсәтергә әзерләнеп, мине дә чакырдылар. Гармунның футляры бик авыр булганлыктан, аны әле биш чакрым җиргә күтәреп бара алмыйм. Шуңа күрә ат җибәргәннәр. Әшмәнгә ана теле укытучысы Акчурина апа үзе килгән.

— Кайтарып та куярсызмы? — дим.

— Кайтарып та куярбыз, идарәдән ат алырбыз,— дигән вәгъдәгә каршы ни әйтәсең?

Кышкы матур кичтә идарә аты җигелгән кашавайда бару үзе бер бәйрәм ләбаса. Сөенә-сөенә киттем инде. Концертта шул ук матур хисләр яңарып, җыр-бию дәрте белән берләште, мин сиңа әйтим. Зурлар арасында үзем генә булгангамы, игътибар да зур иде. Концерттан соң хәтта сәхнәгә менеп, олы-олы абыйлар минем белән гәпләшүне мөгькуль таптылар. Кайвакыт тавыш бизәкләренең ритмнан чыгып киткәләгәненә хәтле игътибар иткәннәр. Анысын үзем дә сизгән идем, билгеле. Шул кадәр бирелеп тыңлауларын кара син!

Менә шулай моңарчы билгеле булмаган сәхнә уңышы килде. Тик азагы гына хәерле була алмады шул.

Иртән иртүк торып, өйгә кайтыр өчен ат көтә башладым. Сабыр гына көтәм — юк. Сабырсызланып көтәм — юк. Акчурина апа өенә барам, апам — ык-мык. Моның мәгънәсе шул: атны ападан түгел, идарәдән сорарга кирәк икән.

— Апа, илтеп куярбыз дип, сез вәгъдә бирдегез бит?

— Бирсәм дә... Мин нишли алам, утарымда ат бар мәллә? Идарәгә бар.

Бу сүзләрнең таяк белән башка суккандай тәэсир иткәнен аңлыйсыздыр инде. Аңгы-миңге хәлдә киттем идарәгә. Килмит ат белән әле генә каядыр китеп барган. Бүтән ат юк. Булса да, конюх аны үз белдеге белән генә бирә алмый. Менә шулай. Кемгә үпкәләргә? Конюхка түгел, әлбәттә. Алдаган кешеләргә. Укытучы апага. Укытучыларны изгегә санап, аларны гел дөресен генә сөйли дип күнеккәнгә һәм шуңа чын-чынлап ышанганга күрә, Акчурина апага рәнҗедем. Менә сиңа укытучы!

Ул көнне ат булдымы, юкмы, икенче көнгә калдыммы, ат беләнме, әллә бәләкәй чана тартып кайттыммы, истә калмаган. Әле дә истә сакланганы — укытучы апа ялганы. Беренче алдануларның иң ачысы...

Бүтән вакытларда мондый хәл килеп чыкмый иде. Клубка спектакльме, киномы күрсәтелгәндә, атны үзебезнең авылдан алып, кумәкләшеп барасың да шулай ук кире кайтасың. Тамашалар алдыннан концертны «мин бирәм». Саратов гармуны белән килүчеләр тынып тора. Аларның һаман бер үк көйләр — урам көе һәм «Шахта». Минем уйнаганым исә — әле күптән дә түгел агитбригада артистлары башкарган катлаулырак әсәрләр: «Сибелә чәчәк», «Карлыгач», «Дөм-дөм» һәм шулай ук композиторлар әсәрләре — Сәйдәшнең «Гөлйөзем ариясе», Ж. Фәйзинең «Яшь наратка сөялеп көтәм сине» (Фатих Кәрим сүзләре), «Йөрәк җыры» һәм башкалар, һәм башкалар.

Кайтышлый концертны авылдаш малайлар, кызлар дәвам итә. Аларның берсе — Әзһәр, җырлый да, саратов гармунында үзе дә уйный. Хәмит җырга сирәк кушыла, ишетелер-ишетелмәс кенә шыңшый. Мәгәр гармун уйныйсы килеп йөргән икән. Бер көнне шул хакта сүз чыкты. Мин инде баян турында хыяллана идем. Хәмитнең баянда уйный алмаячагын беләм, ә гармунда бәлки өйрәнер дигән өмет бар.

— Әйдә, алайса,— мин әйтәм,— миңа баян алыйк та, монысы сиңа булыр.

Хәмитнең чырае кояштан яктырак балкый:

— Әйдә, кайчан?

— Аның өчен баян табарга кирәк.

— Син үзең тап, бәясен мин түләрмен.

Шулай итеп, бик җиңел килештек.

Баян эзлим хәзер. Иң якын базар — Яркәйдә, район үзәгендә. Шунда барам. Баян түгел, гармун сатучы да юк. Андреевка дигән авылда гармун ясаучы оста бар иде, шунда барып карыйм. Оста вафат. Авылында да аның гармуны да, баяны да калмаган. Ичмасам, истәлек өчен генә дә. Тагын буш кул белән кайтам. Йөри торгач, өмет өзелде. «Теге елларда тавышы ишетелеп калган баян кайда икән? Уйнаучысы безнең районныкы иде. Ул армиягә киткәч, баяны калмады микәнни? Кайсы авылда икән? Нишләп тавышы ишетелми? Һичюгы — хәбәре?»

Шулай уйлап, якын-тирә авылларга һаман барыштырам әле. Авылларның берсендә август аенда киез эшләпә кигән бер бабайдан сорыйм. Югары очта кайчакларда бердәнбер гармун тавышы ишетелгәли икән.

— Баянмы?

— Шулайдыр, кайдан белим, үзең барып күр.

Барып күрсәм, бер октавалы — сигез телле тальян. Бас ягында, халык әйтмешли, бакалар гына. Хуҗа сатарга риза. Бик тә очсызга биреп җибәрде. Бушка дисәң дә ярый инде. Ләкин хикмәт андамыни. Хикмәт — Хәмиттә. Булган кадәресенә дә кулына кош эләккәндәй шатланды.

— Шушында өйрәнә тор,— мин әйтәм,— соңыннан күз күрер тагы.

Күңелеңдә көең булмаган көе, ничек гармун уйнарга мөмкин соң? Теләге тормышка ашмады малайның. Минем бармакларга аның бармакларын бәйләп уйнап карыйбыз — көй чыга. Үзе генә уйнаса, юк. Шулай озак азапландык. Эштән чак кына бушаса, күтәрә дә керә гармунын. Тагын бармакларны бәйлибез. Аннары тагын мин уйнаганны карап тора да, кайчан кайсы телгә басылганны хәтеренә сеңдерергә тырыша. Икеме, өчме айдан соң бик гади көйләрнең «скелетларын» уйный башлады.

Эшкә барышлый, өй турларыннан узганда, шул көйләр ишетелеп кала иде.

Җәй азагы. Колхоз эшеннән кайтып төшкелекне ашагач, үзебезгә печән чабу өчен урманга китәм. Күпмедер йөреп кайтуыма, капка төбендә авыл Советы секретаре Шәйдуллина Мәүлиха белән Шәйди исемле милиционер басып тора. Йөрәк жу итте. Чырайларына һәм моңарчы булган гамәлләренә караганда, юньле эш белән йөрмиләр. Уем тиз арада расланды да. Өйгә кергәч, стенадагы рамаларны, фотосурәтләрне тикшереп чыккач та, Шәйди гармун уйнап күрсәтүемне сорады. Уйнадым. Мактаган булды.

— Җирле районда даның йөри. Шәп. Хәзер мин уйнап карыйм инде. Бир әле.

Чынлап та уйнарга азаплана бугай дип, гармунны биргән идем, кая ул, каешларны каптырды да, чыгып та бара. Секунд арасында гармунның каешыннан эләктердем. Ул тарта, мин ычкындырмыйм. Мәүлиха кычкыра, милициягә каршы торуның начар бетәсен әйтеп куркыта. Ә мин куркудан узган. Шәйди пистолет чыгаргач та бирешәсе түгел идем. Тик шул мизгелдә әнкәй кайтып керде дә:

— Балам, бир, бир,— дигәч кенә, бармаклар язылды.

Ләкин хәзерге көнгәчә үкенәм әнинең шул сүзен тыңлаганым өчен...

Киттеләр. Каттым да калдым.

Озак та үтмәстән, Хәмит күршем керде. Урам уртасында, янгын алачыгы янында тукталып, гармунны уйнап карый икән Шәйди.

— Миннән дә начаррак уйный,— дип көлде дустым.

Шаян сүз белән мине юатмакчы, хәлемә кермәкчедер, дип уйлыйм инде. Ләкин ул миннән көлгән генә икән. Анысы соңынтын беленде.

Икенче көнне үк Ишкарга, Сафуан абзыйга ярдәм сорап бардым. район вәкилләре белән ниндидер бик ашыгыч эш артыннан йөриләр, имеш. Вакыт юк, дип, тиз генә ары атлады.

— Икенче вакыт сөйләшербез,— дигән булды.

Мәгәр «Икенче вакыт» та табылмады. Зур эшләр башкарганда, шәхси йомышлар исәпкә керәмени! Минем кайгымыни, ил кайгысы лабаса! Ил хакында уйлаганда, шәхеснең кирәге бетә...

Кирәксезлегемнән исәңкереп, өйгә кайтып егылудан башка чара калмады. Аннары кая гына язмадым! Район прокурорына, милициягә, Уфага — югары прокуратурага. Барысы да җавап бирә: копиясе район прокурорына, гармунны кире кайтарып бирергә кушалар. Район прокурорына барсам, анысы рәтләп сөйләшми дә. Шундый газаплар белән көз үтте, кыш килде. Анысы да узып, тагын җәй килде. Аның тагын азагы. Мине судка чакыралар. Дер калтырап керәм судьяга. Утыз яшьләр чамасындагы карарак чырайлы, мәгәр чибәр кыяфәтле кеше. Шәйди кебек тәкәббер кыланмый. Утырырга кушты, утырдым. Үзе тиз арада чыкты да, шулай ук тиз арада кабат керде. Йа хода! Кулында — минем гармуным! Җаным сыман күргән кадерле гармун! Судья шуны миңа сузды:

— Йә, миңа уйнап күрсәт инде,— ди бу.

Калтыравымны көчкә-көчкә тыеп, гармунны тартып карыйм. Йа Алла! Эче — буп-буш! Мехы тишкәләнеп беткән. Җанын алганнар гармунның. Аптырагач, судьяга карыйм. Нишләсен, ул ярдәм итә аламыни хәзер. Иңнәрен генә селкетеп куя.

— Көй бөтенләй чыкмаслыкмыни?

Көй чыгарлык анысы — әгәр бик тырышсаң. Телләре бозылмаган, карлыга гына төшкән. Шул хәлдә уйнап карыйм. Көйләрнең гадирәкләрен. Судья тыңлый, мин уйныйм. Мин уйныйм, ул җырлап та җибәрә. Сизелеп тора, моңы бар. Ә моңлы кеше явыз була алмый. Шул уй белән эчкә җылы кергәндәй тоела. Һәм өмет аклана да. Күпмедер утырганнан соң, судья абый урыннан тора:

— Булды, рәхмәт.

Әйе, шул сүз дә әйтелде. Аннары өстәл өстендә торган күп кенә кәгазьләр арасыннан бер төргәк чыгарып, миңа сузды:

— Судка чыгарып тормыйбыз, чөнки бүтән дәгъвачы юк. Гармун — синеке.

Минем моңарчы моннан да сөенечлерәк һәм акыллырак сүзләр ишеткәнем булдымы икән? Юктыр, булмагандыр. Бу судьядан ягымлырак, әйбәтрәк кеше дә юктыр дөньяда һәм булмастыр да!

Тойгылар — шундый. Әмма мин аларны сүзгә әйләндерә алырлыкмыни! Юк, әлбәттә. Рәхмәтне дә ничегрәк итеп кенә әйттем икән әле. Хәтерләмим. Рәте була алмагандыр, дип уйлыйм. Кулга кош эләккәндәгедән ныграк сөенеп, үзем кошка әйләнеп, канатсыз очтым. Кайтып житкәч кенә, кулдагы кәгазьләрне карарга кирәге искә төште. Кечкенә эш өчен нихәтле кәгазь җыйналган! Үз хатларым белән бергә, әллә нинди оешмалардан, кешеләрдән алынган язмалар, хатлар, протоколлар. Актарып карыйм, укып карыйм. Бермәлне күзләремә ышанмый торам. Протокол дигәне — Хәмит күршем, Хәмит дустым сүзләре ләбаса! Аның сөйләгәнен Шәйди язып барган да, соңыннан кул куйдырган. Сөйләгән сүзләрем дөрес язылган, дип, имзасын салган... минем ахирәт дустым!

Гармун күтәреп кайтканны күргәндер, мөгаен. Озак та үтмәстән, гармунны талап чыкканнан соң хәл белергә беренче кеше булып кергән кебек, шатлык уртаклашырга беренче керүче дә ул булды. Кергәч тә имзасын күрсәттем. Кызарды гына, ләкин югалып калмады. Характер — нык, әйтерең бармы!

— Булса ни, мин дигән кеше юк бит әле.

Әйе, күзгә карап шулай ди күршем.

Бүтән ни әйтсен, шуннан соң мин нәрсә әйтим? Ярый, төпченмәдем, ачу да сиздермәдем, чөнки шатлыгым чиксез иде, барча вак-төякне шул күмгән иде. Хәерле булсын, үлмибез бит әле, алда тагын күз күрер. Һәм шунысы бар: мине генә түгел, авылны, бөтен якын-тирәне гармун тавышыннан мәхрүм иткән иде бит ул. Мине алмаштырмакчы булгандыр. Әмма хыялы буш булып чыкты. Күрше авылларга түгел, үзебезнең бер урамлы авылга да гармун күтәреп чыга алмады ул. Азмы-күпме мин өйрәткән көйләре үз өйләре диварларыннан узмады. Ходай ярлыкасын үзен. Һәм тагын бер гаҗәп нәрсә, без, әйтерсең, чын мәгънәсендә ачуланышмадык та, алай гынамы, әүвәлгечә дуслар булып калдык.

Гармунның җанын алганнар, дигән идем бит. Мин аны, Уфага барып, ремонтлатачакмын. Гәрчә монысы соңрак булыр...

* * *

Безгә Әсгать абыйның агитбригадада бергә эшләгән танышы — Газимә апа килеп йөри иде. Ул мине налог җыю буенча хисапчы булып эшләргә күндерде. Ишкарда квартирда торып эшли башладым. Налог агенты — миннән бер-ике яшькә олырак кыз, инспектор — Газимә апа үзе. Авыл Советына караган биш авылның барысына да барып, акча җыябыз. Башта әллә ни сизелмәсә дә, алда шактый гыйбрәтле хәлләр көткән икән.

Яңа елда хуҗалыкларга салым билгеләү өчен һәр йорт исәпкә алына. Монысын эшләп чыктык чыгуын. Әмма Райфо дигән җиргә ниндидер таблица кебек язма әзерләргә кирәк. Ачуың килмәгәе, өстәл хәтле калын гына кенәгә тулды. Шуны күтәреп, Райфога миңа барырга туры килде. Анда берничә көн тирләп-пешеп газаплансам да, очына чыга алмыйм моның. Бухгалтерларның өметсез карашларына түзә алмый башлагач, кире кайттым. Миннән соң налог агенты үзе барды һәм, сизүемчә, ул да көч-хәл белән генә эшне төгәлләп кайтты.

Шушы булды эштән күңел кайтаргыч бер сәбәп.

Икенчесе дә көттермәде.

Сугыш заманындагы акча бүгенге Ельцин акчаларыннан бераз гына кыйбат иде. Шактый җыела салым. Бер юлы ярты капчык булгандыр, мин сиңа әйтим. Накладнойлар тутырдым да, капчыкны алып, квартирга кайттым. Кич авыл Советы, колхоз идарәсе тирәсендә буталып йөргәннән соң, икенче көнне, капчыкны күтәреп, үзебезнең өйгә кайттым. Иртән иртүк район үзәгенә барып, акчаларны банкка китердем. Озак кына исәпләде кассир апа. Ниһаять, санаудан тукталып, накладнойга карады.

— Ике мең сум акчагыз чыкмый.

— Чыгарга тиеш.

— Мәгез алайса, үзегез исәпләгез.

Тагын бер сәгать чутлап баш катырыргамыни инде?

— Ярый,— димәк,— булганча язгыз.

Шулай эшләнде дә. Җилкәмдә ике мең сумлык растрата күтәреп, Ишкарга кайтырга мәҗбүрмен. Квитанцияне салым агентына тапшыргач, кая икәнен дә әйтмичә, Әшмәнгә ашыктым. Һәм шуннан соң авыл Советына тиз генә аяк басмадым. Унбиш-егерме көннән соң Газимә апа үзе килә.

— Синең анда ике мең сум акчаң чыкмый. Әллә берәрсеннән алмый калдырдыңмы?

— Алдым.

— Кассада юк бит ул акчалар.

Бер сүз дә әйтә алмыйм. Апа кайгыра:

— Нишлибез соң алайса?

Тагын җавабым юк, кызарам гына, ягъни битемнең кызышканын сизәм. Газимә апа үзе дә, нәрсә әйтергә белмичә, китеп барды.

Соңыннан, нишләптер, түләтәбез дип, борчымадылар тагы. Колхозда эшләп күнегелгәнчә, монда да, дүрт ай эшләгәч тә хезмәт хакы сорый белмичә, бер тиен дә алмый киткән идем. Шул җиттеме, Газимә апа бүтән җай таптымы, ничек булса да, миңа Газимә апаның Әсгать абыйга булган дусларча карашы ярдәм иткәндер, дип уйладым.

Югалды, очты ике мең сум. Ә кемнән шикләнергә? Хуҗабикә ападанмы? Андый гадәте барлыгы ишетелми, сизелми иде. Әнкәйдәнме шикләнергә? Бердәнбер кеше кала — кассир апа. Димәк, мондый хәлнең кабатлануы ихтимал. Димәк, миңа ул бәндәләрдән ерак тору мәҗбүри. Шулай хәл иттем дә.

Бу эштән китәргә мәҗбүр иткән өченче бер хикмәтле сәбәпне онытa язганмын икән. Анысы болайрак булды.

Салым өчен үзебезнең авыл кешеләре исемлеген төзегәндә, үзебездән башлап барлык өйләрдә яшәүчеләрнең барчасы теркәлде. Шул исәптән, хезмәт армиясеннән әле генә кайткан Гомәр абзый да санга сугылмыйча калмады...

Хикмәттер, мин эш ташлап кайтканның икенче атнасында ук, кемнәрнедер ияртеп, безнең авылга авыл Советы рәисе килеп төште дә, туптуры Хәмитләр өенә кереп китте. Капкадан бик ашыгыч рәвештә кереп китүләрен мин дә күреп калдым. Авылда сер озак саклана алмый, чыбыксыз телефон аша шундук фаш ителә. Рәис абзыйның ни өчен килүе дә шул ук көнне билгеле булды. Гомәр хезмәт армиясе дигән җирдән котылып түгел, ә качып кайткан булган икән.

Рәис килгәннән соң өч-дүрт көн узгач, иртәнге якта безгә Хәмит керде. Тыныч кына аның белән сөйләшеп утырган җирдән сискәнеп киттем. Дөп-дөп тәрәзә кагалар. Хәмитнең апасы каушаган кыяфәттә кычкыра:

— Хәмит, чык, әтәй үлә!

Алар өендә әти-әнине, нишләптер, әтәй-инәй дип атыйлар иде.

Күрше хәлен күрше белергә, читтә калмаска тиеш. Хәмит белән бергә, без дә алар өенә керәбез.

Гомәр урам як сәкенең уртасында нәкъ үлгән кыяфәттә сузылып яткан. Тып-тыныч үзе. Үлем газабы кичергәнлеге һич сизелми. Тиз арада

җыелып өлгергән бүтән кешеләр дә шуны сизгәндер, мөгаен. Авылыбызның Нурислам атлы мөхтәрәм кешесе:

— Курыкмагыз, исән, үлми,— дигәч, барыбыз да иркен сулап куйдык. Безне тынычландырган агай берничә минуттан чыгып та китте. Яныннан узганда, мин аның сак кына елмаюын шәйләдем.

Әйе, спектакль иде бу. Әйтергә кирәк, Гомәр абзый үзе сайлаган рольне ярыйсы гына башкарды. Шулкадәр халык алдында, сау-сәламәт икәнеңне белгән килеш, көлмичә, һич югы елмаймыйча түзеп кара син!

Хикмәт нәрсәдә?

Мин үзем болай чамаладым. Бәлки, салым тәгаенләнгән кешеләр исемлеген рәис күреп, Гомәр абзый кайтканны шуның аша белгән, дип уйлаганнардыр. Димәк, эшкә мин дә катнашкан булып чыгам. Бәлки исемлеккә кертелүен Гомәр абзыйдан теге елгы печән өстендә мине «кызык иткән» өчен үч алу түгелме, дип исәпләгәннәрдер. Гөнаһларына керәсем килми, үзләреннән мондый киная сизмәдем. Мәгәр Хәмит белән дуслар булган авылдаш бер кыздан Гомәр абзыйның хезмәт армиясеннән качып кайтканын Әхсән хәбәр иткән, ахрысы, дигән сәер сүз ишетергә туры килгән иде. Спектакльне миңа күрсәтү сәбәбе шунда булса, гаҗәп түгел. Максат: абзыйны Әхсән кызгансын да, бүтән бәйләнмәсен.

Нинди беркатлылар без! Мәкерлерәк, хәйләкәррәк булса да, Гомәр абзый мине шундый көчкә ия дип, авыл Советында нәрсәнедер хәл итешә алырлык дип уйлый алган булып чыга бит! Ә мин анда бүтән барасы да түгел, барсам да бу хакта сөйләшәсе кеше түгел. Алла сакласын!

Уйлыйм ки, авылдан беркем түгел, Гомәр абзыйның качып кайтуын эшләгән җиреннән хәбәр иткәннәр булырга тиеш.

Инде шунысын өстәргә ярыйдыр, минем катнашымнан башка, бер көнне Гомәр абзый юкка чыкты. Ташлап кайткан эшенә үз теләге белән киттеме, әллә төнлә җитәкләп алып киттеләрме, безнең өчен караңгы иде. Ләкин аңа карап абзыйның язмышы фаҗигагә юлыкмады. Сугыш беткәнче үк исән-сау гына кайтып, озын һәм тыныч гомер кичерде.

* * *

Сугыш елларын кичергән кешеләр өчен сугыш — азагынача туктап бетми. Ул чактагы вакыйгалар, хәбәрләр, һич көтмәгәндә бүгенге тормышка, шушы юлларны язган көннәргә килеп керә. Шартламый калган мина шикелле, ярты гасырдан соң атылып, хисләрне яралый. Инде ничәнче кабаттыр, хәтердәге мина ярчыклары җанымны менә тагын бер мәртәбә җәрәхәтләде. Әйтерсең, яшьле, канлы, караңгы елларга яңадан кайттым. Әйтерсең, шул еллар хәтеренә манчылдым. Әйтерсең, кара күздә, шыксыз буранда чыланган өс-башымны тагын бер тапкыр кибәргә эләм. Киемнәр кипкән арада әле матурлык турында уйлыйм, шигырьләр язам...

Туган җиремнән, әйтерсең, еракта калган караңгы дөньядан һич көтмәгәндә, калын гына конверт белән хат һәм кайчандыр үзем язган шигырьләр төргәге килеп төште. Илеш районының ветераннар советы председателе Фазылҗан Хөрмәтулла улы Хөрмәтуллин бөек Җиңүнең 50 еллыгына әзерлек чорында архивлар актарганда, район газетасы архивыннан минем шигырьләр җыйналган бер «Дело»га тап булган. Һәм шуны миңа җибәргән. Хатында шундый сүзләр: «Бу мине кызыксындырган кебек, үзегезне дә кызыксындырыр сыман, чөнки 50 елдан соң узган чорга борылып карау, искә алу, бигрәк тә шул чор яшьлеге белән очрашу үзе бер гомер, яңарыш дип уйлыйм. Беренче шигырь формалары ничек барлыкка килгән, нинди шартларда язылган һәм нинди мохтаҗлыклар аша тормышка ашырылган, боларны барлау кирәк, минемчә».

Мохтажлык дигәнне иң әүвәл кәгазьләр күрсәтеп тора. Кирәкмәскә әйләнгән канцелярия кенәгәләреннән алынган кәгазь битләре. Исем-фамилияләр, нииндидер саннар, графалар. Шуларның буш калган урыннарына шигырьләр язылган. Язылган чаклары — 1944 ел...

Бу чорда нинди әсәрләр язылуы һәм кайсыларының газетага җибәрелүе ихтимал? Билгеле инде, шигырьләрнең эчтәлеген һәм үзенчәлеген сугыш вакыйгалары билгеләгән. Газета көн мәнфәгатьләре белән яши. Ел фасылларына, сәяси даталарга бәйле эшләр барышын күрсәтә бара. Мин җибәргән шигырьләр дә шулай көн кадагына сугарга тырышып язылганнар. Беренче сыйфат, шул чактагы әдәбиятка хас булганча — югары дәрәҗәдәге патриотизм, саф публицистика.

«Ленин байрагы» исемле шигырь 10 гыйнварда җибәрелгән. Аннары — «Егерме өченче февраль», аның артыннан — «Чәчү җитә».

Көләч апрель
Бик бер якын җирдән
Безгә карап көлә шикелле.
Киң болыннар,
Колхоз басулары
Сагынып көтә кебек шул көнне.

Уналты яшьлек патриот шагыйрь шул матур көннәрне нык әзерләнеп каршыларга чакыра. Әсәр редакцияләнгән — наборщиклар танырлык хәрефләр белән кучерелгән (машинкалар юк бит!) һәм шрифт билгеләнгән. Чыкканмы-юкмы, әйтә алмыйм. Минем күзгә чалынмады.

Кырык дүртнең язы совет гаскәрләренең Европа илләренә барып җиткән чагы бит. Верховный башкомандующий приказлары, дөнья күген яктырткан салютлар... Алар, әлбәттә, шигырьгә турыдан-туры килеп керәләр.

Канатландым якты хисләр белән,
Күңел таша — йөрәк сөенә.
Ничек шатланмассың, җиңү арты
Җиңү килгән саен иленә?!

Канга сусап, ерткыч юлбасарлар
Ач этләрдәй шашынып өрсә дә,
Комсыз җаннар,
Юаш коллар эзләп,
Өермәдәй өерелсә дә.

Мәңге-мәңге
Коллык богауларын
Киясе юк изге халкымның.
Халкым кичәр,
Тинсез ташкын булып,
Дөрләп торган үлем ялкынын.

Аңла, комсыз фашист бүресе,
Көлгә очар бүре оясы.
Сез таптаган ачлар дөньясына
Балкып чыгар бәхет кояшы.

Канатландым якты хисләр белән,
Очар коштай йөрәк сөенә.
Ничек инде шатланмасын күңел,
Җиңү килгән саен иленә!

Редакция хезмәткәрләреннән кемдер шигырь читенә: «Бигрәк матур язылган» — дип куйган. Ләкин бу юлы «редакцияләдем» димәгән. Шигырь чыкмаган булырга тиеш.

Публицистик шигырьләр арасына эпиграммалар килеп кергән. Өлкән агайларны зурлаган мактауларга шулай ук сәяси эчтәлек салынган. Агайлар, бабайлар, М. Әмирнең «Миңлекамал» пьесасындагы кебек — югары идеяле. Мәгәр тәнкыйть ителгән затлар да юк түгел. Шундыйлардан — бригадир апаларга багышланган эпиграммалар.

## Әдия апага

Хәл сорашсаң, җавап бирә:
«Эшләрем бик порядке».
Үзе бик еш килми кала
Идарәгә нәрдәкә.
Нәрәд бетәр-бетмәс борын,
Егете янына кача.
Унбиш яшьлек егет белән
Күңел ача таңгача.

## Зәһинә апага

Зәһинә апа кәз-кәз генә
Аның өенә килә.
Ярты алып икенче бер
Егеткә — сөйгәненә.
Ахирәте Әдия белән
Бергә аның киңәше.
Күрше-тирә сөйләгәндә,
Чыңлый микән чигәсе?

Уналты яшьлек үсмер үзеннән бер яшькә кечерәкләрне һәм алар белән булган олырак апаларны шулай тәнкыйть итә. Соңыннан ике эпиграммага:

Төнлә уйнап, көндез аяк
Өсте йоклап йөриләр.
Эшне артка өстериләр —
Менә нинди җиңгиләр!

— дип нәтиҗә ясый.

Бу хәлләрнең әхлаксызлыктан бигрәк фаҗига икәнлеген ул аңлап җиткергәнмени соң ул чакларда! Күрше-тирә сөйләгән бит, җәмәгатьчелек фикере!

Тәнкыйтьтән автор эшләгән бригада җитәкчесе дә котыла алмаган. Монысының аңа шәхси зыяны ук тигән икән. Ул, нишләргә бу хәлдә дип, кешеләрдән киңәш сорый.

Кичегенәк бригадирга
Барган идем ат сорап.
Кыска гына: «Ат юк!» — дигәч,
Калдым бераз аптырап.

...Өем салкын, малларым ач,
Әнием карт, үзем яшь.
Хәзер маллар ачка үлә.
Нишлим, бирегез киңәш!

Хәзер искә төште, һәр хуҗалыкның үзенә салам ташырлык кешеләре калмаганлыктан, колхоз идарәсе һәр йортка салам китертүне махсус кешеләргә йөкләгән иде. Мәгәр бу эш бик тә начар башкарылды. Брига-

дирлар моның өчен артык борчылмадылар. Кешеләр үтенеч белән килгәч, күргәнебезчә, җаваплары бер булды: «Ат юк».

Яшь авторыгыз моның сәбәбен күреп торган һәм аны хикәя итеп тасвирлаган. Хикәя кечкенә булудан файдаланып, мин аны тулысынча китерәм. Ул моңа лаеклы дип саныйм.

### «Хуҗа кайда?..

Төн.

Күрше авылдан — колхоз үзәгеннән кайтып киләм. Төн болытлы. Җил юк. Тынлык. Тик аякларның шыгырдавы гына тынлыкны боза. Авылдан чыгып, шактый бардым. Юлда, салам төялгән чаналар тарткан дүрт-биш малай очрагач, тукталдым. Малайларның тыннары-көннәре беткән, мыш-мыш киләләр.

— Кайсы колхоздан?

Ник сорап торамдыр инде, бу тирәдә тагын нинди авыл булсын.

— Ишкар.

— Кая бардыгыз? — тагын мәгънәсез сорау. Күреп торам ласа.

— Саламга.

— Бә-әй, сезнең саламны шулай бәләкәй чаналар белән туздырталармыни?

— Без бит урлап кына алып кайтабыз.

Уйга калдым. Күләсе дә килә. Йөрәк тә әрни. Урлап кына... Урлап кына алып кайталар... үз саламнарын. Шушымыни терлек азыгын сак тоту? Нишләп ат белән китертмиләр? Ә-ә! Беләм, ат юк! Ләкин бу эшне баш һич сыйдыра алмый.

Бераздан иң кечкенә малай миңа эндәште:

— Абый!

— Ә?

— Саламда әллә нинди ат бар.

Ышанмыйча, кабат сорадым:

— Ат бар? Нинди ат?

— Әйе, саламга ышыкланган да, тик тора. Үзе ябык, үләргә житешкән.

Күңел ышанмый. Төнлә, кышкы басуда ничек ялгыз ат булсын инде?

Ике малайны иярттем дә, салам янына киттем. Чыннан да, бер кара туры ат, башын көрткә терәгән дә, калтырап тик тора. Авылга алып кайтмакчы идек, селкенми дә. Эскерттән йолкып, алдына салам салдык та киттек. Кире Ишкарга килеп, туп-туры ат караучылар йортына килдем. Анда өч егет куна икән. Берсе кызык итеп куна, икесе тайлар карый. Сорап белдем.

— Атлар конюхы кайда? — дим.

— Алар икесе дә өйләрендә куналар.

Атлар янында беркем дә юк. Күтүләре белән әйдәп кит тә бар. Конюх, атларны «Аллага тапшырып», өендә гырлап ята. Янына барып кергәч, башта ул ат турында бөтенләй бер нәрсә дә белмәде. Соңыннан гына йокы аралаш:

— Болыннан кайткач, бер ат эскертләр янына менеп китте дигәннәр ие, шулдыр инде, — дип мыгырданды.

Кояш чыгу белән үз авылыма — Әшмәнгә кайтып бара идем, мескен ат каршыма очрады — теләр-теләмәс кенә кайтып килә.

Шушы хәлгә аптырап, юл буе уйлап кайттым.

Малайлар салам урлап ташый, чөнки ат юк.

Ат юкмы? Бар, бар ат! Ә хуҗа?

Кайда хуҗа?»

...Хикәя редакциягә 15 февральдә җибәрелгән. Аның читенә редакция хезмәткәре: «Газета чыкмады, басылмый» дип язып куйган. Газета чыкмый калган чаклар булгалагандыр. Шул сәбәпле полоса таратылып, кире оештырып тормаган булулары ихтимал. Икенче ихтималлык зуррак. Хикәядә авыл, колхоз үз исеме белән аталган. Кемнәрнедер тәнкыйть итәселәре килмәгән булулары мөмкин. Бигрәк тә шунысы бар: яшь автор шактый зур иҗтимагый әһәмиятле проблемага тотынган. Ул чактагы күмәк хуҗалыкның төп чире! Сәясәттә аны телгә алу куркынычсыз ук түгел. Хәзер дә шул ук хәл дәвам итмиме икән әле...

Онытылган язмалар. Басылып чыкмаганнары. Редакциялəп чыгарырга да мөмкин булгандыр. Тик моны эшлəрлек яки авторны чакыртып төзəттерерлек кешелəр булганмы соң ул чакларда?

Кайберлəренең басылганын да хəтерлим. Шул ук елда фронттагы җиңүлəр белəн рухланып язылган «Дан җырлары» исемле шигырь чыккан иде. Анысын үз күзем белəн күрдем. Соңрак та чыккалады. Хатын-кызларны зурлаган «Ватан гөллəре» исемле бер шигырьне, газетадан күреп, Дүртөйле колхоз-совхоз театрының Гамбəрия исемле бер артисткасы (фамилиясен хəтерлəмим) берничə ел буе сəхнəдəн укып йөрде. Исемне əйтми, фамилияне генə атый. Шуңадырмы, кешелəр минем шигырь икəнне белми, ə үзем сер чишмим...

Матурлыкны тоя белгəн якташларым аша композитор Бəхти Гайсинга барып җиткəн «Идел буе» исемле җыр тексты да — шул чор җимеше.

Əйе, кулъязмаларымны җибəргəн якташым дөрес əйтə: узган чорга яңадан кайту, ə бу очракта минем беренче тəҗрибəлəрнең нинди хəлдə, нинди шартларда ясалуын искə төшерү хислəрне яңартмыйча калмады, əлбəттə. Хатирəлəр татлы да, ачы да, гыйбрəтле дə. Караңгыда яктылык күргəнбез... Өмет өзмəгəнбез.

Күпме югалтулар, корбаннар! Килəчəк бəхетлəр хакына. Бүгенге көннəр хакына дияргə була. Ə бүгенге көннəр нindirək соң? Корбаннар, югалтулар акландымы?

Уйландырыр нəрсəлəр бардыр, күптер. Якташымның хатын укыгач һəм үземнең беркатлы язмаларымны карап чыккач, мин шул хакта уйландым. Уйларның очына чыга алмадым.

Сугыш кичергəн якташларыма — фронтовикларга, хезмəт ветераннарына да уйланырга туры килəдер. Хаттан сизелгəнчə, алар, язмышка буйсынып бетмичə, кешелəр өчен, үз хокуклары өчен, имин килəчəк өчен көрəшне дəвам итəлəрдер...

Мин аларның изге эшлəрендə уңышлар, шəхси тормышларында яңа бəхетлəр, барыннан да бигрəк, ныклы сəламəтлек телəп калам.

* * *

Ярты гына гасырга алга китеп əйтелгəн шушы сүзлəрдəн соң, кире 1944 елга кайтырга туры килə. Гомер агышы шундый бит, нишли алабыз соң?

Печəн өсте узганчы ук, мине үлчəүче (телдə — весовщик дип йөртелə) итеп куйдылар. Вазифам — комбайннардан килгəн ашлыкны исəпкə алу. Мин — колхоз вəкиле. Ə МТС ягыннан үлчəүче миннəн бер-ике яшькə олырак кыз иде. Бер эшне икəүлəп башкардык. Махсус сүз алып барырлык гайре табигый хəллəр булмады, дияргə ярый. Матур көннəрнең берсен искə алмаганда...

Шундый көннəрнең берсендə мəктəптə безне укыткан Зəйнəп исемле апа, Килмит тарантасына утырып, ындыр табагына килеп чыкмаса, һаман шулай бер көй белəн дəвам итəчəк иде. Янында таныш бер кыз да бар. Кулыма газета тоттырдылар. Игълан. Уфада Мəскəү һəм Свердловск консерваторияләренə студентлар кабул ителə. Миңа шунда укырга китəргə тəкъдим итəлəр.

Зиһен тагын чуарлана.

Хəерлегəдер инде, ул елны ашлык сугу сентябрь башында ук тəгəллəнде. Шул форсаттан файдаланып, Уфага китеп тə бардым. Гариза бирдем. Кабул иттелəр. Əмма сүз тəгəллəнə язганда, кара гына чырайлы бер аксак абый, урыннан торып, минем янга килде дə шактый ук сəер киңəш бирергə тиеш тапты.

— Баян бит — авыл сəхнəлəре өчен генə əйбəт. Ə трубада уйнарга өйрəнсəң, телəсə кайсы шəһəрдə эшли аласың. Бəлки шунда керерсең?

Аптырабрак калмыйча нишлим. «Ниндидер торбадан уйнап тораммы инде?» — Әйтелгәне исә, тагын да катгыйрак:

— Юк, миңа баян кирәк, баян гына...

Гаризамны кабул иткән яшь кеше бу сүзләрне елмаюы белән җөпләде. Ул баян буенча укытучы иде булса кирәк.

Мәгәр тиз арада бөтенләй көтелмәгәнчә, уйламаганча хәл ителде. Халык мәзәгендәгечә, без тумаган тайның билен сындырган булганбыз.

Укулар Уфада түгел, Свердловскида икән. Ә минем, өйдән ярдәмсез укый алу түгел, анда барып җитәрлек тә акчам юк. Димәк, хыял күз ачып йомган арада җилгә очты...

Хәзер нишләргә? Укырга керәм дип йөреп, керә алмау оят санала. Бәлки шуның аркасындадыр, җиңелү белән ризалашмыйча, Уфаның үзендә укырга тәвәккәлләп, геология-разведка техникумына керергә булдым.

Ә кайтуымны берничә көн буе икенче бер мөмкинлек көткән иде. Район газетасы редакциясенә чакыралар. Шигырьләр хакында сөйләшергәдер, дип уйласам да, алай булып чыкмады. Эш тәкъдим иттеләр.

Редакциядә, газета белән бергә, район өчен радио хәбәрләре дә әзерләнә. Шул уртак эшнең иҗади өлешен башкару өчен әдәби хезмәткәр кирәк. Шул эшне миңа тапшырмакчылар. Минем өчен гомер буе хыялланган бәхет бит инде бу. Әгәр дә тәкъдим моннан бер ел, һич югы ярты ел элек ясалган булса, дөньяда миннән дә бәхетлерәк кеше булмас иде. Ләкин бүгенге көндә мин авылга хәрби исәптән төшәр өчен генә кайткан кеше шул. Алда — уку, яңа хыял, яңа романтика...

Газетаның редакторы, Бари Ямалов — яшь кенә, ягымлы абый — миңа чат ябышты. Ризалык-фәлән сорау юк.

— Әйдә, бергәләп эшлик әле. Шигырьләр дә язарсың, газетага, радиога материаллар да эшкәртерсең.— Шулай дип, өстәл, урындык күрсәтте.— Урының менә шушы булыр.

«Урыным» — аның каршысында, стенаның икенче ягында. Эш тә бирелде. Ниндидер брошюра кебек нәрсәдә кечкенә мәзәкләр. Сугыш темасына. Дошманнардан көлеп язылганнар. Кулдан килгәнчә тәрҗемә итәм. Редактор абый һәркайсы өлгергәнне көтеп, шунда ук редакцияли бара. «Ответ по существу» дигән мәзәккә төртелгәч, сүзлекләрдән карап интеккәнемне күреп, ярдәмгә килде.

— Тот та «дөрес җавап» диген дә куй инде,— диде.— Молодец. Бүгенгә җитеп торыр. Иртәгә тугызга килеп җит. Икмәк турында шигырь яз.

— Ярар,— дип чыгып киттем инде.

Ныклап сүз башларга минем кыюлыгым җитмәсә, аның өчен бу хәл ителгән нәрсә булып тоелгандыр. Аның урынына үзеңне куеп карасаң, шулай да ул. Шигырь белән мавыккан авыл баласына менә шушылай юл ач та, ул, малай актыгы, имештер, шуннан баш тартсын. Була торган нәрсә түгел. Әйе, ләкин... Минем хәл икенчерәк шул. Нишләп? Нишләп миңа бәхет гел соңга калып килә?

Җитмәсә, редактор абый торыр урыным хакында да сорашмады. Таныш булмаган авылда, бигрәк тә район үзәгендә фатир табу җиңел эш түгел ләбаса. Дөрес, базарга килгәндә туктала торган бер өй бар. Бернинди җиһазсыз, урын-җирсез куныя чыгарга мөмкин. Апа һәрвакытагыча шат: «Кун-кун»,— дип тора. Өстеңнән киемеңне салмыйча гына бөклән дә ят. Шулай. Һәм рәхмәт әйт. Чөнки апаң кунган өчен акча да сорамый.

Яңа фатир эзләү башка килми. Бернинди уйсыз тагын редакциягә юл тотам. Бу юлы редактор мине үзе белән типографиягә алып керде. Хәрефләр җыйганны карап тордык. Төшке ял вакытында ул мине калдырып киткән иде, әлләни уйлап тормыйча, военкоматка исәптән төшәргә киттем. Допризывниклар белән эш иткән лейтенант укырга керүем хакындагы белешмәне карагач:

— Ярый, иртәгә килерсең,— диде.

Ярты көн буш калудан файдаланып, Бари абый кушкан шигырьне яздым. Анда ашлыкның «һәр бөртеге берне үтерә» (ягъни — фашистны) дигән сүзләр дә бар иде. Абый, елмаеп:

— Ашлык бөртеге, чынлап әйтсәк, үтерми инде ул, ә?

Шулай дип, бераз уйларга кушты. Үзгәртмәсәм дә, икенче көнне шигырьне җыярга типографиягә җибәрде. Җыелган текстны үзем дә барып күрдем.

Төшке тәнәфестән соң нәрсәдер эшләп утырганда, кичә военкоматта мине кабул иткән яшь лейтенант килеп керде. Редактор белән кул бирешкәч тә, миңа таба борылды:

— Егет сездә эшлиме?

— Бездә эшли.

— Кирәкле работникмы?

— Кирәкле работник.

Миңа кагылышлы сүзләр тәмам. Аннары минем өчен мәгънәсе булмаган хәлләр турында сөйләшеп утыргач, лейтенант миңа күз дә салмыйча, чыгып китте. Ә иртәгәсен мин аның янына кабат кердем. Бу юлы инде борып чыгарырга, укырга кергән кешене исәптән төшермәскә хакы юк. Шулай да ул сәбәп тапты:

— Военком өйдә юк. Ансыз булмый.

— Кайда соң военком?

— Ерак, Карабашка китеп барды.

Карабашка — унике чакрым чамасы. Мин Әшмәннән шул араны ыһ та итмичә узып йөрим ләбаса. Монысына да исем китми. Лейтенантка бер сүз дә әйтмичә, Карабашка атлыгам. Бәхетемә, военком чынлап та шунда булып чыкты. Авыл Советы тирәсендә йөренә иде. Погонлы кешене тану кыен түгел. Кәгазьләрне каушый-каушый гына суздым:

— Лейтенант сездән башка булмый, ди.

Военком абый елмаеп куйды да, йорт эченә кереп китте. Маэмай зиһене белән артыннан иярдем. Өстәл янына килде дә берсүзсез кул куйды. Мин исә, тагын Яркәйгә ашыктым. Иртән иртүк таныклыкка исәптән төшү хакында мөһер сугылды.

Бари абый белән адәмчә саубуллашканымны хәтерләмим. Янына кереп тә тормадым, ахрысы. Качып киткәндәй, авылга ашыктым. Соңлап килгән бәхетемнән качып. Ул чактагы мәгънәсезлегем өчен, куркаклыгым өчен хәзер дә оят булып китә.

Икенче көнне исә — ерак юл. Гүяки анда, Уфада, сагынып көтәләр!..

Геология-разведка техникумында кабул ителүчеләр исемлегендә үземне күргәч, тулай торак сорап, директорга кердем. Кәримә апа сыманрак хатын-кыз. Техникумның тулай торагы юк икән. Шул хакта ун минутлык лекция сөйләгәннән соң, документларымны кире кайтарырга рөхсәт бирде.

Урам тулы белдерүләр. Тулай торак вәгъдә иткән техникумнарның берсе — авиация техникумы. Укучыларга ул чакта кытлык иде бит. Монысында директор — ир-ат. Кәгазьләрне карап та тормыйча диярлек, «Зачислить», — дип, кул да куйды. Җиңелме? Әйе, артык та җиңел. Ләкин син бу җиңеллекнең хикмәтен тиз арада татый алачаксың. Бик тә тиз арада.

1944 нең салкын айлары, 1945 нең зур өметләр вәгъдә итеп ажгырган кышы... Техникумдагы хәлләр — шуларның турыдан-туры чагылышы. Көненә дүрт йөз грамм ипи һәм бер тапкыр кәбестә шулпасы. Шуның белән яшә. Якын районнардан килгән укучылар ял саен өйләренә кайтып, азмы-күпме ризык алып киләләр. Ә минем авыл ерак. Якын булса да берничек тә булыша алмаслар иде. Менә шундый хәлдә мин. Көчкә генә җан саклап яшим. Калада танышларым юк диярлек. Башымны кая куярга белми йөргән чакларда, үземне хуҗасыз маэмай итеп тоям. Моннан да ачы тойгы, белмим, тагын бар микән...

Укуның рәте юк. Моңарчы русча сөйләшеп карамаган татар баласының рус дөньясына керүе йөзә белмәгән килеш суга сикерүгә тәңгәлдер. Минем бала чактан шушылай — үз теләгем белән тирәнгә кереп — бата язган очракларым булгалаган иде. Тел белмәү шундый бәлаләрнең берсе булды. Ләкин бердәнбере түгел. Бәлаләрнең иң зурысы — сугыш чорында рәтле укытучыларның булмавы. Алданрак монысын искә алган идем инде. Менә шул сәбәпләр аркасында, кайбер фәннәр минем өчен хак җәзага әйләнде. Кайчакларда хәтта хәзер дә төшкә кереп үзәкне өзә.

Рус теле һәм әдәбиятыннан, немец теленнән иң әйбәт укучылар арасындамын. Укытучы апалар мине хәтта яраттылар да бугай әле. Чөнки дәрестән тыш та үз кешеләрчә сөйләшәләр иде. Авыррак булса да, тарихны да җиңә алыр идем. Монда төп фәннәрдән исәпләнгән сызым дәресләре дә бик интектермәде. Җиңелә белмәгән предметлар — физика белән алгебра...

Яз килеп имтиханнар вакыты җиткәч, мин бу фәннәрне тапшырып тормадым. Авылга кайттым. Җәй көне техникумның ярдәмче хуҗалыгына эшкә чакырган хат килүенә караганда, мине укудан чыгармаганнар иде булса кирәк. Мәгәр инде көз анда барып тормадым. Үземне ачлыкка, бәлки үлемгә дучар итеп, авылда калдым. 1946 елдан да ач-ялангачрак вакыт булды микән ил тарихында? Бөлгенлек белән, үлем белән булган мыскыллы сугыш... Корбаннар да сугышның үзендә булганнарга бәрабәр булгандыр. Безнең авыл Советына караган бер авылда ул елны өч йөз җитмеш кабер калыкты. Бер ел эчендә!..

Бу чор хакында байтак язарга туры килде инде һәм, дөресен әйткәндә, хәзер инде бик язасы да килми. Шуны гына, басуларның ул чактагы күренешен генә кабатлап әйтергә ярыйдыр кебек.

Күп җирләр сөрелмәгәнлектән, анда сарут, билчән, шайтан таягы патшалык итә. Урак өсте җиттеме, ак бураннар күтәрелә. Кышкы буранарыңны бәреп егардай ак бураннар. Җир сөрергә, эшкәртергә кеше юк. Солдатлар туган җирне сагынып, яңа бәхетләргә өметләнеп кайта... Ә эш юк. Сагынулары басылганчы, аннары лаеклы шөгыль табылмасмы дип, каңгырып йөриләр-йөриләр дә, өмет өзелгәч, каядыр китеп баралар кичәге солдатлар. Ә бит кайткан чакта алар нинди иде?! Йөзләрендә кояш уйный. Бер солдатның шундый кыяфәте әле булса күз алдыннан китми.

Пароходта бергә кайттык. Кулында — гармун. Уйнап җибәрсә, бөтен халык аның янына җыела. Пароходка гына сыймыйча, пристаньнарда яр буена чыга да гармунын тагын да дәртлерәк тартып, җырлап җибәрә.

> Уйна, дустым, гармуныңны
> Үрләргә менгәндә дә.
> Онтасым юк үлгәндә дә,
> Гүрләргә кергәндә дә.

Кыскарак буйлы, яшел чалбар-гимнастерка кигән җырчы шул бәхетле хәлдә пристаньнарның берсендә төшеп калгач, бүтәннәр моңаеп калдылар бугай. Һәрхәлдә, гармун һәм җыр тавышы бүтән яңгырамады.

Монысы — яз көне. Ләкин көз дә бар бит әле. Тәкъдир кушуы беләндер, көз көне дә бу кешенең пароходка утыруын күрергә насыйп булды миңа. Кулында берни юк. Яшел дигән чалбар-гимнастеркасы инде бүтән төскә кергән. Чыраенда нур дигәннең әсәре генә дә күренми ичмаса. Сүнсә дә сүнә икән кешедә тормыш! Нәкъ менә әсирлеккә эләккән немец солдаты!

Туган-үскән, сөйгән җирләреннән күпләр шулай сулыгып, мең рәнҗешләр белән билгесезлеккә карап, каядыр китеп бардылар.

Киткәннәрнең күбесе туган кырларына әйләнеп кайта алмады. Шуларның тагын берсен искә төшерәм дә, йөрәк әле дә кысылып куя. Чама белән миңа яшьтәш иде. Фәтхелислам исемле. Базы буенда комбайнчы

ярдәмчесе булып эшләгән чагында безгә еш килә иде. Юк-бар сөйләшеп, кечкенә нәрсәләрдән мәгънә табып, вакыт уздыра идек. Көннәрдән-бер көнне, ул, ачыш ясагандай итеп:

— Карале, әрҗә белән ашлык ташучыларның кайберләре басуда үзләре өчен ашлык күмеп калдыра. Әллә сезгә дә берәр бункер калдырыйкмы? — ди.

Әни дә, мин дә көлеп кенә куйгач, ул шатлангандай тоелды. Соңыннан, кыш көне, Ишкарда очрашкач, мине кочаклап ук алды да:

— Без менә шушылай күрешергә тиешле кешеләр,— диде.

Мәгәр озак аралашырга насыйп булмады. Бер елдан соң Уфада очраштык. Кайдадыр грузчик булып эшли. Тулай торагына чакырды. Тумбочкадан алып, сөенечен яшерә алмагандай, үзенең җыйган байлыгын күрсәтергә тиеш тапты дустым.

— Менә күлмәк. Әнкәйгә. Яулык. Монысы — сеңелгә. Ошатырлар микән?

— Искиткеч матур. Сөенерләр инде.

Яз җиткәч тә кайтып, бүләк итмәкче иде ул әйберләрне. Ләкин, нишләптер, кайтмады. Сәбәбе минем өчен билгесез калды.

Нинди матур теләкләр, изге уйлар тормышка ашмый калды бит. Азмы шулай, изге ниятләрне имгәтте хәерсез хәлләр!

Азмы булды үкенечле язмышлар!

Шул җирләрнең мин дә бер баласы, шул чакта ук уйлана идем. Сөрелми яткан җирләрне ник кайткан кешеләргә бирмәделәр икән? Ягъни, хезмәт көненә үзегезгә дә бүләрлек итеп эшләгез, келәтләрегезне кырып-себереп алмабыз, дип вәгъдә ник бирмәделәр? Өч-дүрт йөз грамм бирергә дә теләмәделәр. Шулай иткәндә, җан сакларлык кына, авылда тотынып калырлык кына уңыш җыя алган булырлар иде. Ә болай кешегә дә, дәүләткә дә юк. Чәчүлек орлыксыз калдыра да, язын дәүләт, кайдандыр табып, орлык бирә. Әйләнеш шул — мамык җыю...

Югарыдагы юлбашчы иптәшләр моны күрмиләр микәнни? Авылны, җирне тәртипкә китермичә, ил аякка басар дип уйлыйлар микән?

Шушы җәһәттән бер мәзәк хәл искә төште. «Әдәби Башкортстан» дигән журналга язылган идем. Райбашкарма комитеты рәисе урынбасары Ишкар авыл Советында утыра икән. Ничектер, газета-журналлар хакында сүз чыккан да, мин ала торган журнал телгә кергән. Әлеге урынбасарга һич тә ошамаган бу нәрсә.

— Нишләп әле бердәнбер журналны ул ала? Китапханәгә күчерегез! — дип боерган бу.

Район җитәкчеләре шундый булып чыга. Өстәгеләре дә шул дәрәҗәдә генә булды әллә?

Болар — җирдә басып торыр, тотыныр урыны калмыйча аптыраган унҗиде яшьлек малай күңелендә туган сораулар. Әгәр ул үзе җитәкче булса, мәсьәләләр дөресрәк хәл ителәсе булгандыр бәлки, ә?

Бәндә үз уйларына үзе елмая.

* * *

Бер уйласаң, инде тормыш көйләнергә вакыт җиткән иде. Озак кына кайдадыр зимагурлыкта йөргән Миргасим абзый кайтып, Ишкардан аерылган Әшмән колхозында хисапчы булып эшли башлады. Ләкин гомум хәерчелек шартларында аның эше дә җиңеллек китерә алмады шул.

Әсгать абый да, армиядән соң, яшьләй туган романтик хисләре артыннан ияреп, Кавказ артына, Кара диңгез ягына китеп барган. Мине үз янына кунакка чакыра. Аны-моны уйламастан, китеп тә барам. Ярты юлда — күз алдына китерә алмаслык бәхетсезлек. Гомуми вагонда барган чакта, төнлә минем кесәдән документларымны урлаганнар. Ярый

әле, билет чалбар кесәсендә булып чыкты. Чын мәгънәсендә сукбайга әйләнәсе икәнмен. Гәрчә болай да сөенергә сәбәп чамалы.

Әсгать абый янына күч-хәл белән барып җиттем җитүен. Колхида дигән оҗмах төсле җирдә... танышларында квартирант кына үзе. Озак кунак була алмыйча, тагын авылга кайтып егылдым...

Хәзер мин — бернинди документы, хәтта паспорты да булмаган бер бәндә. Беркем дә түгел. Мин юк. Кара ут эчендә янучы кисәү. Янучы һәм шул утны йотучы.

Хәрби билет һәм паспорт алу өчен күпме интегүләр! Архивка күчкән язмаларны эзләтү, табылгач кәтә-кәтә кәтекләнүләр! Өстәвенә, авыл кешесенә паспорт тиеш түгел дип, яңасын бирми интектерүләр! Күпме вакыт, күпме газап!

Документлар яңартылгач та, гүяки, дөньяда миңа урын юк. Нибары Миргасим абзый урыны гына кала. Вакытлыча. Ул Ишкарның Гажүлә исемле кызы белән танышкан да, туйга бераз кием-салым юнәтим дип, чит калага китешли, хисапчылык эшен миңа калдырды. Читтә берме, икеме ай югалып йөргәннән соң кайтса, аны милиционерлар кулга алалар. Гомумән җәйге-көзге киеренке айларда хисапчылык эшен мин тиешенчә алып бара алмаганлыктан, бу эшкә яңа кеше куйдылар. Ә Миргасим абзыйны, «спекулянт» дип, биш елга хөкем иттеләр. Миргасим абзыйны үзенә каратырга тырышып та максатына ирешә алмаган авыл советы секретаре Шәйдуллина Мәүлиха исемле хатын чаккан иде аны.

Мин тагын берүзем, мин тагын эшсез, урынсыз. Тагын паспортсыз. Миргасим абзыйны кулга алганда тентү кергәч, «Авыл кешесенә паспорт не положено», — дип, милиционер тартып алды. Гүяки, шәхес булу хокукы калмады миңа. Рәсми яктан караганда, беттем, юкка чыктым. Мин — юк хәзер, юк!

Моңарчы берничә кабат агитбригадага чакырганнар иде. Баш тарта килдем. Ни өчен икәнен үзем дә аңлап бетермәгәнмен, әлбәттә. Әсгать абый хакында Сафуан абзыйның: «Артист булып китәр дип куркам», — дип сөйләгәне истә торды. Өстәвенә, һич акылга сыймас нәрсә: үзем укудан баш тартканнан соң да, ничектер, укырга яңадан китәргә дигән уй башта йөри. Авылда ярым эшле, ярым эшсез хәлдә гомер сөрүнең нәрсә икәнен ачыклый алмаган килеш, нииндидер яңалык көтүем. Шул хәлдә дә, бер-ике мәртәбә агитбригада җитәкчесе килгәч, ияреп китмәдем. Бик нык үгетләде, эшләргә теләмәсәң, берничә көнгә генә булса да бар, дип ялынды. гармун агитбригаданыкы, дип, куркытып та карады. Бу җәһәттән мин инде куркудан узган. Курыкмадым да, үгетләренә дә бирелмәдем. Шуннан соң тагын бер кыш узгач кына, боз шикелле каткан фикер үзгәрә төшергә мәҗбүр ителде. Яз азагында язмача чакыру килгәч, кемгәдер иярү түгел, таң-иртәдә торып, үзем тәпиләдем. Бу чакта мин почмакка куып кертелгән җәнлек, чигенер урын калмаган иде. Ашау-эчү ягы мәгълүм, киемнәр искереп, кыяфәтләр шактый котыланган. Көчләп, заемга да яздырганнар иде. Шуны түләрлек акча юнәтмәкчемен...

Район культура йортында Дүртөйледән килгән Харис Хәбибуллин дигән баянчы, режиссер сыйфатында, Риза Ишморатның элеккерәк елларда язган бер пьесасын әзерли башлаган. Мине баш рольгә куйдылар — юрист булырга җыенучы яшь егет роленә. Озак та үтмичә, әзер булып, авылларга чыгарга тиешбез. Ләкин, ходайның хикмәте, шулвакыт минем биткә шеш чыкты да, больницада үзенә күрә операция ясап, ачык җәрәхәт эченә марля тыгып калдырдылар. Икенче юлы врач аны үзе алырга тиеш иде. Ләкин иртәгә дигән көнне юлга чыгасы. Төп рольне уйнаган кешедән башка спектакль була алмый бит. Шуңа күрә, культура йорты директоры пошаманда.

— Син ничек, бюллетень алырсың микәнни?

— Бүллетень бирделәр бирүен.

— Ничек, коллективны подводить итәбез, алайса?

— Эшли башлаганда гына эшне ташлый алмыйм ич инде.

Директор иптәш шул сүзләрдән соң тынычланды.

Шул рәвешле, биттә марля очы күренеп торган килеш, юлга чыгып киттем. Бу кыяфәттә сәхнәгә чыгу мөмкин түгел. Авылда ул чакта медицина пунктлары юк. Бер генә юл калды — марляны тартып чыгарырга. Ай-һай, чыгардың ди, шешкән бит, кул тидереп тә булмый, авырта. Инде нишләргә мөмкин соң? Харис абзый шырпы кабызды да, марляның тырпаеп торган очын тотып, төптән яндырырга кереште. Авырту — әйтеп аңлата алмаслык. Әллә пешүдән, әллә тартылудан, сызланыпмысызланам, ыңгырашам, яшьсез елыйм. Мәгәр рәхмәт төшсен Харис абзыйга, ай-ваема карамастан, пешерә-пешерә, кычкырта-кычкырта булса да, марляны яндырып өзде. Очы күренмәслек булды. Грим сөрткәч, җәрәхәт тә капланды. Һәм... спектакль башланды.

Җырлы роль иде. Бая гына авыртудан үрсәләнгән кеше хәзер күңелле көй суза:

Тау астында салкын чишмә
Чылтыр-чылтыр агадыр.
Иҗтиһад кыл, эшкә башла,
Гомер узып барадыр.

Искергән «иҗтиһат» сүзен ятсынсам да, барыбер, төшереп калдыра алмыйм. Ишетүчеләрнең әйтүенә караганда, җыр әйбәт, ихлас килеп чыга, имеш. Роль башкарылышына карата да шундый ук сүзләр ишетергә насыйп булды. Яшь кеше образы. Чынлыкта мин үземне уйнаганмындыр инде. Шуңа күрәдер, миңа бу юлы сәхнә уңышы килде. Мәгәр минем максат бүтән бит. Минем төп теләгем — концертта чыгыш ясау. Ә янында чын оста барында сәхнәгә чыгу җиңел түгел. Мин әзерләнергә тиеш. Ун-унбиш көн чамасы әзерләндем дә, айның икенче яртысында инде Харис абзыйга чыгыш ясарга теләвемне әйттем.

Нишләп шулай тиз, дип сорарга мөмкиндер. Әйе, тиз. Моңарчы да баян тотып караганым бар иде. Бер-ике ел элек исеме алдарак аталган Нәйрә апа үзенең Фәния исемле кызына баян алгач, аларга кергән идем. Баянны ун-унбиш минут азаплаганнан соң, тальянда уйный торган көйләремне иркен үк уйнап җибәрдем. Янымда торган Кәримә апа Шәрипованың мактау сүзләре әле ишетелеп тора кебек.

— Менә диган егет бит син...

Төс-биткә карата әйткән сүзләрен кабатлау уңайсыз.

Шунысын гына яза алам: аннары ул миңа авырмаска тырышырга киңәш итте һәм шуны өстәде:

— Тик синең кебек кешеләргә яшәү кыен, көнләшүчеләр, төрлечә кимсетергә тырышучылар күп була...

Кәримә апа төскә чибәр һәм бик матур җырлый иде. Бәлки үз тәҗрибәсеннән чыгып әйткәндер. Ләкин аның сүзләре миңа йә иртәрәк әйтелгән, йә соңгарак калган кебек тоелды. Укыган чакта аннан бер генә тапкыр да мактау сүзе ишетмәгән идем. Кайчан гына ачыргаланып тиргәгән апам, бүген килеп әнә нинди ышанмаслык мактау сүзләре яудыра...

Шулай да, һәркем үз тәҗрибәсеннән беләдер, сирәк ишетелә торган мондый мактауларга бик тә, бик тә ышанасы килә бит. Үземә күрше малайның хыянәтен нәкъ шуның белән генә аңлатырга мөмкиндер. Концертларны алып барган Харис абый Хәбибуллин да, баянда уйнавымны игълан иткәндә, кимсетергә тырыша:

— Мин дә уйныйм әле, ди. Әйдә, уйнасын, баянда — Баянов!

Дөресен әйтим, бу вакытта мин бас ягында мажор белән минорны да аермыйм әле. Кайсы рәтнең нинди ладка каравын сорасам, Харис абзый: «Озакламый, син аны үзең белерсең»,— дип кенә куя.

Тыңлаучылар, билгеле инде, минем үз дәрәҗәмдә. Карт баянчыны ничек кабул итсә, мине дә шул чама кабул итә иде. Бер нәрсәдә ул хаклы

булып чыкты, бас партиясе тәртибен, аккордларны тиз арада ишетә белә башладым, төшендем, дия алам. Харис абзыйны бу хәл, ни өчендер, борчый иде. Шуңа күрә, вак-төяктә үч ала. Район үзәгенә кайткач, бөтен начальство күзе алдында, янәсе хур итә — мин җырлый алмаслык тональность биреп, максатына ирешә. Мондый чакта Дүртөйледән үзе белән килгән Зөфәр Солтанов дигән артист, сәхнә артына чыккач, абзыйның якаларыннан эләктереп селкесә, мин, хикмәтнең нәрсәдә икәнлеген белгәнлектән, тегеңә карамыйча да узам. Абзый гаҗәпләнә...

— Менә күрерсез, бу кеше, озакламый безне түгел, үзен дә танымый башлар әле,— дип, әллә яманларга тырыша, әллә, үзе дә сизмәстән, киләчәгемә ышаныч белдерә.

Салгаларга ярата иде. Бер көнне культура йортында зур җыелыш. Гадәттә, халык җыела башлаганда, сәхнә артында йә мин, йә Харис абый үзе баянда уйнап утыра. Бу юлы баян аның кулында иде, соңгарак калган. Мин урамда. Якташы аны ашханәдән алып килә иде бугай. Мине күрүгә, олы урам уртасыннан кычкыра бу:

— Син түгел, мин уйныйм, барыбер мин уйныйм, мин!

Әлбәттә, тагын сүз әйтмичә узып китәм. Елмаймыйм да микән әле.

Абзый безнең районга сөяркәсе белән килгән иде. Авылларда бергә йөрделәр. Ә Яркәйгә килгәч, хатын үз якларына кайтып йөргәли икән. Кайтышлый-китешли почта ташучы егет арбасына утыра. Зөфәр әйтүенә караганда, анда да мәхәббәт уены дәвам итә, имеш. Бервакыт якташы белән чираттагы якалаштан соң, Зөфәр сер чишә:

— Безне интектерергә ярата, үзен дә кызык итик әле. Бүтән түзеп булмый, әйтәбез.

— Нәрсә әйтәбез?

— Сөяркәсенең хыянәт иткәнен.

— Шулаймыни? Чынмы соң бу?

— Шулай. Җай чыккач та син сүз башла, яме. Шундый-шундый сүз йөри, дөрес микән бу? — дигән бул.

Аны-моны уйлау юк, икенче юлы өчәү очрашкач та, шул сорауны, абзыйның үзенә түгел, янәсе, Зөфәргә бирәм. Егет исә, бер дә исә китмәгәндәй, салкын гына итеп, ярып сала:

— Дөрес булмыйча, моны инде бөтен республика белә. Апаның Фаяз белән гулять иткәнен. Белмәсә, шул Харис абзый гына белми торгандыр.

Зөфәр максатына иреште. Абзый бер кызарды, бер агарды. Үзендә әрепләшерлек көч тә тапмыйча, борыны белән порхылдады да, каядыр китеп барды. Хатын белән нинди аңлашулар булгандыр. Анысы билгесез. Икенче көнне тынычланган иде. Миннән кичә иseme аталган «баҗа»сының нindирәк кеше булуын сорашмакчы. Егет минем авылдаш иде. Ләкин:

— Мин белмим, күргәнем юк,— дип котылдым.

Абзый шуннан соң сүзне бөтенләй икенчегә борды. Хәзер ул миңа киңәш бирә:

— Акылың булса, чибәр кызларга карама син. Чибәргә өйләнә күрмә. Чибәрләрнең барысы да — хыянәтче, исеңдә тот.

Сөяркәләр үз араларын ничек хәл иткәннәрдер, безгә караңгы. Ләкин алар моннан соң да Яркәйдән киткәнче бергә булдылар. Зөфәргә дә, миңа да мөнәсәбәтләре моңарча булганнан начарланмады. Кирсенчә, яхшыра төшмәде микән әле.

Зөфәр шаяртуына кушылып бигүк дөрес эшләмәгәнемне сизенсәм дә, ул чакта артык үкенмәдем шикелле. Кешесе шундый иде бит... Хәзер генә, хәтергә килсә, шактый ук уңайсыз булып китә...

Ярты ел чамасы вакыттан соң, алар үз районнарына — Дүртөйлегә кайтып киттеләр. Сәясәт шундый, үзешчән сәнгатьтә «варягларга исәп тоту» дөрес дип саналмый, һәр районның үз сәнгате, үз культурасы булырга тиеш. Шул мәгънәдә, район культура йортына, үз кеше буларак, баянчы булып мин калдым. Вакытлыча дип килгән кеше... 1948 елның

язында, культура йортының сәнгать җитәкчесе сыйфатында, штатка кабул ителдем.

Кием ягы хөрт дигән идем бит. Өстемдә таушалган чалбар һәм гимнастерка. Сәнгать кешесе бу кыяфәттә йөрергә тиеш түгел. Аңа — культурага ия булу фарыз. Моны районның культура-агарту бүлеге мөдире Иламанов фамилияле абый яхшырак белгәндер. Җитәкче генә түгел, шактый ук сизгәр педагог та булгандыр дим. Чөнки көннәрдән бер көнне ул безнең янга яңа костюмнан килеп керде. Махсус шуны күрсәтергә килгәндер дип беләм. Сугышта калдырып кайткан уң кулының терсәгенә хәтле буш калган җиңен кесәсеннән чыгарды да:

— Очсызга гына алдым, әйбәт бит? — дип елмайды.

— Әйбәт.

— Туры килсә, алыр идеңме?

— Алыр идем,— дим, чөнки кибеттә мондый очсызлы әйбәт костюмнар күренми иде.

— Соң, алайса ал, сатам, алайса. Әйтәм бит, бик очсыз.

Бәясен хәтерләмим, чынлап та минем акчам җитәрлек иде. Икенче көнне ул костюмны кулына тотып килде һәм миңа тапшырды. Шул көннән башлап, мин дә, гимнастеркадан котылып, костюм киеп йөри башладым.

Җәй көне Уфада үзешчән сәнгать җитәкчеләре һәм баянчылар өчен курслар оештырылып, мине шунда җибәрделәр. Җиңелрәк әсәрләрне нотадан укып өйрәнерлек белем биреп кайтардылар. Үзлегеңнән өйрәнү, камилләшү мөмкинлеге туды дигән сүз.

Шул ук елның көзендә Башкортстан драматургы Гариф Гомәрнең «Якты елга» исемле пьесасын әзерли башлап, кышын үзешчән сәнгать коллективларына булган смотрга бардык. Республика дәрәҗәсендә — икенче урын.

Мин әсәрдә райком секретаре ролен башкардым. Монда инде үзеңне уйнау гына җитми. Егерме яшьлек чандыр егеткә бу роль бөтенләй дә туры килми, олпатлык җитми. Шулай да репетиция вакытында исемле режиссерлар: «Уеныңа кагылмыйбыз, ничек күнеккән булсаң, шулай уйна»,— диделәр. Барыбер яхшыртып булмый, дияселәре килгәндер бәлки. Бохаров дигән режиссер: «Йөз сызыкларыгыз эре түгел, шуңа күрә, сәхнәдән ул характерлы булып күренә алмый»,— дип куйды. Монысы мин: «Җитәкче роленә туры килмисең,— дип кенә түгел,— артист булып туарга кирәк»,— дип тә аңладым. Әлбәттә смотрда уңышка ирешә алмадым, ләкин коллективыбызның анда икенче урын һәм ике мең сум бүләк алуына канәгать идем.

Икенче юлы Г. Әхметшин дигән драмматургның «Тальян гармун» исемле пьесасын куярга булдык. Музыкаль әсәр. Көйләрен табарга кирәк иде. Шул ният белән Уфага киттем. Министрлар Советы ашханәсендә Рим Сыртланов дигән артист белән очрашып, йөз иллешәр грамм аракы төшергәч, телләр ачылды да, нинди эш белән килүемне әйтеп, аннан ярдәм сорадым. Бер сүзсез риза булды. Икеме, өчме көннән соң, көйләрнең ноталарын китерде. Композитор Мәсәлим Вәлиев аларны үз кулы белән язган иде. Шатлыгым ярдан ашты. Җитмәсә, артист безгә спектакльне режиссер сыйфатында әзерләшергә дә риза булды. Бергәләп республика культура идарәсенә (ул чакта министрлык дип аталмый иде) бардык. Начальник миңа әйбәт карый иде. Үтенечебезне тиз хәл итте. Рим Сыртлановка:

— Ярый, сезгә бер айга командировка бирербез,— дигәч, миңа карап:

— Сезнең эшегез безгә кыйбаткарак төшә,— дип елмайды.

— Режиссерга без үзебез өстәрбез әле,— дип, гүяки рөхсәт сорадым. Монысына ул эндәшмәве белән ризалык белдерде.

Рәхмәт әйтеп саубуллаштык. Районга бер көлтә ноталар белән генә түгел, режиссер белән үк кайтып төштем. Мин бу вакытта (Зыя Мансур Казанга киткәннән соң) культура йортының директоры булып калган идем.

Репетицияләр башланды. Көйләрне ноталар буенча уйнап, башкаручыларга өйрәтәм. Тиз уйнап китүем һәм кешеләргә ничек итеп өйрәтүем Рим Сыртлановка ошагандыр, күрәсең.

— Әйбәт уйныйсың икән, баян — синең икмәгең. Син бу эшне ташламаска тиеш, тагын да ныграк профессиональлашырга тиешсең,— дип кабатлый торган булды.

Җәй тиз уза. Көз якынлашкач, ул Уфага кайтып китәргә җыенды. Спектакльдә катнашкан егетләр аның китәренә бер көн калгач, җыелып утырдылар да, мактау сүзләре өмет итепме икән, аның үзебез турында нинди фикерләр белән китүен сораштыра башладылар. Берсе хакында да аерым сүз әйтмәде, тагын да тырышыбрак әзерләнергә, репетицияләрне дәвам итәргә кирәклеген әйтте. Конкрет фикере минем хакта булып чыкты:

— Музыка ягыннан... сезнең музыкаль җитәкчегез барыгыздан да өстен. Аңа игътибарлырак булыгыз. Аның икмәге — баян. Ә директор дигәндә... аңа директор булып эшләмәскә дә мөмкин.

Мактавы да, яманлавы да бергә булгангамы, аның белән бәхәскә керүче, ризалашмаучы табылмады. Дөрес сүзләр әйтелүен үзем дә чамаласам да, нишләптер, зур тәҗрибәле, күренекле артистның бәяләре һәм теләкләре минем күңелне күтәрә алмады. Мин чак кына икенче төрлерәк уйлый, киләчәгемне күз алдына икенче төслерәк китерә идем. Хыялларым мәктәп ягына юнәлгән иде.

1970 елларда Татар дәүләт академия театрының администратор бүлмәсендә — чирек гасырдан соң — Р. Сыртланов белән тагын очрашырга туры килде. Ләкин ул мине танымады. Теге чакта сезнең әйткән сүзләрегез дөрес үк түгел иде, минем икмәгем баян булып чыкмады, диясем килгән иде. Ләкин моны искә төшерү уңайсыз тоелды. Шуңа күрә бугай, аңа үземнең кем икәнлегемне дә әйтмәдем һәм гомумән сүз катмадым. Сөйләшергә кирәк иде, әлбәттә. Ә хәзер исә хатаны төзәтү мөмкинлеге юк. Шуннан соң күп тә үтмәстән, аның вафат булганын ишеттем...

* * *

Хыяллар, дидек бит. Хәзер шул хакта бер-ике сүз әйтү ярыйдыр.

Техникумның беренче курсы сигезенче-тугызынчы класслар программасын сыйдырганлыктан, бу класслар өчен чыгарылган дәреслекләрнең бөтенесе диярлек миндә җыйналган һәм аларның барысын да үзем белән алып кайткан идем. Кайберләре Яркәйдә өстәлде. Ягъни, башка укучылар белән бергә, көн саен укырга йөрергә мөмкин булыр иде. Ләкин миңа эшләргә кирәк, эшләми укыр өчен әти-әни кирәк. Үзегез беләсез, мин әле үзем әнкәйгә ярдәм итәргә тиеш. «Налогка акча сорыйлар»,— дип, минем янга ул үзе килә. Ягъни уку минем өчен, бая әйткәнчә, хыял рәвешле кала бирә. Хыялның, ярый әле, тормышка ашарга омтылу гадәте бар. Аның шул гадәтенә буйсынып, мөмкинчелек булган саен, дәреслекләр укырга утырам. Тугызынчы класс укучылары белән аралашып, алар узган темаларны үзләштерә барырга тырышам. Дәрес әзерләргә уңайлык булсын өчен, Галиев фамилияле бер укучы белән фатирга да бергә урнашкан идек. Мәгәр бу бергәлек ике-өч айдан арыга уза алмады. Культура йортыннан төнлә генә кайтылып, иртәнге якта иң соңыннан торуым кызларыма тискәре йогынты ясый дип, хуҗабикә апа зарлана башлагач, билгеле инде, башка фатирга күчәргә туры килде. Фатирны мәктәпкә терәлеп торган җирдән таптым. Әби белән бабай гына. Бер гаилә кебек яшәдек. Соңга таба хәтта: «Әйдә, безнең улыбыз бул, өйләнгәч тә бергә торырбыз, тик татар кызы гына булсын»,— ди башлаганнар иде. Монысы, аңлашыладыр ки, мөмкин нәрсә түгел инде.

Бик ихлас еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, дигәндәй, мәктәпкә якынлыгым урын мәгънәсеннән узып, эчтәлек мәгънәсенә үк ия була башлады. Мәсьәләне, минем теләктән башка, язмыш үзе хәл итте, дияргә туры килә. Вакыйга мәзәк төслерәк һәм ул миңа ничегрәк килеп чыкты.

Район Советы башкарма комитетында культура эшләренә председатель урынбасары турыдан-туры катнаша — «җитәкчелек итә». Әхмәтдин Басыйров дигән агай. Эшләребез шаулап барган чакта, абзыйның да лаеклы өлеш кертәсе килеп, ахрысы, ул да җитәкчелекне бермә-бер көчәйтә куйды. Бердәнбер көнне культура бүлеге мөдире булган Иламанов абыйны, эшеннән алып, балалар йорты директоры итеп, ерак авылга җибәрделәр. Урынбасарның әле моның белән генә күңеле булмаган икән. Безнең өстә дә болытлар куера башлады.

«Тальян гармун» — әзер. Үзәк урамнарга зур-зур такталарга язылган игъланнар чыгып басты. Аларда режиссерның да (Р. Сыртланов), музыкаль оформлениенең кемнеке икәнлеге дә (Ә. Баянов) бармак хәтле хәрефләр белән күргәзелгән. Спектакль үзе дә шау-шу кузгатып узды. Менә шул чакта көчәйде Басыйровның «режиссерлык» осталыгы.

Шактый зур көч куелгангамы, мин авырып киттем. Утыз сигез градуслы температура аркасында врачтан белешмә алдым да авылга ашыктым. Әлеге дә баягы — сагыну галәмәте. Мәгәр кайтып җитүем булды, авыл Советыннан хәбәр: иптәш Басыйров һич кичекмәстән үз кабинетына чакыра. Авыру хәлдә, тагын уникe чакрымны атладым инде.

Урынбасар кем беләндер гәпләшеп утыра иде. Хәлемне, чыраемнан күрептер, үзе түгел, әңгәмәдәше сорады. Грипп дигәч, баш чайкап куйды. Басыйровның исе китми. Мәгәр ачуы купканлыгы да сизелми иде. Тыныч кына:

— Спектаклегездән соң кәеф бик киткән иде дә...— дип, никтер тыйлыкты.

Җитәкчеләргә чакыру билетлары бирү гадәтебез бар. Үзе һәрвакыт безнең тирәдә йөргәч, аңа чакыру билеты җибәрмәгән идек. Шуның өчен кәефе кырылганын сизеп:

— Сез бит инде үзебез кебек, чакырып торасы юк, дип уйлаган идек,— дим.

— Аның өчен түгел, юк. Лампаларыгыз лепелдән тора, бозык хатыннар күзе кебек.

Елмаештык, әлбәттә. Җитәкчеләрнең җитди сүз алдыннан шаярып ала торган гадәте була. Монысын шул мәгънәдә кабул иткәч, сүзнең эшкә күчүен көтәсе кала. Анысы ни булыр? Лампа лепелдәвен әйтер өчен генә мине авыру хәлдә кышкы салкында уникe чакрымны җәяү узарга мәҗбүр итмәгәндер бит?

Катырак сүз көтеп, чыраена карыйм. Халыкча әйткәндә, чиртсәң кан чыгарга торган бәхетле чырай. Ул авыр елларда да газап кичергән кеше түгел. Сугышта булмыйча, тылда да нужа күрмичә, корычтай сәламәтлеген саклый алган. Һәм әнә уртача зурлыктагы түгәрәк, алсу, чибәр битендә көлемсерәү билгеләре сызылып узды. Монысы нәрсәдән — безнең ишеләрне теләсә кайчан, теләсә нинди хәлдә урыныннан кузгата алырлык хакимлек көче тоюыннан түгел идеме? Бүтән мәгънәдә кабул итү кыен, чөнки мин көткән җитди фикер тәки әйтелмәде. Арабызда килеп чыккан кечкенә каршылык шулай җиңелчә шаяру белән хәл ителде, дип уйларга мөмкин иде. Мәгәр алай түгел икән.

Берничә көннән райфодан ревизия килеп, бухгалтер белән көн буе утырдылар. Андый-мондый нәрсә сизелмәде, әлбәттә. Мәгәр яңадан бер атнадан мине район Советы бюросына чакыралар. Утырышны Басыйров алып бара. Башта — ревизор сүзе.

Республика смотрында безгә ике мең сум акча бүләк ителгән иде бит. Шуны күчерү өчен культура йортының банктагы исәп номерын сорагач, агымдагы исәп номерын хәтерләмәү сәбәпле, дәүләт акчасын ала торган исәп номерын биргәнмен. Ул исәптән агымдагы расходлар өчен акча

алырга ярамый икән. Ә без ул бүләк акчасын алган идек. Ревизор шул ялгышлыкны күрсәтә.

Культура йортында башка сәнгать коллективлары чыгыш ясаганда, аренда өчен күпмедер акча түлиләр. Безнең бухгалтер, имештер, аларның бер чыгыштан алынган гомум кеременнән түгел, ә салымнан калган өлешеннән генә үзенә тиешле процентны ала икән. Монарчы гел шулай эшләнә килгән һәм моның өчен бер директорга да бәйләнмәгәннәр. Ә бу юлы бәйләнделәр. Элекке Сталин акчасы белән өч йөз сум җыела. Айлык хезмәт хакының өчтән бер өлеше. Телгә керерлек нәрсә дә түгел кебек. Мәгәр гаепләү сүзләре шулкадәр зурайды ки, әйтерсең, кеше илгә хыянәт иткән. Аерманы миннән түләтмәкчеләр.

Карабаш авылында МТС директоры булып эшләгән Хафизов фамилияле кеше (Басыйровның авылдашы булып чыкты) сүзләре бигрәк тә гыйбрәтле иде.

— Без районндагы иң авыр эшләрне үгез булып өстерибез. Ә безгә шул спектакльләргә чакыру билетларын... кызганалар!

Ни өчен үгез, ат яки трактор түгел, дип гаҗәпсенәм. Абзый моны сизмичә дәвам итә:

— Ике мең сумны дөрес алмаганнар...

— Безгә бирелгән бүләк акчасы,— мин әйтәм,— теләсәк, аны, ведомость төзеп, спектакльдә катнашкан кешеләргә таратырга хакыбыз бар иде. Ә без кирәкле әйберләр алдык — тәрәзә пәрдәләре, задник өчен тукыма...

— Әгәр түләтсәк? — дип, бирешмәскә тырыша МТС директоры.

Басыйровның моңа ук йөрәге җитмәде, әлбәттә. Сүзне икенче кешегә — район сәламәтлек бүлеге мөдире, кара йөзле яһүдә апага бирде. Анысы белән гомердә беренче очрашуым. Ә ул күз дә йоммый, минем янга кабат-кабат керүен тасвир итә:

— Берничә мәртәбә лекция укырга тәкъдим белән мөрәҗәгать иттем, риза булмады...

Монысына инде чыдый алмыйча:

— Клевета! — дип кычкыруымны сизми дә калганмын.

Басыйров мине тәртипкә чакыра, яла ягучы апа, телсез калып, урындык артына ябыша. Шул сурәтне генә хәтердә калдырып, чыгып та китәм. Ә ишек төбендә безнең берничә үзешчән артистыбыз тыңлап торган икән. Шуларның берсе шат елмаеп озата калды. Кемнәргәдер кызык...

Мәгәр хәлне ачыклап бетермичә эшне дәвам итү мөмкин түгел. Шуңа күрә, берничә көннән Басыйров янына керәм.

— Уңышлы спектакль куйган өчен бюрога куйдыгыз, рәхмәтегез шушы булдымы? — мин әйтәм.

Уңышны инкарь итә алмаса да, җитәкче тәнкыйть итәргә бурычлы. Күзгә карап:

— Анда синең ни катнашың бар? — дип, гүяки биткә бәрә.

— Минә сиңа... режиссер эшен мин тәгәлләдем.

— Режиссер? Анысы нигә?

Үзе бюро утырышын минә дигән итеп куя алган кеше, режиссер эшенең нәрсә икәнен белми. Бәхәсләшү кыен. Шунлыктан икенче фикергә күчәргә туры килә:

— Музыканың ноталарын Уфага барып алдым. Үзем өйрәнеп, башкаларга да өйрәттем. Спектакль вакытында баянда башкардым.

— Нинди ноталар? Барысы да халык көйләре.

Композитор өчен мактау булып яңгырашлы сүзләр мине телсез калдырды. Аудиенция тәмам. Бүтәнчә бу кешене күрергә теләк калмады. Аннан өстенрәк булган кеше — башкарма комитеты председателенең үзе белән булган очрашуны гына искә алырга мөмкиндер кебек.

Культура йортының директор бүлмәсендә басып торабыз.

Райкомның беренче секретаре һәм башкарма комитет председателе килеп керде. Киногa килгәннәр. Вак-төяк сүзләрдән соң, председатель (фамилиясе — Каганов) өстәлдәге хромкага ымлап:

— Берәр көй уйнап җибәр әле,— диде.

Дөресен әйтим, уйный белә идем. Урынбасары белән булган низагтан соң, председательнең үзе белән эшне көйләр өчен ходай үзе биргән җай иде бу. Бигрәк тә райкомның беренче секретаре күңелен күрү зыян итмәячәк иде. Аларга бит әлләни дә кирәкми. Елмаеп-көлеп кенә һич булмаса «Алмагачлары» көен генә сыздыр да, вәссәлам. Аларның якты карашы — синең кесәңдә. Ләкин... ләкин шул. Абзыйның тавышында боерык чалымы, теләгенең мәҗбүри үтәләчәгенә нык ышану сизелде дә, сыныма каткандай, аягүрә бастым да калдым.

— Йә.

Шушы ымлыктан соң гына шок төслерәк хәлдән чыга яздым бугай. Аның үзе кебек үк, нык тавыш белән җавап кайтарам:

— Хромкада уйнамыйм.

Хромка белән баянны аермыйча булса кирәк, абзый гаҗәпләнә:

— Ничек уйнамыйсың?

Сәнгать боерыкка буйсынмый, дигән уйны эчтә калдырып:

— Шулай, хромкада уйнамыйм,— димен.

— Ә нәрсәдә уйныйсың?

Үзешчән артистларыбызның берсе ярдәмгә килә:

— Нервыларда!

Җитмәсә, үзе хихылдап та куя.

Җитәкче иптәшләрнең хәле җайсыз. Тарапунька белән Штепсель төсле (секретарь — озын, преседатель — кыска) икесенә бер сүз әйтмичә басып тордылар. Чөнки хатыннары елмая... Бераздан соң гына, кырт борылып, чыгып киттеләр. Берничә көннән Каганов мәктәп директорына шалтыратып:

— Без аның эшен бюрога куябыз, ә сез аны эшкә алгансыз,— дип тиргәнә икән...

Әйе, шушындый холык белән миннән нинди чиновник чыксын? Рим абый хаклы. Әйе, директор түгел мин. Әйе, мин мәктәпкә китәргә мәҗбүрмен. Тик артык каушарга да сәбәп юк иде. Үз гамәлен Басыйров усаллык күрсәтмәкче булып башласа да, чынлыкта яхшылык булып чыкты. Миңа мәктәптә бишенче-җиденче классларда физкультура дәресләре һәм үзешчән сәнгать түгәрәген җитәкләү вазифасы йөкләнде. Иң мөһиме, укытучылар белән якыннан аралашу мөмкинлеге туды. Аларның яхшы карашларыннан файдаланып, буш вакытларда дәресләргә дә кереп утыра башладым. Күбесенчә, нишләптер, рус классларына керә идем.

Унынчы класста инде, рәсми рәвештә укучы буларак кабул ителеп, укытучы икәнемне онытып, башкалар белән бергә имтиханнарга әзерләнә башладым. Әйткәнемчә, рус класслары белән булдык. Моның мәгънәсе шунда, рус классларында укытучыларның күбесе — институтны күптән түгел генә бетереп килгән яшьләр булганлыктан, алар белән аралашу җиңелрәк иде. Барлык предметларны рус программасы белән тапшырдым. Физикадан һәм татар әдәбиятыннан башкасын. Татар әдәбиятыннан имтиханны бирмәскә дә мөмкиндер дип уйлаган идем дә, директор абый Гаянов:

— Әгәр бу предметны тапшырмасаң, аттестат бирмибез,— дигәч, каршы торып булмады.

Татар әдәбиятын, әлбәттә, болай да ярыйсы ук әйбәт белә идем. Күп нәрсә ятланган. Кыенлык тумады. Физикадан гына, элекке комплекс сакланганмы, таныш булмаган укытучыдан куркып, укыту бүлеге мөдиренең үзенә — Сәлмәнов фамилияле абыйга татарча тапшырдым. Телдән ярыйсы гына сөйләгән кебек идем, мәгәр укытучы өстәмә сораулар биргәч, төртелебрәк калдым. Соңыннан укытучы билгене яклабрак куй-

дым дигәндәйрәк ишарә иткәч, хәтерем калган иде. Хәзер исә, нишлисең, ул әйткәнчә булгандыр дип, горурлыкны җиңәргә тырышам. Үзегез беләсез, монысын тану да җиңел түгел...

Каһәр төшкән фән. Инде аның белән бүтән очрашырга язмасын!

Бу теләгем кабул булды булуын. Мәгәр Сәлмәнов белән соңгы очрашу түгел икән әле. Университетның беренче курсын бетереп кайткач, Яркәй урамында очраштык. Культура-агарту бүлегенең элекке мөдире Иламанов абый белән басып торалар иде... Яннарына барып исәнләштем. Күпмедер вакыт хәл-әхвәл сорашканнан соң, Сәлмәнов агай теге чактагы имтиханны хәтеренә төшерептер, әлбәттә, киная белән генә, шаяртып куйды. Тәгаен сүзләре истә калмаса да, мәгънәсе онытыла торган түгел. Тел төбе: без сине кеше иттек, дигәнне аңлата иде. Дөрес сүзгә җавап юк. Баш кына кагып куям. Ул исә:

— Ник шулай әйткәнне беләсеңдер инде? — дип кабат сорый.

Үзем мондый басымны күтәрә алмыйчарак торганда, минем өчен Иламанов абый җавап бирә:

— Белә, белә!

Хәл җайсызрак тоелды. Ул чакта бит мин — берниндн ярдәмчесез, хәтта киңәшчесе дә булмаган ятим малай, ярдәм итәргә теләмәсәләр, аяк чалырга уйласалар, мәктәпкә чакырып китерү түгел, эш бирү, дәресләргә йөрергә рөхсәт итү, бигрәк тә имтиханнарга уздыру кебек зур игелекләр эшләмәсәләр, нишли алган булыр идем? Мине юлдан чыгарып ташлау өчен директорның яки укыту бүлеге мөдиренең (Сәлмәновның!), аннан соң имтиханнар комиссиясе рәисенең, хәтта теләсә кайсы укытучының тискәре бер сүзе җитә иде бит. Алар исә, яман сүз әйтү түгел, хәтта якыннары төсле итеп карадылар. Ялгыша язган чакларымда борчылып торулары әле дә күңелдә җылы хис кузгата.

Шулай бер көнне, Әшмәнгә («Һаман шул Әшмән!» — диярсез) кайту аркасында, чираттагы имтиханга соңга калган идем. Кара инде син башсызлыкны — шундый вакытта нинди гамьсезлек күрсәтергә кирәк бит! Директор абый, борчылып, ишек төбендә үк басып тора:

— Нишлисең син, ә? Иптәшләрең бирен бетерә ләса. Бар, тиз, йөгер!

Рәхмәт әйтә белмичә генә йөгердем инде. Имтихан немец теленнән иде — уңышлы гына тапшырдым. Директор абыйның йөзен кызартырлык булмады, дип беләм.

Гөнаһ шомлыгы, имтиханнардан соң ук, нинди сәбәп беләндер, Ганов абыйны директорлыктан алдылар. Бик хәтере калган абый бер көнне читкә — Урта Азиягә китәргә җыенуын әйткәч, шундый тәкъдим ясады:

— Әйдә, син минем белән. Укырсың, мин кулдан килгәнчә материаль ярдәм итәрмен. Шулай җиңелрәк булыр.

Ул минем укырга тиешле кеше булуымны төшенгән икән. Әле ярдәм итүе җитмәгән, киләчәктә дә шулай дәвам итмәкче. Ләкин ул үзенең ярдәмен һич тә басым ясап әйтү түгел, хәтта киная белән дә сиздермәде. Шуңа күрә, аңарга карата күңелдә рәхмәт хисләре бүгенге көннәргәчә сүрелмичә саклана килә. Сәлмәнов абый миңа ап-ачык итеп әйтте. Югыйсә бит аның янында торган Иламанов абыйның да: «Үз теләге белән бирелгән әсирлегеннән, Әшмән урманыннан дөнья киңлегенә беренче булып аны мин алып чыктым бит!» — дияргә хакы бар иде. Ләкин юк, бу хакта ул киная белән дә ымламады. Һәр кешенең үз холкы, әдәп дәрәҗәсе. Хикмәт, бәлки, шундадыр.

Әллә сәбәп анда гына түгел идеме? Әллә язмышка әверелерлек зур игелек күрсәткән ул абыйларга тиешенчә рәхмәт әйтә белмәдемме икән? Сәлмәнов абый шуңа күрә үз яхшылыгын басым ясап әйтергә тиеш тапканмы? Ләкин бит минем дә акланыр җаем юк түгел. Мәктәпне ел саен дистәләрчә кешеләр тәмамлый, һәркайсы һәр укытучыга аерым-аерым рәхмәт әйтә алмый. Күбесе ул хисне күңеленә салып кына кал-

дыра. Шундый мисалларның берсе — мин. Онытмыйм. Һәм хәзер дә аларны әүвәлге кыяфәтләрендә күз алдына китерәм.

Гаянов абый — директор — соры китель һәм туры чалбардан. Сәлмәнов — уку-укыту бүлеге мөдире — кара китель һәм галифе чалбар кигән. Директор аннан калынрак гәүдәле, ярты башка калкурак. Мөдир — кыскарак, чандыррак. Мәгәр берсе-берсенә шактый охшашлар. Икесе дә берәр күзләрен сугышта калдырып кайтканнар. Гаяновның уң күзе — пыяла, ләкин дөньяны бик яхшы күрә. Шул сыңар күзе белән җитди карап, миңа кисәтү ясый: «Син нишләп болай соңга калып йөрисең? Бар, тиз, тиз!» — ди.

Сәлмәнов абыйның сул күзе урынында күзлек хәтле кара япма. Шул япманы капшап куя да: «Без сине кеше иттек!» — дип шаярта. Һәм, «Ни өчен шулай әйткәнне беләсеңдер инде?» — дип өсти. Янда гына торган Иламанов абый кулсыз җиңен күтәреп куя да, минем өчен: «Белә, белә!» — дип җавап бирә. Хәтер ихтыяры белән мин аларның өчесен бергә итеп күз алдына китерәм.

Дүртенчесен дә онытмыйм. Анысы — имтихан комиссиясе рәисе Ягъфәров. Хәтердәге күренешкә үзенә хас җитезлек белән килеп керә. Урта буйлы, ыспай гәүдә. Битендә күренер-күренмәс шадрасы да бар. Сүзләрен һич икеләнүсез, нык итеп әйтә. Тиешле сүзен миңа да ап-ачык итеп җиткерде.

Минем әзерлек дәрәҗәсен үзе күреп беләсе килгәндер инде, берничә кабат класска кереп, тыңлап торды һәм сораулар бирде. Соравына җавап ала алмаган чагы да булмады түгел. Шулай да (күзәтүләреннән нәтиҗә ясаптыр) имтиханнар беткәч, ул миңа авиация институтлары кебек вузлар белән мавыкмаска, авыл хуҗалыгы институтына керергә тәкъдим итте. Тәкъдименең хыялыма туры килмәве түгел, аның белемем дәрәҗәсенә бәя биреп, ары табан укырга тиешле икәнлегемне тануы мөһим бит!

Нинди авыр шартларда укудан ваз кичмәү, ниһаять, өлгергәнлек аттестаты алып чыгу минем өчен күпләрнең хәленнән килә алмаслык уңыш, җиңү иде, дип исәплим. Хәзер шуны гына өстисем килә, башында булмаган кешегә ярдәм итеп булмый. Һәм мин ул игелекле абыйларның ышанычын акладым, йөзләренә кызыллык китермәдем, дип әйтә алам...

Менә шулай — инде синең ары табан укып китергә хокукың бар. Ләкин... Ләкин оҗмахка керер идем дә, гөнаһлар җибәрми тора, дигән сүз бар шул. Кара сакал. Кая барсаң да иярә. Кара сакал — мохтаҗлык, беркемнән дә ярдәм көтмәү хокукы... Димәк, син эшләргә тиеш. Азмыкүпме акча юнәтергә. Һич югы — шәһәргә барып җитәрлек. Свердловскига барып җитә алмаганыңны онытмадыңмы? Инде бу хәл кабатлана алмаска тиеш.

Ронога барып эш сорыйсың. Булган тәҗрибәң буенча — физкультура сәгатьләре һәм үзең өчен яңа фән — рус теле һәм әдәбияты.

Бер җай килсә килә бит ул. Җәй көне элекке Яхин дигән килдекиттерәк роно мөдире алмашынып, аның урынына районга исеме әйбәт яктан танылган Латыйпов фамилияле абый килгән иде. Теләгемне ишеткәч тә:

— Ярый, Карабаш мәктәбенә шундый укытучы кирәк, риза булсаң, бүген үк кит,— диде.

Шулай диде дә, үзе белән бергә эшләгән инспектор апага Карабаш белән бәйләнешкә керергә кушты. Мин шул апаның нәрсәнедер рәсмиләштергәнен көтеп, икенче бүлмәдә торырга тиешлемен. Апа тиз арада минем янга керде дә, киңәш сорый:

— Менә бер сүздә тукталып калдым әле,— ди.— «Везти» дигән сүз бар бит. Шунда «т» дән алда «з» языламы, әллә «с» ме?

— Нишләп «с» булсын, «з» языла.

— Ә бит кагыйдә бар — саңгырау тартык авазлар алдыннан килсә, «з» хәрефе «с» белән алмашына. Бесплатный, беспризорный, бесстрашный...

— Болары — бүтән очрак. Ә сез әйткәне — икенче, «возить» сүзеннән алына — везти. «С» белән алыштырсаң, бүтән мәгънә — «вести» килеп чыга.

Апа чынлап киңәш сорый дип уйлаган идем. Күп тә үтми аңлавымча, ул миннән имтихан алган икән! Әгәр җавап бирә белмәсәң, хәлнең мөшкелләнә төшүе имтимал булган. Димәк ки, яшәсен белем!

Карабаш мәктәбендә әйбәт кабул иттеләр. Директор да, укыту бүлеге мөдире дә чын белемле кешеләр иде. Бернинди каршылыксыз — мәктәп шартларында бу гайре табигый хәл! — дусларча да, житди дә булган мөнәсәбәтләр белән матур гына яшәдек һәм эшләдек. Бергә эшләгән кешеләрне әле булса сагынып искә алам.

* * *

Тик шунысы да: сагынмыйча искә ала торган кешеләр дә бар шул. Юк дип булмый.

Бервакыт — минем гармунны милиционер тартып алгач — якын-тирә авыллар тынып калган кебек, мин мәктәпкә киткәч, район культура йортында да шундыйрак хәл туды. Кичләрен танцылар вакытында хромка гармунында уйнарга бер аяклы инвалид абзыйны чакыралар. Ә мәктәптә көндезге озын тәнәфесләрдә, ә кайбер көннәрдә кичләрен дә укучылар һәм укытучылар баян тавышы яңгыраган залда бииләр, ял итәләр...

Мин Карабашка күчкәч, район үзәге, гомумән, музыкасыз калды. Башта культура-агарту эшеннән Иламановны, соңыннан мине китәргә мәҗбүр иткән Әхмәтдин Басыйровның моңа эче пошмый иде, әлбәттә. Чөнки Карабашка кайтып (бу — аның туган авылы) мәҗлес корган чакта, мине дә шунда чакыргалый һәм сүз барышында үз гамәлләре өчен һич тә үкенү сиздерми иде. Тормыш мин уйлаганча бармый, анда шәхси мөнәсәбәтләр өстенлек итә, ә иҗтимагый мәнфәгатьләр сабыр итеп тора... Минем өчен — беренче сабаклар. Әмма да нишлим, алардан соңыннан да нәтиҗә ясадым дия алмыйм. Әйе. Монысы — сүз җаеннан әйтү генә. Ә төп фикерем шул: күренекле артистның ул чакта: «Синең икмәгең — баян», — дигән киңәшен тота алмадым. Иң төп сәбәп — мине һәвәскәр музыкант дәрәҗәсе канәгатьләндерә алмады. Ә профессиональлыкка ирешү өчен әр-яңадан укый башларга соң иде инде. Тормыш минем өчен бу кадәресен күпсенде...

Яркәйдә узган өч ел эчендә башка эшләр тәкъдим итү очраклары да булгалады. Партия райкомында инструктор булып эшләгән бер апа Дәүләт куркынычсызлыгы комитетының район бүлеге башлыгы тәкъдимен җиткерде. Шунда эшкә күчү мөмкинлеге бар икән, ризалык сорыйлар. Музыкадан да аермаска ниятлиләр. Күпмедер вакыт узгач, яңа хәбәр: мин ул эшкә ярамыйм икән. Гаҗәпләнмичә хәлем юк:

— Нишләп алай, ярамыйм?

— Нәселең туры килми. Шуны тикшергәннәр.

Кайчандыр мулла, җир биләүчеләр, үз вакытларында үлеп, дөрес эшләгәннәр, безнең биографияне бозмыйча киткәннәр, дип көлеп сөйләшә идек. Мәгәр алай гына булмаган, барыбер истә калганнар булып чыга...

— Мине эшсез калдырырлар микәнни?

Инструктор апа юата:

— Юк, алай түгел. Теләсә нинди эштә эшләргә мөмкин, диделәр. Тик КГБга гына ярамыйсың.

Монысы шулай. Юридик институтка керергә уйлавымны белеп булса кирәк, прокуратурада суд тикшерүчесе булып эшләгән бер иптәш калага күчмәкче һәм үз урынына мине калдырмакчы. Уйларга булдым. Спектакльләрдә баш рольләрне уйнап килгән дустан киңәш сорыйм. Дус һич тә икеләнмичә:

— Алай ук тиз үрләргә ярамый, соңыннан кыен булуы бар,— ди.

Бу эшне үти алырмынмы дип, үзем дә икеләнә идем, дусның бер сүзе җитә калды — тәкъдимнәреннән баш тарттым. Карабашка киттем.

Укытучы — язучылык эше кебек ук җитди, иҗади хезмәт. Аңлыйм. Әгәр аңа гомер багышларга уйласам, институтка читтән торып укырга керергә һәм эшне дәвам итергә мөмкин иде. Ләкин нишлисең, монысы да минем максатка туры килми. Күңел тарткан кешеләр, мәхәббәткә чакырган затлар да бар төсле тоелса да, гомер багышларлык эш булса да, болар минем язмыш түгел әле. Минем язмыш кайдадыр еракта.

Тормышка ашачак хыялым мине шунда көтә.

* * *

Су өсләрендә пароход,
Ямансу тавышлары...

Төштә пароходка утыруны кешеләр, ни өчендер, үлемгә юраганнар. Әгәр төштә шулай булса, өндә ничегрәк икән?

Шул хакта уйланыр чагың җитте.

Урманнар-кырлар, елгалар-әрәмәләр кочагында кошлар һәм җәнлекләр хокукында яшәгән яланаяклы малай ул син идеңме? Үзлегеннән хәрефләр танып укырга өйрәнгән малай — күләгәдә шытып, сабакларын яктыга сузган аксыл үсенте — син идеңме? Син идеңме ул — башлангыч сыйныфлардан ук көзге һәм язгы пычраклар, кышкы салкыннарда тез тиңентен көртләр яра-яра биш чакрымдагы мәктәпкә таң белән торып ашыккан малай? Син идеңме ул — әнкәсе күкрәгеннән аерыла алмыйча интеккән сабый төсле, туган җирнең тарту көчен җиңә алмыйча газап чиккән һәм киткәч тә кабат-кабат шунда кайтып егылган үсмер? Музыкага, матурлыкка иярә-иярә киңрәк дөньяга чыга башлаган яшь егет син идеңме?

Ахрысы, ул син идең... Дөресрәге, мин идем...

Еллар аша караганда үзенә-үзе чит тоелган менә шул егет, туган җиренә мәхәббәтен һәм гомер таңында үзенә игелек күрсәткән якташларына рәхмәт хисләрен, азмы-күпме алган сабакларын, тәҗрибәләрен биштәрләп, ерак юлга, сәфәргә китеп бара.

Атлы тарантас, келтер-келтер генә, Агыйдел ярына китерә. Яр буенда — пристань. Бер кулына җиңелчә күк чемодан, икенчесенә шул ук төстәге плащ тоткан юлчы, сыгылмалы басмалар буйлап, дебаркадерга уза. Бу вакытта Агыйделнең күгелҗем ераклыгыннан, шәүлә төслерәк булып, пароход инде үзе дә күзгә чалына. Елга киңлекләрендә кешеләрнең юлга әзер булырга тиешлеген искә төшерергә чакыру авазлары яңгырый.

Юлчыларны ул нинди тормышка, нинди язмышка таба, кайларга чаклы илтеп җиткерер икән?

Су өсләрендә — пароход...

*1996.*

# ШИГЪРИЯТ



## Мөхәммәт Мирза

### Килен

Пар бөркелде кыңгыраулы шәп атлардан.
Мамык мендәр — басып кердем бусагадан,
Тел очымда бер кашык бал тәме һаман —
Саклый күрсен зат күрмәгән усаллардан.

— Кыз баланың иле-көне читтә, балам
Никахны да йола гына итте заман.
Затыбызга дәвам өчен биргән ходам,—
Хуш киләсең, берек! — диде каенанам...

Чишмә суын күрсәткәндә, күбәләкләр
Бер алдыма, бер яныма төшеп очты...
Тәңкә салдым, җыеп, учлап ак таш салдым:
Чишмә-судай ургып торсын куанычым!

### Син туган бу төндә

Син туган бу төндә
Иделне боз тотты:
таллардан аерып,
ярлардан аерып,
«кабып гүя йотты» —
кем шулай котыртты?..

Агыйдел — алкын су,—
җаныма ялкын су,—
шул төндә югалды;
таллары, ярлары
ак бәскә уранды —
көн күрде — төн алды.

Табигать көчендә:
Агыйдел өчен дә,
тал-ярлар өчен дә.
Күмерләнә-көя
яшен-ут җанкаем
суык төн эчендә...—
Синең туган төндә.

* * *

Аерма татлы газабың,
Шигърият, бу колыңнан:
Сине эзләп килде җаным
Мең яктылык елыннан!

* * *

Әткәм-әнкәм гомер биргән—
Үзләренекен өзеп...
Раббым бер, шөкер итәм мин:
Дүрт ягым да сау-төзек!

* * *

Булган су тегермәне,
булган җил тегермәне—
аларын юган вакыт,
калган тел тегермәне.

**Шикләнүчегә**

Чүплектән тапкан сөяген
Кемдер талый дип белеп,
Куып җибәрмәкче бер эт
Үз күләгәсен—өреп.

* * *

Иң әвәл йөзеп чыкканнар,
Соңрак салынган басма...
Ярлар ярларга тоташкан
И Кеше, Синең аша,—
Акылың, хисең аша!..

* * *

Гөлчәчәгем ачты чәчәкләрен,
Бүлмәм тулды алсу, моңсу нурга.
Юылды да бетте юшкыннары —
Күңлем тулды нурлы моңга — җырга!

## Ике газәл

* * *

Һәр ташуда ун адым чигенде яр.
Ни хәл итим, түгел минем ихтыяр.

Узган елда агып китте ун тирәк,
Бу ташуда ничәсе җанын кыяр?

Катлам-катлам бозлар килеп орынды:
Ярны тотып калды тамыр — түзде яр;

Йөзенче кат оруында, йә Ходам,
Ун тирәкне кочаклап, убылды яр...

Агыйделдән агып китте ун тирәк,
Сулкылдармы бу өзек тамырлы яр?

...Ташкын судай, гомерләр дә, и Мирза,
Узып бара — елап калыр кайсы яр?..

* * *

Тулган айда күрдем йөзең төсләрен,
Уяндылар мәрткә киткән хисләрем;

Ничек ялгыз дип әйтим мин үземне?
Кабат кайтты — гел минеке кичләрең.

Бергә чакның күпме сере аларда,
Серләремне һичкемгә дә чишмәдем.

Хәтер — диңгез, бәхтем булган шуңа тиң,
Син — корабы, актан — җилкән төсләрең!

Татлыдан да татлырак ни җиһанда? —
Учларыңнан чишмә суын эчкәнем!..

Ак корабың йөзеп бара, и Мирза,
Тулган айга бакчы, шул ук җилкәнең!..



# Гөлзада Әхтәмова

## Егерменче гасыр

И, дәһшәтле егерменче гасыр!
Яшьләр тулы кайнар чишмә син...
Шул чишмәнең моң-зарларын кабат
Оныкларым берүк эчмәсен.

Шәфкатьлелек, мәрхәмәтлек хисен
Туу белән буып үтергән
Инкыйлаблар, диеп, җанны кыйган
Заманнарың — канлы хатирәң...

Тетрәндерә җанны, куркыныч ул
Артка борылып хәтта караулар.
Юк тынычлык. Юк ышаныч, өмет,
Яхшылыкка барын юраулар.

Үтеп бара егерменче гасыр.
Кара таплы тәне калтырый.
Кемдер йоклый. Кемдер барын йолкый.
Ач-ялангач халык аптырый...

Мең дәһшәтле егерменче гасыр!
Хакыйкатең тирән күмелгән.
Бәхет, шатлык, күңел тынычлыгың
Ерак офыкларга эленгән.

## Зәңгәр хыял

Зәңгәр хыял ак томанга куна-куна,
Очып китте — агачларга орына-орына.
Өзелеп калды бары аннан сары яфрак,
Сагыш янда, өметләрем генә ерак.

Зәңгәр хыял ак томанга оча төренеп,
Әкрен генә күзләремә китә күренеп.

---

Гөлзада ӘХТӘМОВА — *Алабугада яши, укытучы, төбәк тарихы буенча кызыклы мәкаләләр, Чаллыда дөнья күргән «Мәхәббәтле иреннәр» һ. б. шигырь китаплары авторы.*

Ак теләкләр телим ихлас күңелемнән.
Хыялларсыз ничек яшим? — телгәләнәм.

Үземә дә инде күптән яңарасы:
Зәңгәр төстә хыялымның манарасы,
Ымсындыра кулларымны сузган саен.
Җиргә тарта тик итәктән ап-ак каен.

Зәңгәр хыял, зәңгәр хыял дәшә күккә.
Күңел кылым өзелердәй — соңгы чиктә.
Гомеркәем, бәгырькәем, бу хыяллар
Күкрәгемә генә, димәк, сыялмыйлар.

Зәңгәр хыял, бәллүр хыял, якты хыял.
Ашкындыра күрәчәгем — менәр кыям.
Ничек җирдә бер хыялсыз яши алыйм?—
Чал ташларга бәрелә-бәрелә очар җаным.

## «Мин беләм»

Хыялларның татлы мизгелендә
Гизүчеләр әйтер:
— Мин беләм:
Дөнья матур, җир өсләре ямьле,
Гашыйк ярым чибәр, мин сөям!

Кайгыларның кара диңгезендә
Чайкалучы әйтер:
— Мин беләм:
Дөнья вәхши, тирә-якта сөрем,
Нигә һаман яшәп интегәм?

Уй уйламый гомер кичергәннәр,
Ваемсызлар әйтер:
— Мин беләм:
Дөнья төссез, төшләр ак та кара,
Үзгәрмәсен тормыш — бер дигән!

* * *

Көнләшәмме, юкмы? Әйтә алмыйм.
Синең күзләр шундый матур карый.
Башкага да карый. Миңа карап,
Ахры, арый.

Яратаммы, юкмы? Әйтә алмыйм.
Сагынуларым, беләм, бигрәк көчле.
Кем белән син бүген? Минем йөрәк,
Ахры, көнче.

«Яратмасам һич көнләшмәс идем»,—
Диеп кабатлыйсың ничәнче кат?
Көнләшүне, бел, түбәнлек диләр,
Бары ярат...

Үземә дә, бәлки шул ук җавап!

# УЛ ТОРМЫШНЫ ЯРАТА ИДЕ



Үсеш динамикасы ягыннан язучыларны ике төркемгә бүләргә мөмкин.

Була шундый иҗат әһелләре, алар башлангыч чорларында ук зур тизлек белән «кала тавын» яулап алалар да, соңрак бер урында таптана башлыйлар яки бөтенләй үк түбән таба тәгәриләр. Була тагын шундыйлары, алары исә тау түбәсенә әкренләп, әмма ышанычлы адымнар белән үрмәлиләр һәм ахыр чиктә иҗатларының «йөзек кашы» булырлык әсәрләр иҗат итәләр.

Мәхмүт Хәсәновны, мөгаен, икенче төр язучылар рәтенә кертеп карарга кирәктер. Ул «беренче адымнарын» тыйнак кына башлады, гомеренең уртасында да уртакулрак әсәрләр иҗат итте, әмма әсәрдән әсәргә осталыгын чарлый барып, соңгы дәвердә берсеннән-берсе уңышлырак эшләнгән роман, повестьлар тудырды. Әйе, әдип түбәннән югарыга күтәрелде, югарыдан түбәнгә мәтәлеп төшмәде — бу юл катлаулы вә четерекле, әмма гыйбрәтле булды.

Мәхмүт Мәкъсут улы Хәсәнов 1927 елның 21 декабрендә Татарстан Республикасының Саба районы Югары Кибәхуҗа авылында туа. 1937 елда алар гаиләләре белән Зеленодол шәһәренә күченеп киләләр. Әдәбиятка һәм театр сәнгатенә бала чактан ук гашыйк егет 1944 елда — димәк, унҗиде яшендә — Мәскәүнең А. В. Луначарский исемендәге Дәүләт театр сәнгате институтына (ГИТИСка) укырга керә. Биш елдан соң, ягъни институтның актерлык факультетын тәмамлап, Казанга кайта һәм Яшь тамашачылар театрында актер булып эшли башлый. Тагын бер елдан соң аны Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында уйнарга чакыралар. Шушы чорда, дөресрәге 1949—1951 елларда беренче хикәя, очерклары вакытлы матбугатта күренә башлый. 1954—1956 елларда Татарстанның беренче нефтьче-разведчиклары тормышына багышланган «Яңа горизонт» повесте, эшчеләр тормышыннан алып язылган «Урман шаулый», «Кыюлар юлы» дигән повестьлары басылып чыга. Бу әсәрләр, әдәбиятта заман темасын яктыртудагы өлгерлек үрнәкләре буларак, әдәби тәнкыйтьтә дә уңай яктан бәяләнәләр. Кыскасы, Мәхмүт Хәсәнов алдында яңа гаризонтлар ачылган чор бу.

*«...Әмма Бөгелмәдә миңа озак эшләргә туры килмәде. Нәкъ шул елларда Мәскәүдә М. Горький исемендәге әдәбият институты каршында язучылар өчен Югары Әдәбият курслары ачылган икән, дигән хәбәр таралды. Кабул итү шартлары каты: иң беренче шарты — СССР Язучылар әгъзасы булу. Икенчесе — һәрбер республикадан нибары бер генә кеше кабул ителәчәк. Шул сәбәпле конкурс игълан ителгән. Татарстаннан биш-алты кешенең гариза бирүенә дә карамастан, мин дә бәхетемне сынап карарга булдым. Җавап озак көттермәде. Конкурска җибәрелгән әсәрләребез белән танышканнан соң, бары бер мине генә кабул иткәннәре билгеле булды.*

*Бу — 1955 елның җәе иде.*

*Шулай итеп, мин яңадан студент. Яңадан Мәскәүдә. Аерма тик шунда, сугыш елларында ачлы-туклы яшәгән чаклар бик еракларда, томан артында калган... Югары курсларда исә һәр туган көн бәйрәмгә тиң иде дисәм, һич тә хаклыкка хилафлык кылу булмас. Анда — илебезнең төрле почмакларыннан җыелган төрле милләт әдипләре. Җәмгысы кырыклап кеше. Кем әйтмешли, җитмеш мирдән җыелган булсак та, бер гаиләдәй тату яши идек.*

*...Сәбәбе нилектән булгандыр, мине аеруча яраталар, үз итәләр иде. Әрмәннәр «Хасанян» дип дәшсә, грузин Вано Цховребов «Махмудашвили» дип кенә җибәрә. Дусларча шаяруның, уен-көлкенең һич тә иге-чиге юк иде».*[1]

Әйе, Мәхмүт ага тормышны, кешеләрне ярата иде һәм кешеләр дә аңа (күп чакта!) шундый ук хисләр белән җавап кайтаралар иде. Аңлашыла ки, шушы ярату, тормышны тирәнрәк аңларга омтылу хисе аның тулаем иҗатына да уңай йогынты ясады. Аның иҗади яшьлеге, әйткәнебезчә, Татарстанда нефть ятмаларын эшкәртә башлау чорына туры килде. Һәм гаҗәп тә түгел, Югары әдәби курсларны тәмамлап кайтканнан соң, ул нефтьчеләр тормышны якыннанрак өйрәнү максатыннан (дөресрәге, мәҗбүриләп) Азнакайга күченеп китә (ул анда егерме елдан артык яши) һәм бер-бер артлы хикәя, повесть, романнар иҗат итә. Шушы елларда ул «Саф җилләр» (1961—1963) нефть төбәгендә автострадада эшләүчеләр тормышын яктырткан «Юллар, юллар...» (1964), КамАЗ төзелешенә багышланган «Кама таңнары» һәм «Инженерлар», тарихи-революцион темага «Саумы, кояш» (1973), колхоз тормышыннан алынган «Хәдичә», нефтьчеләргә багышланган «Шөгеровлар» кебек киң полотнолы әсәрләрен «тудыра».

Әмма бу юл, текәгә күтәрелү, аңа җиңел генә бирелми. Гел шат, гөрелдәп көлеп йөрүче, батыр йөрәкле, Алыптай бәдәнле Мәхмүт агабыз менә нәрсә ди. «Истәлекләр»дән үзен тыңлап карыйк.

*«...Казаннан киткәч, күп нәрсәгә күзем ачылды. Чын, турылыклы дус дип йөргән каләмдәшләремнең чын йөзен күрдем. Кайберләре ачыктан-ачык хыянәт иттеләр. Шундый чакларда Казаннан китүемә чынлап торып үкенә башлый идем».*

Шулай да тоннель артында кайчан да булса яктылык күренәчәк, дигәндәй, аны шул коткаручы яктылыкка әйдәп чыгучылар Хәсән ага Туфан белән Сибгат ага Хәким булалар.

*«...Шулай тома ялгыз, шөбһә белән өмет арасында каңгыраеп яшәгәндә, көтмәгәндә-уйламаганда, тугрылыклы якын дустым Сибгат ага килеп чыкты... Мәкерле, икейөзле «дуслар»дан чак кына зарланып алдым булса кирәк.*

*— Зарланма!..— диде Сибгат ага гадәтенчә тыныч, сабыр гына...*

*...Көчең бар, дәрт-дәрман да җитәрлек... Кулга тотарлык зур әсәр, чын әсәр кирәк. Телгә керерлек, укучылар күтәреп кабул итәрлек әсәр кирәк. Синең кулдан килә торган эш бу. «Хокук якларга» ташланмый торган, бомба шартлагандай тәэсир итәрлек әсәр кирәк. Масштаблы фикер йөртә беләсең... Сюжет һәм композицияне төзи беләсең. Бу сыйфатың һәрбер әсәреңдә диярлек чагыла...*

*...Азнакай яклары безнең аксакалларыбызны да яңа әсәрләр иҗат итәргә илһамландырды, дәрт бирде. Әсәрләребез өчен материалны да бергәләп тупладык. Күрше-күлән авылларда да күп булдык, ферма хезмәткәр(ләр)е белән дә очраштык. Әле дә булса хәтеремдә, Хәсән ага ферманың буеннан-буена йөреп, сыерларның исем-кушаматларын язып йөргән иде. Аның бу шөгыле миңа чак кына сәер тоелган иде.*

*Сибгат ага исә, гомерләре буена фермада эшләгән өлкән яшьтәге савымчылар, көтүчеләр белән гәп сатарга ярата иде.*

*Әгәр дә мин хәзер: «Саф җилләр» романымны иҗат итәргә Сибгат Хәким белән Хәсән Туфан көч-дәрт, илһам бирделәр, кулымнан диярлек тотып яздырдылар дисәм, бик күпләрне гаҗәпләндерер иде, мөгаен. Әмма бу шулай иде...*

*...«Саф җилләр» матбугатта да уңай бәяләнде. Кемнең кем булуы белән исәпләшеп тормаучан, сәнгать әсәрләренә карата ифрат та таләпчән... Ибраһим ага Гази Хәдичә образы турында болай дип язган иде: «Шунысы гаҗәп, башта Хәдичәдән җирәнгән булсам, ахырда мин аны яраттым. Әйе, Хәдичә үзен яраттыра. Бу исә авторга да, безгә дә сабак».*

Гомумән, Мәхмүт Хәсәновның иҗат лабораториясен, күңел тирбәнешләрен аңлау, ул чактагы, ул еллардагы гомуми әдәби процессны чамалау җәһәтеннән әлеге истәлекләр уникаль документ булып торалар. Кызганыч ки, кеше китә... Һәм үзе белән бик күп әйтелмәгән серләрне дә алып китә. Башка бик күп язучылардан аермалы буларак, Мәхмүт ага үзенең йөрәген ачып салудан курыкмаган. Бу да бит олы әдәбиятның дәвамы.

*«...Чак кына чигенеш ясап, ул еллардагы тормышым, иҗади эзәнлегем турында бер-ике авыз сүз әйтәсем килә. Тормышым түгәрәкләнде, менә дигән,*

---

[1] Бу юллар Мәхмүт Хәсәновның архивында сакланып калган «Дустым да, остазым да иде» дигән истәлекләреннән алынды. Әлеге әсәрдән алга таба да өзекләр китерелер. Чөнки язучының асыл кичерешләрен, эчке дөньясын, иҗат лабораториясен тулырак аңлау өчен аның үзеннән дә төгәлрәк әйтеп бирү мөмкин түгел.— Н. Г.

*теләсәкем кызыгырлык гаилә корып җибәрдем*[1]*. Иҗади эшем дә, кем әйтмешли, үкереп алга бара. Дәртләндереп, илһам биреп торучым, тугрылыклы дустым-остазым — Сибгат ага да янымда. Шундук Хәсән Туфан. Иң хикмәтлесе шунда — икесе дә миңа зур ышаныч белән, олуг өметләр баглап карыйлар...*

*...Ул вакытта инде ил өстеннән чын мәгънәсендә шифалы, саф җилләр исә башлаган иде. Минем әсәрләрем өчен дә... юл ачылды. Баштарак (чак кына кыскартылып булса да) «Шөгеровлар», бераздан «Хәдичә»м дөнья күрде. Икесе дә искиткеч матур рецензияләр белән каршыланды. «Хәдичә» турында группачылардан курыкмыйча уңай фикер әйткән кеше, талант иясе Хәсән Сарьян булды. ...Хәсән Сарьян үзенең «Бүгенге авыл һәм кешеләре» («Казан утлары» журналының 1975 ел 1—6 саннарында чыккан роман һәм повестьлар турында)» дип аталган докладында Хәдичә образын күкләргә чөеп мактады. ... Хәдичә образына туктап ул болай диде: «Инде әсәр турында гомуми нәтиҗә ясап, шуны әйтәсем килә: Мәхмүт Хәсәновның бу әсәрендә бик нык эшләнгән бер образ бар, ул — Хәдичә. Автор аны бик тә яратып, хатын-кызның нечкә хисләрен белеп язган. Хәдичәне мин үзем нәфис күңелле хатын буларак та, көчле натура буларак та яратып кабул иттем. Шуның өстенә ул бөтен эш, бөтен җаваплылык үзе өстенә төшкән, колхоз производствосын әйдәп баручы Заман герое буларак та үрнәк итеберлек шәхес. Хәдичә — Мәхмүт Хәсәновның әдәби уңышы: кешелекле дә бу, эшчән дә бу, мәхәббәтле дә бу».*

Мәхмүт Хәсәнов чын мәгънәсендә тынгысыз җанлы әдип иде. Сәяхәтче иде. Ул заман сулышын тоеп яшәде. Аның өчен бервакытта тема кытлыгы булмады. Кайда яңалык — ул шунда иде.

*«...Уңышлар белән канатланып яңа әсәр язарга керештем. Роман гадәти түгел. Чорыбызның бөек төзелеше КамАЗ автомобиль гигантын төзүчеләр турында. Әсәр бик катлаулы булыр сыман иде. Хикмәт, дөньяда тиңдәше булмаган төзелеш булуында гына түгел, аның татар җирлегендә барлыкка килүе, аның татар халкы тормышына, гасырлар буе тупланып килгән гореф-гадәтләренә дә, милләт буларак рухи үзенчәлекләренә дә күпмедер дәрәҗәдә йогынты ясаячагы турында иде.*

*Әлеге тиңдәшсез төзелештә мин ялгыз түгел, һаман да шул гел хәрәкәттә, гел ил гаме белән яшәүче тынгы белмәс Сибгат ага Хәким белән. ...Мин романымны «Кама таңнары» дип атадым. Тора-бара хәтта икенче китабын — «Инженерлар» дип исемләнгән дәвамын да яздым».*

Бүген бу юлларын укыйсың да хәйран каласың: Сибгат ага белән Хәсән ага Мәхмүт Хәсәнов өчен чын мәгънәсендә юл күрсәтүче, киңәшче булганнар икән. Хәзер бар микән ул андый олуг шәхесләр, «кече энекәшләренә» һәрдаим ярдәм итәргә әзер торучы аксакаллар. Әллә соң заман башка, җен башкамы?

*«...Инде сабыр канатларым сына дип кенә торганда зарыгып, интизарлар булып көткән хәбәр килеп төште. Очар өчен канат кирәк булган кебек, иҗади юлыңда да Сибгат Хәким, Хәсән Туфан ише олы җанлы, игелекле-шәфкатьле, әүлияларга тиң кешеләр очратасың икән!»* — дип яза Мәхмүт Хәсәнов һәм Сибгат аганың үзенә атап язылган хатыннан түбәндәге юлларны китерә: *«Һәрвакыттагыча темаларны оста тотасың. «Шөгеровлар» бик кызык тема язар өчен, искиткеч кызык! Үзебезнең җир, Шөгер тавы, нефть һәм Шөгеровлар нәселе, токымы һәм Америка. Ясалма түгел, просто тормыш үзе. Бик әйбәт урыннар шушы өлештә. Әсәрнең күп урыннарын яратып укыдым. Китап итеп тапшырганчы әле эшләрсең дип уйлыйм. Эшләргә кирәк. Мин күбрәк Шөгеровлар династиясенә игътибар итәр идем, шушы сызыкны гына алып барыр идем. Шөгер тавын да просто натуралистик бер тау гына түгел, безнең тарих, төрле вакытлар узган җир, бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр белән. Шөгеровлар шунда туган. Америка вәкиле шул җир белән таныша бит! Бу тау символ. Шушындый поэтик сурәтләү җитми. Син егермедән артык әсәр язган кеше. Хәзер тәҗрибәң зур, көчең-энергияң аллага шөкер. Шөгер тавын куптарырлык. Тик ятмыйсыңдыр, эшлисеңдер, минем фикерләрне дә искә ал...»*

Һәм нәтиҗәдә укытучысының да «фикерләре искә алынган» «Шөгеровлар» романы дөньяга килә.

Исеменнән үк аңлашылганча, әсәрнең үзәгендә Шөгеровлар династиясенең язмышы; ләкин язучы моның белән генә чикләнми, шушы «язмыш» аша ул татар халкының үткәнен, бүгенгесен, киләчәген тасвирлый. Әсәрнең сюжеты бик кызык коллизиягә нигезләнгән. Шөгеровлар — данлыклы нефтьчеләр нәселе. Рахман

---

[1] Бу чорда Мәхмүт Хәсәнов, беренче хатыныннан аерылып, Мәрьям ханымга өйләнә. Мәрьям ханым бүген дә Мәхмүт Хәсәновның якты истәлеген саклый.

карт заманында Бакуда нефть чыгарган, герой дәрәҗәсенә ирешкән. Улы Корбан да нефтьче. Оныгы Ногман да әлкәннәр эзеннән атлый. Кыскасы, тормыш арбасы җай гына теркелдәп алга бара. Ләкин көтмәгәндә, уйламаганда нәселне сискәндерерлек бер хәл булып ала — аларга АКШтан миллионер Шандор килеп чыга. Кызык иң: кем соң ул сәер миллионер, ни өчен ул нәкъ менә Шөгеровларга килгән? Бу романында да Мәхмүт Хәсәнов үзен әнә шундый укучыны кызыксындырырлык тормыш материалы таба белүче оста итеп таныта, иҗатында тагын бер матур сәхифә булырлык әсәр иҗат итә.

Мәхмүт Хәсәновның «ата балыкчы» икәнлеге «бөтен дөньяга» билгеле иде. Бу турыда булганын да булмаганын да кушып язучылар арасында күп сөйләнелде. Кем белә, язучы бәлки нәкъ менә табигать белән күзгә-күз очрашканда язарына ризык тапкандыр да соңрак ак кәгазьгә төшергәндер? Мөгаен, шулайдыр. Архивтагы ядкярләр әнә шул хакта сөйли.



Лениногорски шәһәрендә яшәп иҗат итүче Шамил Бикчурин белән алар озак еллар дус, фикердәш булып яшәделәр. Бу иҗади дуслыкка илаһи тын иртәләр, серле Ык елгасы, бөдрә таллар да шаһит. Әлеге рәсемдә Шамил Бикчурин Мәхмүт Хәсәновның чираттагы «балыкчы ялганнарын» тыңлап утыра.

Ә икенче рәсемдә...

*...Фотолар өемен актаруымны дәвам итәм. Хәсән Туфан, Сибгат Хәким белән бергә төшкән фотолар аеруча күп. Арада аеруча истә калырлыклары бик тә кадерлеләре бар. Менә без, таң кебек якты булып, җыр кебек матур булып ишелә-ишелә аккан гүзәл Ык буенда кармаклар салып ятабыз. Икенче бер фотода шул ук табигать бизәге — Ык буенда, учак янында утырабыз...*

*Алгы планда Хәсән ага Туфан утыра. Ул сырган чалбардан. Аякларында кирза итекләр. Өстендә дә сырма. Гадәттәгечә яланбаш. Кулындагы чыбыгы белән таралган кисәүләрне учаккарак тарта, мул булып төшкән күмерне бер тирәгәрәк җыя. Бары тик шуннан соң гына, алдан ук хәзерләп куелган коры-сарыны учакка сала. Учак гөлт итеп кабына... Шуны гына көтеп торган кебек, эңгер-меңгер тагын да куера төшә. Елганың ике ярын кавыштырырга теләгәндәй, тирә-юньне сыек томан пәрдәсе сара. Елганың аръягындагы таулар тезмәсе артыннан, дозорга чыккан кебек, тулы ай калка.*

*Учакның икенче ягында Сибгат Хәким утыра. Мин палатка янында. Тынлык хөкем сөрә. Сөйләшмибез, һәркем үз уена чумган. Андый чакта сүз артык. Хәсән ага Туфанга игътибар итәм. Йөзе шул тикле дә җитди, уйчан...*

*Шушы урынга җиткәч сүзне Сибгат агага бирәсем килә. Аның Хәсән Туфан истәлегенә багышланган «Аккош күлендә сагыш, моң...» дигән язмасында монды-*

*ерак юллар бар: «...Ә Ыкта нәрсә калган? Ыкка җилкендерүче кеше ата балыкчы Мәхмүт Хәсәнов иде. Октябрь, җилсез, йомшак, җылы. Ык әрәмәләре тартты безне. Мәхмүт борчакны күп сипсә дә, балыгы әллә ни эләкмәде, әмма җәелеп, тулып аккан Ык үзе, болыны, бай табигате белән ниндидер хыялый, шигъри дөнья эченә алып керде. Мәхмүт безне балыкка гына дип алып килгәндер. Әмма мин аңа шушында очраштырган өчен эчемнән рәхмәт укыйм... Кинәт Ык тынлыгына юлыккан Туфанга да бу сихри дөнья шулай сәер тоелгандыр дип уйлыйм. Ярлар тын. Әрәмәләр тын. Әрәмәдә гөлҗимеш, балан. Балыкчылар...»*



*Шул ук язмасында әдип, Хәсән Туфанның учак ягарга яратуын, учак ягарга, «изге бер эшкә тотынган кебек керешүен» сурәтли. «Ипләп чыбык-чабык сындырды. Бөтен шартын китереп учак якты. Күмерләре төшкәч, учакның өстенә үк иелде, бөтен гәүдәсе белән шундый иелде, утка менә-менә авар төсле иде. И актарды утны, и болгатты утны... Ахак-күмерләр эченнән нәрсәдер эзли иде ул, нәрсә эзли? Нәрсәне югалткан!..»*

Мәхмүт Хәсәновның 1987 елда «Язгы ажаган» романы басылып чыкты һәм аңа шушы әсәре өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге тапшырылды. Гомеренең соң ноктасын ул әнә шулай егетләрчә — һаман да үргә күтәрелеп барышлый куйды.

Ул балык тотарга яраткан Ык ага да ага...
Ул яккан учаклар дөрли дә дөрли...
Тормыш дәвам итә.

Истәлекләрне укып чыкты һәм әзерләде
**Наис ГАМБӘР.**

# Мәхмүт Хәсәнов

# ЗӨБӘРҖӘТ

## хикәя

Зөбәрҗәт уянып киткәндә төн иде әле. Нindидер көч аны урыныннан күтәрде. Ул караваты буена җәелгән келәмдәге чүәкләрен аяклары белән капшап табып киде дә, кул сузымындагы урындык башына эленгән халатын җилкәсенә алып салды. Торышлый өстәл лампасын кабызды.

Ул тәрәзә янына килеп басты. Эре-эре кар бөртекләре, яктыга омтылган төнге күбәләкләр кебек, тәрәзә пыялаларына килеп сарылалар, аннары, бүлмәгә үтеп керә алуларына өметләрен җуйгандай, яңадан очып китәләр.

Зөбәрҗәт бүлмә эчен күздән кичерде. Өстәлнең урта бер җирендә вазага утыртылган өч-дүрт кенә төп ак чәчәк моңаеп утыра. Кичә аңарда ахирәт дусты Алмазиянең туган көнен уздырдылар. Алмазия дигәне, нәкъ Зөбәрҗәт кебек, адәмчә тормышын кора алмаган чая гына бер яшь хатын.

Мәҗлестә нибары алты кеше иде. Алмазия белән Әсгать, тагын бер пар һәм Зөбәрҗәтнең яңа танышы — Хәким. Мәҗлес шактый җылы үтте, табын тирәсе гөрләп торды. Алмазиянең туган көне булуга да карамастан, Зөбәрҗәт адресына әйтелгән комплементларның да бер дә исәбе-хисабы булмады.

Соңыннан, кунаклар таралыша башлагач, Хәким үзенең калырга теләге барлыгын белдерде. Зөбәрҗәт, тел төбенә тирән мәгънә салып: «Теләк котырта, оят тыя дигән сүз барлыгын онытма, тәти егеткәй. Аннары, кешенең тынычлыгын бозудан курыккан кебек, кешенең ялгызлыгын да ихтирам итә белергә кирәк...»,— дигән булды.

Хәким дә җавапсыз калмады. «Кирәгеннән артык акыллы хатын-кыздан да мәрхәмәтсезрәк кеше юктыр»,— диде ул. Аннары, сүзне уен-көлкегә борып: «Гомумән, андыйлардан куркам мин»,— дип өстәп куйды.

Кичә саубуллашканда Зөбәрҗәт аның бу сүзләренә әллә ни игътибар итмәгән иде. Ә менә хәзер башында кинәт кенә: «Нишләп соң әле ул бик җиңел генә буйсынды, китте дә барды?..»,— дигән уй чагылып китте.

Чыдый алмаслык күңелсез, ифрат та моңсу иде аңа. Ул башка нәрсә турында уйларга тырышып карады. Эш урынын, хезмәттәшләрен күз алдына китерде. Ул да булмады, аның белән электрон-хисаплау үзәгендә перфораторчы булып эшләүче бер яшь кенә кызның: «Зөбәрҗәт апа, сезне кайчандыр Баһрам абыйның кәләше булгансыз дип сөйлиләр. Хакмы шул сүз?..» — дигәне исенә төште. Кыз теле белән: «Бигрәк тә инде пар килгән булгансыз», дисә дә, аның шефы Баһрам абыена үзенең үлепләр гашыйк булуы күзләрендә ярылып ята иде. Бу сөйләшү моннан ике-өч кенә көн элек булган иде.

Әйе, Баһрам теләсә нинди хатын-кызны һуштан яздырырлык ир хәзер. Зөбәрҗәт үзе дә аның артларыннан үкенечле бер соклану белән карап калгалый.

Баһрам! Бу мизгелдә Зөбәрҗәтнең уйлары, елларны кире чигереп, узган көннәргә алып киттеләр... Моннан унбиш еллар элек, алар унынчы класста укыганда, Баһрам шактый ук төссез, «авыл гыйбадына» тартымрак гап-гади бер егет иде. Баһрам шул чакта ук инде Зөбәрҗәткә гашыйк иде. Дөрес, тыйнак-басынкы Баһрам бу турыда тел тибрәтмәде, әмма

Зөбәрҗәт моны күңеленең кай җире беләндер тоя иде. Ут белән мәхәббәтне яшереп булмый ди бит.

Әмма Зөбәрҗәт, класстагы барлык кызлар кебек, Илфат исемле егеткә гашыйк иде. Зифа буй-сынлы, бик чибәр егет иде ул. Һәрвакыт яхшы киенеп йөрер иде. Шуның өстенә тагын, зур киләчәкләр юрыйлар, олы өметләр баглап карыйлар иде Илфатка, унынчы класста укыганда ук инде аның берничә шигыре басылып чыкты. Конвертына газет һәм журнал штемпельләре куелган хатлар килә торган иде. Шул серле хатларның эчтәлеген белер өчен генә дә җаннарын фида кылган булыр иде Зөбәрҗәт. Күңелнең сөю көтеп моңланган, тулган чаклары булгандыр шул.

Аннары таралыштылар. Врач булырга хыялланган Зөбәрҗәт институтка керә алмады, бер баллы җитмәде. Әүвәлге хыял канаты шунда сынды аның. Хәер, азмыни андыйлар. Хәтта, кызлар табынган уку отличнигы Илфат булып Илфат та теләгән җиренә керә алмаган икән, дигән сүзләр йөрде. Аның каравы «Сократ маңгай» Баһрам бик җиңеллек белән университетка, үзенең теләгән факультетына кереп, студент булды. Математиканы бик яхшы белә иде шул.

Егет өченче курста укыганда алар Зөбәрҗәт белән очраша башладылар. Ә инде дүртенче курска күчкәч бергә булырга вәгъдәләр бирештеләр. Баштарак Зөбәрҗәтнең әти-әниләре бу турыда ишетергә дә теләмәделәр. Карап туймаслык бердәнбер кызлары «адәм рәтлерәк» кешегә дә чыга алыр иде дип уйлаганнардыр инде. Аның каравы, йөрәк түрендә Баһрамга карата яшерен мәхәббәт саклап йөргән Кифая: «Бәхетле дә соң син, Зөбәрҗәт!» — дип, ихлас күңелдән тәбрикләде. Яшермәде, Зөбәрҗәтнең язмышына кызыгуы турында ачыктан-ачык әйтте дә салды.

Нәкъ менә шул көннәрдә уйламаганда-көтмәгәндә очраттылар да инде алар Илфатны. Классташлар әлеге шатлыктан дөньяларын оныткандай урам уртасында туктап калдылар. Бер-берсен бүлеп, сорау артыннан сораулар яудырыштылар. Ахыр чиктә бер-берсен ишетер, әйткән сүзләрен аңлашыр хәлгә килделәр. Илфат Урал янындагы шәһәрләрнең берсендә яши икән. Башы-аягы белән сәнгатькә чумган. Үзе режиссер, үзе драматург. Ә хәзер янәсе Казан каласына илһам алырга дип, «яшьлеге» белән очрашырга дип кайткан. «Казан» гостиницасында туктаган. Алар, култыклашып, бөтен тротуарны иңләп, урам буйлап киттеләр. Һәм беренче очраган мороженое кафесына керделәр. Ничектер шулай килеп чыкты ки, Кифая әлеге компаниядә үзенең артык кеше икәнен сизенде һәм, юк сәбәбен бар итеп, гафу үтенде дә, китеп барды.

Йогышлы чир кебек үзен сиздереп, гомере буена бимазалап торачак адымын нәкъ менә шул көнне ясады да инде Зөбәрҗәт. Кафедан соң алар гостиницага, Илфат номерына кайттылар. Бу очрашу куанычыннан тәмам исергән егет әле яңарак кына халык театры сәхнәсендә куелган әсәренең афишасын күрсәтте. Бу минутта ул Зөбәрҗәткә бик сирәк кешеләр генә ирешә ала торган талант иясе булып тоелды. Ул арада Илфат каяндыр бер шешә вино чыгарды. Очрашу хөрмәтенә дип, берәр рюмка күтәрергә тәкъдим итте. Сүз иярә сүз китеп, Зөбәрҗәт тә тиздән тормышка чыгачагы турында ычкындырды. Кемгә икәнлеген ишеткәч, Илфат күзгә күренеп үзгәрде, сылу йөзенә моңсу күләгә кунды. «Син аңар әрәм...»,— диде ул, кызның бу адымы белән килешергә теләмәвен белдереп. Зөбәрҗәткә бу сүзләр таныш иде инде. Чөнки әнисе дә булачак кияүне бик үк өнәп бетерми. Хәер, Зөбәрҗәт үзе дә күңеленең кайсыдыр почмагында шуңа охшашлы тойгы йөртә иде.

Вино үзенекен итте. Илфат кыюлана төште. Укыган елларда ук Зөбәрҗәткә үлеп гашыйк идем дип, йөрәген ачты. Сүзләренә караганда, әле һаман да оныта алмыйча иза чигә икән... Шунда ул Зөбәрҗәтне, кочагына алып, шашынып үбә, иркәли башлады. Зөбәрҗәт тә үзенең хис-тойгыга бирелә, акылы томалана башлавын тойды. Әмма инде ул каршылык күрсәтә алырлык хәлəттә түгел иде.

...Ул кичне Баһрам Зөбәрҗәтне гадәттә очрата торган урында тапмый. Озак көтә. Ахыр чиктә, соң булуга да карамастан, Зөбәрҗәтләрнең өенә китә. Аның кайдалыгын сорагач, кызның әнисе: мин дә синнән нәкъ шул турыда сорамакчы идем, дип бик дорфа итеп җавап кайтарган һәм Зөбәрҗәтне табып алып кайтырга кушкан.

Баһрам эзли китә. Ахыр чиктә Кифаяларга барып чыга. Шунда ул Илфат турында ишетә, аның «Казан» гостиницасында туктавын белә. Администрациядән классташының кайсы номерда туктаганлыгын белеп, өске катка күтәрелә. Әмма дежурныйның: «Егет өйдә» диюенә дә карамастан, Баһрамның шакуына җавап бирүче булмый.

Ә инде Зөбәрҗәт, аңына килеп: «Ой-й, нишләдем мин?.. Нишләдем?!» — дип, өтәләнеп сикереп торып, җәһәт кенә киенеп коридорга чыкканда, стена буендагы креслоларның берсендә Баһрам утыра иде...

Егетләр салкын гына күрешәләр. Баһрам: «Тизрәк бул, әниең таптырта...», — дип, Зөбәрҗәтне өйләренә кадәр озатып куя. Шул озатудан соң алар очрашмый башлыйлар. Атна-ун көн чамасы үткәч, искәрмәгәндә урамда очрашалар. Шунда Баһрам бары тик бер авыз сүз әйтә: «Бигайбә, Зөбәрҗәт! Тормышны аны хыянәттән башламыйлар...»

Шуннан соң Зөбәрҗәт тормышында үзгәреш артыннан үзгәреш булып кына торды. Үзенә бер төрле серлелек белән өретелгән әлеге тормышы баштарак үзенә чак кына охшый да иде кебек, үзе кебек үк иркәле ахирәтләр дә, җан атып торган дус-ишләр дә табылды. Үзен очар коштай хис итеп яшәве белән чак кына горурлана да иде. Ни әйтсәң дә, үзе баш, үзе түш. Эш дисә, менә дигән, квартирасы да теләсә кем кызыгырлык. Дус-ишләр яшәсен, алар барында дөньяның астын өскә әйләндерергә мөмкин. Зөбәрҗәт һичкайчан да үзен алданганга яки ташланганга санамады. «Нәрсә? Кем ташланган? Минме? Ха-ха!.. Мин үзем теләсә кемне ташлыйм...» — дип башын артка атып көләргә ярата иде.

Еллар үтә торды. Баһрам белән Кифая, кавышып, менә дигән тормыш корып җибәрделәр. Хәзер, әнә, ике бала үстереп яталар. Баштарак Зөбәрҗәтнең моңа әллә ни исе китмәде. Үзен тиңдәшсез бәхетле санаган Кифаяны, ничектер, аңлап бетерми иде, «Бала-чага чүпрәк-чапрагы белән мәж килүдән, ир көен көйләп нинди бәхет таба икән?» — дип уйлый иде ул. Әмма күңел түренең кайсыдыр почмагында Кифаяның тигез тормышына карап, чак кына көнләшү хисе барлыгын да тойган сыман була иде.

Тәрәзә артында әллә кар сирәгәйде, әллә яктыра башлады. Бераздан күрше-тирәдәге йортларның кар каплаган түбәләре, алар арасындагы төпсез сыман булып тоелган бушлыклар аермачык күренә башладылар. Әмма Зөбәрҗәт тәрәзә яныннан китмәде. Бу минутта аның башында буталчык уйлар, күңелендә, нәкъ өйләр арасындагы төпсез упкыннар сыман, шыксыз бушлык иде.

Зөбәрҗәт кабат кичәге мәҗлесне күз алдына китерде... Менә «җил яклыгы» белән даны чыккан әхирәте Алмазия утыра. Күптәнге танышлар алар. Очрашулары да мәзәк булды. Алмазия аның Зөбәрҗәт исемле икәнлеген белгәч, шак катарлык сүз ишеткәндәй, кулларын шапылдатып куйган иде. «Исемегез бигрәк инде старомодный икән. Әйдәгез, Зоечка дип үзгәртәбез», — дигән тәкъдим ясаган иде. Зөбәрҗәт каршы төште. «Хет исемемне ватмагыз», — дигән иде ул. Соңрак дуслаштылар. Алмазиянең үз фәлсәфәсе бар: «Бәхет-хискә бирелүгә, хиссез-тойгысыз бәхетнең булуына ышанмыйм. Шуңа күрә дә аларны яңартып тору ягында мин», — дияргә ярата ул, уенын-чынын бергә кушып. Әмма Зөбәрҗәт ерык авыз ахирәтенең бәхетле булуына ышанмый. Тирәнтен уйлый, эчкә җыя белмәгәнгә генә шулай үз-үзен алдап яши торгандыр, дип уйлый иде ул.

Соңгы елларда Зөбәрҗәт бәхет, тормыш турында ешрак уйлаштыргалый. Вакыты белән ялгызлык хисе җанын шундый китереп баса аның, чыдар чамасы калмый. Күңелендә шулай давыл кузгалгалаган чакларда

тормышын яңадан үзгәртеп кору теләге туган сыман була. Чыннан да, яшьлектә ясалган бер ялгыш адымны гомерлек юлдаш итеп, дуадак каздай япа-ялгыз яшәп булмый бит инде. Әнә, яшьлеге дә, элеккеге матурлыгы да торган саен әкренләп чигенә бара...

Соңгы елларда йокысы да тынгысыз аның. Төшләрендә дә гелән каядыр чаба, ашкына, билетлар ала, каядыр олы юлга чыгарга кабалана. «Әллә, ходаем, үз башыма ашкынуыммы икән?» — дип тә уйлап куйгалый.

Шулай итеп, кайчандыр үзе теләп алган ирекнең тора-бара ялгызлыкка, яман бер афәткә әверелер дип кем уйлаган. Ә инде әлеге хәленең гомеренең соңгы көненә кадәр сузылачагы турында уйлый-нитә калса, бетте, Зөбәрҗәтнең күңеле өши башлаган сыман була. Бөтен барлыгын үзәк өзгеч эч пошуы биләп ала.

Зөбәрҗәт андый җанны кыйнаучан шыксыз уйлардан тизрәк арыну ягын карый. Чөнки андый уйлар хатын-кызлар өчен, бигрәк тә Зөбәрҗәтише ялгызак сылу хатыннар өчен бик хәтәрләр. Андый уйлардан каушый, ихтыярларын җуя башлыйлар алар. Аннары инде ваклануга, дәрәҗәңне төшерүгә дә, икенче төрлерәк итеп әйтсәк, тормышның астагырак баскычына төшүгә дә бер генә адым кала.

Теләр-теләмәс кенә таң атып килә. Шәһәр инде күптән уянган. Шул чак, уйларыннан арып-алҗып, башы катып торган Зөбәрҗәтне сискәндереп, звонок шалтырады. Бу аваз искәрмәстән булгангамы, телефон яки ишек звоногы шалтырадымы, абайламыйчарак калды. Бу вакытта кеше йөрмәс дип, телефон трубкасын алды.

Ахирәте Алмазия икән.

— Ал-ло!.. Дускаем, бу мин идем. Йокыңнан уяттыммы әллә? Ә? Тыңла әле...

Алмазия элеккеге җан дусларыннан кемнеңдер Кырымнан кайтып төшүе, сирәк очрый торган кучтәнәчләр алып кайтуы турында шалтырата икән. Бүген алар кичке мәҗлескә чакырулы икән.

— Ничек, барырбыздыр бит? — дип сорап куйды Алмазия.

Күңелендә давыл кайнаса да, Зөбәрҗәт: юк, бер кая да бармыйм, җиткәндер, ниһаять, дип тел тибрәтеп сүз әйтә алмады. Авыр итеп бер көрсенде дә:

— Ярар... Карарбыз,— дип җавап кайтарды.

*Ноябрь, 1977 ел.*



ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ӨМЕТНЕ АКЛЫЙК

1997 ЕЛДА ЖУРНАЛ БИТЛӘРЕНДӘ БАРГАН
«БҮГЕНГЕ ПРОЗА ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ»ГӘ ЙОМГАК

Бүгенге татар прозасының халәте күпләрдә бәхәсле фикерләр тудыра. Әдипләр һәм әдәбият сөючеләрнең үзара әңгәмәләрендә, журналның аерым саннарын тикшерүгә багышланган редколлегия утырышларында, матбугат битләрендәге чыгышларда да соңгы елларда язылган һәм дөнья күргән чәчмә әсәрләрдән ризасызлык авазлары ишетелгәли. Сәбәп нәрсәдә? Чыннан да, әллә проза жанры аксыймы, әллә сәяси кыйблалар үзгәргән бер чорда язучылар рухи маякларын югалтып, кая барырга белми бер урында таптаналармы?

Мөмкин кадәр шуларны ачыклау өчен редакция 1997 ел дәвамында журнал битләрендә бүгенге проза турында сөйләшү оештырган иде.

Аерым жанрларга багышланган сөйләшүләр, фикер алышулар эзлекле рәвештә байтактан уздырылып килә. «Түгәрәк өстәл янында сөйләшүләр», «Бер сорауга — бер җавап» сәхифәсе һәм махсус тематик анкеталарга җаваплар алу да редакциянең эш тәҗрибәсендә еш файдаланыла. Алар барысы да бер максатка — тегеяки бу жанрга әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итүгә, язучыларның активлыгын арттыруга юнәлдерелә.

Проза турындагы бу сөйләшү өчен дә иң алдан сораулар тәгаенләнде, алар язучыларга таратылды, журнал аша күп санлы укучыларга, әдәбият сөючеләргә барып ирешә.

Ел буе дәвам иткән фикер алышуда байтак әдипләр, әдәбият сөючеләр катнашты, шулардан 22 авторның язмасы журнал битләрендә басылып чыкты.

Сөйләшү барышында нәрсәләр ачыкланды соң?

Фикер алышуда катнашучылар иң элек шуны билгеләп үттеләр:

Татар прозасының бай һәм көчле традициясе, ныклы тамырлары бар. Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Г. Ибраһимов кебек каләм осталарының әсәрләре бүген дә укучылар йөрәгендә яши, алар өчен кадерле җан азыгы булып тора.

Совет чорында да ныклы идеологик кыса булуга да карамастан, әдәбиятыбызның алтын хәзинәсен тәшкил иткән әсәрләр иҗат ителде. Алар бүген дә язучылар өчен осталык мәктәбе булып тора, аларны иҗат серләренә өйрәтә һәм олы иҗатка дәртләндерә.

Соңгы елларда объектив һәм субъектив сәбәпләр аркасында китап бастыру, укучылар белән аралашу нык кыенлашуга да карамастан, татар әдипләре уңышлы гына әсәрләр иҗат иттеләр. Яңа басмалар һәм нәшриятлар ачылу күпмедер дәрәҗәдә уңай роль уйнады, проза шактый төрләнде диярга мөмкин.

Үзгәртеп кору, демократик бәйсез дәүләт төзүгә омтылыш татар халкының милли үзаңын уятып-кузгатып җибәрде. Шуның нәтиҗәсе буларак, татар прозасында тарихи һәм документаль жанрлар алга чыкты. Милләтнең күренекле уллары һәм кызлары турында кызыклы әсәрләр дөнья күрде.

Мәйданга күп кенә үзенчәлекле яңа авторлар чыкты, аларның иҗаты укучыларда билгеле бер кызыксыну уятмый калмады, әлбәттә.

Шулай ук проза жанрында сурәтләү ысулының төрләнүе, байый төшүе дә күзәтелә: кыйссалар, истәлек-мемуарлар күренә башлады, язучылар каләменнән роман-хроника, эссе кебек язмалар төшеп тора.

Санап кителгән әлеге сыйфатлар бүгенге татар прозасының шактый өметле икәнен дә раслый. «Казан утлары»ның тиражы яңадан үсә башлау да нигездә

прозадагы җанланыш чаткылары белән аңлатыла булса кирәк. Соңгы берничә елда журналыбыз битләрендә «Татар хикәяләре хәзинәсеннән» рубрикасы белән даими рәвештә бирелә килгән әсәрләр дә бүгенге проза үсешенә, һичшиксез, уңай тәэсир ясаячак.

Әлбәттә, бүгенге проза җитешсезлекләрдән дә азат түгел. Аларның байтагы объектив характердагы кыенлыкларга бәйле. Кыргый базар шартлары халыкларны икътисади яктан матди хәерчелеккә төшереп кенә калмады, ул рухи-әхлакый ярлылануга да китерде. Дәүләтнең иҗат кешеләренә, мәдәнияткә, фәнгә игътибары нык кимеде. Иҗат кешеләренең, аерым алганда, язучыларның, хезмәте тиешенчә бәяләнми.

Соңгы елларда өлкән яшьтәге тәҗрибәле әдипләрнең байтагы гүр иясе булды. Алар чын татар мохитында тәрбияләнеп үскән, телнең бөтен нечкәлекләрен белгән, оста каләм ияләре иде. Яшь алмаш исә кętелгәннән күпкә аз булып чыкты. Башка төбәкләрдә татар мәктәпләре ябылу сәбәпле, әдәбиятка яшьләр, нигездә, Татарстаннан гына килә башлаган иде.

Иң аяныч шул: татар авылы үзе дә табигыйлыгын, чын миллилеген күпмедер дәрәҗәдә югалта бара инде. Авыл егет-кызлары да күңелләренә милләтебезнең изге рухи-әхлакый хәзинәсен өлкәннәргә караганда шактый аз сеңдереп киләләр. Татар теленең байлыгы, табигый сыгылмалылыгы, нечкәлеге, хиссилеге, миллилеге яшь әдипләрнең әсәрләрендә әлегә шактый сыек чагыла.

Язучылар үзләре дә әдәбиятка һәм иҗатның мөһим мәсьәләләренә тиешенчә игътибар бирә алмыйлар. Аларны матди кыенлыклар авырлыгы, тормыш кайгысы басты. Язучылар берлегендә иҗади җыелышларның, секция утырышларының бик аз уздырылуы да әдәбиятның үсешенә тискәре йогынты ясый.

Байтак вакытлар тиргәлә килгән әдәби тәнкыйть соңгы елларда тәмам югалды. Басылып чыккан әсәрләр үзләренең тиешле бәясен алмый, алар хакында җанлы әңгәмә, фикер алышу юк. Әсәрләрнең халык һәм әдәбият өчен булган рухи кыйммәтләре үзләштерелмичә, тиешенчә аңланмыйча, халык аңында беркетелмичә кала. Бүгенге прозаның җитешсезлекләренә карата да әдәби тәнкыйть үзенең принципиаль сүзен әйтә алмый. Шунлыктан әдәбиятта талымсызлык чәчәк ата башлады. Түбән зәвыкка йөз тоткан язмалар күбәйде.

Югарыда саналган кимчелекләр бүгенге татар прозасы алдында торган объектив кыенлыкларга барып тоташа.

Ләкин прозабызның «саф» үзенеке генә булган, ягъни бары тик язучылардан гына торган җитешсезлекләр дә байтак әле.

Нинди җитешсезлекләр соң алар?

Күп кенә әсәрләрдә авторларның рухи-әхлакый һәм гражданлык позицияләре ачык тәгаенләнмый. Вакыйгаларны һәм күренешләрне битараф сурәтләү өстенлек итә. Нәтиҗәдә әсәрнең тәэсир көче кими. Авторның вакыйгалар агышын, тормыш күренешләрен тасвирлауга актив мөнәсәбәте, тагын да тәфсилләбрәк әйткәндә, тормыш өчен, аның кая таба, нинди әхлакый кануннар буенча агуы өчен җаваплылык сизүе җитенкерәми. Юкса, әдипнең иҗатчы һәм шәхес буларак зурлыгы да нигездә әнә шуңа килеп бәйләнә ләбаса.

Чама хисен югалтып күләм артыннан куу да язучыны бизәми. Калын-калын роман-повестьларның мәгънәви эчтәлеге тар булу нык күзгә ташлана. Әсәрләрдә күтәрелгән проблемаларның сайлыгы, заман китереп чыгарган гаять җитди каршылыклар белән чагыштырганда аларның ваклыгы, тарлыгы әдипләребезнең идея-фәлсәфи яктан әзерлекләре түбән булуы хакында сөйли. Бу яктан алып караганда без хәзер гасыр башында һәм совет чорында иҗат ителгән күп кенә уңышлы проза әсәрләре дәрәҗәсеннән дә нык түбән төштек.

Әсәрләрнең тематик яктан тарая баруы да күпләрне борчый. Элекке елларда татар прозасында шахтерлар тормышы, туган җирен ташлап киткән мөһаҗирләр язмышы, диңгез-океаннар гизүче татар егетләре һ. б.лар азмыкүпме тасвирлана иде. Мондый темалар бүгенге татар укучысының рухын баета, аның күңел офыгын киңәйтә, шәхес буларак уйлану масштабын зурайта иделәр. Икенче төрле әйткәндә, алар милләтнең зур шәхесләре үсүгә булыштылар.

Шулай ук бүгенге прозада татарлар таралып яшәгән төрле төбәкләр тормышы да чагылмый диярлек. Мисал өчен, хәзер Урта Азия дәүләтләрендә берничә йөз мең милләттәшебез яши, көн күрә. Ә аларның яшәеше безнең бүгенге прозада чагыламы? Себер һәм Әстерхан татарлары турында да шундый ук сорауны куярга мөмкин.

Бүгенге көндә татар милләте үз алдына зурдан-зур максатлар куйганда һәм олы, якты уйлар белән яши башлаганда — мондый тематик һәм географик тарлык — безнең прозаның заман таләпләренә, милләтнең иолы рухи ихтыяҗларына җавап бирә алмавы дип аңлашыла. Без, татар язучылары, шушы хәлне аңлап үзебезнең җыелышларыбызда чаң сугабызмы соң? Бу юнәлештә эшне җанландыру буенча нинди дә булса чаралар билгелибезме?

Кызганычка каршы, йөз меңнәрчә милләттәшләребез, әдәбият сөючеләр таркалган СССРдан бүленеп чыккан бәйсез дәүләтләрдә аерылып калды. Безнең китаплар һәм газет-журналлар аларга барып җитә алмый.

Милләт өчен гаять мөһим шушы проблеманы хәл итү буенча әлегә принципиаль чаралар күрелгәне юк. Ул төбәкләрдәге укучылар белән рухи бәйләнеш булдыру кирәклеге көн кебек ачык югса. Бу — милләтебез агачының тармакларын, тамырларын саклау дигән сүз.

Проза үсешендә күзәтелгән тагын бер кимчелек — чын матур әдәбият әсәрләре кимүгә таба барган бер вакытта әдәби мәйданны документаль һәм мемуар яссылыгындагы әсәрләр күмеп китте. Дөрес, бу үзе бер дә начар күренеш түгел, әмма менә чын проза, матур әдәбият әсәрләре нишләп чагыштырмача азрак языла? Ә бит чынлап уйлап караган вакытта прозаның нигезен нәкъ әнә шундый әсәрләр тәшкил итә. Җанлы образлар, характерлар яшәешенә нигезләнгән, үзенчә сәнгати чынбарлык хасил иткән, сихри әдәбият дөньясы белән күңелне тылсымлаган, үзенә ышандырган һәм үзенә ияртеп барган әсәрләр күрергә тели укучы бүгенге прозада.

Сөйләшүдә катнашучыларны нык борчыган мәсьәләләрнең берсе тагын шул: соңгы елларда прозада «негатив», «кара» проза үрнәкләре артык ишәеп китте. Әйе, бер караганда, авторларны аңлап та була. Чыннан да, урыс империясе эчендә озак еллар яшәп һәм совет чоры диктаторлары заманында халкыбыз, аның намуслы уллары, кызлары гаять зур авырлыклар күрде. Безнең милләт вәкилләре империя балтасы астында меңәрләп кырылды. Бүгенге тормыш та кара төскә, җинаятькә, пычраклыкка үтә бай. Монысы — һич тә кире кагып булмастай тормыш хакыйкате. Монысы — безнең кырыс чынбарлыгыбыз.

Ләкин... Ләкин чынбарлык ничек кенә пычрак булса да, адәм баласы барыбер яши һәм ул яшәргә тиеш!

Ә ул ничек, нинди тормышка омтылып, нинди идеалларга таянып, кая таба ымсынып яшәргә тиеш соң? Аның җан, күңел омтылышы нинди булырга тиеш?

Кызганыч, күп кенә әдипләребез әсәрләрендәге каһарманнарны әнә шундый перспективалы уйлар белән баетмыйлар. Укучыга да киләчәк өчен яктылык калдырмыйлар диярлек. Тормышта да, әдәбиятта да гел кара төсләр һәм кара көчләр генә тантана итkәч — кеше ничек яши алырга тиеш?

Шул уңайдан соңгы елларның проза әсәрләрендә натурализм күренешләренең артык күбәюен дә билгеләп үтү кирәк. Укучының аңына да, хисенә дә тәэсир итми торган мондый күренешләр аркасында әсәрләрнең күләме бик тә зурая, нәтиҗәдә аның тарту көче кими, сәнгать дәрәҗәсе түбәнәя. Кайбер авторларның мәхәббәт күренешләрен тасвирлаганда натуралистик мавыгуы да берни белән дә аклана алмый.

Кызганыч, әнә шундый рухтагы әсәрләргә каршы куярдай, романтик күтәренкелек биргән әсәрләрне соңгы елларда безнең китап укучылар бөтенләй диярлек күрми башладылар. Г. Ибраһимовның «Табигать балалары», «Сөю сәгадәт»е шикелле, М. Әмирнең «Агыйделе» һәм Ф. Хөснинең «Йөзек кашы» кебек әсәрләрне сагына хәзер татар укучысы.

Юк, романтик әсәрләр дигәндә сүз тормышны буяу, бизәү һәм реаль тормыш конфликтларыннан качу турында бармый. Ә кеше күңеленә, аның рухына, җанына дәрт бирердәй, канат куярдай әдәби-сәнгати көч турында бара. Әдәбиятыбыз хәзинәсендә элек көчле булган бәрәкәтле һәм шифалы ул агымны хәзер — ул безгә бигрәк тә тансык булган чорда — югалтмыйсы иде бит.

Әсәрләрдә уңай геройның югалуын да шушы ук уйларга ялгап әйтергә кирәк. Бүгенге көндә яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсе җәмгыять каршына иң үзәк проблема булып килеп басканда, аның мөһимлеге, актуальлеге тагын да арта төшә. Хәзерге чынбарлык яшәү өчен бик тә авыр, катлаулы булса да, анда күбрәк кара көчләр өстенлек итсә дә — барыбер арада энҗе кебек балкып торучы,

ныk иманлы, керсез күңелле, кешелекле кешеләр дә күп бит әле. Әдәби әсәрләрдә әнә шундый якты шәхесләрнең бай рухлы эчке дөньяларын сурәтләп, алар башыннан кичкән авыр хәлләрне тасвирлап, нигә әле безгә кеше рухының матур мөмкинлекләрен, олы мөмкинлекләрен күрсәтмәскә?! Нигә әле без бүген бигрәк тә яшь буыннар күңеленә матур, изге орлыклар салмаска тиеш?! Моны бүген яшәгән әдипләр эшләмәсә тагын кем, нинди көч эшләр?!

Хезмәт кешесенә, аның эчке дөньясына игътибарның нык кимүе дә уңай күренеш дип бәяләнә алмый. Тормышның, яшәүнең нигезендә м ә х ә б б ә т һәм х е з м ә т ята икән, безнең татар прозасы да менә шушы олы хакыйкатьтән ераклашырга тиеш түгел. Чөнки кеше күңеленең иң кадерле, иң мәгънәле хис-кичерешләре дә нигездә әнә шул зур хакыйкатьләр тирәсендә туа һәм яши. Шәхеснең чын бөеклеге һәм матурлыгы да әнә шундый яктылыкта яхшырак һәм тулырак күренә. Димәк, биредә безнең әдипләр өчен әле бик күп ачылмаган рухи хәзинәләр ята.

Сөйләшүдә катнашучылар бүгенге байтак әдипләрнең иҗади фантазиясенең шактый ук ярлы булуын да билгеләп үттеләр. Ә бу хәл исә үз чиратында әсәрләрнең идея-эстетик җегәрен киметә, аның колачын тарайта. Билгеле, көчле иҗади фантазия — ул талантның аерылгысыз өлеше.

Хәзер басыла торган роман һәм повестьларда композиция-сюжет таләп-ләренең санга сугылмавын дискуссиядә катнашучылар аеруча борчылу белән билгеләп үттеләр. Чыннан да, артык зур күләмле әсәрләр күбәйгән икән — бу асылда әлеге таләпләрнең үтәлмәве нәтиҗәсе.

Авторларга карата редакторларның тиешенчә таләпчәнлек күрсәтмәүләре дә күз алдында. Нәтиҗәдә укучыга еш кына артык зур күләмле, көпшәк эчтәлек-ле әсәрләр тәкъдим ителә.

Әйе, иҗат кешеләре арасында канатлы сүз булып йөргән «кыскалыкта — осталык» дигән тәгъбир соңгы елларда онытыла төште кебек. Хикәя жанрына мөнәсәбәт моны аеруча ачык чагылдыра. Без хикәянең сүз кадерен белергә өйрәтүче, аз күләм белән зур мәгънәләр бирергә сәләтле, тирән фәлсәфи фикер-ләр сыйдыра алган җитди жанр булганын онытып җибәрәбез. Кайбер яшьрәк язучылар исә, башта хикәядә көчен дә сынап карамыйча, шунда ук зур күләмле әсәрләргә кереп китә. Бу мәсьәләдә үзебезнең хикәя осталарының тәҗрибәсен өйрәнү дә җитми. Әдәби журналлар да әлеге жанрга урынны мул бирәләр дип әйтеп булмый.

Шулай ук прозада юмор-сатира әсәрләренең аз булуын да гадәти хәл дип санарга ярамый. Тормыш үзе купкырлы булган сыман, безнең проза да аны бөтен булган төрлелегендә, җанлылыгында чагылдырырга тиеш. Ә юмор-сати-ра ул — укучының яраткан жанры. Бездә аз санда булса да бу жанрның күренек-ле осталары бар. Әмма аларга да иҗади активлыкларын тагын да арттырырга һәм үзләренә яшь алмаш үстерү турында да уйланырга кирәк түгелме икән?

Детектив һәм фантастик әсәрләр бөтенләй язылмый дип булмый, әмма алар гына бүгенге укучының зур ихтыяҗын канәгатьләндерми әле. Замана бу жанрга бигрәк тә зур таләпләр куя. Хәзерге тормыш чынбарлыгы үзе үк детектив әсәрләргә охшый барган бер вакытта, бу жанрда язарга алынган әдиптән инде зуррак фантазия һәм киңрәк, тирәнрәк фәлсәфи гомумиләштерү сорала.

Әлеге сөйләшүдә катнашучылар бигрәк тә ассызыклап шуны билгеләп үттеләр: соңгы елларда телебезнең нәфислеге, сыгылмалылыгы әдәби әсәр-ләрдә тиешенчә чагылмый. Күпчелек проза әсәрләре коры һәм тәэсирсез тел белән языла. Хәзерге прозада шигърилек, хислелек кимү нигездә әнә шуның белән аңлатыла. Ә бу инде кеше күңеленең нечкә кыллары чиртелмичә кала дигән сүз.

Шуның белән бергә сөйләшү барышында бүгенге п р о з а н ы ү с т е р ү ө ч е н к и р ә к л е ч а р а л а р һәм о е ш т ы р у э ш л ә р е дә аталды. Алар нин-диләр соң?

Әдәби журналларда елның иң яхшы әсәрләрен билгеләп бару кирәк. Бу — талантлы әдипләр өчен стимул булачак, яшь әдипләр өчен үзенчә бер үрнәк ролен үтәячәк, ә укучыларга әдәбият диңгезендә дөрес юнәлешне табарга ярдәм итәчәк.

Ел дәвамында басылып чыккан әдәби әсәрләр турында әдипләрнең җый-налып сөйләшүләрен, ел йомгакларына багышланган җыелышларны оештырыр-га кирәк. Бу юнәлештә элек яшәп килгән матур традиция онытылмаска тиеш.

Прозаның аерым проблемалары буенча фикер алышулар, бәхәсләр, дискус-сияләр оештыру да эшкә ярдәм итәчәк.

Соңгы елларда әдәбиятка килүче яшь талантларның әдәби әзерлеге түбәнәю сәбәпле, Язучылар берлегендә алар өчен әдәби курслар оешыру максатка ярашлы булыр иде.

Басылып чыккан проза әсәрләренә бары тик күләмгә карап кына каләм хакы түләү әсәрләрнең сыйфаты өчен кызыксынуны бетерә, шуңа күрә мондый алымнан баш тарту эшне яхшыртырга ярдәм итәр иде. Яхшы сыйфат өчен түләү дә яхшы булырга тиеш. Шулай ук, талантлы язылган, югары сыйфатлы әдәби әсәрләрне яхшылап пропагандалый белергә дә кирәк.

Укучылар белән очрашуларны, укучылар конференцияләрен даими үткәрү максатка ярашлы булыр иде. Алар әдипләр өчен ике яклы элемтә булдырырга, димәк язучының рухи һәм социаль тәҗрибә белән баюына булыша. Бу чаралар әдәбиятның колачын киңәйтәчәк.

Тагын ике елдан без яңа гасырга — яңа меңьеллыкка — 2000 нче елга атлап керәчәкбез. Менә шушы яңа чорга безнең татар милләте нинди хәлдә, ә тагын да мөһимрәге, алга нинди өметләр белән килеп керә? Ул алдагы елларда нинди эчке кануннар, нинди рухи-әхлакый принциплар буенча яшәргә тиеш?

Искә төшерик: без яшәгән XX гасырның тәүге елларында татар халкы зур күтәренкелек кичергән. Яңа гасырга — XXI гасырга — атлаганда да әнә шундый олы оптимизм белән рухланасы иде.

Шундый зур өметләр белән карый бүген милләтебез язучыларга, каләм ияләренә — кеше рухын, кеше җанын тылсымлый алучы сүз осталарына.

Милләтебезнең әнә шундый олы өметен акласак иде!

Яңа гасыр бусагасын чын мәгънәсендә бар яктан да көчле милләт булып атлый алсак иде!

***Әдәби тәнкыйть бүлеге.***



# ТАРИХТАН ГЫЙБРӘТ, ХАЛЫКТАН ГАЙРӘТ АЛЫП...



Әле генә студентларга Һади Такташ иҗаты хакында лекция укыдым. Мин анда: бөек шагыйребез үзенең беренче чор иҗатында мәңгелек темаларга өстенлек биргән, ә 1923 елда язган «Такташ үлде» әсәреннән соң каләмен чор ихтыяҗларына буйсындырырга мәҗбүр булган дигән фикер үткәрдем... Мөсәгыйт Хәбибуллин тудырган әсәрләр хакында язарга дип кулыма каләм алгач та, кинәт кенә шушы әйткәннәрем исемә төште. Чыннан да М. Хәбибуллин иҗаты да нәкъ шулай икегә бүленә. Беренчесендә ул көн таләбе белән нык бәйләнештә булса, сиксәненче еллар урталарыннан исә, киресенчә, аның иҗатында мәңгелек мәүзугләр — халкыбызның олы тарихи үткәне — үзәккә куела.

Әйе, укучылар аның «Икмәк кадере», «Тау белән тау очрашмаса да», «Чоңгыллар», «Унсигезенче яз», «Сулар үргә акса да» кебек әсәрләрен бер-бер артлы укып килделәр. Өлкән әдибебез А. Расих әйтмешли, «тыйнаклык, кызыксынучанлык һәм үз осталыгын арттыру өстендә туктаусыз эшләү»[1] аның язучы буларак әсәрдән-әсәргә җитлегә баруына китерде. Шушы әйтелгән кадәресе дә аңа әдәбиятыбызда лаеклы урын алырга җитәр иде. Әмма сиксәненче елларның урталарыннан М. Хәбибуллин тарихи мәүзугларда яза башлады. Шуннан соң ул бары тик тарихи өлкәдә генә каләм тибрәтеп килә. Укучылар аның һәр әсәрен көтеп ала, яратып укый. М. Хәбибуллин иҗаты хәзерге татар прозасының үзәк урамына чыкты һәм шуннан уңышлы баруын дәвам итә.

Шунысы куанычлы, Мөсәгыйт ага үзе дә киң күңелле кеше. Ул тарихның тирән катламнарын беренчеләрдән булып ача башлаган Н. Фәттахның иҗатын бик хөрмәт итә. Бу әдип аның өчен күп яктан үрнәк булып тора. М. Хәбибуллин болай ди: «Ител суы ака торур» дигән әсәрдән соң татар әдәбиятында гүяки революция була. Журнал («Казан утлары») татар халкының тарихына игътибарын арттыра. Татар халкының тарихы турында фәнни мәкаләләр, язмалар чыга»[2]. Әйе, бу сүзләрдә тарихи теманың үсеп китүендә ул вакыттагы бердәнбер әдәби журналыбызның тоткан игелекле урыны да бик дөрес билгеләнә.

Китап белән укый-укый танышкан кебек, кешене дә аның белән аралаша-аралаша ача барасың. Шуның кебек, М. Хәбибуллин да әдәбият сөючеләргә үзенең дә, ерак үткәннәребезнең дә яңа якларын мавыктыргыч итеп күрсәтә белә.

1996 елның декабрендә бер төркем язучылар Ютазы, Баулы якларына барып чыктык. Бу сәфәр егерменче-утызынчы елларда берсеннән-берсе үзенчәлекле әсәрләр иҗат иткән, шигъриятебез тарихында үзенең якты эзен калдырган Сирин Батыршинның тууына 100 ел тулуга багышлап оештырылган иде. Шагыйрьнең Баулы зиратындагы кабере янында искә алу митингы булды. Көн салкын булуга карамастан, якташ шагыйрьләре белән чиксез горурланучы Баулы һәм Ютазы районнары халкы шактый күп җыелган иде. Шуннан соң без җирле музейга кердек. Юлдашларымның берсе — танылган язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин иде. Күрәм, ул биредә аеруча дулкынлана. Сәбәбе дә бар. Чөнки ул шушы як кешесе. Яшь чагында биредә шофер, автомеханик булып эшләгән. Мондагы район

[1] Казан утлары, 1971, № 2, 184 б.
[2] Казан утлары, 1992, № 5, 25 б.

газетасында каләмен сынап караган. Шуңа күрә район музеенда аның тормыш юлына һәм иҗатына багышланган махсус стенд оештырылу да табигый тоела. Мин биредә әлегә кадәр яхшы ук таныш булган Мөсәгыйт абыйны үзем өчен өр-яңадан ачкандай булдым.

Баулы яклары — таулы як. Бу таулар, җирнең тирән катламнарыннан чыгып, күкрәкләрен көчле җилләргә каршы куйганнар. Алар өчен табигатьнең бернинди гарасаты да куркыныч түгел. «Әнә шул таулар артында, кырык-илле чакрымда, минем туган авылым Габдрахман булыр,— ди ул.— Туган бишегем Оренбург өлкәсенең Абдуллин районына керә. Менә бу таулар, дулкын-дулкын булып, Уралның иң читтәге бөжраларын тәшкил итәләр».

Авыллар да, кешеләр кебек, төрле язмышлы булганнар. Мөсәгыйтьләрнең ерак бабаларының нәсел-нәсәбе Пенза губернасы Красная Слобода өязе Богдан авылына барып тоташа икән. Үз иманына тугрылыклы булган татарга көн итү кайда да җиңел булмый. Өстен катлаулар өчен иман — байлык. Җир-суын, мал-мөлкәтен саклап калу бәрабәренә Богдан авылы алпавыты да чукынган. Шуннан соң, дөньяга сыймыйча, үзенең элеккеге милләттәшләрен икеләтә-өчләтә тапкыр арттырып җәберли башлый. Бу явызлыкларга түзә алмыйча, авылның гаярь егетләре Габдрахман исемле көчле рухлы ир җитәкчелегендә 1832 елда моннан күчеп китәләр. Рә тавы, Ык елгасы буйлары аларның күңеленә хуш килә. Шушында төпләнеп калалар. Авылга да Габдрахман дип исем бирәләр. Менә 165 ел дәвамында әлеге авыл кешеләре бу тирәдә үзләренең затлылыклары, иген эшенә уңганлыклары, рух байлыгы белән абруй казанып яшиләр икән.

Мондый үзенчәлекле үткәне булган авылда туып үскән Мөсәгыйт Мөдәррис улы, КДУның татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлавына карамастан, тарих белән кызыксынмыйча кала алмаган. Бу кызыксыну иң әүвәл туган авылының гыйбрәтле үткәне белән бәйле булырга тиеш. Күрәбез, Габдрахман авылының нәсел-нәсәбен белү өчен Оренбург өлкәсе кысалары гына тар булып чыга. Пенза якларына да сукмак салырга кирәк икән. Бу исә тикшеренүчене татар мохитенең киңрәк мәйданнарына һәм катламнарына илтеп чыгара.

М. Хәбибуллин үзе тарихи мәүзугларга яза башлавын шактый гадиләштереп аңлата. Таҗикстандагы Рудәкый исемендәге урта мәктәптә тарих укытырга туры килә аңа. Ләкин сизә: рәсми дәреслекләрдә язылганча гына укытсаң, балалар сиңа ышанып бетми. Алар син сөйләгәнгә өстәп тәкъдим ителгән китаплардан укыйлар, куелган сорауларга җавап та бирәләр кебек, ләкин телләре белән әйткәннәре ихластан түгел. Димәк, алар мәктәптән тыш ниндидер чыганаклардан мәгълүмат алалар, күңелләрендәге сорауларга канәгатьләнерлек җавап тапмыйлар. Әйтик, шул ук дәреслекләрдә Англиянең Һиндстанны яулап алуы чит җирләрне колонияләштерү дип атала, ә Россиянең Казан ханлыгын, Төркестанны көч белән буйсындыруы тарих фәнендә уңай күренеш дип бәяләнә. Югыйсә, бер илнең икенчесенә басып керүе бары тик явызлык, караклык дип кенә бәяләнергә тиеш иде бит.

Шул ук рәсми тарих китапларында татарларны нинди генә ямьсез эпитетлар белән тамгаламыйлар. Чыннан да, кемнәр булган безнең борынгы ата-бабаларыбыз, әни-әбиләребез? Моның асылына төшенеп булмыймы? Бу хакта нинди дә булса чыганаклар сакланып калмаганмы? «Мин,— ди ул,— үземә бер ачыш ясадым: балалар тарихны, нигездә, үзләре укыган тарихи әдәби әсәрләр буенча хәтерләрендә ныграк калдыралар икән». Әмма, шул ук вакытта, ул бер катгый таләпне шарт итеп куя: «без үз тарихыбызны үзебез язарга тиеш»[1]. Моны башка халыкларның тарихчыларына ышанып тапшырып булмый. Ник дигәндә, алар субъективлыктан, мәсьәләгә үз кавеме күзлеге аша караудан арына алмыйлар. Менә шуннан М. Хәбибуллин өчен уннарча елларга сузылган эзләнүләр чоры башлана.

Сүз дә юк, биредә эш тегеләре яки бу зыялыбызның тарихи катламнарга үтеп керергә әзер булуы, шуны нәтиҗәле файдалануында гына түгел. Н. Фәттах, М. Хәбибуллин, Ф. Латыйфи, Җ. Рәхимов, Р. Мөхәммәдиев, Ә. Рәшитов, В. Имамов кебек каләмдәшләребезгә күңелләрне сорап торган тарих өлкәсенә үтеп керү өчен тиешле сәяси-иҗтимагый шартларның барлыкка килүе кирәк иде. Ягъни Хрущев «җепшеклеге» яки аннан соңгы йомшарулар, ниһаять, җәмгыятебездә кискен үзгәрешләргә китергән сиксәненче-туксанынчы еллар вакыйгалары булмаса, М. Хәбибуллинның «Кубрат хан», «Илчегә үлем юк», «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный», «Шайтан каласы», «Хан оныгы Хансөяр» кебек романнарының язылуы да, басылып чыгуы да була алмас иде.

---

[1] Казан утлары, 1992, № 5, 24—25 бб.

Язучы үз әсәрендә туплаган барлык материалларын беркайчан да әсәрләрендә биреп бетерә алмый. Чөнки аларның күбесе автор уйланмасының тышында кала. Бу М. Хәбибуллин иҗатында да расланды. Ул тарихтагы бөек шәхесләребез хакында, аерым алганда Кубрат хан, Кодрак хан, Ишкул хан, Иллек хан, Болгар хан, Тукый хан, Айдар хан, Хәнджәл хан, Зөбәер хан, Мөхәммәтәмин хан, Силки хан, Алмас хан, Микаил хан, Әхмәд ханнар турында гаҗәп кызыклы мәгълүматлар туплый. Ләкин сурәтләү өчен аларның берсен — Кубрат ханны ала. Бу борынгы бабабыз, Азов диңгезе буенда Бөек Болгар дәүләтен төзеп, Византия империясен үзе белән санлашырга мәҗбүр итә алган. Шуңа күрә аның һәм балаларының тарихта калдырган тирән эзе язучының игътибарын аеруча җәлеп иткән. Дөресен әйткәндә, М. Хәбибуллин бу тарихи шәхесне хәзерге буыннар өчен өр-яңадан тудырды. Кубрат хан, аның уллары Батбай, Кодрак, Аспарух, Балкыр, Аслан исемнәре телгә керде. «Эрмитаж» фондыннан Кубрат хан хәзинәләре Казаныбызга китереп күрсәтелгәч, инде әлеге ханның бөеклеген җисемләрәк тойгандай булдык.

«Кубрат хан» романы белән М. Хәбибуллин иҗат мөмкинлекләренең яңа сәхифәсен ачты. Әлбәттә, биредә уңышның Кубратның шәхес буларак җәлеп итү көчендә генә түгел, бәлки, язучы өчен иң мөһиме булган образ тудыру осталыгында. Кубрат хан акылы белән көчле. «Мин ераграк күрәм, мине Болгарның киләчәге дә борчый»,— ди ул. Әмма сәяси җитәкче акылына гына түгел, бәлки үз артында торган көчнең зурлыгына яки кечкенәлегенә таянып эш итәргә тиеш була. Кубрат нәкъ менә шундый җитәкче буларак тәкъдим ителә.

М. Хәбибуллин Болгар тарихына кабат-кабат әйләнеп кайта. Минем уемча, аның «Тарих сәхифәләрен актарганда»[1] дигән эссе жанрында язылган уйланулары зәвыклы укучыларга шулай ук фикерләү өчен күп мәгълүмат бирә. Монысы инде Идел буе Болгары чорындагы хәл-әхвәлләрне тасвирлауга багышланган. Үзәктә болгарларның ислам динен кабул итүләренә бәйләнешле фәлсәфи бәяләү, фикер йөртү тора. «Язучы буларак мине Ибне-Фадлан бик кызыксындырмый»,— ди ул. Гарәп сәяхәтчесенең бу очракта иң игелекле эше, әлбәттә, аның «обшу илдә ниләр күргән»леге, «бабаларыбыз турында нинди тарихи мәгълүматлар калдырган»лыгы. Аның сурәтләвендә болгарлар затлы, әхлаклы, таза рухлы булып күренәләр. Ислам динен кабул итү исә болгарларның бу матур сыйфатларын тагын да ныгытырга гына ярдәм итә. Ислам диненә кадәр болгарлар табынган Тәңре динен мәҗүсилек дип кенә карап булмавы бәхәссез. Тәңре дине — Ислам өчен табигый рәвештә җирлек әзерли. Алла урынына кайчакта Тәңре сүзен кулланабыз икән, моның тирән мәгънәсе, аерылгысыз эчке бәйләнеше бар. Ибне Фадлан сурәтләгән кайбер чит кавемнәрнең яшәү рәвешендәге шыксызлыклар фонында без моны тагын да яхшырак тоябыз. М. Хәбибуллин Ибне Фадланның бу сәяхәтнамәсенә гаҗәп кызыклы шәрехнамә бирә. Дөресендә, мең еллык тарихыбызга бик кызыклы, дәлилле, этрафлы күзәтү ясый. Без биредә тарихны белүче, хөрмәтләүче, аның ачы сабакларын истә тотып, акыллы эш итәргә өндәүче аксакалыбызны күрәбез. Язучының быел Хәтер көне алдыннан «Шәһри Казан» газетасында берничә санда басылган «Дәверләргә сузылган каһәр» дигән язмасы да кайнарлыгы, бәхәскә корылганлыгы белән укучыларда кызыксыну уятты.

Дөрес, соңгы вакытларда М. Хәбибуллин иҗатына карата матбугатта тәнкыйть фикерләре дә чагылып үтте. Әлбәттә, хаклы әйтелгәннәре дә байтак, киләчәктәге иҗатында язучы аларны искә алыр дип уйларга кирәк. Чөнки фикер әйтеп чыгучы каләмдәшләребезнең теләге изге — тарихи үткәннәребезнең мөмкин кадәр дөрес сурәтләнүен күрү, М. Хәбибуллин әсәрләренең сәнгатьчә тагын да камил булуларын теләү. Бу — ахыр чиктә тулаем әдәбиятыбызның абруе турында гамьләнү. Мөсәгыйт Хәбибуллинның да бар омтылганы шул, лабаса. «Татар язучысы буларак, мин бүген алны-артны белми үз халкым өчен иҗат итәм», дип язган иде ул 1994 елда «Җыен алдыннан» дигән бер чыгышында. Җитмеш яше тулган көннәрдә без аңа бу юлда тагын да зуррак уңышларга юлыгуын телибез.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН.**

---

[1] Мирас, 1994, № 7—8.

# ТАТАР ЗИРАТЛАРЫ

Фәндә зират һәм каберлекләрне өйрәнә торган берничә гыйльми тикшерү юнәлеше бар. Археологлар — борынгы каберлекләрне казып, ул чорларда яшәгән кешеләрнең дини ышануларын, матди культураларын, көнкүрешләрен; антропологлар — каберләрдә калган кеше сөякләре буенча аларның тышкы кыяфәтләрен торгызалар. Мисалга, әйтик, тарихи шәхесләрдән Әбугалисинаның, Аксак Тимернең, Иван Грозныйның кыяфәт-сыннары аларның казып алынган сөякләре калдыклары буенча эшләнгән. Этнографлар күмү йолаларын тасвирлыйлар. Каберлектәге эпиграфика язмаларын өйрәнүчеләр борынгы кешеләрнең телен, дәүләт төзелешен, кешеләрнең җәмгыятьтә билгән урыннарын, дини мәзһәбләрен билгелиләр. Кабер өстендәге конкрет корылмалар архитекторлар һәм сәнгать белгечләре тарафыннан өйрәнелә.

Татарстанда археологлар нигездә VIII—XII гасырлардан калган каберләрне шактый гына тирәнтен өйрәнеп, ул дәверләр тарихына күп ачыклыклар керттеләр. Аеруча А. Х. Халиков тарафыннан Танкеевка, Олы Тархан, Кайбеле каберлекләре кебек атаклы археологик истәлекләр өйрәнелеп, урта гасыр болгар халкының Идел—Кама буйларында барган этник тарихы ачыкланды. Олы Тигәнәле авылы янында табылган мадьяр каберлегенең дә өйрәнелүе этник тарихыбыз өчен әһәмиятле булды. Археолог Е. А. Халикованың борынгы болгарларның (XII гасырны да кертеп) каберлекләрен өйрәнү нәтиҗәләре кызыклы: болгарлар XII гасыр ахырына ислам диненә күчеп бетkәннәр. Ләкин, кызганычка каршы, Урта Идел археологиясендә фәкать «болгар культурасы» дип берьяклы һәм тенденциоз юнәлештәге казу эшләре алып бару тарихыбызны фальсификацияләүгә китерде.

Хәзерге Татарстан җирендәге урта гасырларда булган Алтын Урда, Казан ханлыгы, Нугай урдасы тарихы турында регионның урыс империясенә көчләп кертелгәннән соң кичергән үзгәрешләренә карата Казан археологлары бер дә рәтле, канәгатьләнерлек җавап бирерлек эш башкара алмадылар. Аларны өйрәнүгә беркадәр фәкать болгар һәм татар эпиграфикасын өйрәнүчеләр генә өлеш кертеләр. Кабер ташларының телен өйрәнүчеләр язмалар аша болгарларның теле ни рәвешле булуын, алар җәмгыятенең структурасы хакында мөһим ачышлар ясадылар.

Укучыларга тәкъдим ителгән бу хезмәттә без аларны татар зиратлары һәм аларның тарихи үткәннәренә карата үзебезнең археографик экспедицияләр вакытында уздырган күзәтүләребез белән таныштырабыз. Тикшерену өчен материал итеп нигездә Татарстандагы зиратлар файдаланылды.

* * *

Татар халкы яшәгән һәр төбәктә узган катлаулы тарихның шаһитләре булган борынгы зиратлар бар. Әлеге зиратларда каберләр өстенә куелган язулы ташлар, буралар, тактадан эшләнгән чардуганнар, таштан яки булмаса кирпечтән эшләнгән дөрбәләр (мавзолейлар), истәлек өчен кабер өстенә утыртылган агачлар, гади генә язусыз (ә кайчакта тамгалы) кыргый ташлар, кабер өстен белдерү өчен утыртылган баганалар һ. б. күрергә мөмкин.

Татар авылларында аның тарихына бәйле рәвештә «Ханнар зираты», «Иске зират», «Морзалар зираты», «Яңа зират», «Чирмеш зираты», «Чуваш зираты», «Ар зираты», «Урыс зираты», «Керәшен зираты», «Әүлия зираты», «Изгеләр зираты», «Юлда үлгән билгесез кеше зираты», «Хаждан кайтканда үлгән кеше

зираты», «Исереп үлгәннәр зираты», «Ачлык елда үлгәннәр зираты» һ. б. бар. Боларның һәрберсе — конкрет авылның тарихы белән бәйләнешле рәвештә барлыкка килгән тарихи урыннар. Зиратларга карата халыкта әүвәлдән хөрмәт һәм олылау хисләре булган, борынгылар кабер яки зиратларның тылсымлы көчләренә ышанганнар. Гадәттә узган гасырда каберләрне карап, тәрбияләп тору өч-дүрт буын буена барган. Халык арасында алар белән бәйле төрле ышанулар яшәгән. Казан арты авылларында йөргәндә төрле-төрле ышанулар белән очрашырга туры килде. Аларның кайберләрен язып үтү мөһим:

**— Борынгы заманда авылның (яки ыру-кабиләнең) зиратын дошман басып алса, авыл буйсынган саналган. Димәк, ата-баба каберләрен саклый алмаган халык колга хисапланган;**

**— Зиратлар, каберләр тирәсендә үскән җиләк-җимешләрне ашарга ярамаган;**

**— Зират яки каберләр янында табигый йомышларны үтәү тыелган;**

**— Зират белән авыл арасында елга булырга тиеш, чөнки кайбер өрәге каты кешеләрнең өрәкләре зираттан чыгып кешеләр янына килергә, аларга зыян салырга мөмкин булган. Әгәр авыл белән зират арасында елга булса, өрәк аннан үтә алмый дип ышанганнар.**

Әүвәл зираттагы берәр кабердән өрәк чыккан дип ышансалар, аны казып, мәетне үтәли уздырып казык кагу гадәте булган.



*1. Татарстанның Кайбыч төбәге, Акъегет авылы зиратындагы 1895 елда куелган кабер ташы. һ. Йосыпов фотосы.*

Әгәр мәет юып кәфенләнгән булса, аның йөзен ачып карау хәзер дә тыела. Кырым татарларында мәетне зиратка алып барып юып, югач йөзен ачып күрсәтмичә күмәләр. Бу гадәт әүвәл Идел буенда да шулай булганга охшый, чөнки Болгар шәһәре зиратында сакланган мунча хәрабәләре шушы йола файдасына дәлил булып тора.

Әгәр берәр хәсрәте, чире, борчуы булса, изге саналган кешенең каберенә барып догалар кылып, сәдакалар куеп китә торган булганнар. Казан тирәсендәге шундый изге каберләрдән «Касыйм шәех кабере» (Норлат стансасы кырында), «Гайшә бикә кабере» (Иске Казан янында), «Идрис хафиз кабере» (Котлы Бөкәш авылы янындагы зиратта), «Мәгълүм хуҗа кабере» (Биләр авылы янында, Балынгуз тавында), «Сөембикә манарасы астындагы изгеләрнең каберләре», (Казан ханнары каберләре), «Кабан күле башындагы изгеләрнең каберләре», «Җиде изге кызның каберләре» (Казандагы Яңа Бистә зиратында), «Теше сызлап үлгән кыз кабере» (Казандагы Иске Бистә, Казаков мәчете янында булган), «Изгеләр кабере» (Арча төбәге Иске Ашыт кырында) һ. б. бар.

Бу изге каберләрдән изге кешеләрнең чыгып йөрүләре хакында риваятьләр дә сөйләнә. Ул изгеләр сәдака, дога өмет итеп чыгалар икән. Алар киләчәкне дә әйтә алганнар. Мондый чыгып йөргән изгеләрне «хуҗалар», «хуҗалар чыккан» дип сөйлиләр. Кешеләр хуҗалар белән сөйләшергә, алардан киләчәк турында сорашып белергә мөмкин, дип ышанганнар. Хуҗаларга вәгъдә бирсәң, аны бозу бик нык җәза белән тыелган. Соңгы елларда хуҗалар күренү турындагы сүзләр Болгар шәһәре һәм Әтнә төбәгендә язып алынды.

Иске каберләрдә бурсык кереп йөрерлек тишекләр була. Бу тишектән үлгән кешенең җаны кереп-чыгып йөри дип ышанучылар бар.

Ниндидер авыр хәлләргә төшкән кешеләр бу авырлыктан котылсам, зират әйләндерер идем дип нәзер әйтә торган булганнар. Нәзер әйтү үз-үзеңә вәгъдә бирү дигән сүз. Авыр хәлләре узгач, аерым кешеләрнең нәзерләрен үтиселәре килмәгән, ләкин нәзерем тотып, тагын да яманрак хәлгә таруым бар дип куркып,

аны юри генә булса да үтәгәннәр. Мәсәлән, зират әйләндерү кебек чыгымлы эштән нәзер әйтүчеләр зиратны җеп сузып кына биш-алты рәт әйләндереп чыкканнар. Мондый нәзерләрне күз буяп үтәүчеләр соңгы елларгача шул гадәтләрен куалар.

Ләкин татар тарихында зиратларны тәртиптә тотып, аның тирә-ягын карап торучылар да аз булмаган. Олы Мәңгәрдән миллионер Гатаулла Сәлимҗанов (—1918) шундый милләтпәрвар кеше булган. Галимҗан Барудиның атасы сәүдәгәр Мөхәммәтҗан Галиев (1832—1908) үз акчасына Казандагы Яңа Бистә татар зиратын кызыл кирпечтән салынган дивар белән әйләндереп алган була. Аның стеналары әле дә урыны-урыны белән саклана.

Татарстан, Мари Эл, Киров өлкәсендәге татар зиратларының күпчелеге агачлар белән капланган. Ләкин Татарстанның Кама аръягы районнарында зиратларга агач утырту XX гасыр урталарыннан соң гына таралып бара, хәтта бөтенләй агачсыз зиратлар да күп күренә.

Татарстан җөмһүрияте җирләрендә сакланып калган ташландык борынгы зиратлар, иске зиратлар, аерым каберләр яки кабер ташлары катлаулы тарихи вакыйгаларның шаһитләре булып калганнар. Болгар дәүләте заманында ук аның җирләрендә төрле борынгы кешеләрдән калган кабер-зиратлар булып, алар турында төрле риваятьләр таралган булгандыр, күрәсең. Чөнки гарәп сәяхәтчеләре Ибн Фадлан, Әбү Хәмид әл-Гарнати язмаларында ук гадәти булмаган каберләр (сөякләр) хакында төрле риваятьләр китерелә[1]. Ул вакытта борынгы каберләрне мөселманнар карашыннан чыгып әкияти «Гад кавеме» халкына нисбәтләгәннәр.

Мөселманлык кабул итү белән мәҗүсилеккә бәйле ташландык зират-каберләрне Урта Иделдә «чирмеш зираты» дип атау гадәткә кергән. Халык аларны мөселман каберләре урнашу тәртибенә охшамаганга, аерылып торганга шулай атаган, чөнки борынгыдан калган каберләр турында тарихи хәтер булмаганга шул универсаль термин кулланылган. «Чирмеш зираты» дип аталган каберлекләр белән бәйле рәвештә кайбер мәҗүси йолалар да сакланган. Мәсәлән, авылдагы берәр хуҗалыкның мал-туары авырса, хуҗа чирле малын әлеге зират тирәсеннән әйләндереп кайта торган була. Бу аеруча атлар күбенсә, бәвел итә алмаса, аларны йөртеп кайтулары белән бәйле мәгълүм чара булып танылган. Мондый йола фәкать әүвәлдән авыл тарихы белән бәйләнмәгән, мөселман зиратларына охшамаган каберлекләргә карата гына кулланылган. Югыйсә тарихи хәтер булган каберләр турында халыкның телендә конкрет атамалар була, мәсәлән, юлда өшеп үлгән яки үтерелгән очраклы кешеләрнең каберләре, исереп үлгән кешеләрнең каберләре әнә шундыйлардан. Явыз ният белән йөреп үлгән кешеләрне дә мөселман зиратына күмдермәгәннәр, аларның каберләре читтә тора.

Мөселман татар ышануы буенча мәетне кыр аркылы йөртергә ярамаган, шунлыктан аларны кайда үлсә, шул җирдә күмгәннәр. Әгәр мөселман мәхәлләсе булса, шәхесе мәгълүм мәрхүмне җеназа укып шунда күмгәннәр. Кунакка барган, хаҗга барган җирендә үлеп калган кешеләр һәм аларның каберләре хакында күп кенә риваятьләр бар. Мәсәлән, шагыйрь Шәмсетдин Зәкинең хаҗга барганда Таганрог шәһәрендә, Габделнасыйр Курсавиның Истанбул янындагы Искәндәриядә үлеп калуы хакында хәбәрләр сакланган. Татарстандагы Саба авылында кунакка килгән бер кыз үлеп калган була. Саба зиратында әлеге кыз кабере өстенә утыртылган каенны әле соңгы елларда да «Кунак кыз каены» дип атап йөртәләр иде. Казан артында хатын-кыз кабере өстенә каен, ир-ат кабере өстенә нарат утырту гадәте кергән булган. Хәзер инде ул гадәт онытылып, төрле агачлар утыртылалар.

Зиратларда каберләр өстенә күбрәк усак агачы утыртуны хуп күргәннәр. Ни өчен дигәндә усак агачының яфраклары җил исмәгән чакта да шыбырдашып селкенеп торалар. Усак яфракларының даими шыбырдап торуы мәетләр рухына тәкьбир әйтеп тору дип саналган. Зиратларда агачлар утырту ислам дине ышанулары белән бәйле, монда угро-финнар йогынтысы юк.

Әүвәл җәйге эссе көннәрдә яңгырлар озак булмый торса, кайдадыр кырда, күмелмәгән мәет ята, шуны табып күмми торып яңгыр яумас, дип ышану бар иде. Һәм кешеләр кыр-урманнарны карап чыгалар иде. Кырдагы аерым каберләр өстенә чиләкләп су да сибеп кайтулар турында хәбәрләр ишетелгәләде. Тарихи

[1] Ковалевский А. П. Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921—922 гг.— Харьков, 1956.— Б. 139.; Путешествие Абу Хамида Ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131—1153 гг.) — М., 1971.— С. 30.

чыганакларда мәетләрнең яңгырны яудырмый, тотып торуына ышану турында хәбәрләр бар. Мәсәлән, борынгы заманнарда, хазарлар, яңгыр яумаса, үзләренең мәетләренә табыну йоласы уздыра торган булалар. Мәетләрнең янгыр яудыруга кодрәте житү турындагы бу ышану бик борынгы заманнарда һәм күп халыкларга хас булган, күрәсең. Бүгенге көндә татар халкында мәет күмгән вакытта кабер өстенә аз гына яңгыр бөртекләре төшсә дә, ул мәетнең изгелеге хакындагы галәмәт булып хисаплана.

* * *

VIII—IX гасырларда Урта Иделгә күчеп килгән болгарларның башка кавемнәр белән үзара аралашуы, Алтын Урда дәүләте чорындагы миграция давыллары, Казан ханлыгы төзелү, Казан ханлыгының җимерелүе, урыс хөкүмәтенең чукындыру сәясәте яңа зиратлар барлыкка килүгә тарихи сәбәпләр булганнар.

Болгарларның традицион яшәү урыннарында XIV гасырның икенче яртысында булып үткән социаль тетрәнүләр, аларның авылларына бик күп фажигаләр алып килә. Чума-холера эпидемияләре һәм урыс ушкуйникларының 1360 елдан соң башланып киткән һөҗүмнәре, 1395 елда Аксак Тимернең бөтен Алтын Урданың утрак тормышлы шәһәр һәм авылларын ут белән өтеп алуы, Кама елгасының сул ягындагы һәм Тау ягының бөтен районнарын туздыруы — Болгар олысының төп утраклык өлкәләрен юкка чыгара яза. Чуаш теле элементлары белән язылган XIII—XIV йөз болгар кабер ташларының юкка чыгуы да шушы хакта сөйли. 1395—1396 елгы җимерелүдән соң, Болгар, Биләр, Сарай, Кәрдәр, Суар, Сенбер, Җүкәтау шәһәрләреннән чыккан татарлар Ыкның түбән агымына, Нократ буйларына, Кама буенча менеп Чулман үзәнлекләренә, Камадан төньякка таба китеп Казан артына, Тау ягының төньягына (хәзерге Апас, Зеленодол, Кайбыч төбәкләренә) олы елга ярларыннан читкәрәк китеп урнашалар, яңа авыллар, булачак шәһәрләрне башлап җибәрәләр. Унбишенче гасыр башында Нократ буйларында, Казан артында һәм Тау ягында барлыкка килгән яңа авыллар болгар авыллары өстенә утыргандырмы-юктырмы, аны кистереп әйтерлек документлар юк. Ләкин, алар болгар зиратларын файдаланмыйча, яңа зиратлар башлаганнар. Шунлыктан Нократ буйларында, Казан артында һәм Тау ягында сакланып калган болгар кабер ташларының барысы да күптән ташланган, иске зиратлар өстендә саклана-лар. Мәсәлән, Иске Ашыт, Эзмә, Иске Кирмән, Иске Кишет, Кече Кайбыч, Урыс Урматы, Татар Әҗәле, Кибәк хуҗа, Олы Әтрәч, Олы Әшнәк, Салтыган h. б. авыллардагы истәлекләр шуның мисалы.



*Татарстанның Азнакай төбәгендәге Чаллы авылы зиратындагы XIX гасыр кабер ташы. М. Әхмәтҗанов фотосы (1978).*

Урыслар Казан ханлыгын барлык авыл-шәһәрләре белән җимереп бетергәч, анда күп урыннар буш кала. Урыслар төзегән писцовая кенәгәләрдә йөзләрчә «пустошь», ягъни «бушап калган авыл урыннары» санала. Казан илендә канлы яулап алучылар үтмәгән, кул салмаган авылларның саны бишкә дә тулмыйдыр. Күпчелек халык илен-җирен, бабаларының каберләрен ташлап Көнчыгышка — Нугай урдасы җирләренә — Агыйдел, Ык, Дим буйларына барып төпләнә. Шулай ук Мамадыш, Әгерже, Алабуга төбәкләрендә туктап калучылар да житәрлек була. Археограф С. Вахиди тарафыннан 1929 елда Минзәлә кантунында тупланган материаллар бу яклардагы күп кенә татар авылларының Казаннан һәм Казан тирәсендәге авыллардан күчеп килүләрен хәбәр итәләр.

Казандагы 1552—1557 елларда барган сугышлардан соң исән калган аз санлы татарлар, аулаграк урыннарда яңа авыллар корып утыра башлыйлар. Еш кына Казан ханлыгы дәверендә булган авылларның зиратлары ташландык хәлдә калган. Мәсәлән, Иске Мәнгәр, Иске Кишет, Иске Әҗем, Кара Дуган, Кече Әтнә, Югары Сәрдә, Әлдермеш, Чыршы, Чыпчык, Камай, Кишмәт, Урта Аты, Наласа, Казакълар, Күгеш, Бәчек, Кече Кайбыч, Татар Танае һ. б. лар әнә шундыйлардан. Яки соңыннан барлыкка килгән авылларның зиратлары үсеп, искеләренә күрше булып торсалар, кушылып уртак зират булып киткәннәр. Шулай ук борынгы ташларны яңа зиратларга күчерү очраклары да мәгълүм. Мәсәлән, Арча станциясе янындагы Казан ханлыгы дәвереннән калган җиде борынгы ташның берсен Тукай урамы артындагы яңа каберлеккә менгереп урнаштырганнар, калганнарын бульдозер туфрак белән күмеп калдырган.

1976—1977 елларда Чаллы шәһәре янында ГЭС төзү вакытында Актаныш, Әгерже, Минзәлә тирәләрендәге шактый зиратлар күчерелде. Шул ук вакытта күп кенә XVII—XX гасыр татар эпиграфик истәлекләре дә җимерелде һәм су астында калды. Каберлекләрдән чыккан кеше сөякләрен татар зиратларына траншеялар казып, целлофан капчыкларга тутырып күмделәр. Кайбер урыннарда җеназа укып күмүләрен дә күрергә туры килде.




*Татарстанның Азнакай төбәгендәге Чаллы авылы зиратындагы кабер ташы (1810). М. Әхмәтҗанов фотосы (1918).*

Казан ханлыгы җимерелгәннең беренче елларында татар зиратларындагы ташларны каберләреннән алып төзелеш эшләрендә файдаланганнар. Башкаланың зур зиратыннан һәм Казан ханнары зиратыннан бер таш та исән калмаган. Казан Кремль стеналарының һәм XVI—XVII гасырда төзелгән чиркәүләренең, йортларының нигезләренә меңнәрчә татар кабере ташлары түшәлгәндер. Урыс сәяхәтчеләре бертуган Чернецовларның XIX гасырның беренче чирегендә Казанда булган чакта алып барган юлъязмаларында Кремльдәге Благовещения чиркәве стеналарында мөселман язулы таш күрүләре хакында язып калдырганнар[1]. Мондый гадәт Алтын Урданың башкаласы булган Сарай шәһәре хәрабәләре белән дә кабатлана. Төрек географы Кятиб Чәләби үзенең XVII гасырның беренче яртысында Сарай җимерекләре арасында таштан эшләнгән зур-зур дөрбәләр, кабер ташы рәвешендә бастырылып куелган язулы колонна күрүе хакында яза[2]. Сарай шәһәрен урысның җиңел акыллы патшасы, Иван Грозныйның улы, Федор Ивановичның боерыгы буенча бөтенләй җимереп бетереп, аның кирпечләреннән Әстерханда крепость коралар. Алтын Урда ханнарының каберлегендәге зур дөрбәләр дә шулай җимертелә (ул ханнар зираты бүгенге Әстерхан өлкәсенең Хәрәбәле төбәге, Лапас авылы янында булган[3]). Әүвәлге татар дәүләте җирләрендә аларны басып алганнан соң, XVI—XIX гасырларда төзелгән чиркәүләрнең һәрберсенә дә татар кирпече яки кабер ташы керми калмагандыр. Мәсәлән, Татарстанның Биектау районына караган Урыс Алаты чиркәвенең нигезенә 7—8 лап «куфи язулы» кабер ташы салынган. Болгар шәһәрендә XVIII гасырда салынган

[1] Әхмәтҗанов М. Чиркәү тирәсендә уйлар/Татарстан хәбәрләре.— 1994.— 12 ноябрь.
[2] Әхмәтҗанов М. «Каһарман катил» дастаны/Идел.— 1995.— № 10.— 33—37 б.б.
[3] Егоров В. Л. Историческая география Золотой Орды в XIII—XIV вв.— М.: «Наука», 1985.— С. 117.

чиркәүнең нигезе һәм идәннәре XIII—XIV гасыр мөселман кабер ташларыннан түшәлгәнлеген күпләр күзләре белән күргәндер. Тарихчылар Арбузов Баран авылы чиркәве нигезеннән дә бер XIV гасыр мөселман ташы тапканнар иде. Тәтеш төбәгендәге Ямбакты чиркәве бусагасындагы XIII гасыр мөселман ташын тарихчы Гайнетдин Әхмәров укып күчереп язып алган. Татар халкының бөтен Русия җирендә XVII—XVIII гасырларда да тынычлап яшәрлек мөмкинлеге булмый. Көчләп чукындыру сәясәте 1775 елга кадәр корал кулланып алып барганлыктан, бүгенге Воронеж, Пенза, Рязань, Мордовия, Киров, Тамбов, Түбән Новгород өлкәләрендәге һәм Татарстан, Чуашстан җирләрендәге татарлар авылларын, зиратларын



*Кыргызстанның Ош өлкәсендәге мазар авылы янында Караханилар дәүләте давереннән калган XII гасыр мөселман кабер ташларындагы язу үрнәкләре.*

ташлап Урал буйларына, Себер, Казакъстан якларына качып барып утырырга мәҗбүр булганнар. Идел—Урал буйларындагы авылларга да тынычлык булмаган, көчләп чукындыруга, милли һәм социаль изүгә каршы көрәшкә күтәрелгән татар авылларын урыс армиясе көлгә әйләндереп бер генә кат узмаган — көлгә әйләнгәннәр урынына икенче, анысы яндырылса өченче, дүртенче татар авыллары үсеп чыккан. Шунлыктан һәр татар авылы кырында 3—4 әр иске зиратлар тарих шаһитләре булып сакланалар.

* * *

Татар зиратларындагы кабер өсте корылмалары һәм кайбер күмү йолалары хакында археологлар мөселман болгарларның кабер өсләрендә 1280 елларга кадәр язулы ташлар яки таштан эшләнгән дөрбәләр булуы хакында материаллар күрсәтмиләр. Кыпчакларның бабалар культы белән бәйле булган таш сыннары да (балбаллар) татар каберлекләрендә XIII гасырда да аннан соң да очрамыйлар.

Урыс тарихчылары тарафыннан язылган елъязмалардан күренгәнчә, Алтын Урда дәүләтендә монголларның күпләп яшәүләренә дәлил булырлык каберлекләр дә мәгълүм түгел. Әйтик, археолог Г. А. Федоров-Давыдов XIII гасырда Көнчыгыш Европага монголлар килгән дип әйтерлек чыганаклар күрми[1].

Татар һәм болгар зиратларындагы кабер өсләрендә тарихта беренче мәртәбә язулы кабер ташлары һәм дөрбәләр кору 1280 елдан соң, Алтын Урда мәдәниятенең бер элементы буларак башланып, татар халкында бүгенгәчә кайбер үзгәрешләр белән дәвам итә. Аның өзлексез килгән тарихлы традициясе татарның күршесе булган башкортта, чуашта, марида, удмуртта, мордваларда һәм урыста да юк.

Сакланып калган археологик истәлекләр Алтын Урдада кабер өсләренә язулы ташлар һәм дөрбәләр (мавзолейлар) кору йоласының Кырымнан Уралгача һәм Киров өлкәсеннән Әстерхангача таралган булуын раслыйлар. Әлеге темага багышланган хезмәт авторларыннан Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйри, Г. Рәхим, В. Вельяминов-Зернов, С. Вахиди, Һ. Юсупов, Ф. Хәкимҗанов һәм башка татар эпиграфик истәлекләрен өйрәтүчеләр һәм Г. А. Федоров-Давыдов, С. Плетнева, С. Смирнов, Р. Фәхретдинов кебек дистәләрчә археологлар шул караштa торалар.

Атаклы татарларның каберләре өстенә куелган язулы кабер ташларының саны җиде гасыр дәвамында берничә дистә меңнәргә җиткәндер. Аларның Урта Идел өлкәсендәге үрнәкләре яхшы гына өйрәнелгән, ә инде татарлар яши торган башка өлкәләрдәге, шәһәрләрдәге татар зиратлары, бай фактик материаллар булуга карамастан, өйрәнелмәгән. Ул ташлар татарның тарихын, телен, әдәбиятын, сәнгатен өйрәнү өчен мөһим чыганаклар булырлар иде.

Инде хәзер язулы кабер ташларының кайдан, нинди традиция белән килеп чыкканлыклары хакында фикер йөртик.

Барыннан да бигрәк кабер өстенә ташлар эшләтеп куйдырту өчен матди чыгымнар кирәк. Алтын Урда дәүләтендә XIII гасыр ахырында моңа зәмин тупланган булган инде. Чөнки бу дәүләтнең берничә йөз шәһәрендә ак таш сарайлар, зур мунчалар, керамика һәм чуен кою остаханәләре, кәрвансарайлар, зур-зур мәчетләр, мәдрәсәләр, су үткәрү системалары, манаралар, дөрбәләр, күперләр корылган. Тарихчы В. Л. Егоров Алтын Урданың Аккирмән шәһәреннән XIV йөздә Европага иң яхшы сыйфатлы бодай чыгарылып торуы хакында яза[2].

Батый хан заманында Алтын Урда дәүләтенең гаскәре Хорезмнан килгән төрки телле татарлардан торган. Аларны икенче төрле кыймаклар дип тә атаганнар. Ул татарлар мөселман булып, Караханиләр дәүләтенең һәм Хорезм шаһлыгының төп халкын тәшкил иткәннәр. Караханилар дәүләтендә инде XI гасырлардан бирле язулы кабер ташларын куя килгәннәр, дөрбәләр корганнар. Аларның үрнәкләре Кыргызстан, Казакъстан галимнәре һ. б. лар тарафыннан өйрәнелеп, матбугатта тасвирланган[3]. Кыргызстан җирләре һәм Казакъстанның көньяк өлеше — Караханилар дәүләтенең үзәк өлкәләрен тәшкил иткәннәр.

Үз чиратларында эпиграфик таш язмалар һәм кабер өсте корылмалары төзү традициясе Төрек каганаты дәверләренә китә. Һәм бу хакта киң фәнни әдәбият


---

[1] Федоров-Давыдов Г. А. Кочевники Восточной Европы под властью золотоордынских ханов — Изд-во Московского университета, 1966. — С. 157.

[2] Егоров В. Л. Историческая география Золотой Орды в XIII—XIV вв. — М.: «Наука», 1985. — С. 79.

[3] Джумагулов Ч. Эпиграфика Киргизии. Выпуск 3. — Фрунзе: Изд-во «Илим», 1987. — С. 167; История Казахской ССР. Т. 1. — Алма-Ата: Изд-во АН Казах. ССР, 1957. — С.С. 94—95; Якубовский А. Ю. Две надписи на северном мавзолее 1152 г. В Узгенде//Эпиграфика Востока. Т. I. — М. — Л.: Изд-во АН СССР, 1947. — С. 27—32; Бернштам. Уйгурская эпиграфика Семиречья//Эпиграфика Востока. Т. I. — С. 33—37; Дьяконов М. М. Несколько надписей на кайраках из Киргизии//Эпиграфика Востока. Т. II. — М. — Л.: Изд-во АН СССР, 1948. — Б. 9—15; Беленицкий А. М. Из мусульманской эпиграфики в Таласской долине//Эпиграфика Востока. Т. II. — С. 16—18.

бар[1]. Хәлбуки, каганатны төзүчеләр арасында тугыз татар, утыз татар, угыз, төрек һ. б. кабиләләр бар[2]. Амур буендагы халыкларда да язулы кабер ташлары кую, үзенчәлекле мавзолейлар кору гадәте Төрек каганатының тәэсире белән килеп чыккан булса кирәк. Безнең игътибарны XIX гасыр этнографы Р. Маак тарафыннан Амур буе халыкларының кабер өсте корылмалары ясалган сурәтләре җәлеп итте[3]. Тырское борыныңдагы XV гасыр кабер ташы, андагы кытайча язуны исәпкә алмаганда, Татарстандагы XIX—XX гасыр татар кабер ташлары кыяфәтенә охшаш[4]. Ә кабер өстенә агачтан корылган йортның орнаментлары XV—XVIII гасыр татар кабер ташларындагы бизәкләрне бик хәтерләтәләр.



*Амур елгасы буенда яшәгән халыкларның кабер өсте бурасы.*

Бу нәүбәттән татарларның борынгыдан килгән төш юрамышы да бик гыйбрәтле. Татар төшендә йорт төзегәнен, түбә япканын, идән җәйгәнен, бура бураганын, морҗа чыгарганын, яки булмаса бура эчендә калганын, йорт эченә кереп киткәнен күрсә — үлемгә юрый. Димәк, утраклык хаҗәтләре белән бәйле эшләр күчеп йөргән вакытларда, татарларның фәлсәфәсе буенча үлем билгесе булган. Шунысы кызыклы, казакъ, кыргызларның да зиратларында төрле төсле (аеруча зәңгәр) белән буялган дөрбәләр күплеге күзгә ташлана. Димәк Төрек каганатының мәдәни традицияләре Караханилар цивилизациясе аша аларда да саклана. Каралтыларны төрле ачык төсләргә буяу гадәте татар халкында бүгенгәчә яши әле: агач йортларны, капка-коймаларны, агач мәчетләрне татарлар ачык зәңгәр, яшел, сары төсләргә буярга яраталар. Шулай ук бүгенге заманда борынгы дөрбәләр урынына калган агач яки тимер чардуганнарны да матур ачык зәңгәр, яшел, ак, кара, көмеш сыман төсләргә буяп киләләр.

Кабер ташларының, дөрбәләрнең күренешләре, алардагы язулар, бизәкләр гасырлар дәвамында яңарып торалар. Татар халкы үз бәйсезлеген югалткач, аның хәләл байлыклары ятлар «кесәсенә» агыла. Шунлыктан кабер өсте корылмалары да үзләренең барлыклары, кыяфәтләре белән заманның байлыгын яки

---

[1] Малов С. Е. Памятники древне-тюркской письменности Монголии и Киргизии.— М. Л.: Изд-во АН СССР, 1959. С. 106; Васильев Д. Д. Корпус тюркских руханических памятников бассейна Енисея.— Л.: «Наука», 1983.— С. 125.

[2] Айдаров Г. Язык Орхонских памятников древнетюркской письменности VIII века.— Алма-Ата, 1971.— С. 109, 110, 113.

[3] По следам древних культур. От Волги до Тихого океана.— М., 1954.— С. 240.

[4] Шунда ук.— Б. 233.

ярлылыгын, гыйлемнең югарылыгын яки наданлыкны, югары рухны яки төшенкелекне күрсәтәләр. Монда һәр татар өлкәсенең үзенчәлекләре, традицияләрнең яшәве яки үлә бару процесслары чагыла.

Дөрбәләр белән дә шул ук хәл. Мәсәлән, Болгардагы «Кара пулат», яки Бакчасарайдагы «Нәнкәҗан» дөрбәләре кебек корылмалар Русия империясе составына кергәч, инде төзелә алмыйлар. Хәтта ки, Шаһ Гали (1555 ел) һәм Әфганнарның да дөрбәләре күләм ягыннан кечерәкләр һәм архитектура җәһәтеннән милли үзенчәлекләрен югалтканнар.

Татарның мөстәкыйль дәүләтләре дәверләрендә күпләп төзелгән, Көнчыгыш Аурупа өлкәләрендәге дөрбәләрнең асылда тик нигезләре генә сакланган. Аларның эзләре бүгенге Татарстандагы, аеруча Ык буендагы татар зиратларында һәм Биләр, Болгар шәһәрләре булган урыннарда күренәләр.

XVIII—XIX гасырларда татар авылларында яндырылган кирпечтән һәм сирәк кенә ак таштан эшләнгән һәм архитектура ягыннан бик гадиләшкән дөрбә үрнәкләре сакланалар. Мәсәлән, Татарстанның Әтнә төбәгендәге Бәрәскә авылында 1785 елда кызыл кирпечтән корылган Шәех Ибраһим бине Йосыф Бәрәскәвинең калын диварлы, ишек, тәрәзәләренә челтәрле чуен рәшәткәләр куелган дөрбәсе (аның биеклеге заманында ике метр чамасы булып, хәзер ишелеп килә) бүгенге көндә сакланып калган мондый корылмаларның иң зурысы.



*Татарстанның Әтнә төбәге Югары Бәрәскә авылы зиратындагы кызыл кирпечтән эшләнгән дөрбә. Р. Фәхретдинов фотосы (1996).*

Ул зиратта шулай ук тагын бер кирпечтән эшләнгән дөрбә саклана. Ак таштан эшләнгән дөрбә нигезе Өлә Казакълары авылы зиратында да бар. Арча төбәгенең Яңа Тазлар (Байкал) авылында XIX гасыр урталарыннан калган дөрбә күренә. Дөрбәләр Әгерҗе төбәге Тирсә авылында күп булалар, ләкин аларны җирле администрация 1957 елда җимерттереп, өстенә авыл хуҗалыгы техникасы саклый торган лапас эшлиләр. Әгерҗе төбәгенең Нәҗәр авылында кызыл кирпечтән XIX гасыр урталарында эшләнгән бер ишан дөрбәсе бар. Чистай шәһәренең татар зиратында кирпечтән эшләнгән (XIX йөз) зур гына түбәсез дөрбә саклана һ. б.

Татарларда дөрбәләр эшләү сәнгатенең юкка чыгуына Русия хөкүмәтенең аларга таш һәм кирпеч корылмалар салуны тыю турындагы законы тәэсир иткән, дип уйларга нигез бар. Шунлыктан кабер өсләрендәге дөрбәләр үтәгән хаҗәтне, агач материалыннан эшләнгән чардуганнар алган. Агач материалы Урта Идел зонасында күп булып, һәркем аны таба алган. Агачтан эшләнгән чардуганнар «бура» дип аталганнар. Гадәттә кабер өстенә корылган бураларның бүрәнәләре чама белән 10—12 см юанлыкта була иде. Бураның биеклеге дә

төрлечә — 100—125 см чамасында. Озынлыгы — 2—2,1 метр, киңлеге — 1—1,1 метр чамасында эшләнә. Буралар Татарстанның һәр районындагы зиратларда да очрыйлар иде. Бүгенге көндә сакланып калган буралар, мөгаен, калмагандыр да инде. Соңрак, баганалар утыртып, такталар сугып ясалган чардуганнар бураларны кысып чыгардылар. Безнең гасырның икенче яртысында яңа куелган кабер бурасы булуы шикле. 1950 еллардан соң чардуганнар баганаларга агач рәшәткәләр сугып та ясала башлады. 1970 еллардан соң агач чардуганнар урынына күбрәк металл чардуганнар куелалар. Аларны тимер трубалардан, калын тимер арматуралардан эшлиләр. Төрле орнамент мотивлары белән бизәклиләр. Чардуганнарны чуен яки башка коелма металлдан матур калыпларга коеп та эшлиләр. Бу өлкәдә халыкның фантазиясе шактый бай күренә.

Кабер эчендә, кыйбла як стенада «ләхет» дип аталган куышлык ясала. Ләхетнең биеклеге 50—60 см, шулай ук стенага кереше дә бер 50 см чамасы тирәнлектә була. Борынгы заманнарда ләхетнең стеналарын кирпечләр белән тышлап ныгытканнар; Әгерҗе ягындагы Тирсә зиратында җимерелгән XVII—XVIII гасыр каберләрен күрүчеләр, ләхетнең кирпечләр белән ябылуы хакында сөйләделәр.

Комлы урыннарда кабер казырга туры килгәндә, ләхет алу мөмкин булмаганда, кабернең идән җирендә 30—35 см тирәнлектә канау казып, мәетне шул чокырга йөзен беркадәр кыйблага каратып күмәләр. Канау-ләхет өстенә калын такталар тезәләр.

Алтын Урда дәвереннән калган каберләрдә мәетләрне, юан имән бүрәнәләрне урталай ярып, эчләрен каезлап, шунда салып, яркаларны каплап, аларны кузгалмаслык итеп беркетеп кабергә куеп күмү очраклары бар. Казан ханнарының бизәкле табутларга салынып күмелгән булулары да мәгълүм булды.

* * *

XIII гасырлардан бирле куела килгән кабер ташларының кем тарафыннан ясалып, язылып куюы күп очракта мәгълүм түгел, осталар үзләрен бик тыйнак тотканнар. Хәлбуки, борынгы ташларның ясаучы осталары оста каллиграфлар һәм рәссамнар да булганнар. Бу хәл озак елар буе шулай дәвам иткән.

Фәкать XVII гасырда гына кайбер ташларның осталары эшләренә имзаларын куя башлыйлар. Мәсәлән, Әгерҗе төбәге Салагыш авылында «Әүлия ташы» дип йөртелгән ташны» 1069 һиҗри, 1659 руми елда Тиләш углы Дусмәт исемле оста эшләгән. Минзәлә төбәге Бикбау авылында да бер «Әүлия ташы» бар икән. Аны 1067 ел һиҗри, 1657 ел миладида Дәвиш хафиз исемле кеше язган булып чыкты. Шул ук Бикбау авылында һиҗри 1100, милади 1689 елда куелган ташны Аккуҗад исемле оста язып калдырган. Лаеш, Алабуга, Кукмара якларындагы XVII гасыр ахырында эшләнгән дистәләрчә ташлар Килмөхәммәд бине Ишман оста тарафыннан эшләнгәннәр. Инде килеп, XVIII гасырдагы ташларны карасак, аларны эшләгән бер генә остаың да исемен әйтә алмыйбыз. Фәкать XIX гасырның икенче яртысында гына кайбер исемнәр-имзалар ташларда күренә башлый. Мәсәлән, Әгерҗе төбәге Тирсә авылы зиратында Мортлы Мөхәммәдзакир язып куйган таш бар, Әтнә төбәге Олы Мәңгәр зиратында Фәтхелкадыйр әл-Казани (1912), Кальметов Казани (1913) кебек осталарның эшләре мәгълүм.

XIX гасыр ахыры XX гасыр башында эпиграфик һәйкәлләрнең төрле калыпларда эшләнүләре күзгә ташлана, ләкин ниндидер бер уртак типка якын килү, эзләнү процессы да сизелә, һәр районда, хәтта кайбер авылларда да XIX гасыр кабер ташларының үзенчәлекле типлары булган. Мәсәлән, Казан артындагы Мөндеш, Олы Мәңгәр, Түбән Оры, Кенәр авылларының зиратларындагы XIX гасыр ташлары тышкы күренешләре белән бер-берсеннән шактый аерылып торалар.

Шулай да күп эшләре сакланып калган, эпиграфик истәлекләр ясау белән шөгыльләнгән ике останың эшчәнлеге аеруча күрсәтеп үтәсе килә.

Аларның беренчесе — Бәрәңге авылында яшәгән (хәзерге Мари-Эл республикасының) Әхмәт бине Хафизетдин (1877—1931) исемле мәгърифәтче. Ул кеше Бәрәңге авылының шактый зур күләмле бай тарихын язган, мәдрәсәләр өчен дәреслекләр төзеп бастырган. Аның хезмәтендә Шиһабетдин Мәрҗанинының беркайда да басылмаган хатлары сакланган. Әхмәт бине Хафизетдин башта махсус таш карьерыннан йомшак хәлдә ташны кисеп алган, аннары аңа трафарет белән тиешле бизәкләр төшереп язып куйган, шулар нигезендә эпитафияне уеп текст язган. Аның ташы «Бәрәңге ташы» дип атала. Ул оста эшләгән эпиграфик язмалар Татарстанның Арча һәм Әтнә төбәкләрендәге зиратларында сакланалар.

Икенче оста Буа шәһәреннән Гарифҗан Вәлиди-Буави (Вәлитов) исемле мөгаллим иде. Гарифҗан Вәлиди-Буави (1879—1946) Ырынбур, Волгоград, Әстерхан якларында укыткан. Волгоград өлкәсенә караган татар авылларының тарихы турында аның «Шура» журналы битләрендә зур мәкаләсе дә басылган. Шулай ук Октябрьгә кадәрге татар матбугатында да аның мәкаләләре күренә. Гарифҗан Буави 1910 еллардан башлап үзенә генә хас стильдә эпиграфик истәлекләр эшләп яза башлый. Аларның күбесе күләм ягыннан зур түгел. Уртача 15 × 15 × 50 см зурлыктагы шакмаклы колонналардан торалар. Колоннаның дүрт ягына каллиграфик язулы тарих вакыйгалары һәм шигырь язылган. Безнең тарафтан Гарифҗан Буавиның Буа шәһәре һәм аның тирәсендәге татар авылларындагы Бикмурас, Түбән Наратбаш һ. б. зиратларда илледән артык эше сакланганлыгы ачыкланды. Ул еш кына үзенең ташларына «Гарифҗан Буави» дигән имзасын ташның бер читенә язып куя торган булган. Бу кеше озак еллар буе Буа шәһәрендәге татар мәктәбендә хезмәт дәресләре биреп гомер иткән. Үзенең дә кабере Буа шәһәре татар зиратында саклана.

Урта Иделдә җиде йөз ел буе татар эпиграфикасы культурасы үсеп эволюция кичерә. Аның үсешендә кызыклы этаплар бар. Бу этапларда татарның мәдәни күтәрелүе дә, төшүе дә чагыла.

**Беренче этап:** 1280—1360 еллар — бу дәвердә татар эпиграфик истәлекләрнең тел һәм архитектура-декоратив формалары үзенчәлекләре барлыкка килә.

**Икенче этап:** 1490—1550 еллар — бу дәвердә татар эпиграфикасы тагын да үсеп китеп, бердәм тел һәм бизәлеш архитектурасы калыплашып житә яза.

**Өченче этап:** 1680—1700 еллар арасы — бу этап Казан ханлыгы чоры эпиграфик типларын кабатлауга омтылу, ләкин бизәлеш һәм күләм ягыннан начарлану чорын тәшкил итә.

**Дүртенче этап:** 1870—1930 еллар — татар эпиграфикасының бай төрләре, бизәкләре барлыкка килеп чәчәк ату чоры.

**Бишенче этап:** 1960 еллардан башлана һәм бүгенгәчә дәвам итә. Соңгы этапны да татарның эпиграфик сәнгате үсешендә эзләнү чоры дип карарга кирәктер. Бу дәвернең төп үзенчәлеге — милли эпиграфикабызның көннән-көн үз йөзен югалта баруда күренә. Әлбәттә, бу үзгәреш һәйкәлләрнең тышкы күренешендә, алардагы язмаларның, телнең бозылуында да чагылыш таба. Еш кына аларда мөселман атрибутлары — иман калимәләре, догалар, ай-йолдыз эмблемалары төшеп кала. Исем-фамилияләр язылышындагы шапшаклыкның чиге юк. Мондый күренеш Казан һәм Татарстандагы татар зиратларында шактый нык тамыр җәйде. Татарстаннан читтәге татар зиратларындагы эпитафия язмаларында деградация тагын да күңелсезрәк төс алган. Бер нәрсә бары күңелне юата: татарлар үзләренең милли зиратлары булуны яклыйлар, аларда милли төсне шактый югалткан хәлдә дә, эпиграфик ядкярләр куялар.

Совет властеның баштагы елларында зиратларга кырын карау да шактый үзен сиздерде. Зиратлардагы борынгы мөселман ташларын 1930 елларда җыйнап колхоз фермалары нигезенә салдыру (Олы Мәңгәр), борынгы зират өсләренә бакча утыртулар (Олы Әтнә), борынгы зиратларны бетереп аның өстенә административ биналар салулар (Сарман, Теләнче Тамак, Бәрәңге, Тирсә һ. б.), яки аларны бөтенләй сукалап, сөреп ташлап иген басуына кушулар (Иске Кишет), яки Казанда Киров районындагы татар зираты ташларын 1956 елларда су астында каласы дип (тик калмаган) махсус ваттырулар, Казанның Әҗем мәчете районындагы татар зиратын бетереп, өстенә шәһәрнең бишенче больницасын салып куюлар коммунистик, социалистик лозунглар чакыруы, боеруы буенча эшләнде. Мондый вәхшилекләр Татарстанда гына түгел, Кырымдагы, Ташкенттагы, Җаектагы (Уральск) һ. б. җирләрдәге татар зиратларына карата да эшләнделәр һәм хәзер дә эшләнеп торалар. Миңа Ташкент шәһәрендә күренекле татар зыялылары Әбүбәкер Диваев, Нәүширван Яушев, Габделгазиз Монасыйпов, Ибраһим Түләкиләр күмелгән зиратны эзләргә туры килде, тик аның өстенә күп катлы зур йортлар салып бетергәннәр иде инде. Җаек шәһәрендә Г. Тукайның остазы Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин һ. б.лар күмелгән зиратны бөтенләй бетерү хәленә җиткергәннәр, дип сөйлиләр. Моны фәкать Ахыргы заман алдыннан җирне кызыл балчыгына тикле ашап килүче Әэҗүҗ-Мәэҗүҗ кавеме чыгышы белән генә тиңләштерергә мөмкин. Татарның дошманнары аның тарихи эзен кызыл балчыкка кадәр калдырмый кырып бетерергә тырышалар. Халкыбыз бу эшләрнең ни белән бетәсен, соңгы 80 елда аның башына кертелгән әфьюннан айнымыйча аңлый алмас инде, ахры.

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

**Равил Әмирхан**

# КАЗАНЛЫ ӘМИРХАННАР

## Хөкемдар һәм дипломат

Инде сүзебезне Казанлы Әмирханнардан иң фаҗигале язмышлы Ибраһим турында башлап җибәрербез...[1]

Тарихыбызның 70 еллык тоталитар дәвере сәхифәләрен актарганда әле һаман да бәгырең куырылып, тетрәнеп куясың: нихәтле иҗтиһад, якты омтылыш, игелекле гамәл үсентеләре тамырында көе корытылган, никадәр саф күңелле, эчкерсез, намуслы җаннар җинаятьчеләр өере тарафыннан хаксызга корбан ителгән икән бит! Милли тормышыбыз, үткәнебез кысаларында күзаллаcак, әлеге чор тагын да шомлырак, чирканычрак булып гәүдәләнә. Тагын кайсы кавемнең затлы, зыялы вәкилләре өстенә берьюлы котсыз-иләмсез гаепләрнең бөтен бер көлтәсе ыргытылды икән? «Милләтче», «солтангалиевче», «сәгыйдуллинчы», «троцкийчы», «җидегәнче», «фәлән илнең шпионы», «халык дошманы»... Болары да буш җирлектә шытып чыкмаган — тамырлары шул ук дөмбәсләү максатында «иҗат ителгән» «басурман», «панисламист», «пантюркист», «пантуранист» һәм тагын әллә нинди шуңа охшаш тәгъбирләргә барып тоташа.

20—30 нчы, аннары 40—50 нче елларда Советлар иле дигән мәмләкәттә бихисап шәхесләребезнең тәрҗемәи хәлләре һәм гамәлләре әнә шул, заманында башкитмәле, төшенчәләр белән бәйле. Хәятен тәмуг дәһшәте өткән шундый затларыбыз арасында классик әдибебезнең бертуган энесе, Г. Тукайның дусты, татарның Совет чорындагы тәүге дипломатларыннан берсе, югары дәрәҗәле юрист, җөмһүриятнең хокукый нигезләрен ныгыту эшенә лаеклы өлеш керткән күренекле дәүләт эшлеклесе Ибраһим Әмирхан да бар (1889—1938). Кылган гамәлләренә генә түгел, исеменә дә ярты гасыр дәвамында богау салынган иде аның. Тәрҗемәи хәле дә, татар халкының, республиканың иҗтимагый-сәяси, мәдәни тормышында уйнаган роле дә әле өйрәнелмәгән диярлек. Бу бигрәк тә Ибраһимның дипломатик яссылыктагы эшчәнлегенә хас. Әмма булган кадәр мәгълүматлар да кече Әмирханның зур, максатчан натура, кабатланмас биографияле шәхес булуы турында сөйли...

Мөхәммәдзарифның төпчек улы 1889 елның 5 сентябрендә дөньяга килә. Абыйсыннан дүрт яшькә якын кечерәк булса да, аларның балалык һәм үсмер еллары бер-берсеннән аерылгысыз рәвештә диярлек үтә. Үз карамагында беркадәр вакыт укытканнан соң, Зариф мулла кече улын да заманының иң атаклы мәдрәсәләреннән саналган «Мөхәммәдия»гә бирә. Ибраһим шунда абыйсы Фатыйх белән бергәләп белем ала.

Ике бертуганның ни рәвешле мәдрәсәгә килеп йөрүләре, киенүләре, ашауэчүләре хакында «мөхәммәдия»че Миргазиз Укмасыйның 1940 елда язылган хатирәләре кызыклы. 1897 ел турында сүз алып барып, ул, мәсәлән, болай ди: «Иртә белән Фатыйх һәм Ибраһим Әмирханнарны бик матур кара ат белән өстенә калын толып кигән кучер мәктәпкә китереп куя торган иде. Аларның

---

[1] Бу турыдагы язманың кыскача варианты журналның 1996 елгы 1 санында басылган иде. Ләкин «Казанлы Әмирханнар»ның бөтенлеген саклау максатыннан һәм әүвәлге материалның байтак урыннары кыскарган булуын искә алып, биредә тулы текстны бирү тиеш табылды.— *Редакция.*

Ахыры. Башы 10, 11 саннарда.

кулларында сумкалар, өс-башлары шәһәрчә матур киенгән. Без, бала булу сыйфаты белән, Казан мулласының балалары, дип, аларга сокланып карап тора идек. Алар төшке аш вакытында ләвәшләр, сумсалар ашыйлар, без авылдан килеп, озак вакыт уку сәбәпле, күгәрә төшкән икмәк ашыйбыз, җылы аш күп вакытта юк. Болар җимертеп кич белән тагын кучер белән өйгә кайтып китәләр, җылы, тәмле аш, йомшак урында йоклыйлар, теләгән вакытларында мунча, ашарга теләсәләр, кәләвә, төсле кәгазь, карандаш — барысы да болар кулында иректә дип, мин үзем шәхси боларга кызыга идем. Икесенең дә төс-бит бик матур, килештереп тегелгән киемнәр, җитмәсә, алар төрле модага алмашынып торалар. Син бер камзолга яки бер чалбарга мохтаҗ, алар аны төрле фасонга алмаштырганга, безнең күк ярлы авыл шәкертенә бу кадәр зур алдынгылык бәхет күк тоела иде. Һәм утырачак та күк тоелмый торган матур, утыра торган урыны киң, асты тар, бик юка табанлы матур чана белән, кара атның өстендә «көмешләр» тезгән шләя, җинел камыт, нечкә тубылгы дуга, тар каештан эшләнгән «көмешләр» тезелгән җүгән, аның тезгенен икегә аерып, дуганың ике ягына тарттырып куелган тасма дилбегә. [Кучер] шул ат белән мәдрәсә алдына тукталган да, Әмирхановларны көтә. Алар, дәресләрен бетерүгә, ашыкмый гына икәүләп урамга чыгалар, без, авыз суыбызны корытып, аларны карап торабыз. Ямщик алар утыра торган яктан чана алдына япкан тирене ачып, аларны утырта һәм алларына тагын теге тире юрганны ябып, тасма дилбегә белән атка чиртә дә, алар шул вакыт күздән юк булалар... Менә мин, аякта агач башмак, авылдан яңа килгән малай, боларга карап сокланам, әле үзем Казанның рәтен белмим... Әмирханнарның зурлыгына, Казан йортларының зурлыгына, мәчетләрнең зурлыгына, анда җәелгән яшел сукноларга, «зур» кешеләргә исем китә».[1]

Үсә төшкәч, бу ике туган мәдрәсәдә торып укый башлый. Абыйсы төсле үк, Ибраһим да зирәк, укуга һәвәс, тере һәм аралашучан шәкертләрдән була. Әйтик, аның «мөхәммәдия»челәрнең яшерен өй спектакльләрендә 1903 елдан ук якыннан катнашуы, ул гына да түгел, аларны оештыруда, сәхнә өчен кирәк-яраклар табышудагы елгырлыгы мәгълүм. «Артистлыгы» да хәйран була моның. Мәсәлән, үндүрт яшьлек Ибраһим үзенең шәрикләренә Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасын күрсәтүчеләр арасында була. Ул анда тегенди-мондый гына түгел, ә төп каһарман, ягъни Закир ролен башкара.



*Ибраһим Әмирханның Бәйрут көллиясендә укыган чоры. 1911 ел.*

Күп нәрсәдә абыйсына ияреpгә күнеккән, аның фикере белән нык хисаплашкан Ибраһим, заман таләбенә муафикъ рәвештә урыс телен бик тырышып өйрәнә. Инде әйтелгәнчә, 1904 елның җәендә ул Фатыйх белән берлектә берничә ай буена Самарада ниндидер курсларда укып кайта. Шул ук елның көзендә Ибраһим, инде Казанда, абыйсыннан күрмәкче, китап-дәфтәр күтәреп, яңадан учительгә йөри башлый.[2] Мөгаен, бу кеше — Фатыйхка да урысчадан һәм башка сәяси-иҗтимагый «фәннәр»дән дәрес биргән С. Н. Гассар булгандыр.

Абыйсының ялкынлы тарафдары булган Ибраһим, әлбәттә, «Мөхәммәдия»дәге яшерен түгәрәкләрдә, әдәби-музыкаль кичәләрдә, биредә чыгарылган сатирик кулъязма, җилем басма гәзитләрдә дә катнаша. Ул гайре рәсми «Иттихад» оешмасының да, аның мәгънәви варисы мәшһүр «Әл-Ислах» комитетының да эшлекле әгъзаларыннан санала, 1904 елда, бигрәк тә 1905—1906 елларда

---

[1] ТӘСИ (ИЯЛИ) Фәнни архивы, 16-ф., 2-тасв., 46-эш, 1—2 б.
[2] Нуруллин Ибраһим. Фатих Әмирхан, 49 б.

аеруча зур куәт алган шәкертләр хәрәкәте «казаны»нда кайный, «Әл-Ислах» үзәк комитеты башлыкларының берсе буларак, милли тормыштагы искелеккә, торгынлыкка каршы көрәш, яңага, европача белемгә йөз белән борылу идеясен алга сөрә.

1905 ел революциясе либеральрәк фасылда калыпланган укучы яшьләр хәрәкәтенә яңа рух өрә, «Мөхәммәдия» шәкертләре шул мәдрәсә җирлегендә оешкан «Әл-Ислах» комитеты торган саен суллаша, өлешчә эсерлар, башлыча социал-демократлар йогынтысына бирелә. 1905 елның октябрь күтәрелеше көннәрендә Казанда «халык милициясе» оеша. Гомуми саны берничә йөзгә җиткән милиционерлар арасында шәкертләр дә байтак хисаплана. «Әл-Ислах» комитеты әгъзасы, бик хәрәкәтчән һәм өлгер Ибраһим да күңелле (ирекле, доброволец) сыйфатында шушы милициягә языла. 19—21 октябрьдә, ягъни Казанда революционерларның «Шәһәр коммунасы» хакимлек иткән кыска бер чорында кулларына кызыл тасмалар бәйләп, «инкыйлаби тәртип» саклаучылар, полицияне коралсызландыручылар арасында безнең Ибраһим да активлык күрсәтә. 21 октябрьдә халык күтәрелеше бастырылгач, башка милиционерлар белән берлектә, Ибраһим Әмирхан да кулга алына. Уналты яшьлек үсмерне зинданга эләгүдән Казанның абруйлы мулласы — Зариф хәзрәтнең катышуы гына коткарып кала. Полиция аның өстеннән яшерен күзәтү оештыра.[1]

Инкыйлаб хәрәкәтендә, укучы яшьләр кузгалышында турыдан-туры катнашкан Ибраһим, абыйсы Фатыйхның ярдәмчесе буларак, Казанда үткәрелгән яшерен бөтенрусия шәкертләр съездларын (1906—1907) оештыручыларның, аларны мәгънәви яктан җитәкләүчеләрнең берсе була. «Әл-Ислах» комитетының башта шул исемдәге җилем басмасы, аннары рәсми гәзите тирәсенә заманының алдынгы карашлы зыялы яшьләре — Ф. Әмирхан, Г. Тукай, С. Рәмиев, К. Бәкер, В. Бәхтияров һәм башкалар туплана. Ибраһим Әмирхан, шәкертләр хәрәкәтен җитәкләүчеләрдән буларак, бу даирәнең үз кешесе санала. Әлеге фактны мәгълүм дәрәҗәдә 1908 елның маенда алынган бер күмәк фото да раслый: бирелә Г. Тукай, Ф. Әмирхан, В. Бәхтияров, К. Бәкер белән бергә, бөек шагыйребез белән янәшә терәлеп диярлек утырган Ибраһим да сурәтләнгән. Бу уңайдан шуны искәртү дә урынлы булыр. 30 нчы еллар азагыннан башлап «халыклар атасы» фатихасы белән корбан ителгән шәхесләрнең сурәтләре әүвәлге фотолардан «юылу» гадәте канат җәйде. Шушы принципка нисбәтән, без әле генә сүз алып барган күмәк сурәт тә котсыз рәвештә имгәтелеп, анда гайре табигый халәттә (бушлыкны тутыру уңышсыз) өч шәхес кенә «тырпаеп» калган иде: Ф. Әмирхан, Г. Тукай һәм В. Бәхтияров. Әйтерсең, тарихта атаклы журналист, публицист, җәмәгать эшлеклесе Кәбир Бәкер дә, татарның тәүге дипломатларыннан берсе, дәүләт эшлеклесе Ибраһим Әмирхан да булмаган...

«Столыпин реакциясе еллары» дигән атама алган чорда Ибраһимның хәле шактый тотрыксызлана, төшенкелеккә бирелгән, сүлпән-битараф чаклары еш була. Алдынгы зыялылар тирәсендә кайнаган кеше, тәпле генә белемгә ия булса да, ул үз-үзен тиз генә таба алмый, каләм эше дә аны бу чорда артык мавыктырмый. Хәер, соңрак ул кайбер гәзит-журналларда язышкан булырга охшый. Һәрхәлдә, без аның татар телендәге беренче хатын-кызлар журналы «Сөембикә»дә «Кызларга бигрәк тә тиеш» дигән мәкаләсенә тап булдык.[2] Ибраһим «Әл-Ислах» даирәсенә тартым кайбер яшьләр белән кәеф-сафа корулардан да тайчынмый, «режим»ны да ярыйсы гына бозгалап куя. Бу хәлләр күбрәк аның аттестатка имтиханнар тапшырып, университетка укырга керү хыялы җимерелә баруы белән бәйләнгән булса кирәк. Тәпле европача белем алу өчен байтак кына акча кирәк, ә улларын хак мөселман рухында тәрбияләргә тырышкан, алардан дин-диянәт, шәригать «тоткасы» ясауга өметләнгән ата-ана дөньяви, урыс калыбындагы «иләс-миләслек»кә юл куярга ашкынып тормый, димәк, алардан матди ярдәм көтү урынсыз. Яшь мәхдүм, ягъни хәзрәт малае, рухи кризис кичерә.

Нәкъ шул чорда Ибраһимга бәхет дигән нәрсә саран гына булса да елмайгандай итә. Бу вакытларда мөселман-татар дөньясының эре кәсәбәчеләре сәүдәмилек эшләрен кискен конкуренция шартларында алып барырдай милли кадрларга мохтаҗлык кичерә. Шундый атаклы затларның берсе, Оренбургның мәшһүр миллионеры Әхмәд бай Хөсәенов, аеруча зиһенле шәкертләрне үз хисабына Төркиянең Бәйрүт шәһәрендәге махсус американ көллиясенә (колледжына) укырга җибәрә торган була. 1908 елда бу коммерция уку йорты Ибраһимга да тәкъдим ителә. Яшь мәхдүм бер мәлгә икеләнеп кала, чөнки алыш-борешкә,

[1] Коммунист Татарии, 1989, № 12, с. 68.
[2] Сөембикә, 1913, № 1, 27 октябрь.


сәүдәгә бәйләнгән эшчәнлеккә тулысынча битараф ул. Әмма ул йортының тулаем дөньяви, исеменең дә бик яңгыравыклы булуын игътибарга алып, кичәге «ислахчы» ахыр чиктә ризалыгын белдерә. Дөньяви көллия икән, форсаттан файдаланып калырга кирәк. Һәм егет янадан шәкерт булып китә.

Көллиягә эләккәннән соң, Ибраһим зур дәрт, тырышлык белән инглиз, гарәп, төрек телләрен үзләштерә, дөньяви һәм махсус фәннәрдән киң мәгълүмат ала.

Унтугыз яшьлек егетнең туганнан туган сеңелләре Фатыйма белән Өммегөлсемгә 1908 елның 30 октябрендә Бәйрүттән язган почта открыткасы сакланган. Гаед бәйрәме белән котлаган бу язма шактый гыйбрәтле. Бердән, ул чит илдән урысча адрес белән тоткарлыксыз килгән. Икенчедән, анда «прошу передать в день праздника» дигән искәрмә бар. Димәк, ул чорларда андый үтенечләр дә жиренә житкерелеп торган. Өченчедән, открытка бүгенге «ташбака йөреше» белән чагыштырганда бик тиз килеп житкән. Төп текст мондый:

«Сөекле сеңелләрем Фатыйма, Өммегөлсем! Гаед шәриф мөбарәк булсын. Жизни, Мәрьям апага сәламнәрне почта күтәрә алган кадәр жибәрдем. Бер хат йибәргән идем, алгансыздыр. Хат язсаңыз, шат улырмын. Сагъ улыңыз. Ибраһим»[1].

Ара-тирә мәхдүм туган якларына, Казанга да кайтып китә. Бер кайтуының шаһиты шул, ул Мәрьямбану апасына һәм Өммегөлсемгә, артына үз кулы белән язып, 1911 елның 22 вә 23 августында ике сурәтен бүләк иткән. «Мөхтәрәмә Мәрьям апага ядкяр өчен» бирелгән фотодан затлы озын чапан кигән, башына ак чалма ураган рухани чалымлы егет карап тора. «Сөекле сеңлем Өммегөлсемгә онытмасын өчен вирелмештер» дигән сурәт икенчерәк фасонда. Бирелә традицион шәрекъ жиләненә аркылы-торкылы һәм бил тирәли патрон тасмалары таккан, өстенә кара чапан бөркәнгән, түбәсенә чүл гарәбенекедәй асылынма баш киеме кигән, кулына ау мылтыгы тоткан ялан тәпиле яугир күзен текәгән.




*Ибраһим Әмирханның Җиддә каласыннан сеңлесе Фатыймага язган хаты. 27 февраль, 1927 ел.*

Ниһаять, 1913 елда көллияне уңышлы тәмам итә ул. Хәзерлекле егетне белемен тагын да арттыру өчен Америкага жибәрергә карар кылалар. Бу планны тормышка ашыру максатында ул Казанга кайта һәм яңа ерак сәфәргә жыена башлый. Гонаһ шомлыгына каршы, 1914 елның жәендә Бөтендөнья сугышы кабынып китә. Корылган ниятләр чәлпәрәмә килә. Ибраһим инде Казанда калырга мәжбүр. Хәзер аның төп шөгыле шул — татар мәдрәсәләрендә мөгал-

[1] Шәхси архив.

лимлек кыла. Зур гына белемгә ия булган мәхдүм яңа эшкә бөтен көчен бирә, шәкертләр укытуда иҗади алымнар куллана, тиз арада шөһрәт казана. Шушы чордан башлап ул тутырган анкеталарның «һөнәре» («профессия») дигән графасы турысында даими рәвештә «халык укытучысы» («народный учитель») гыйбарәсе кереп урнаша.

Ибраһимга инде егерме биш яшь. Апасы күптән вафат. Фатыйх инвалид, димәк, абыйсының гаилә коруы инде бик икеле. Ә төпчеккә башлы-күзле булу өчен берәр киртә бармы соң? Каян килсен ди, сау-таза егет ич ул. Менә кәләш эзләү мәшәкате башлана. Булгач-булгач, гөл төсле матур булсын инде ул яшь бикәч, үткән-сүткән артына каерылып карарлык булсын, «ну бу Ибраһим чын җегет икән, асыл кошны аягыннан эләктергән», дисеннәр. Кияү буласы кеше әнисе остазбикә алдына мондыйрак таләп куя:

— Әни, миңа Казанның иң матур кызын димләгез!

Шуннан китә кыз сайлау. Ибраһимга кәләш, Бибирабигага килен буласы кызларны кыл иләктән дигәндәй үткәрәләр. Казанны, тирә-юньне бетереп, укалы фәрештә эзлиләр болар. Һич табар әмәл юк, егет тегеләрне рәттән яраксызга (бракка) чыгара йә булачак кодалар мач килми. Ә бәхет дигәненең шушы Яңа Бистәдә, каршы як урамда гына йомылып ята икән ләбаса. Күршеләре Рәхимҗан Дәминов кызы Нәфисә, чәчрәп торган гүзәл булмаса да, күркәм йөзле, сылу гына туташ, ничек моңарчы күзгә чалынмаган соң?!.

Яшьләр бер-берсенә ошый. Ата-ана да риза. Никах, туй, кодалашу кебек йолалар үз тәртибе белән гамәлгә ашырыла. Кыскасы, җиһанга яңа Әмирханнар гаиләсе аяк баса. Зариф хәзрәтнең өе хәзер бәләкәйләнебрәк китү сәбәпле (остазбикә кыз балалар да укыта) бер катлы йортка уртачарак бүлмә зурлыгында гына икенче кат үстерелә. Кияү белән яшь бикәч шунда яши башлый. Матур гына гомер кичергән яңа гаиләнең тормышы, кызганычка каршы, камил булып бетми: бер-бер артлы туган балалары Мөхәммәд тә, Әхмәд тә сабый чакларында ук дөнья куя.

1915 ел. Бөтендөнья сугышының иң кызган чагы. Ул, туймас аждаһа сыман, үзенә яңадан-яңа корбаннар сорый. Инде җирәбә Ибраһимга төшә: кару белмәс татар егете Никки (Николай II) белән Виллинең (кайзер Вильгельм) ерткучы аппетитлары өчен башын утка тыгарга, иксез-чиксез урыс империясенең иминлеген саклап, үзе кебек үк миңгерәүләтелгән герман солдаты белән якага-яка килергә тиеш. Юк, Ибраһимның башына тай типмәгән әле, америкам көллиясен ул эчен прусс штыгы айкап чыксын өчен тәмамламаган. Һәм егет, «туп ите» булырга кайчан да соң түгел икәнен фәһемләп, ул чордагы башка бик күп рекрутлар кебек үк, соры шинель киюдән тайчынып, бер шәһәрдән икенчесенә күчеп, каңгырып йөри, инглиз теленнән хосусый дәресләр биреп, җан асрый. Ләкин язмыштан узмыш юк, дигәндәй, аңа Николай патша мобилизациясеннән котылу насыйп булмый. 1916 елда Казанга ярым яшерен төстә кайтып керүе белән «качкын»ны кулга алалар һәм, әллә ни кырыс чаралар күрмичә, Сары Тау вилаятендәге Сердобск шәһәренә, ягъни хәрби частька озаталар.

1916 елның ахыры, 1917 елның башы. Ибраһим Әмирхан 161 нче запас пехота полкының кече унтер-әфисәре дәрәҗәсенә «күтәрелә». Ул биредә кырыс гаскәр тормышының, хәрби вәзгыятьнең, гаделсезлекнең бөтен әчесен татый. Оста хатиб (оратор), урыс һәм татар телләрен яхшы белгән унтер-әфисәр тиз арада солдатлар алдында абруй казана, хәтта аларның сугышка, хөкүмәткә каршы хәрәкәтләренең җитәкчесе булып китә. Февраль инкыйлабы булып, патшаны төшергәннән соң, солдатлар аңа зур ышаныч күрсәтә, полк комитетына сайлый. Ибраһим, урыс телен начар белүләре сәбәпле, инкыйлаби, сугышка каршы кузгалышка зәгыйфьрәк тартылган татар хәрбиләре арасында пропаганда эше алып бара. Тиздән элекке унтер татарларның Сары Тау губернасы корылтаена делегат итеп җибәрелә һәм анда Сары Тау өлкәсенең милли идарәсе әгъзасы итеп сайлана. Ибраһим бу идарә составында 1918 елның башына чаклы кала, татар хәрби фиркаләрендә сәяси тәрбия эшләре белән шөгыльләнә.

Инкыйлаби настроениеле солдат массалары арасында эшләү күп яктан аның киләчәк язмышын да билгели. 1918 елның башында Ибраһим туган шәһәренә кайта, тиздән Казанның 7 нче участогы халык хөкемдары (судьясы) итеп сайлана. Октябрь түнтәрешеннән соң иң хәтәр чор була бу. Учредительное собрание куып таратыла, илдә сәяси вәзгыять кискен үзгәрә, ул да булмый, ата улны, ана кызны белмәгән имәгеч, канлы ватандашлар сугышы җәелеп китә. Кыйблалар чуала, киләчәк калын томан пәрдәсе артыннан бөтенләй төсмерләнмәс була. Халык арасында инде шактый гына күзгә күренә башлаган Ибраһим җиде юл чатында кала. Нишләргә? Язмышны нинди мәсләк белән бәйләргә? Хәзрәт малаеның

Октябрь гайәсенә (идеяләренә), бигрәк тә аның бөтендөнья пролетариат революциясе хакындагы шигарьләренә мөкиббән китүе шикле. Ләкин кырыс чынбарлык бар бит әле, аның белән дә хисаплашмыйча булмый. Зәйнәп апа Әмирханиянең заманында колагына чалынган мәгълүматлары буенча, бу болгавыр заманда юл билгеләү мәсьәләсендә Фатыйх Әмирханның киңәше хәлиткеч көчкә ия булган, имеш.

— Энем, хәзер заман бик чуалчык, дөньяның кая таба барганын чамалау мөхальдер (мөмкин түгелдер). Болай итү мәслихәт булмасмы, син большевик агайлар фиркасенә языласың, ә мин үземнең милли тәрәккыйпәрвәрлегемә тугрылык саклыйм. Андый-мондый хәл килеп чыкса, бер-беребезгә ярдәм кулы сузу әмәлен табарбыз.

Шулай булгандырмы-юкмы, хәзер тәгаен генә әйтүе кыен, әмма 1918 елның февралендә Ибраһим рәсми төстә большевиклар партиясенә языла. Рекомендацияләрне дә әллә кайдан эзләп йөрисе юк, берсен күршесе, мәдрәсәдәше, хәзер күренекле большевик булып киткән Мәхмүд Дулат-Али бирә... Халык хөкемдары булуы белән генә чикләнмичә, Ибраһим Казан губкомы мөселман бюросында да актив эшчәнлек җәелдерә.

1918 елның җәе. Ватандашлар сугышының бөтен илне тетрәткән чоры. Казан Советка каршы корал күтәргән акчехлар кулында. Җан кыюларның яңа этабы инде бу. Ибраһим суеш мәйданына әйләнгән шәһәрне вакытында ташлап чыгалмый, яңа мобилизациягә эләкмәс өчен җизнәсе һәм апасы өендә, Апаковларда качып ята. Ләкин аның эзенә тиз төшәләр. Әүвәлге унтер-офицерне, хәзрәт малаен, инде тагын алмашынган властька хезмәт итәргә күндермәкчеләр. Бертиктән икенчесенә ташлануны һичкайчан өнәмәгән мәхдүм, билгеле ки, бу эшкә атлыгып тормый. Шул ук вакытта тегеләрнең коммунист халкы белән ничегрәк «мөгаләмә» кылуларын да бик яхшы белә. Аклар, әлбәттә, моның мулла малае, атаклы әдипнең бертуган энесе булуыннан хәбәрдар. Шунлыктан алар Яңа Бистә халкының җыенын оештыралар һәм Ибраһимны, ай-ваена куймыйча («халык теләге буенча»), бистәнең квартал комитеты «рәисе» итеп «сайлап» куялар. «Квартальный» Әмирханны «дружинниклар отряды» төзергә мәҗбүр итәләр. Ибраһим Бистәнең үзендә тәртип саклау дигән сылтау белән, отрядның читкә чыгып, төрле казалар кылуына юл куймаска, үз карамагында туплап тотарга тырыша. Һәрхәлдә дружиначылар халыкның канын коюда катнашмый, чехлар кысрыкланып куылгач та кызыл яу белән чәкәләшми, бәлки, шуның ягына чыга.

Фетнә афәтен кичергәннең соңында Ибраһим Әмирхан янадан үзенең элекке эшенә — халык хөкемдары постына кайта. Җигелеп эшләгәндер, күрәсең, өлгер һәм хәзерлекле хезмәткәрне губерна юстиция бүлеге тиздән Казан халык хөкемдарлары советы рәисе урынбасары итеп күтәрә. Абруй дигән нәрсә көннән-көн үсә, исеме дә таныла башлый Ибраһимның. 1919 елда ул инде Казан губернасының милләтләр эше буенча бүлек мөдире. Бу инде олы «карьера»га юл ачылу дигән сүз.

Ләкин ватандашлар сугышы дәвам итә әле. Инде көнчыгыштан Себернең «верховный правител»е Колчак һөҗүм итеп килә. Монда инде ике сөйләшеп торулар юк, «губодел» мөдирен «үз ирекге белән» гаскәргә озаталар. Ни дисәң дә, коммунист бит. 1920 елда И. Әмирхан Совет республикасының Запас армиясе политбүлегендә аз санлы милләтләр секциясе мөдире (заведующий секцией национальных меньшинств) вазифасын үти. «Маршлы» Казан укчы дивизиясе оешу белән Зариф хәзрәт улы дивизия политбүлеге башлыгы ярдәмчесе итеп билгеләнә һәм фронтка җибәрелә. Казан укчы дивизиясе Көньяк фронтта таратылуга (расформирование) юлыкканның соңында Ибраһим 51 нче Мәскәү дивизиясенә күчерелә. Бирелә ул башта Утлы (Огневая) бригадада инструктор-оештыручы, аннары шул дивизиянең политбүлегендә мөселман секциясе мөдире булып эшли. Аның тәрҗемәи хәленең бер сәхифәсендә Перекопта Врангельгә каршы һөҗүмдә катнашуы (1920) теркәлгән. Бу катнашуның ни рәвешле булганлыгы хакында тәфсилле мәгълүматыбыз юк, алай да Сиваш җәһәннәмен ерып чыгусыз булмагандыр, мөгаен.

Кызыл яу Кырымны «азат» иткәннән соң, мәмләкәттә ватандашлар сугышына нигездә нокта куела. Инде теттереп социализм нигезләрен генә саласы кала. Әлбәттә, бу эшне хәзерлекле белгечләрсез башкарып чыгып булмый. Шушы шартларда американ көллиясен тәмам кылган Ибраһимга да лаеклы шөгыль табыла. 1920 елда И. Әмирхан гаскәрдән чакырып алына, бер яктан, Симферополь ревкомы әгъзасы, икенче яктан, Симферопольнең дә, өязенең дә халык мәгарифе бүлеге мөдире итеп билгеләнә, шул ук вакытта партиянең Кырым өлкә комитеты мөселман бюросы әгъзасы вазифасын үти. Бу эшләрнең һәркайсы

бихисап көч, түземлек, һиммәт һәм өлгерлек сорый. Ару-йончылудан аяктан егылыр дәрәҗәгә җитсә дә, йокысызлыктан күз кабаклары шешеп, күзләре кызарып чыкса да, Ибраһимның ял турында уйларга вакыты булмый. Бер сәгатькә түгел, бер минутка да «тугарылырга» ярамый. Заманны һәм «партия дисциплинасы» шуны таләп итә. Җебеп төшәсең икән, беттең, хәрби коммунизм вакытында үгетләүләр, озак сөйләшеп торулар юк.

1920 ел. Июнь. Татарстан автономиясе төзелеп, «чуаш биялəе» хәтле генә мәйдан татар халкының дәүләте дип игълан ителә. Аны гамәлгә кую, юлга салу өчен, мәгълүм инде, тәҗрибәле кадрлар кирәк. Партия, совет, хуҗалык, мәдәният эшләрен яңа нигездә алып барырдай белгечләргә бар җирдә дә кытлык сизелә торган заман бу. Билгеле ки, Ибраһимны да онытмыйлар. РКП (б) ҮК күрсәтмәсе буенча И. Әмирхан 1921 елда хәрби хезмәттән бушатыла (демобилизацияләнә) һәм Татарстан партия өлкә комитеты карамагына җибәрелә. Өлкә комитеты, Ибраһимның тәҗрибәсен һәм риясызлыгын (бескорыстие) игътибарга алып, аны кассацион трибуналның әгъза-докладчысы сыйфатында юстиция халык комиссариатына (Наркомюст) җибәрә. Җөмһүрияттә, барлык илдәге кебек үк, яңа икътисади сәясәт (НЭП) хөкем сөрә, шуңа нисбәтән төрле шәкелдәге җинаятьчелек гөрләп чәчәк ата. Билгеле, бу җинаятьчелек сыртларын яңадан кабарткан нэпманнар «казынуы»на гына баглы булмый, хөкүмәт үзе үк чыгарган кануннарны бозуда үзе дә кимен куймый. Мулла гаиләсендә миһербанлык рухында тәрбияләнгән намуслы шәхес буларак, Ибраһим иң җаваплы, үзе өчен хәтәр мизгелләрдә дә принципиальлек күрсәтергә тырыша, гаделлек сагында торырга омтыла. Һәм шуның бәрабәренә үзенә байтак кына дошманнар әзерли.

Хәлбуки, йогынтылы шәхесләр аның эшен тагын «күреп ала». 1922 елда Ибраһим инде Югары (Верховный) трибунал рәисе ярдәмчесе, ә 1923 елдан — өлкә суды рәисе урынбасары. Заманына күрә зур постлардан хисаплана болар. Ибраһимның җөмһүрият күләмендәге «карьера»сының иң югары ноктасы, мөгаен, шулдыр. Һәм ул бу вазифаларын намусы кушканча башкарырга омтыла. Хәер, «партия дисциплинасы» дигән нәрсә аны да аяктан екмый калмагандыр. «Сәяси уяулык» күрсәтергә дә туры килгәндер хөкем әһеленә, югыйсә мулла малайларына караш сагаюлы, «особый».

Аны күреп белгән кешеләрнең хәтерендә Ибраһимның образы болайрак гәүдәләнә. Көнкүрештә йомшак мөгаләмәле, игътибарлы, тиз аралашучан, киң һәм кече күңелле, үзен вәкарьле (солидно) тота, вакчылланып маташмый, сүз сөйләргә, тормышка ашмас вәгъдәләр бирергә яратмый. Киң белеме, табигый зыялылыгы (интеллигентность) белән эшләгән даирәсендә дә зур абруй казана ул.

Балалар үстерергә насыйп булмаса да, Ибраһимның гаиләсе ишле генә була: җәмәгате Нәфисә, кайнанасы Газизә Яушева, абыйсы Фатыйх, мәрхүмә Сәгадәт апасының кызы Разия, соңрак Разияның энесе Мәхмүд. Өйләнгәнче туганнан туган энесе Гомәр дә яшәп алгалый бирeдә...

Ул чорларда Казанда яңа торак йортлар салынмый диярлек. Җөмһүрият күләмендә зур гына постлар биләгән Ибраһимны, әлбәттә, фатирсыз калдырмыйлар инде. Ләкин юристыбыз, ни хикмәттер, гел бер йорттан икенчесенә күчеп йөри, күрәсең, яшәү шартлары зур гаилә өчен бик үк уңайлы булмагандыр. Әйтик, әти-әнисенең Яңа Бистәдәге өеннән киткәннән соң (аны сатып китәләр бугай), ул абыйсы Фатыйх, хатыны, кайнанасы һәм башкалар белән



*Ибраһим белән Нәфисә Әмирханнарның илчелектә эшләгән чоры. 31 август, 1925 ел.*

бер-бер артлы (хәзерге исемнәре белән атасак) Нариман, З. Солтан, Насыйри, Миславский, Зур Кызыл урамнарына күчә, соңгы фатиры исә Бауман урамы белән бәйле.

Бу тынгысыз, михнәтле заманда, революциягә кадәрге төсле үк, Ибраһимның иң якын киңәшчесе һәм рухи яктан арка таянычы абыйсы Фатыйх була. Кичләрен алар озак гәп коралар, теге яки бу мәсьәләне һәр яклап тәфтиш кылалар, бер-берсе белән килешмәгән чаклары да була, әмма ахыр чиктә һәрвакыт диярлек уртак бер фикергә киләләр.

Кинәт И. Әмирхан язмышында кискен борылыш. Сәләтен, телләр белүен, хезмәтчән сыйфатларын, киң мәгълүматлылыгын һәм тәҗрибәсен күздә тотып, Совет хөкүмәте 1924 елда Ибраһимны дипломатик эшкә тарта. Яңа эш урыны итеп Хиҗаз (бераздан Согуд Гарәбстанына керә) билгеләнә. Биредә генераль консул вазифасын татарның күренекле дипломаты Кәрим Хәкимов үти. Элегрәк Хәкимов климаты һәм яшәү шартлары Гарәбстанныкыннан күпкә унайрак булган Персиядә эшләгән була, Хиҗазга килгәндә әле гарәпчәне белми. И. Әмирхан илчелекнең сәркәтибе, тәрҗемәчесе сыйфатында Хиҗазда ике ел буена җиң сызганып эшли, үзенең әзерлекле, төпле белгеч икәнен күрсәтә, кайбер көнбатыш мәмләкәтләренең төрлечә аяк чалуларына карамастан, Хиҗаз, аннары Согуд Гарәбстаны белән Советлар иле арасында хезмәттәшлекне ныгытуга байтак көч куя. Оста әңгәмәче, аралашучан, чит ил дипломатлары белән тиз уртак тел табучан Ибраһим, бер Согуд Гарәбстанында гына ятмый, билгеле. Хатынының ватанына язган хатларыннан аңлашылганча, алар дипломатик миссия белән Абиссиния, Италия, Австрия кебек илләргә дә сәфәр кылалар. Әмирхан «кызыл паша» Хәкимовның уң кулы була, байтак кына бәхәсле, четерекле мәсьәләләрне җайга салуда күренекле роль уйный. Җирле телне белмәгән Хәкимовка Ибраһимовның ничек ярдәм итүе хакында сүзне озайтып торуның хаҗәте юк. Кызганычка каршы, Ибраһимның консуллыкта эшләгән дәверен без әле бик аз беләбез.

Шәхси архивыбызда бер кызыклы гына вәсика (документ) бар. Ул илченең туганнан туган сеңлесе Фатыймага язган открыткасы. Әлбәттә, аннан дәүләтидипломатик характердагы мәгълүматлар эзләү урынсыз. Язмадан күренгәнчә, җаваплы эштә эшләгән житди илче юмор хисеннән дә мәхрүм булмаган икән. Хат Хиҗазнең үзәк шәһәре Җиддә каласыннан язылган. Текстны тулысынча китерәбез.

«Фатыйма! Син инде Казанда вакытта да безне бөтенләй онытa торган идең. Хәзер белми үк башлагансыңдыр. Мин хаҗи булгач инде, үзең беләсең ул кешеләрнең догаларын алырга кирәклеге тугрысында. Менә шуңар күрә, кардәш кеше бит, искә төшерим дип бу мәктүпчекне җибәрәм. Ибраһим. Җиддә, 27 февраль 1925 сәнә.

Хәмид, Госманга (Фатыйманың бертуган энеләре.— *Р. Ә.*) сәламнәрем, өйләнмәделәрме әле?[1]

И. Әмирхан туганнарына бу чорда бер генә хат язмагандыр, дип уйларга кирәк. Калганнары инде эзсез югалган, күрәсең. Ә менә хатыны Нәфисәнең әнисенә, апаларына юллаган открыткалары байтак сакланган. Гәрчә бу язмаларда иренең консуллыктагы эшчәнлеге хакында бер генә сүз булмаса да, яшәешкөнкүрешләрен, сәяхәтләрен тасвирлау җәһәтеннән шактый кызыклы алар.

Үрнәк өчен илче хатынының бер кечерәк хатына урын бирәбез. Ибраһим белән Нәфисә бик вәкарьле (солидно), европача һәм дәрәҗәләренә муафикъ кыяфәттә төшкән фотосурәт артына мондый сүзләр язылган:

«Мөхтәрәмә әни җәнаблары!

Сезгә Азмарада (Асмэра.—Эфиопиядәге шәһәр.— *Р. Ә.*) үткәргән вакытларыбызның хатирәсе уларак, ошбу рәсememезне җибәрәм. Без Азмарада 26 көн торып, 21 ендә, август, иртә сәгать 10 да Азмарадан поезд берлә китеп, 4 тә Массауага (Эфиопиянең порт шәһәре — *Р. Ә.*) килеп, прахудка урнашып, кич берлә шул ук көнне сәгать 10 да прахудымыз кузгалды. Шулай итеп, без 21 нче август киченнән бирле һаман диңгез өстендә прахудта. Бүген 31 август кич сәгать 6 да Неапольгә житеп, без шунда прахудтан төшәбез инде (әле сәгать 3 көндез). Бүген Неапольдә куныш, иртәгә поезд берлә Римга китәбез (4—5 сәгатьлек юл Римга). Римга барып җиткәч, сезгә телеграм бирсәк кирәк. Римда күп булса бер атна калырмыз. Шулай итеп, күрешер вакытлар якынаеп килә, Аллаһе теләсә, сәламәт булсак. Сезләр сәламәттерсезме инде. Ничектер сездән, 3 ай бит инде, хат ала алмаганымызга. Фатыйх абый үләр алдыннан күп мәетләр күргән кебек,

---

[1] Шәхси архив.

хәзер дә һәр көнне күп мәетләр күрәм. Аллага тапшырдым. Фатыйх абыйны һәр көнне күрәм. Разияга рәсемемезне Римнан җибәрәм. Анда да рәсемгә төшәмез. Хәзергә хушыгыз, исән-сау булуыгызны теләп, Нәфисә»[1].

Хат 1926 елның 31 августында язылган.

1926 ел. Дипломат язмышында безгә төп сәбәпләре әлегә мәгълүм булмаган яңа кискен борылыш. Бәлки, бу «буржуаз белгечләр»дән арыну шаукымы белән бәйле булгандыр. Ни дисәң дә, мулла малае эшче-крәстиян вәкиле түгел шул. Ничек булса да булган, Ибраһим хатыны белән ватанына, Казанга кайтып төшә. Иң якын туганы, рухи терәге булган абыйсы инде юк. Ибраһимның бер канаты сынгандай була. Өстәвенә, туган җиренә зур өметләр баглап, якты планнар корып кайткан «хаҗи» үзенә карата мөнәсәбәтнең кире якка таба капыл үзгәрүен тоя. Бу вакытта җөмһүриятнең югары даирәләрендә нииндидер тынчу атмосфера, йомыклык, һәр нәрсәгә шикләнеп карау галәмәтләре өстенлек ала башлаган була. Беркадәр читкә тибәрелгән Ибраһим 1927—1928 елларда үзенә хас булмаган вазифага тартыла, авыл хуҗалыгы банкының рәисе урынбасары булып эшли.


Рухына, интеллектына туры килмәгән шөгыль тәҗрибәле белгечне канәгатьләндерми, билгеле. Ул үзен яңадан Наркомюст системасына кайтаруларын сорый. Ниһаять, 1928 елның 8 мартында аны ТАССР Главсуды һәм Наркомюст коллегиясе әгъзасы итеп раслау турында карар кабул ителә. Биредә ул 1932 елгача эшли. Элекке илченең намуслылыгы, гаделлеге, үз дигәнендә торучанлыгы кайбер түрәләргә бик үк ошап бетми. Мөстәкыйль участокка чыгару (выдвижение) сылтавы белән (янәсе аның белеме һәм тәҗрибәсе зарур) Ибраһимны, вакытлыча, дигән булып, шул ук елда промторг идарәсе рәисе итеп билгелиләр. Чыннан да, ике ел дигәндә И. Әмирхан андагы эшне җайга сала һәм яңадан Наркомюст челтәренә әйләнеп кайта. Ләкин озакка түгел. Җитәкчелек тарафыннан төрлечә бәйләнүләрнең, аяк чалуларның яңа этабы башлана хәзер. Әлбәттә, Ибраһим да характер күрсәтмичә, бәхәсләшмичә калмагандыр. Наркомюстта яшел авыз түгел ич инде ул, тормыш тәҗрибәсе дә җитәрлек, кешелек гоурлыгы да бар. Ләкин Кировның гомерен өзгән 1934 ел элекке мулла малае өчен дә фаҗигале юлның башы була. Ибраһимның «язмыш тәгәрмәче» әкренләп упкынга таба тәгәри башлый.

1935 елда И. Әмирханнан үч алу өчен «уңайлы» форсат туа. Большевистик партия сафларында чираттагы «чистарту», «кан җибәрү» («кровопускание») башлана. Хәсет җаннар әвәләгән әләк-донослар нигезендә, Бауман райкомы бюросы 1935 елның 18 ноябрендә Ибраһимны партиядән чыгара һәм эшеннән азат итә. Ул заманда (хәер, 80 нче елларның уртасына кадәр дә) фиркадән чыгаруның нинди афәт белән бәйләнгәне хакында озак сөйләп торуның хаҗәте юк. Бу инде синең бетүеңә беренче сигнал, ягъни муеныңа элмәк салыну дигән сүз. Нинди гаепләр ташлана соң И. Әмирханга? Шәхси властеннан явызларча файдаланганмы, «социалистик законлылык»ны бозганмы, берәрсенә нахак бәла якканмы, партия линиясенә каршы чыкканмы, уңга яисә сулга тайпылганмы ул? Берсе дә түгел. «Гөнаһлары» бик иске инде аның, ә хәзер бераз пассиврак кына икән. Ягъни: 1) янәсе үзенә партстажны 1918 елның 1 февраленнән «үзләштергән» (присвоение); 2) 1918 елда акчехлар вакытында Казанда кораллы дружина оештырган; 3) партия һәм иҗтимагый тормышта пассивлык күрсәтә.

«Җинаятьләр» әлегә баш китәрлек үк түгел кебек. Һәм бу юлында Зариф хәзрәт улына ничектер котылып калырга насыйп була. Бәхетенә каршы, фиркагә кергән вакытында аңа рекомендация биргән кайбер шәхесләр әле исән була (мәсәлән, партконтроль «эш»ләрендә Каюм Саттаровның белешмәсе бар). Тикшерү нәтиҗәсендә шунысы ачыклана: бернинди үзләштерү юк, Ибраһим партиягә 1918 елның 1 февралендә кергән, № 78 партбилет аңа губкомның мөселман бюросы тарафыннан бирелгән, ә райкомда 1919 елда расланган икән. Әлеге «ачыш»ка таянып, партколлегия үзенең 1936 ел, 10 февраль утырышында элекке дипломатны партиядә 1919 елгы стаж белән торгызырга, дигән карар кабул итә. Шунда ук Әмирханның фиркагә кергән чагында үзенең акчехлар чорындагы гамәлләрен яшермәве дә искәртелә. Ибраһимның муенындагы элмәкне вакытлыча бушаткан бу карар партия өлкә комитеты тарафыннан 1936 елның 1 июлендә раслана.

Ләкин Сталин өере җәһәннәменнән котылу исеме инде бер мәртәбә пычратылган кешегә насыйп булмый. Эшеннән бушатылган Ибраһимның тормышында иң соңгы кара дәвер башлана. Ул көч-хәл белән Зеленодольск фанер

[1] Шәхси архив.



Военный Трибунал
ПРИВОЛЖСКОГО
ВОЕННОГО ОКРУГА
16 октября 1958 г.
№ 517-п
г. Куйбышев (обл.)

СПРАВКА

Дело по обвинению АМИРХАНОВА Ибрагима Зарифовича, 1889 года рождения, уроженца и жителя г.Казани, арестованного 23 декабря 1937 года, до ареста работавшего юрисконсультом фанерного завода № 10 в г. Казани, пересмотрено Военным трибуналом Приволжского военного округа 14 октября 1958 года.

Постановление от 3-го ноября 1938 года в отношении АМИРХАНОВА Ибрагима Зарифовича отменено и дело производством прекращено за отсутствием состава преступления.

АМИРХАНОВ И.З. реабилитирован посмертно.

ВРИО ПРЕДСЕДАТЕЛЯ ВОЕННОГО ТРИБУНАЛА
ПРИВОЛЖСКОГО ВОЕННОГО ОКРУГА
ПОЛКОВНИК ЮСТИЦИИ
/ЛЫШАКОВ/

*Ибраһим Әмирханның гаепсезлеген раслаучы белешмә. 16 октябрь 1958 ел.*

заводына мескен бер вазифа белән юрисконсульт булып урнаша. Аннан Казанга кайтып йөрүләре үзе бер бәла. Наркомюст коллегиясе әгъзалыгыннан шушы дәрәҗәгә төшерелгән Ибраһимны элек моның күләгәсеннән дә курыккан бәндәләр дә типкәли башлый. Канатлары каерылган кеше өстеннән хәзер төрле органнарга шикаятьләр языла, эшчәнлегенең аерым хасиятләре сабын күбегедәй күпертелеп, яла өстенә яла ягыла. Шундыйларның берсе — Яңа Бистә «карачкысы», үзенә туган тиешле Нәфисәне беренче мәртәбәсендә Хиҗазга алмаганы өчен әледән-әле иренә, Ф. Әмирханга каршы котыртучы, бөтен тирә-юньгә хәсетлеге, явызлыгы белән танылган Хөршид тәтәй була. Тәкъдир каһәренә юлыккандыр инде, бу бәндә соңгы елларын тома ялгызлыкта үткәрә, юләрләр йортында җан тәслим кыла. Ибраһимны гаепләү «эш»ләрендә аның өстеннән иң «үтергеч» донос язган тагын ике адәмнең фамилиясе теркәлгән. Боларның берсе — нәмәгълүм Хәйруллин, икенчесе — ниндидер Зәйнуллин. Хәер, боларны алдан хәзерләнгән текстка кабыргалары сынганчы кыйнап кул куйдырганнар бугай.

Чоры шундый: бу вакытта партаппаратта һәм башка совет-хуҗалык органнарында «халык дошманнары»н мөмкин кадәр күбрәк табу һәм фаш итү уе белән янган кешеләр эшли яисә аларга бу җәһәттән план җиткерелә. Шуңа нисбәтән, 1937 елның 3 мартында партия өлкә комитеты РКП (б) Бауман райкомы бюросының И. Әмирханны партиядән чыгару турындагы карарын үз көчендә калдыра. Заман күзлегеннән караганда, бу инде үлем җәзасына хөкем итү белән бер.

НКВД наряды Бауман урамы, 54 нче йорт (элекке «Бристоль» номерлары) 6 нчы фатирда (хәзер 16 нчы) яшәгән Әмирхан артыннан 23 декабрьнең кара төнендә килеп җитә...

Хәзер инде Ибраһимга берьюлы 1918 елның җәен дә, заманында Солтангалиев белән эшләгән кешеләр илә очрашуларын да (димәк, «милләтче», «солтангалиевче») һәм, иң кәттәсе, Хиҗазда вакытта янәсе япон разведкасы белән элемтә урнаштыруын да «исенә төшерәләр» (димәк, «шпион»!). Бу «җинаятьләр» пунктлар тәртибендә болайрак калыплана: 1) 1918 елда акчехлар Казанда вакытта аларга ярдәм күрсәткән; 2) милләтчел солтангалиевчеләр оешмасында катнашкан; 3) Япония файдасына җасуслык кылган.

Бар, 1937 елда үзеңнең гаепсез икәнеңне исбатлап кара син! Ә бит бу пунктларның берәве генә дә үз чоры шартларында кешене стенага терәү өчен җитә калган. «Халык дошманы» мөһере җуелмаслык итеп сугылган Ибраһимга бернинди дәлилләр, аңлатма язулары, апелляцияләр ярдәм итми. Бар гаепләүләрне кире кага элекке илче, эшне объектив карауларын сорый. Ләкин заманының адәм түзмәслек җәза ысуллары эшкә җигелгәч, ватылмаган-имгәнмәгән әгъзасы калмагач, сына, җанын рухи өметсезлек били. Инде котылу булып күренгән үлемне тизләтү өчен үзенең чыннан да «милләтче», «солтангалиевче», «япон шпионы», «халык дошманы» булуын «таный»...

1938 елның 3 ноябрендә ТАССР НКВДсы өчлеге Ибраһим Әмирханны атарга хөкем итә. Хөкем карары шул көнне үк җиренә җиткерелә. Кырык сигез яшьлек азамат ирнең гомере шулай итеп нахакка өзелә, ә исеме «халык дошманы» сыйфатында тарихтан сызып ташлана... Мөгаен, гәүдәсе аның фаҗигале язмышын уртаклашкан бихисап корбаннар белән берлектә Архангельски зиратына күмелгәндер.

50 нче елларның азакларына кадәр Ибраһим Әмирхан кебек «халык дошманнары» хакында авыз ачып сүз әйтергә ярамады. «Беренче жепшеклек» дәверендә Бибисәгадәтбану кызы Разия абзасының намуслы исемен кайтару йөзеннән тиешле даирәләргә мөрәҗәгать итә, «эш»не кабат карауларын сорый. Озак кына йөри торгач, 1958 елда аңа мондый белешмә тоттыралар: «Постановление от 3-го ноября 1938 года в отношении Амирханова Ибрагима Зарифовича отменено и дело производством прекращено за отсутствием состава преступления».

Бәй, бернинди җинаятьче түгел икән ич Ибраһим Зарифович, җаны ялгыш кына кыелган, була инде дөньяда андый гына хәлләр! Аннары хәзер, егерме ел вакыт үткәч, искедә казынулар нигә кирәк!

80 нче еллар башы. Җылы җилләр исә башласа да, «халык дошманы» дигән тәгъбир кулланылыштан нигездә инде төшеп калса да, аклану (реабилитация) дигәннең дә төрле дәрәҗәләре бар иде әле. Әйе, диләр иде ул чорда, «по гражданской линии» абзагыз гаепсез, ләкин бит «по партийной линии» торгызылмаган, димәк «анда» нидер бар... Аның хакында язарга, авыз тутырып сөйләргә телисез икән, партиядә торгызу мәсьәләсен күтәрегез, бәлки, әле колак та салып куярлар.

«Аклау», «торгызу» юлында яңа тәшәббесне (инициативаны) минем үземә күрсәтергә туры килде. Бу эшкә хәер-фатиха бирүчеләрнең иң беренчесе Мөнирә апа Сәйдәшева булды. Ибраһим Әмирханның тормыш юлын өйрәнү, эшчәнлегең ачыклау-барлау эшенә ул гомумән байтак өлеш кертте. 1984 елның 2 ноябрендә мин, абзамны «партияле буларак аклау» макстатында партия контроле комиссиясе исеменә гариза яздым. Берникадәр вакыт узгач, үзебезнең кадрлар бүлеге кабинетында бер мөһим очрашу оештырылды. Минем белән махсус әңгәмә өчен моңарчы бөтенләй мөнәсәбәткә кергәнем булмаган дәүләт иминлеге комитеты вәкиле килде. Ул беренче нәүбәттә Разия Әмирханиянең кем булуы, минем аңа һәм Ибраһим абыйга кем туры килүем, аннары эш кузгатуымның сәбәпләре белән кызыксынды. Боларны шәҗәрә фрагменты төзеп аңлатырга туры килде. Шаһитлардан башка үткәрелгән әңгәмә соңында бик рәсми сөйләшкән комитет вәкиле миңа Ибраһим Әмирханның бернинди дә гаебе булмавын искәртте, аны «просто оговорили», дип аңлатты, бу шәхес хакында теләсә күпме язарга, сөйләргә мөмкин генә түгел, бәлки эшчәнлеген гомумән пропагандалау кирәклеге турында өметле фикер әйтте. Рәсми булса да, бу очрашудан күңелемдә җылы тәэсир калды.

Тиздән махсус чакыру кәгазе алдым. Шуның нигезендә 1985 елның 16 гыйнварында мин реском бинасындагы партконтроль комиссиясенә килдем (пропуск системасы, бинага керү мәшәкатьләре турында язып тормыйм). Комиссия дигәнең бер хатын-кыз гына гәүдәләндерә булып чыкты. Эшне озынга сузмыйча, бу вәкилә ярым тантаналы, ярым фаҗигале бер дежур тон белән, «Ибрагим Зарифович Амирханов был осужден 3 ноября 1938 года» (җәзалау, атылу хакында сүз юк), дип минем «күземне ачты» һәм абзамның партия стажын 1919 елдан торгызырга карар кылынуы турында хәбәр итте. Нихәтле тыныч-битараф булырга тырышсам да, бугазыма кисәк тыгылган төердән тиз генә арына алмадым. Бичара Ибраһим абый! Синең намуслы исемеңне бөтенләйгә кайтару, заманына күрә, һәртөрле конъюнктура тышауларыннан бушату өчен энеңә ярты гасыр үткәннән соң шулай мескенләнеп йөрергә язган икән! Мескенләнмичә, дилбегә бит әле һаман да синең җаныңны кыйган җәллад варислары кулында.

1958 елдан аермалы буларак, хәзер кулга бернинди дә кәгазь бирелмәве (хәтта үзләре җибәргән чакыру кәгазен дә алып калдылар, миндә коры конверты

гына саклана), мондый белдерүләрнең телдән генә игълан ителүенә басым ясап, ханым безнең монологка охшаш бер яклы әңгәмәбезгә нокта куйды. Әйе, тавыш-тынсыз атабыз, тавыш-тынсыз аклыйбыз, югыйсә тагын эз кала бит! Гомумән, тавышында металл чыңы иде вәкилләнең. Күз буяр өчен генә булса да, гафу үтенү, димим инде, миңа теләктәшлек белдергән, хәлемә кергән булу, һич югы бер миһербанлы сүз әйтү жинүчән-тәкәббер кыяфәтле ыспай ханымның уенда да булмагандыр, мөгаен. Киресенчә, ул, шәхсән бер-бер гаебе булмый калмагандыр әле Ибраһимның («квартальный булып йөргән ич»), дигәнрәк фикерен яшереп тә маташмады. Тулаем алганда, аклау, торгызу, дигән үтә формаль акт нәтиҗәсен игълан итү дә функционерлар өчен артык мәшәкать саналды ул чакта. Бу — исемлек буенча ату, исемлек буенча ярлыкауның типик бер галәмәте, шомлы еллар кайтавазы гына иде...

Ләкин, ничек кенә булмасын, уңай моментны кулдан ычкындырырга ярамый иде. Форсаттан файдаланып, без Мөнирә Абдулловна Сәйдәшева белән ашыгыч төстә мәгълүматлар туплый башладык. Төрле рәсми даирәләргә, хәтта ки тышкы эшләр министрлыгына мөрәҗәгать иттек (башлыча Мөнирә апа), аны күреп белгән кешеләрдән кыскача гына булса да истәлекләр язып алдык, иске татар матбугатын өйрәндек, архивларда актарындык (нигездә, мин). Һәм Ибраһим Әмирханның йөз еллыгына, заман рухына туры китеребрәк (партиянең иярдә чагы) зур күләмле мәкалә әзерләдек. Башта бу материалның сыгынтысы, нык кына кыскартылып һәм «шомартылып», «Амирханов Ибраһим Зарифович» исеме белән рәсми сериялда дөнья күрде.[1] Ләкин, миңа бүгенгәчә бик үк аңлашылып җитмәгән сәбәпләр аркасында, язманың авторы итеп никтер М. А. Сәйдәшева гына күрсәтелгән булып чыкты. Бик үк күңелле булмаган «аңлашулар»дан соң без, материалны тагын да баета һәм тирәнәйтә төшеп, ул чорның үтә рәсми вә таләпчән басмасы булган «Коммунист Татарии» журналына тәкъдим иттек. Редакциядә мәкаләне нык кына «кыстылар», без язганга караганда да «кызартып», эчтәлеген милли хасиятләрдән бөтенләй диярлек арындырдылар. Язмабыз шул «камилләштерелгән» килеш «Вся жизнь — служение народу» дигән исем астында басылып чыкты.[2]



*Апаковлар гаиләсе. Сулдан уңга: Мәрьямбану Әмирхания-Апакова, итәгендә улы Госман, Өммегөлсем (утырганы), Фатыйма, гаилә башы Габделшәкүр, өлкән улы Габделхәмид. Казан, 1907 (?) ел.*

Ләкин Ибраһим Әмирхан турындагы материалның заманында күп яктан имгәтелгән булуы һәм бары урыс телендә генә дөнья күрүе күңелемә озак вакытлар тынгылык бирмәде. Анары чорыбызның рухы да мәсьәләгә яңача килүне таләп итә иде. Нәтиҗәдә мин мәкаләнең яңартылган һәм тулыландырылган вариантын эшләп, аның байтак өлешен «Шомлы еллар кайтавазы» дигән баш астында «Казан утлары» журналында бастырып чыгаруга ирештем.[3]

Инде Ибраһимның хәләл җефете Нәфисә Әмирхания хакында да берничә сүз әйтик. Шунысы бар, безгә килеп ирешкән шифаһи (словесный) мәгълүматлар аны, кызганычка каршы, күбрәк тискәре яктан сыйфатлый («недалекая», миһербансыз, җилбәзәк, Ф. Әмирханның, әдип вафатыннан соң байтак кулъязмаларын яндырган һ. б.). Нәкъ менә Нәфисәне күздә тотып булса кирәк, язучы бер заман бик ачынып: «Ну эләгә дә соң Әмирхановларга хатыннар!» — дип ычкындырган, имеш.

Әмма тискәре шәкелдәге хатирәләрне яңарту (ә мисаллар җитәрлек) безнең үзебезне дә, язмабызны да бизәмәстер. Тулаем алганда, бичара бер хатын була ул. Төпле белем алырга туры килмәгәнлектән, чәч-сакал китәрү урынында (пари-

---

[1] Борцы за счастье народное. Книга третья. Казань, Таткнигоиздат, 1988, с. 26—30.
[2] Коммунист Татарии, 1989, № 12, с. 67—71.
[3] Казан утлары, 1996, № 1, 167—176 б.

кмахерская) кассир һәм кием бирүче (гардеробщица) булып эшләгән чагы да булган Нәфисәнең. Ирен зинданга илтеп тыгу белән «халык дошманы» хатыны өчен кара көннәр башлана.

1983 елның 26 апрелендә без галим Марсель әфәнде Әхмәтҗанов белән Ибраһим һәм Нәфисә соңгы чорда яшәгән фатирны эзләп таптык. Бауман урамы, 54 нче йорт, 12 нче фатирда 1935 елның октябреннән бирле яшәгән 77 яшьлек Шәргыя апа Шәйхетдинова (Кукмара ягыннан, Красная Полянадан килеп урнашкан, 1906 елның 22 декабрендә туган) белән озак кына әңгәмә кордык. Аның сүзләре буенча, Әмирханнар бу йортның 6 нчы (хәзер, ягъни 1983 елда, 16 нчы номер) фатирына 1937 елда Кабан күле буеннан күчеп килгәннәр икән. Шәргыя апа алар белән шактый якыннан аралаша башлаган, ләкин бер-ике ай торгач та, Ибраһимны «кара козгын» алып китә, ә хуҗабикә генә булган беркатлырак Нәфисә, ирен нәрсәдә гаепләүләре хакында хәтта юньләп белмичә дә кала. Ирен алганнан соң, Нәфисәне нык эзәрлеклиләр, каядыр сөрергә җыеналар. Бичара хатын елый-елый ялвара, үзенең Казан кызы икәнен әйтә, шунда ата-анасы җирендә үләргә калдыруларын үтенә. Ләкин бәладән котыла алмый. Аның өстеннән, бигрәк тә торак урынын кинәйтү максатында, хәзер (ягъни 1983 елда) Нәфисә фатирында (инде 16 нчы номер) торучы Субаев дигән кеше йөри. Нәтиҗәдә, «халык дошманы» хатынын биредән куып чыгаралар, «бушаган» фатирга әләкче Субаевлар кереп урнаша...

Нәфисәнең шуннан соңгы изалануларын күз алдына китерү кыен түгел инде. Аны эшкә алмыйча интектерәләр, кая килеп керсә дә, бусагага күрсәтәләр. Анда-монда сугылып, эт типкесендә йөргәннән соң, бичара хатын Яңа Бистәгә, туганнарына (Кәтиевларга) кайтып егыла. Анда да кочак җәеп каршы алмыйлар Нәфисәне, чөнки НКВД капшавычларының Кәтиевларга таба да сузылачагын беләләр. Йончылган, кыерсытылган, кеше күзенә күренерлеге калмаган бичараның акылына зыян килә. Үзен дә, туганнарын да азаплый торгач, чит мәмләкәтләрне урап кайткан элекке илче хатыны 1943 елның кышында кырык җиде яшен дә тутырмастан дөнья куя...

## Апаковлар

Әмирханнар фамилиясен йөртмәсәләр дә, Хөсәен Әмирханның кызы, Мөхәммәдзариф белән Мөхәммәднәҗип хәзрәтләрнең бертуган сеңлесе Мәрьямбану балалары хакында каләм тибрәтү дә, безнеңчә, лязем булыр. Боларның гаиләләре кан-кардәшлек белән дә, мәгънәви-рухи җәһәттән дә шулкадәр береккәннәр ки, Казанлы Әмирханнарны, бигрәк тә Фатыйх белән Ибраһимны, Апаковлардан башка күз алдына китерү мөмкин түгел.

Гаиләнең башы Габделшәкүр Мортаза улы Апаков (1860—1923) урта кул сәүдәгәр, Мәкәрҗә юлларын күп таптаган, алай да мал-мөлкәт туплауда әлләни майтара алмаган, тере генә, ачык зиһенле, музыкага һәвәс (укып та йөргән) кин күңелле бер кеше була. Заманы, традицион татар өе өчен сирәк күренеш — бүлмәсендә пианино торткан (бәлки, кызы Өммегөлсем өчен алгандыр). Күрше генә йортта тереклек сөрүче Габдрахман исемле бертуган абыйсы, аның җәмәгате, балалары белән бер гаиләдәй көн күргән, дөнья куган.

Өлкән кызлары Фатыйманы (1891—1971) инде безнең замандаш дияргә мөмкин. Тәрҗемәи хәленә тәфсиллерәк тукталу мөмкинлеге бар. Юаш, карусыз, күндәм, тәкәллефсез, сабый күңелле, һәркемгә ярдәмчел. Безнең шәхси архивыбызда мәшһүр Шәрекъ клубының «Театральный комиссия»се тарафыннан Фатыйма Апаковага атап язылган берничә чакыру кәгазе бар. Аларда миһербанлы туташны махсус оештырылган балалар кичәсенә чакырып, сабыйларны карап, күңелләрен ачып, аларга күз-колак, мөрәббия (тәрбияче) булуны үтенгән юллар теркәлгән. Кәгазьләр «Театральный комиссия» яки клуб идарәсе сәркәтибе (секретаре) Шиһаб Әхмәров имзасы белән юлланган. Типография ысулы белән басылган мондый чакыру кәгазьләре тарихи ядкярь, чыганак булу ягыннан да илтифатка лаек. Менә шуларның берсеннән өзек (датасы күрсәтелмәгән, 1914—1915 еллар булырга тиеш):

«Хөрмәтле Фатыйма Апакова җәнабларына!» Ошбу сәнә гыйнвар 25 ндә шимбә көн, 27 сендә дүшәмбе көн Шәрекъ клубы «балалар кичәсе» ясаячактыр. Шул кичәләрдә тәртипне саклар вә балаларга нәзарәт итеп (күзәтеп), аларны уйнатыр вә җуандырыр өчен, театральный комиссия бу хосуста сезнең ярдәмегезне үтенәдер...»[1]

[1] Шәхси архив.

Туташ, әлбәттә, мондый чакыруларның берсен дә кире какмаган.

Фатыйма Апакова инкыйлабка чаклы Казанда урыс гимназиясен тәмамлый, совет чорында башта медицина техникумында, аннары медицина институтында белем ала, әзерлекле белгеч буларак, шәһәрнең төрле сырхауханәләрендә табиблык вазифасын үти. 20 нче елларда, кече сеңлесе Фәүзияне дә ияртеп, Ташкент якларында да эшләп кайта. 1941—1945 елгы сугыш чорында хәрби госпитальдә яралы гаскәриләрне дәвалый. Урысчаны «су кебек эчүе» дә мәгълүм. Пенсиягә чыкканнан соң да табиблык хезмәтеннән, медицинадан читләшми. Кияүгә чыкмавы сәбәпле, балалары юк.

Икенче бала Өммегөлсем (1897/98—1916) — гаиләсендә генә түгел, бөтен даирәсендә сөйкемле сөяк, ярымфәрештәгә тиңләштерелгән зат. Ф. Әмирханның җан аткан сеңлесе. Журналист Ш. Байчура истәлекләренә караганда, Өммегөлсемнең рәсеме Ф. Әмирхан бүлмәсе диварында даими эленеп торган. Тыйнак кына тормышлы сәүдәгәр гаиләсендә үскән бу кыз (җитмәсә, ризыкка да бик нәзберек була, ипи дә ашамый), зур авырлыклар кичереп, татар кызлар мәктәбен тәмамлый. Аннары, үзлегеннән әзерләнеп, мең мәшәкать белән, атаклы Шумкова кызлар гимназиясенә укырга керә. Безнең шәхси архивыбызда бу уку йортында гыйлем алучы гимназисткаларның күмәк фотосы саклана. Алар арасында кардай ак алъяпкычлы, озын калын толымлы Өммегөлсем дә бар. Кызга бик нык тырышырга, көч куярга туры килә. Ул көне-төне укый. Музыкага да сәләте һәм омтылышы ифрат көчле була. Шуңа күрә бер үк вакытта музыка мәктәбенә дә йөри, бу өлкәдә дә зур уңыш казана. Педагоглар, туганнары, таныш-белешләре аңа зур өметләр баглый.

Өммегөлсем гимназияне алтын медальгә тәмамлый. Унөч яшенәчә татарча гына укыган кыз, урыс гимназиясендә укып, шундый нишан алсын әле! Бу хәл — заманында татар дөньясы өчен искитмәле вакыйгаларның берсе, ярым могҗиза.

Төпле дөньяви белемгә ирешкән туташ хыял дәрьясына чума: татар кызлары өчен дә махсус гимназия ачылсын иде дә, Өммегөлсем анда кардәшләренә дәрес бирсен иде. Ә яңа буын балалар ул чиккән мәшәкатьләрне, татыган кыенлыкларны күрмәсен иде... Әмма ни аяныч! Авыр тормыш шартларында (өстәвенә 1914 елда сугыш башланып китә) ачлы-туклы уку, көн-төн алны-ялны белмичә шөгыльләнү яшь туташның сәламәтлеген корт урынына кимерә. 1915 елда аңарда үпкә туберкулезының беренчел билгеләре күренә башлый. Тизагышлы (скоротечная) чахотка ул чор өчен өметсез чир, бернинди дә дәва, им-том ярдәм итми. 1916 елның мартында чәчәк кебек гомер өзелә. Фәүзия апа Апакова (аның турында сүз алда булыр), әтисе Шәкүрнең кызы вафатыннан соң идәнгә тәгәри-тәгәри илереп елаганын әле дә булса хәтерли. Аяныч вакыйгага инде сиксән ел диярлек вакыт үтсә дә, ул бу хакта сөйләгәндә күз яшьләрен тыя алмый.

Бу югалту Ф. Әмирханны да тетрәтә. «Кояш» газетендә ул «Өммегөлсем Апакова» исемле мәрсия (некролог) белән чыга. Йөрәк җылысы, туганнарча мәхәббәт һәм тирән юксыну хисләре белән сугарылган мәкаләсендә әдип сеңлесенә, халыкның үз эченнән чыккан, халык белән бергә аның тормышының бөтен ачы вә төчесен татыган зыялы бер кыз, дип бәя бирә. Мәрсиядә мондый сүзләр бар: «Мәрхүмә үзенең гаять гафиф (саф, гыйффәтле), пакь вә яхшы хатын-кызларга махсус йомшак табигате белән үзе катышкан бөтен даирәләрдә үзенә каршы бер мәхәббәт вә самимият (чын күңеллелек) казана иде. Аны сөяләр вә ихтирам итәләр иде».[1] Табуты тере чәчәкләргә күмелгән Өммегөлсемне соңгы юлга озатырга бихисап кеше килә.

Өммегөлсем Апакова, Ф. Әмирхан даирәсенең иң хөрмәтле һәм сөекле бер вәкиле буларак, әдипкә хатын-кыз типларын сурәтләгәндә илһам биргән, аны иҗади эзләнүләргә рухландырган якты шәхес буларак мәгълүм.

Апаковларның өлкән улы Габделхәмид тә (1900—1968) төшеп калганнардан булмый[2]. 1919 елдан ул ярлылар комитеты (комбед) әгъзасы. НЭП чорында икмәк җыеп йөргән, атасы һөнәрен искә төшереп, вак-төяк белән сату итеп тә алган. Яңа хакимияткә ошамаган ниндидер гамәлләре өчен («сыйнфый дошман»нарны фаш итү чоры) сөргенгә җибәрелгән, аннан башы исән кайткан. Сугышка чаклы хисапчы, ревизор-бухгалтер булып эшләгән. 1941—1945 елларда фронтта. Махсус белеме булмаса да, үткенлеге, һәрнәрсәгә һәвәслеге аркасында, фельдшерлык хезмәтен башкарган. Сугыштан исән-имин кайткач, әүвәлге һөнәрен яңарткан. Өч мәртәбә гаилә учагы кабызган, балалары һәм оныклары хәзер

---

[1] Кояш, 1916, 17 март.
[2] Тукай белән кузна уйнавы мәгълүм.

җаваплы гына эшләрдә эшли. Бер килене — Сәйдә абыстай Апакова (1935 елгы) — хәзер бөтен Казанга танылган дин әһеле, остазбикә.

Кече малай — Госман (1905—1954) гадәти генә биографиягә ия. Өлкән яшькә җиткәч, хәрби заводта бригадирлык кылган, броньга калдырылганлыктан, фронтка юлы төшмәгән. Соңрак обоз детальләре заводында, аннары Плетәндә эшләпә бүлегендә эшләгән. Хәзер Казанда балалары, оныклары яши.

Апаковларның иң кечесе, хәзер бердәнбер исән калган балалары — Фәүзия апа 1910 елда туган. Сәләтле кыз башта «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе янәшәсендәге татарча кызлар мәктәбендә укый, аннары аны Пушкин урамындагы (хәзер педагогия университетының музыка факультеты урнашкан бина) урысча мәктәпкә бирәләр. Монда уңышлы гына белем алганнан соң, ул сигезьеллык төзүчеләр техникумына аяк баса, аны тәмамлагач, төрле курсларга йөри, медицина белән шөгыльләнә, укуны эш белән чиратлаштыра. 1938—1942 елларда Казан дәүләт стоматология институтында белем ала, аны тәмамлап, югары квалификацияле врач-стоматолог булу шәрәфенә ирешә. Яшь белгечне Алексеевский районының урта Тигәнәле авылына участок врачы итеп җибәрәләр. Ул анда сигез ай эшләп Казанга кайта. Һәм кайтуына гаскәргә мобилизацияләнә. Табибәбез фронт юлларын таптап, башыннан байтак маҗаралар кичерә, госпитальләрен берничә тапкыр бомбага тотуның шаһиты була, җиңү көнен медицина өлкән лейтенанты сыйфатында Польшада каршылый. «Германияне җиңү өчен», «1941—1945 еллардагы Ватан сугышында җиңүнең 30 еллыгы» һәм башка шундый юбилей медальләре белән бүләкләнә. Сугыштан соң ГИДУВ та белем күтәрү курслары үтә. Аннары Фәүзия — участок врачы (терапевт). Яңа Бистәдәге Мех комбинатындагы сырхауханәдә дә эшләп ала ул, соңрак Игумный бистәсендә янә участокта табибә, Бишбалтада хәрби врач вазифаларын башкара. Шунысы гыйбрәтле, Фәүзия Апакова 1965 елда берьюлы пенсиягә һәм кияүгә чыга. Тәүге һәм соңгы мәртәбә никахлана. Хәзер Казанда яши, балалары юк.

## Казанлы Әмирханнарга бәйле урыннар

Инде өлкән буын Казанлы Әмирханнар белән бәйле урыннар хакында да берничә сүз әйтербез. Истәлекле урыннар бик күп, һәм без аларның барысына да тукталмыйча, иң әһәмиятлеләренә генә хронологик рәвештә кагылып үтәрбез. Беренче нәүбәттә безнең игътибарны Гафури урамы, 35 нче йорт җәлеп итәр. Биредә Хөсәен, Мөхәммәдзариф, Мөхәммәднәҗип хәзрәтләр гомер сөргән, соңыннан Мөхәммәднәҗип дәмолла гаиләсе Чистайдан еш килеп йөргән, Бибисәгадәтбану, Фатыйх, Ибраһим туган. Фатыйх белән Ибраһим бу йортта 1921 елның азакларына кадәр яшәгән. Кызганыч ки, бик истәлекле әлеге бина хәзер хәрабә хәлендә.

Каршы якта урнашкан мәһабәт «Иске таш мәчет» (Гафури, 34 а) шулай ук Әмирханнар нәсәбе белән тыгыз бәйле. 1803 елда салынган (ул чакта әле агач бина) бу мәчеттә Әмирхан бине Габделмәннән имамлык кылган, 1830—1840 елларда торгызылган таш мәчеттә инде соңрак Хөсәен, Мөхәммәдзариф һәм Мөхәммәднәҗип хотбә укыган. Әлбәттә, биредә Фатыйх та, Ибраһим да еш булган. Мәчеттән ерак түгел җирдә (Зайцев урамы, 4) «Әмирхания» мәдрәсәсе бинасы урнашкан булган. Биредә өлкән буын дүрт хәзрәт дәрес әйткән, Фатыйх белән Ибраһим тәүге сабакларын алган.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе дә (Тукай, 34) Әмирханнар өчен гаять истәлекле биналардан санала. Биредә озак еллар буена Фатыйх белән Ибраһим йөреп тә, шунда торып та белем эстәгән, олуг мәгърифәтче һәм дин әһеле Г. Барудиның фатихасын алган, аның сәләтле шәкертләреннән саналган. Әлбәттә, бу ике туган мәдрәсә белән гомуми комплекс хасил иткән Галиев (Баруди) мәчетенә дә (Тукай, 40/22) йөргәннәр. Баруди йортына да (Тукай, 57) еш «сугылганнар».

1908—1909 елларда «Әл-Ислах» гәзите идарәсе урнашкан йорт та (Тукай, 63) гаять истәлекле. Габделшәкүр һәм Мәрьямбану Апаковлар гаиләсендә Казанлы вә Чистайлы Әмирханнар һәрвакыт үз кешеләр булган, биредә Фатыйх Әмирхан 1906 елның мартында полициядән качып яткан, «Әл-Ислах» тирәсендә рухи яктан «игезәге» Г. Тукай белән бергәләшеп, кешелеклелек, демократик идеаллар өчен көрәшкән. 1990 елда элекке «Әл-Ислах» бинасы кемнәрнеңдер фәрманы белән җинаятьчел рәвештә сүтеп ташланды. Хәзер аның урынында кыргый чаганнар, шайтан таяклары гына үсеп утыра.

Биредән ерак түгел, кыйгач-каршы якта мәшһүр «Шамил йорты» (Тукай, 74). Апаковлар ягыннан кардәш тиешле Шамилләрдә Фатыйх Әмирхан еш булган.

Шуның бер нәтиҗәсе сымак, булачак әдип 1907 елда Мәскәүдә Заһид Шамил белән «Тәрбияи-әтфаль» журналы чыгарган.

Бишбалта Бистәсенең дә мәгълүм күләмдә Әмирханнар белән бәйләнеше бар. Әйтик, Бибисәгадәтбану белән Габдулла Әмирхани йортында (Большая, 66) Зариф белән Рабига, башка өлкән буын туганнарыннан тыш, Фатыйх та бик еш булган, берничә тапкыр бирегә Тукайны да ияртеп килгән. Шунда ук янәшәдә Габдулла хәзрәт имамлык иткән мәчет (Большая, 67), аңа терәлеп үк диярлек салынган бинада («Әмирхания») Сәгадәт кыз балалар укыткан.

Хәзерге Париж Коммунасы урамы да Ф. Әмирхан исеме белән беркадәр бәйле. Әлекке «Сарай» номерлары урнашкан бинада (9 нчы йорт) шәкерт спектакльләренең репетицияләре үткән.

Революциягә кадәр Первая Гора, хәзер Ульяновлар дип йөртелгән урам да истәлекле. Элекке М. Н. Сухановлар утары, гасыр башында Габитовлар йорты булган бинада (№ 31), «шимбәчеләр» татар яшьләре өчен спектакльләр уйнаган. 1904 елның 18 гыйнварындагы ике спектакльдә яшь Фатыйхның да катнашуы билгеле.

Спектакльләр, димәктән, тагын шунысын да теркәп узыйк: булачак әдип 1906 елның 5 маенда Приказчиклар союзы клубында (Большая Красная, 29) татарның беренче ачык спектаклендә уйный. Уен 22 декабрьдә куелган тамашаның (татар театрының туу көне дип исәпләнә) «генераль» репетиция»се була. Әлеге җәһәттән «Новый клуб» хакында да (Горький, 3; аннары Горький, 13) берничә сүз. Бирегә Ф. Әмирхан 1906 елдан башлап спектакльләргә йөри, әдәби-музыкаль кичәләрдә катнаша, гомуми тамашаларга, очрашуларга йөрүен 1923 елга чаклы дәвам итә.

Горький урамы белән бәйләнешле тагын бер факт: Кекин йортындагы (№ 8/9) Ряхина хосусый гимназиясендә 1914—1915 елларда Зәйнәп Әмирхания белем ала.

Хәзерге Ирек (элекке Театр) мәйданы да мәгълүм дәрәҗәдә Әмирханнар ядкярен саклый. Шәкерт Фатыйх ул замандагы «Театр мәйданы»нда урнашкан Шәһәр театрына урыс спектакльләренә йөри, 1926 елның 12 мартында исә аны мәйданда рәсми сурәттә соңгы юлга озаталар, җеназа мәрасимен кинотасмага төшерәләр.



*Зәйнәп Әмирхания энеләре (сулдан уңга) Илдус, Равил һәм Расим белән. 1964 ел.*

Университет урамы, 17 нче йорт та әдип эзләрен саклый. Бу бинада озак еллар эшләп килгән «Старая клиника»да Ф. Әмирхан параличтан соң (1907) берничә ай дәваланып ята, аягына баса алмаса да, башка җәһәтләрдән яхшы ук сихәтләнә.

Әдип биографиясен, әлбәттә, «Шәрекъ клубы»ннан (Татарстан, 8) башка да күз алдына китерүе кыен. 1910 елдан башлап Ф. Әмирхан бу милли мәдәният үзәгенең, автор буларак та, тамашачы буларак та, төп фигураларыннан санала.

«Шәрекъ клубы» белән янәшә генә урнашкан «Болгар номерлары» да (Киров, 14/19) Ф. Әмирхан тормышында билгеле бер урын тоткан биналардан. Биредә заманында Г. Тукай, В. Мортазин-Иманский яшәгән, Һ. Максуди мәшһүр «Йолдыз» газитен нәшер иткән, Ф. Әмирхан исә 1908 елның мартына чаклы биредә «Әл-Ислах» газитен җитәкләгән, 1908—1911 елларда вакыт-вакыт торып киткән.

Инде сүтелгән булса да, бер әһәмиятле бинаны искә алып китик. Элекке Дальнеархангельская урамы, Литовченко йорты саналган өй (Такташ, 111), җәйге дача сыйфатында «ислахчы»ларның, алдынгы татар яшьләренең (Ф. Әмирхан, Г. Тукай, К. Бәкер һ. б.) ял итү урыны һәм иҗади максатларда җыелу урыны булган.

«Амур» номерлары дип аталган бина (Киров, 70) аеруча истәлекле. Биредә сөекле шагыйребез Г. Тукай, татар сәхнәсе йолдызлары Г. Кариев, С. Гыйззәтуллина-Волжская яшәгән, Ф. Әмирхан «Кояш» газитендә (1912—1918) җаваплы сәркатиплек кылган. Шунысы да мәгълүм: Тукай белән Әмирханның бүлмәләре янәшә булган, шагыйрь бер кешелек 9 нчы, әдип — ике кешелек (коляскасын этеп йөртүче малае белән) 11 нче номерны биләгән. «Амур» номерлары урнашкан Печән базары мәйданы 1913 елның апрелендәге аяныч вакыйганың да телсез шаһиты. Биредә мәрхүм Тукайны соңгы юлга озату мәрасиме уза. Җеназаны Казанның иң могътәбәр имамнарыннан саналган Мөхәммәдзариф Әмирхан укый.

Мәйдан турында сүз чыккач, шуны да өстәргә кирәктер: хәзерге Тукай кинотеатры янындагы Юнысов мәйданында (татарның гайре рәсми митингҗыелышлар, төрле массакүләм чаралар үткәрү урыны булган) 1920 елда Зариф хәзрәт белән Ф. Әмирхан М. Вахитов һәйкәленә нигез салу тантанасында катнаша, ә 1926 елның мартында биредә әдипнең үз җеназасы укыла.

Инде шактый ишле, «кушма» гаилә, ягъни Фатыйх, Ибраһим, Нәфисә Әмирханнар, Нәфисәнең әнисе Газизә Яушева, Сәгадәтнең кызы Разия, улы Мәхмүд (кайвакыт) яшәп алган биналар хакында кыскача мәгълүмат. 1921—1923 елларда алар «Арыслановлар йорты»нда, икенче исеме «Таш пулат» (Нариман, 90), «Залыйм йорты», ягъни Луи Зальмга нисбәт ителгән бинада (Насыйри, 40), хәзерге З. Солтан һәм К. Насыйри урамнары чатындагы (№ 6/12), аннары Миславский урамындагы (№ 3) йортларда торып алалар, ә 1923 елда Ф. Әмирханның соңгы яшәү урыны булган Л. А. Колодкина йортына (Жуковский, 12/46) күчеп киләләр. Шунысы гыйбрәтле, бу йортта безнең буын вәкиле Искәндәр Гомәр углы Әмирхан гомер сөрде. Әйе, тарих, юк дисәң дә, кабатлана икән ул...

Хәзерге В. И. Качалов исемендәге урыс зур драма театры бинасы да (Бауман, 48) Әмирханнар биографиясенең кечкенә генә булса да бер сәхифәсен тәшкил итә икән. Биредә 1922 елның җәендә Ф. Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» исемле комедиясе премьерасы куелган. Аерым ложага утырып, әдип үзе, Газизә Яушева, Фатыйма һәм Фәүзия Апаковалар яңа әсәрне тамаша кылган.

Черек күл бакчасының да Ф. Әмирхан белән бәйләнеше шактый гына. 1922—1925 елларда җәй көне ул бирегә коляскасы белән чыгып утыра, яшь-җилкенчәк, бигрәк тә кызлар белән уратып алынган килеш рәхәтләнеп шаярта, сүз уйната. Замандашлары сүзләренә таянсак, әдип бакчага нигездә кызлар «күзәтер» өчен чыга торган була. Сафия апа Локманова искә алганча, буйдак Фатыйхыбыз болай дип әйтергә күнегеп киткән: «Матур җанашлар карарга чыгам әле!»

Өлкән буын Әмирханнар белән бәйләнешле биналарның тагын берсе — элекке «Бристоль» номерлары урнашкан йорт (Бауман, 54/10). Биредә фаҗигале 1937 елда Ибраһим белән Нәфисә яшәгәннәр һәм үзләренең кара язмышлары белән шунда очрашканнар.

Билгеле инде, бу зур, борынгы нәсел турында сүз алып барганда ахирәт, Ходай Тәгалә хозурына кайту, әрвахларны искә алу мәсьәләсен дә читләтеп узып булмый. Рухани-шәригати яктан дарелбәка (мәңгелек йорт), дөньяви җәһәттән үзенә күрә бер музеханә яки архив вазифасын үтәгән Яңа Бистә татар зиратында берничә буын Әмирханнарның җаны үзләренә мәңгелек тынычлык тапкан. Биредә дөньялыкта байтак игелекле, саваплы гамәлләр кылган Хөсәен (1893), Биби-

рабига (1918), Мәрьямбану (1919), Мөхәммәдзариф һәм Мөхәммәднәҗип (1921), Фатыйх (1926), Разия Габдулла кызы (1968), Зәйнәп (1977), Разия Борһанетдин кызы (1979), Морат (1981), Госман (1983), Искәндәр Әмирханнар (1996) ата-баба туфрагы, ата-баба рухы дигән төшенчәне җисмани яктан гәүдәләндерәләр. Әмирханнар нәселенең берничә вәкиле башка зиратларда: Бибисәгадәтбану (1911) Бишбалтада (1957 елдан соң каберлек су астында калган), Маһруй (1987) — Олы һәм Кече Дәрвиш авыллары мәзарстанында, Мәлихә (1988) — Самосыровода дәфен кылынган.

Казанның Зәйнәп, Мәхмүд, Гомәр, Госман, Хаува, Рашид, аларның балалары (Сажидә, Синан, Мөхәммәд, Рәшад, Сәлим, Мәлихә, Морат, Искәндәр, Даниял, Флора, Илдус, Расим, Равил, Наил, Сания, Мөнирә, Сафия, Фәрит) яки оныклары белән бәйле урыннары хакында яза башласаң, үзенә бер китап килеп чыгачак. Моның өчен җөмһүрият башкаласының һич югында яртысын «айкап чыгу» таләп ителә. Әмирханнарны төп уку яисә эш урыннарын гына күздә тотканда да, Казан кремле, Фәннәр Академиясе, дәүләт университеты, педагогия, технология университетлары, Авыл хуҗалыгы академиясе, финанс-экономия институты, Татар иҗтимагый үзәге, Милли мәҗлес, Татарстан китап нәшрияты, матбугат йорты, медицина институты һәм училищесы, елга техникумы һәм башка шундый бик күп объектларны, мәктәп-гимназияләрне, фәнни-тикшеренү институтларын яки бюроларын, предприятиеләрне тасвирларга кирәк булачак. Урамнар-йортлар турында инде әйткән дә юк.

Практик яктан бик матавыклы бу эшне мин бу юлга калдырып торам.

## ЙОМГАК

Шулай итеп, без риваятьләрдә һәм рәсми вәсикаларда XVI йөзнең урталарыннан башлап чагылыш тапкан мәшһүр Әмирханнар нәселенең кайбер гамәлләренә, яшәгән вә эшләгән урыннарына үзебезгә мәгълүм күләмдә күзәтү ясап чыктык. Әлбәттә, әлеге токымда һәркайсына аерым кыйсса багышларлык затлы, атаклы шәхесләр бар. Фатыйх Әмирхан — моның ачык мисалы.

Безнең әлеге тыйнак кына хезмәтебезне язудан төп максатыбыз — яшь буын Әмирханнарны үзләренең борынгы нәселе, җисми һәм рухи тамырлары, гасырлар дәвамында милләт, милли мәдәният, дин-иман, кешелеклелек, прогресс хакына кылган игелекле фигыльләре белән кыскача гына булса да таныштыру иде. Бабалары тормышыннан вә язмышыннан моңарчы хәбәрсез диярлек гомер сөргән яшь-җилкенчәк, бәлки, әлеге юлларны укып, үзенә гыйбрәт алыр, ата-бабалары хакында күбрәк белергә теләр, үзенең буш, кысыр җирлектә дөньяга килмәвенә горурлык хисләре кичерер.

Безнең күңелдә тагын шундый өмет чаткысы да пыскый әле. Бәлки, Әмирханнарның миннән соңгы бер токымы яисә вәкиле, шушы кыйссаны укыганның соңында, изге бер тетрәнү кичерер, илһамланыр, нәселе алдында олуг җаваплылык тоеп, без башкарып өлгерә алмаган эшкә яңа сулыш өрер, нәсел тарихыбызның тагын да тирәнрәк катламнарын күтәрер, инде өйрәнелгәннәренең дә биографик-гамәли офыкларын киңәйтер.

Сигез-тугыз ай эчендә, биниһая көч вә һиммәт сарыф итеп, ун табак диярлек күләмдә («Чистайлы Әмирханнар» да күздә тотыла) китап язуыбыз — вакытыбызны кая куярга белмәгәнлек галәмәте түгел. Зиһен якты чакта һәм кулыбыз иҗади фасылда каләм йөртергә сәләтле вакытта татар халкының күренекле бер нәселе булган Әмирханнар хакында белгән мәгълүматларны теркәп калдыру, безнеңчә, бик мөһим. Бу гамәл әлеге фамилиягә нисбәтле токым өчен генә түгел, бәлки алар дәрәҗәсендәге башка мәгърур нәселләргә дә билгеле бер этәргеч бирү максатында эшләнде.

Әгәр халкыбызның өметле каләм ияләре башка токымнарның да хәят-мәгыйшәтен китап калыбына салып бәян итсә, без үз милләтебезнең башка кавемнәр хозурында вә даирәсендә бер дә ким-хур булмавына тагын бер кат инаныр идек. Борынгы бабаларыбыз тарихын тәфтиш кылу, нәсел тамырын бөтен гыйбрәтләре, казанышлары, югалту-фаҗигаләре белән ачып салу — яшь буынны милләтпәрвәрлек рухында тәрбия кылуның иң үтемле һәм чагыштырмача ансат үтәлердәй ысулыдыр. Бу мәгънәви-рухи бурычны безгә һичкайчан да истән чыгармыйсы иде.

*1995*

# МУЛ ҖИМЕШЛЕ ИҖАТ



Күренекле галим, Татарстанның атказанган мәдәният эшлеклесе, Кол Гали исемендәге бүләк иясе Әнвәр Хәйри турында каләм тибрәтә башладың исә, уңып-тешәлеп беткән бәяләмәләр, битараф буяулы гыйбарәләр белән генә котыла алмыйсың. Традицион, «дежур» сүзтезмәләр үзеннән-үзе читкә тибәрелә, бу тынгысыз иҗат кешесенең эшчәнлеге нииндидер башка, күз ияләнеп житмәгән жете төсләр таләп итә башлый. Итми дә хәле юк. Чөнки 70 нче еллар башыннан ук ашкынулы иҗат дәрьясына колач салып кереп киткән Әнвәр әфәнде фәлсәфә, дин тарихы, милләтебезнең йөзек кашына торырдай бөек мәгърифәтчеләре һ. б. хакындагы бихисап тормышчан-актуаль язмалары белән татар җәмәгатьчелегенә генә түгел, бәлки киңрәк даирәдә дә киң танылды.

...Ирексездән хәтергә 1973 елның кышы килеп төшә. Бермәлне безнең Зәйнәп апа Әмирхания белән гомер сөргән фатирыбызга мәһабәт гәүдәле, ачык-мөлаем карашлы, кыяфәтенә голямалык чалымнары иңгән бер егет килеп керде. Ярымбөдрә куе чәчләре, килешле мыегы, үз-үзен әдәпле вә вәкарьле тотышы, мул интонацияле көр тавышы белән шунда ук иске заман зыялыларының соңгы бер «могиканы» булган Зәйнәп апабызны «өнсез» итте. Бер-ике минут та үтмәде, болар арасында шунда ук дустанә гәп куерып китте. Татарстан дәүләт музееның фәнни хезмәткәре булган Әнвәр Хәйруллин Ф. Әмирханның туганнан туган сеңлесе, 80 яшьлек апага киңәш-табыш сорап, аннан кайбер мәшһүр шәхесләр турында белешмә бирүен үтенеп килгән икән. Бу фотосурәттәге кешене тану зарурлыгы килеп чыккач, әңгәмәгә мин дә кушылдым. Беренче мәртәбә очрашуыбыз булса да, сөйләшү ничектер иkenчә, тагын да эшлеклерәк юнәлеш алып китте һәм, баштагы рәсмирәк кысалардан чыгып, милли үткәнебезне өйрәнү, фәннең объектив җирлектә үсеш мәсьәләләре хакында иркен бер фикер алышуга әйләнде. Әнвәр әфәнде алып килгән бер рәсемдә мин, тарихчы-аспирант, заман модасына муафыйк блуза кигән егерме яшьлек Я. М. Свердловны «шәйләп алдым». Әңгәмәбез дәвамында ул моңа шиген белдерсә дә, соңыннан, бер очрашуда минем фаразның расланууын икърар итеп, кулымны кысты:

— Карале, малай, теге кеше чыннан да Свердлов булып чыкты бит әле.

...1983 ел. Май ае. Әбрар ага Кәримуллин, Әнвәр әфәнде һәм мин Уфа каласына командировка белән килеп төштек. Баш-күз алуга, кунакханәгә урнашып «форма»га керүгә ярты тәүлек җитә калды. Аннары инде безне гыйльми стихия, эзләнү шаукымы бөтереп алды. Архив, китапханә, фәнни учакларны айкап йөрибез. Ышаныч акланып бетмәсә көенәбез, табышларга ихлас сөенәбез. Илһам дигән галәмәт безнең ярсу йөрәкләрне жилкетепме-жилкетә. Әбрар ага төпле киңәшләр, юнәлеш бирә, могътәбәр кешеләр белән таныштыра. Ә менә Әнвәр әфәнденең төп максаты — Ризаэддин бине Фәхреддин, гадирәк итеп әйткәндә, Риза казый мирасын өйрәнү икән. Бүгенгедәй истә: олуг галимнең берәр кульязма хезмәтеннән күчермә алган мәлдә юлдашыбызның күзләре уттай яна. «Гали баба һәм кырык карак» әкиятендәге тылсымлы мәгарәгә кергән Касыйм да ул кадәр үк әсәрләнмәгәндер, мөгаен. Тупланган материалы бөтәйгән саен Әнвәр үз-үзенә урын таба алмый, табыш-ачышлар белән бүлешкәндә тынына кадәр кысыла. Аның бу халәтен 30 тиенлек лотерея билетына «Волга» машинасы

откан кешенең куанычына гына тиңләргә мөмкиндер. Хикмәти хода, мин дә шул көннәрдә, үзем өчен Риза казыйны яңадан ачкандай булдым. Һәрхәлдә, нигездә Әнвәр Хәйри тәэсирендә миңа да тиз арада «Фәхретдин жене» кагылды. Корбанын ычкындыра торган җен булмады бу «хәерсез», чөнки үземә дә Риза казый иҗатын һәм мирасын пропагандалап, ике китап, берничә дистә мәкалә бастырырга туры килде.

...80 нче еллар уртасы. Кинәт фәнни эшем өчен үтә зарур бер кульязма вәсикага — гарәпчә язулы нәсел шәҗәрәсенә юлыгам. Уңып, таушалып, кайбер урыннары танымаслык булып кыршылган кәгазьне бик җентекләп, лупа ярдәмендә өйрәнсәм дә, боргалап-сыргалап язылган аерым исемнәрне танып бетермим, дөрес укуыма шикләнәм. Текстны иске язуны белгән, кульязмалар белән эш иткән байтак галимнәргә күрсәтәм, ләкин миннән артыгын алар да майтаралмый. Ахыр чиктә юлым Әнвәр хозурына төшә. Һәм ни диярсез? Ул «эһ» тә дими, лупасыз-нисез, бер күз ташлау белән миңа кирәк шәхесләрне чатнатып укып бирә: рәхим ит, монысы Габделмөэмин, ә тегеләре Габделмөнәҗип белән Габделмөһимән!

Җае туры килгәндә шуны да әйтик инде: хәтта иң әкәмәт рәвештә сырлап язылган борынгы вәсикаларны да Әнвәр Хәйри кебек оста, йөгерек укуны миңа үз гомеремдә бик сирәк очратырга туры килде. Мондый маһир белгечләрне барлап чыгу өчен бер кулның бармаклары да җитәдер, мөгаен. Һәрхәлдә, мин шуннан артыгын белмим.

Әнвәр Нәҗип угылы Хәйруллин 1947 елның 7 ноябрендә Татарстанның элекке Тельман, хәзерге Аксубай районына кергән Шәрбән авылында гаиләдә сигезенче бала булып дөньяга килә.

Әтисе Нәҗибулла абзый белән әнисе Гыйльмиҗиһан апа гади колхозчылардан хисаплансалар да, бик укымышлы кешеләр булып, гарәп имлясын да, яңалифне дә, кириллицаны да бик яхшы беләләр. Шушы белемнәрен бер дә заяга җибәрмичә, алар буш вакытларында балаларын җыеп, баштарак чыра, соңрак җиделе-унлы лампа яктысында аларга кич буе төрле-төрле китаплар укыйлар. Китап эзләп әллә кая йөрисе булмый, чөнки өй китапханәсе шактый бай була. Әнә шулай итеп, балаларда кечкенәдән үк китапка, гомумән, иҗат җимешенә мәхәббәт тәрбияләнә.

Әнвәр авыл мәктәбенең сигез сыйныфын тәмамлаганчы гел «бишле»гә генә укый һәм уңышлары өчен чирек саен бүләкләнеп килә. Малайның хәтере хәйран калырлык була, чөнки сабакны дикъкать белән тыңлап утырып, ул икенче дәрестә укытучының үз сүзләре белән үк җавап бирә. Нәҗибулланың төпчек улы шул кадәр йотлыгып укый ки, дүртенче сыйныфта вакытында ук инде мәктәп һәм авыл китапханәләрендәге барлык китапларны «сөреп» чыга. Бу казанышлары белән генә чикләнмичә, Әнвәр үзлегеннән латинча укырга өйрәнә һәм яңалиф белән басылган өйдәге китапларны да «су урынына» эчеп бетерә. Шуннан соң ялынып-ялварып, әтисеннән гарәп алфавитын яздырып ала. Тора-бара хәрефләрне, аннары гадирәк сүзләрне үзләштереп, уку-язу күнекмәләре ала башлый. Әмма шул шөгыленә мөкиббән китеп йөргәндә, белемгә, һәр яңалыкны калебенә сеңдерергә омтылучы баланың башына һич көтмәгәндә «ярамый» күсәге килеп төшә. Әнвәр бишенче сыйныфта укый башлаганда, мәктәпнең озын коридорына бөтен балаларны тезеп бастырып, иртәнге линейкада малайларның кесәләрен актарып, рогатка, карандаш очлый торган кечкенә пәке ише «хәтәр» коралларны «конфискацияләү» гадәткә керә. Шундый бер тентү вакытында Әнвәрнең кесәсеннән берничәгә бөкләнгән гарәп алифбасы һәм малай үзе укырга-язарга өйрәнгән бер-ике дәфтәр бите килеп чыга. Шушы кот очарлык «гөнаһлары» өчен мәктәп завучы яшүсмер малайны бөтен мәктәп күз алдында һуштан яздырганчы кыйный. Моның белән генә дә чикләнмичә, бөтен балаларга «җинаятьче» белән аралашмаска боера, дивар газитләрендә, «яшен»нәрдә аннан көлгән язмалар, карикатуралар урнаштырырга әмер бирә, ә әтисен педсоветка чакыртып, улын мулла итеп үстерүе өчен авылдан сөрергә дә күп сорамаячакларын белдереп, зәһәр чәчә. Шушы «тәрбия»дән соң Әнвәребез, гарәпчә язулы китапны уку түгел, аңа орынырга да курка һәм тора-бара бу шөгылен бөтенләй истән чыгара...

Көннәрдән бер көнне Әнвәрнең тормышында зур борылыш булып ала. Шулай бер көнне, дөресрәге, төн уртасында, колхоз эшеннән кайтып керсә, баскыч өстендә ап-ак эчке киемнән әтисенең тәмәке пыскытып утырганын күрә. Бу гайре табигый күренештән «мужиг»ыбыз сискәнеп-тетрәнеп китә, «нәрсә булды икән», дип күңеленә шом йөгерә. Ләкин каравыллап утыруның үз хикмәте бар икән. Йомшак кына эндәшеп, Нәҗибулла абзый аны үз янына утырта, тормышның ифрат катлаулы булуын, анда үз урыныңны табып яшәргә, ә моның

өчен укырга, төпле белем алырга кирәклеген төшендерә. Ахыр чиктә иптәшләре белән бергә Мораса мәктәбенә укырга китәргә үгетли. Мондый «басым»ны, «ирексезләү»не көтмәгән һәм өнәмәгән малай, кисәк киреләнә, «укымыйм мин», дип кырт кисә. Ләкин дөнья күргән әти кешенең бер бик үтемле дәлиле, хәтта ки аяктан екмалы «соңгы» чарасы бар икән. Ул шуны эшкә җигеп, басынкы тавыш белән болай дип белдерә: «Улым, иптәшләрең укып кеше булыр, ә син шулай калырсыңмы? Башың бар, сәләтең зур, әгәр алар белән укырга китәр булсаң, бер сарыкны сатып булса да, үзең күптән кызыгып йөргән зур велосипед алып бирәм». Мондый ук зур мөкяфәтне көтмәгән Әнвәр бер мәлгә югалып кала һәм, артык озак баш ватып тормыйча, ризалыгын бирә.

Иртәгесен, кем әйтмешли, намаздан ук торып, утыз чакрымны җәяүләп, Әнвәр Мораса авылына укырга элдертә. Бер атнадан соң туган Шәрбәненә кайтса, ни күрсен, әтисе аңа чыннан да өр-яңа велосипед алып куйган икән. Булачак галимебез, шулай итеп, велосипедка «алданып», укырга кереп китә һәм шуннан соң инде бу шөгыльгә беркайчан да хыянәт итми. Шулай итеп, 1966 елда Әнвәр Хәйруллин Колбай Мораса урта мәктәбен уңышлы тәмамлый һәм инде, берниндн велосипедларга да «алданмыйча», үз иреге вә теләге белән Казанга, укуын дәвам итү өчен юл тота.

Зур өметләр баглап, Казан дәүләт университетына керергә дип килсә, ни күрсен, имтиханнар инде тәмамланган, студентлар кабул ителеп беткән. Соңга калып килгән икән, Шәрбән егетен көтеп тормаганнар, хәерсезләр. «Инде нишләргә?» — дип университет алдында иңсәсен кашып торганда, көтмәгәндә каршысына бер авылдашы һәм сабакташы килеп туктый. Исәнләшеп, хәл-әхвәлне сораштыргач авылдашы, Әнвәрне ияртеп, Казан театр училищесына алып китә. Документларны тапшыруның икенче көнендә үк имтиханнар башлана. Күрәсең, белеме дә, «әртислек» хосусиятләре дә җитәрлек булгандыр, егет Театр училищесы студенты булып китә. Кем белә, бәлки киләчәктә якташы Кариев төсле татарның мәшһүр артисты да булып киткән булыр иде, тик Әнвәр бу уку йортының нәрсәсендер өнәп бетерми. Бередә бер ел изаланганнан соң, имтиханнар тапшырып, университетның тарих-филология факультетына, татар теле һәм әдәбияты бүлегенә «иңә».

Әйтергә кирәк ки, Әнвәрнең остазы Лена Кәлимулла кызы Таҗиева һәрдаим дөрес юнәлеш биреп, ярдәм итеп тора, үзенең шәкертендә фәннең үтә авыр вә четерекле тармагы булган гарәп телендәге чыганаклар белән эшкә олы мәхәббәт, шул ук вакытта тәвәккәллек тәрбияли. Моның өчен Әнвәр Хәйри үзенең укытучысына чиксез рәхмәтле. Борынгы кульъязма чыганаклар белән эшләү тәҗрибәсен өйрәткән, аларның бар нечкәлекләрен һәм үзенчәлекләрен бәян кылган икенче остазы — Мостафа Ногманга карата да Әнвәр әфәнде шундый ук рәхмәт хисләре саклый. Асылда нәкъ менә Мостафа ага ярдәме вә йогынтысы белән сәләтле студент борынгы кульъязма чыганакларга олуг ихтирам белән карарга, аларның яшерен серенә төшенергә өйрәнә...

Ниһаять, Әнвәрне 1974 елның маенда СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына, яңа оешып килүче иҗтимагый фикер тарихы бүлегенә эшкә чакыралар. Аңа биредә, борынгы чыганаклар белгече һәм гарәп телен дә белүче буларак, «Г. Курсави һәм Ш. Мәрҗани әсәрләрендә рационалистик фәлсәфә» исемле фәнни тема йөкләнә. Әлеге теманы уңышлы төстә төгәлләгәннән соң, Әнвәр Хәйри Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») исемле ике томлык тарихи хезмәтен тулысынча тәрҗемә итә. Төрле каршы җилләрнең исүе, җаваплы урыннарда утырган түрәләрнең чикләнгән мәсьүлияте аркасында мәшһүр хезмәтне тулаем нәшер итеп булмый, әмма галим аның бер томлык иң мөһим өлешен 1989 елда Татарстан китап нәшриятында бастыруга ирешә.

Институтта эшләгән елларында Әнвәр әфәнде шулай ук бөек мәгърифәтче, дин эшлеклесе, фикер иясе Ризаэддин бине Фәхреддиннең иҗатын тәфсилләп өйрәнә, аның Уфада, Башкортостан Фәннәр Академиясе архивында саклanучы кырык томлык кульъязмалар фондын битен-биткә өйрәнеп чыга. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1993 елда Р. Фәхреддиннең «Болгар вә Казан төрекләре» исемле бер томлык әсәрләр җыентыгы дөнья күрә. Әнвәр Хәйри тырышлыгы вә һиммәте белән төзелгән бу китап, халкыбыз тарихының гүзәл бер ядкаре сыйфатында галим-голямада гына түгел, гади укучылар арасында да абруй казанды. Ошбу хезмәтнең әһәмияте хакында үзебезгә дә «Гыйлем диңгезеннән бер тамчы» исеме белән күләмле рецензияләр бастырырга туры килде («Татарстан хәбәрләре», «Мирас»).

Болардан тыш, галим бөек мәгърифәтчебез Каюм Насыйриның «Фәвакиһелҗөләса фил әдәбият» («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше») исемле энциклопедик хезмәтен тәрҗемә кыла һәм басмага әзерли. Кызганыч ки, төрле сәбәпләр аркасында, монысын нәшер итә алмый. Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләгән чорда Әнвәр әфәнде чын галим булып җитешә: бертуктаусыз эзләнә, китапханәләрдә, архивларда басылып эшли, күп санлы экспедицияләрдә катнаша, фән өчен гаять кыйммәтле булган бихисап мәгълүматлар туплый, кайчагында исә чын мәгънәсендәге ачышлар ясый. Аерым алганда, ул Мәскәү, Ленинград (ул вакытта), Ташкент, Бохара, Оренбург, Уфа, Казан һәм башка шәһәрләрнең архивларында, китапханәләрендә бинһая кыйммәтле табылдыкларга юлыга һәм алар турында матбугатта даими төстә информация биреп бара, фәнни мәкаләләр бастыра.

Алар арасында Ш. Мәрҗани һәм Р. Фәхреддиннең алда телгә алынган капиталь хезмәтләреннән тыш, Г. Курсавиның аерым фәлсәфи язмалары, Р. Фәхреддиннең «Ислам дине — нинди дин?» («Мирас», 1991—1993), «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр» («Мирас», 1993—1995), «Тәрбияле бала» («Сабыйга», 1996—1997), «Әһле гыяль, ягъни өй җәмәгате» («Ялкын», 1997) кебек материаллар, З. Камалиның «Фәлсәфи игътикадия»се «Инану фәлсәфәсе»), М. Бигиевнең «Кавагыйде фикъһия»се («Мөселман хокукы кагыйдәләре») Г. Ибраһимовның «Борынгы ислам мәдәнияте», Р. Гайнеддин төзегән «Намаз» китабы, Й. әл-Кардавиның «Хәләл һәм хәрам»ы, табиб Низамеддинның, Габделвахид мөфти ибне Сөләйманның, Мөсәгыйдь бине Мостафа әл — Йортышиның, Мөхәммәд-Хәсән бине Хөсәеннең — һәрберсенең аерым-аерым «тыйбб китап»лары, шулай ук «Иман шартлары», «Коръәни Кәрим» һ. б. күп тармакларга караган әһәмиятле хезмәтләр бар.

Чыннан да, Әнвәрнең хезмәтләре киң мәгълүматлы булулары, фәлсәфи нигездә корылганлыклары белән аерылып тора, аларда халыкның гаҗәп гыйбрәтле, бер үк вакытта шанлы да, фаҗигале дә үткәне тасвирлана. Бу җәһәттән Аксубай ягы егете, татар халкының иң күркәм йолалары үрнәгендә, хәзерге җәмгыятьтә милләтебезнең дини-әхлакый яңарышы өчен зарур булган шәхес тәрбияләү мәсьәләсенә дә аерым игътибар бирә. Аның әлеге мөһим проблемага багышланган фәнни, тарихи, әхлакый, дини шәкелдәге чыгышлары матбугатта чагылыш таба, даими агарту формасы буларак, радио һәм телевидениедән яңгырый. Мәсәлән, Әнвәр әфәндене шәрекъ телләрендә язылган борынгы кульязма чыганаклардан иҗади файдаланып укылган лекцияләре төрле катлам зыялыларында һәм тыңлаучыларында җанлы кызыксыну уята.

Татарстанда Әнвәр Хәйри оста журналист буларак та мәгълүм. Аерым алганда ул «Мирас» журналын оештыручыларның һәм нигез салучыларның берсе. Киң диапазонлы публицист, Әнвәр әфәнде, кирәк матбугатта, кирәк радиода булсын, берсеннән-берсе тормышчан, мөһим мәсьәләләр буенча чыгышлар ясый. Мондый игелекле эшчәнлек, әлбәттә, бәяләнмичә калмый. Озак еллар буена рухи һәм матди мирасыбызны халыкка кайтарып бирүдәге вә аларны армый-талмый алга сөрүдәге казанышлары өчен мәкаләбез каһарманы янә зур мәртәбәгә ирешә — 1994 елда Кол Гали исемендәге Халыкара бүләккә лаек булды.

Инде Әнвәр әфәнденең үсеш баскычларын билгеләгән аерым хезмәтләренә тәфсиллерәк тукталу ихтыяҗы бар. Кем белә, бәлки, аның шушы «эш графигы» гыйлем дөньясында тәүге адымнарын ясаган яшьләргә матур өлге булыр. Кыйссабыз каһарманының беренче гыйльми хезмәте ерак 1967 елга, фәнни түгәрәккә йөргән чорга ук карый. Ә менә җитди фәнни хезмәте 1972 елда, университетның бишенче курсында читтән торып укыганда башкарыла. Сүз борынгы ядкяр, Казан шәһәренең К. Насыйри урамындагы бер йорт дивары эченнән табылган җиз кувшиндагы борынгы төрки вә фарсы телләрендәге язучыларның тел-стиль үзенчәлекләрен тәфтиш кылу хакында бара. XV гасырда эшләнгән әлеге савыт, Әнвәр әфәндене ачыклавынча, Казан ханы Мөхәммәд Әминнән (1518 елда вафат) гаскәр башлыгы Күбиккә бүләк ителгән булган икән. Үзлегеннән экспертиза дәрәҗәсендә тикшерү үткәргән студентның казанышы күп кенә белгечләрнең игътибарын җәлеп итә. Итәрлек тә шул: яшь кенә егет үзенә кадәр бу язуны укырга тырышып та, аның серенә төшенеп җитә алмаган күренекле галимнәр — тел белгече, профессор М. Фазлуллин һәм борынгы кульязмалар белгече З. Максудоваларның укылышта вә тәрҗемәдә җибәргән төгәлсезлекләрен, хәтта

ки, зур ялгышларын күрсәтә! Әнвәрнең әлеге эксперименталь-гыйльми хезмәте студентларның университетта үткәрелгән фәнни эшләре конкурсында беренче урынны ала һәм бөтенсоюз конкурсына тәкъдим ителә.

Шушы фасылдагы тикшеренүләр алга таба да Әнвәр Хәйри эшчәнлегенең аерылгысыз өлешен тәшкил итә. Әйтик, янә бер бакыр савытның эчке вә тышкы якларына уелган язуларның серенә төшеп, профессиональ бәя бирү була. XVIII гасыр ядкяре булган әлеге савытның аскы өлешендәге (һәм андагы түгәрәкләр эчендәге) язулар фал ачар өчен, ягъни кешенең язмышын алдан белер өчен кулланылса, өске өлешендә тоташ чокылганнары — Коръәни Кәримнең Ясин сүрәсен хасил итә. Соңгысы — халык медицинасында эчке авырулардан арыну өчен кулланылган икән.

Шуңадыр да инде, Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләгәндә, гарәп язулы берәр табылдык юнәтсәләр, бар галим-голяма, аспиранттан башлап фән докторына кадәр, Әнвәр әфәндегә булышлык сорап килә иде. Һәрвакыт ярдәмчел, беркемне дә кире борып чыгармый торган егетнең бу эчкерсезлегеннән үз максатларында гына файдаланучылар да аз булмады: Әнвәр укып тәрҗемә иткән текстны үзләренеке итеп, аның исемен дә телгә алмыйча басып чыгаруда бу бигрәк тә ачык чагылды. Ләкин галим, боларның һәммәсен белә торып та, ярдәм вә киңәш сорап килүчеләргә аркан борылмады, аның үз һөнәренә бирелгәнлек, профессиональ омтылыш вә кызыксыну кебек сыйфатлары, барысыннан да өстен чыга килде. Гыйльми мөхит кешеләренең Әнвәрне «самородок», «аяклы энциклопедия», дип атаганнары хәтеремдә.

Болар купшы сүзләр генә түгел. Чөнки, минем гөманымча, галим башка гамәлләрен кылмаган, фәкать бер Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар»ын гына бүгенге укучы аңларлык телдә тәрҗемә кылып нәшер иткән тәкъдирдә дә — татар гына түгел, дөнья фәне тарихында да үзенең лаеклы урынын алган булыр иде. Ник дигәндә, галим әзерләп чыгарган бу китап дөньяның күп кенә мәмләкәтләренә таралды, аңа, татар халкы тарихын бозуларсыз, объектив чагылдырган хезмәт буларак, чит ил галимнәре дә киң таяна. Әнвәр әфәнде үзе язган классик тарихчылардан тәрҗемә кылган хезмәтләрнең һәммәсенең дә диярлек язмышлары шундый. Аның әсәрләрен җиһанның күп кыйтгаларында, мәмләкәтләрендә беләләр, авторын эзләп, хезмәтләре өчен рәхмәт әйтеп, төрле илләрдән шалтыраталар, хатлар язалар. Казанга юллары төшсә, күреп китәргә тырышалар икән. Әйе, аның һәр җитди хезмәте диярлек (башка жанрларга кагылып тормыйбыз) кыйммәтле вә күп гасырлык мирасыбыз җәүһәрләрен халыкка кайтарып бирүгә юнәлгән. Болар исәбенә «Җиз савытка язылган борынгы язу» («Мирас», 1994, № 11—12); «Кизләү авылы ядкяре» («Мирас», 1995, № 1—2), «Борынгы болгар чоры рухи мәдәнияте» (1994, № 5—6), шул ук журналда басылган Уфадагы Үзәк Диния нәзараты тарихына багышланган язмалар тезмәсе, «Мирас»ның әүвәлге санынннан башлап, журналдан киткәнчегә, ягъни 1995 елның уртасына кадәр һәр номерында урын алган «Халык медицинасы», «Татар халкының килеп чыгышы», «Авыллар тарихы», «Фәлсәфи мирасыбыз», «Рухи мәдәниятебез», «Дин вә әхлак» һ. б. бүлек-рубрикалардагы саллы хезмәтләр керә.

Әнвәр әфәнде тарафыннан тәрҗемә ителеп, матбугатта яңгыраш тапкан хезмәтләр кирәк фәнни, кирәк тарихи, яки кирәк дини эчтәлектәге, кирәк Коръәни Кәрим булсын, үзләренең мөкәммәллеге белән белгеч-галимнәр вә дин әһелләре тарафыннан, кагыйдә буларак, югары бәяләнеп килде.

Бу җәһәттән беренче чиратта Әнвәрнең «Әкияти ак чимал» исемле зур күләмле язмасы искә төшә («Мәдәни җомга», 1996, гыйнвар). Мәкалә, беренче карашка, төзү максатларында гына кулланыла торган чимал — гипска багышланган төссез генә язма булырга тиеш иде кебек. Әмма автор бу очракта да, үз-үзенә тугры калып, бөтен бер фәнни тикшеренү үткәрә, чималның барлыкка килү тарихыннан башлап бүгенгәчә булган кулланыш даирәсен күрсәтә, берочтан Болгар вә Казан ханлыгы чорларына тукталып, Кол Гали һәм Мөхәммәдъяр әсәрләреннән моңа бәйле өзекләр китерә. Мәкаләнең матур тел, мавыктыргыч итеп язылуына сокланып, шагыйрә Гөлшат Зәйнәшева авторга хәтта болай дип әйтеп куйган: «Әй, Әнвәр, рәхмәт яусын үзеңә бу язмаң өчен, сокланып та, гаҗәпләнеп тә укыдым. Моңарчы мин ул гипсны сынган әйберләрне турайтып, катырып куя торган әйбер дип кенә белә идем. Гипс турында да шулай күркәм итеп язып була икән, каләмең искиткеч матур, гипстан тәмам кәнфит ясагансың бит!..»

Байтак дин әһелләре, мөхтәрәм хәзрәтләр, галим эшчәнлегенең күркәм якларын күз уңында тотып, аңа мондый мактау сүзләре әйтәләр, рәхмәтләр укыйлар икән: «Әнвәр әфәнде, язган хезмәтләрең, сөйләгән сүзләрең безнең өчен

үрнәк, син бит без эшләргә тиешле булып та, без башкара алмаган фигыльләрне кыласың, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтендә бул!..»

«Нур өстенә — нур» дигәндәй, 1996 елда кыйссабыз каһарманының тагын бер күркәм хезмәте — «Ислам дине бәйрәмнәре» исемле китабы дөнья күрде. Беркем өчен дә сер түгел, соңгы елларда, халык дингә, иманга йөз белән борылгач, дини әдәбиятка ихтыяҗ бермә-бер артты, шул нигездә бихисап китаплар басыла башлады. Фәкать алар арасында, шактый күп җибәрелгән фактик хаталар өстенә, дини бәйрәмнәребезне тасвирлап, аларның асылын тарихи шәкемдә аңлатып язган хезмәтләр юк иде, дияргә була. Менә шушы бушлыкны тутыру юлында да Әнвәр әфәнде зур эш башкарды, бәйрәмнәр темасын билгеле бер калыпка салды, җирле, милли хосусиятләренә аеруча зур игътибар бирде. Китапның тышлыгы да, эчке ягы да, эчтәлегенә муафыйк рәвештә нечкә зәвыклы рәсемнәр һәм бизәкләр белән нәкышланган. Сыйфатлы кәгазьдә басылган әлеге затлы китап мөселманнарга да, дин әһелләренә дә бүләк булды, галимнәрне дә яңа мәгълүматлар белән баетты. Шуңадыр да инде, автор бу игелекле гамәле өчен төрле тарафтан рәхмәт сүзләре ишетә.

Әнвәр Хәйри иҗатының тагын бер казанышы турында да әйтми китеп булмый. 1997 елның башында, Ризаэддин бине Фәхреддиннең Әнвәр әфәнде тарафыннан 1993 елда нәшер ителгән «Болгар вә Казан төрекләре» исемле бер томлык китабы, латин хәрефләрендә басылып, яңадан дөнья күрде. Бу саваплы эшне Төркиядәге «Әхмәд Мәңгәри вакыфы»ның Казандагы Фәнни киңәшчеләре башкарды. Әсәр хәйрия максатларында басылды һәм аны төрки халыклар яшәгән мәмләкәтләрдә вә ерактагы татар диаспорасы учакларына тарату күздә тотыла. Шунысына игътибар итик, «китапның бу басмасы 1992 елда Төркия мәмләкәтенең Анталия шәһәрендә халыкара тюркология конференциясендә кабул ителгән уртак латин алфавитында бастырылды. Болай эшләү — бер яктан, китапны чит илләрдәге милләттәшләребез дә иркен укый алуга хезмәт итсә, икенче тарафтан Татарстандагы һәм Русиядәге татарларны да уртак латин әлифбасы белән якыннан таныштыруга ярдәм итәчәк», диелә аның албитендә.

Вакыфның әлеге әсәрне бастырырга алынуы, очраклы хәл түгел, билгеле. Китап белән бик нык кызыксыналар, аның 1993 елгы басмасы да илебездә генә түгел, дөньяның күп мәмләкәтләрендә дә таралды. Күренә ки, әлеге китапта Р. Фәхреддиннең берничә хезмәтен туплап, тәрҗемә итеп, кереш мәкалә язып дөньяга чыгарган Әнвәр Хәйри хәзерге вакытта халыкның тарихи белемен тирәнәйтү, үзаңын үстерү юлында нинди әсәрләргә мохтаҗлык барын яхшы белеп эш итә.

Галим турында боларга өстәп янә бик күп язарга мөмкин булыр иде. Ләкин, сүзебез артык озынга китмәсен өчен, Әнвәр Хәйринең күп санлы иҗади казанышларыннан тагын берсенә генә кагылып китәбез. Эш шунда ки, киңкырлы иҗат кешесе — галимебез үзенең көчен Коръәни Кәримне тәрҗемә итү кебек гаять кыен, җаваплы вә күп һиммәт сорый торган эштә дә сынап карады. Һәм, әйтергә кирәк, бу фронтта да «махы бирмәде». 1990—1991 елларда «Казан утлары» журналында илле җиде сүрәне берьюлы гарәпчә язылышта, шулай ук кириллицадагы фәнни транскрипциядә, аннары аңлатмалар белән тәрҗемәдә әзерләп бастырды. Бу гамәл — һәр теләгән кеше Кәлямулланы үзлегеннән укырга, аңларга вә файдаланырга өйрәнсен өчен кылынды. Хезмәт мөэмин-мөселманнар тарафыннан бик җылы кабул ителде, дин әһеләре матбугатта аның турында уңай фикерләр әйтте. Халык әле дә булса Коръән Кәримнең Әнвәр әфәнде тәрҗемә кылган сүрәләрен сорый һәм эзли икән. Алай гына да түгел, бу тәрҗемә белән Кытайда, Төркиядә, Америкада, Румыниядә һ. б. илләрдә гомер сөрүче милләттәшләребез генә түгел, Лондонда яшәүче мөселманнар җәмгыяте дә кызыксынды. Җәмгыятьнең бер вәкиле 1991 елда Казанга килеп, Әнвәр Хәйригә мөрәҗәгать итте, әгәр дә галим шушы башлаган эшен Англия мәркәзенә барып тизрәк тәгалләсә, аңа моның өчен барлык тиешле шартлар тудырылачагын һәм соңыннан, хезмәтнең нәшер ителеп, бөтен дөньяга таратылачагын вәгъдә кылды... Ләкин кая ул!.. Әнвәргә бу сәфәр хакында авыз да ачтырмадылар. Хәерле булсын, исән-сау булса, галим, иншаэ Аллаһ үзенең изге гамәленә үзебездә дә нокта куярга җай табар әле...

**Р. ГОСМАНИ.**

**Әлфинә Сибгатуллина**


# ТӨРКИЯДӘ—БЕЗНЕҢ ТУРЫДА

Совет империясе таркалу һәм коммунизм шәүләсе юкка чыгу белән төрки милләтләрнең үзара якынаюы, берләшүе өчен комачау булган шартлар да бетә башлады. Элекке Советлар Берлегендә яшәгән төрки халыкларның бер-берләре белән бәйләнышлары артуы хәзергә әллә ни сизелмәсә дә (чөнки әлегә һәркайсының үз хәле хәл), һәр төрки җөмһүриятнең бәйсез Төркия белән күп кенә өлкәләрдә рәсми аңлашмалар төзүе, үз чикләрен төрекләр өчен ачуы—билгеле хәл. Әйтергә кирәк, бу якынаюлар өчен беренче адымны ясаучы, дуслык-туганлык элемтәләрен ныгытырга омтылучы булып Төркия Җөмһүрияте тора. Ничәмә-ничә еллар буе безнең советлар читлегендә интекkәнне читтән карап торырга, безнең хакта бары Аурупада чыккан китап-журналлардан гына укып белергә мәҗбүр булган Төркия хәзер, шөкер, тормышыбызның һәр тарафы белән якыннан таныша ала һәм күпмедер күләмдә безнең хәлебезне җиңеләйтергә омтыла. Бүгенге көндә без төрек кешесен үз мәмләкәтебезнең шәһәрендә түгел, авылында күреп тә гаҗәпләнмәгән кебек, безгә дә Төркиягә барып кайту, башка төрки җөмһүриятләргә барып кайтудан күпкә ансат һәм мәшәкатьсезрәк тоела.

Төркия белән үзара танышу-дуслашуның беренче чоры инде узды: рәсми һәм рәсми булмаган делегацияләр еш оештырылды, галимнәр, артистлар, эшмәкәрләр, укучылар, укытучылар бер-берләре белән танышып, хезмәттәшлек итә башладылар, алла кушып, бу хезмәттәшлек тагын да киңәйсен, көчәйсен. Үзара якынаюның икенче чоры исә берләшү-туганлашуның милли культура, тел-әдәбият, мәгърифәт, әхлак, дин кебек рухи, иҗтимагый, идеологик даирәләргә җәелеп, тагын да тирәнәюен күз алдында тота. Төрекләр—безнең иман кардәшләребез дә бит. Шунлыктан элекке Советлар Берлегеннән таралып чыккан төрки халыкларның дини хәяте һәм киләчәге дә алар игътибарыннан читтә кала алмый. Алласызлык ялганыннан туйган, әмма дини тәрбиядән дә мәхрүм калган урта һәм яшь буынның аңын аулап-яулап алу өчен соңгы елларда безнең якларга нинди генә дин һәм секта әһелләре килмәде! Бу очракта ялгышлардан, милли афәттән котылып калуның иң дөрес юлы—халыкның үз тарихына, борынгы гореф-гадәтләренә һәм инанычларына таба борылуы булды. Татар халкы үзенең элек-электән динле, иманлы булуын, башка халыкларга да ислам нурын таратуын онытмады, бөтен мөселман дөньясында танылган Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин, Габдерәшит Ибраһимов, Муса Бигиев кебек зур дин галимнәре барлыгын исенә төшерде.

Татар яшьләрен төрле дини йогынтылардан саклап калу эшендә татар зыялыларына һәм руханиларына ярдәмгә төрек кардәшләребез килде. Аларның ярдәме практик өлкәдә дә (мәктәп, мәчет, мәдрәсәләр ачуда, аларны китапдәреслек, укытучылар белән тәэмин итүдә, безнең шәкертләрне Төркиягә җибәреп укытуда һ. б.), теоретик өлкәдә дә сизелерлек. Халык аңыннан җуела барган әлеге галимнәребезнең исемнәрен, хезмәтләрен кире кайтаруга да нәкъ менә төрекләр булышлык итә дисәм, бер дә ялгыш булмас. Мисал өчен, Габдерәшит Ибраһимов һәм Муса Бигиев турында бездә бары-югы берничә мәкалә генә басылып чыккан вакытта, төрек галимнәре алар хакында саллы гыйльми хезмәтләр нәшер иттеләр. Бу урында әлеге хезмәтләргә тукталып китүне үзебезнең бурычыбыз саныйбыз.

Габдерәшит Ибраһимов (1850—1944) — озын һәм бәрәкәтле гомерен ислам динен тарату эшенә багышлаган кыю каһарман. Патша Россиясендә яшәгән барлык мөселманнарны берләштерү идеясе белән янып, мәктәпләр ачкан, газета һәм китаплар нәшер иткән, казыйлыктан сәяси гамәлләргә кадәр күп төрле өлкәләрдә хезмәт күрсәткән гайрәт иясе ул. Габдерәшит Ибраһимовның гаять әһәмиятле эшләреннән берсе — аның 1907—1910 еллар арасында Русиядән башлап, Урта Азия, Монголия, Кытай, Япония, Корея, Индонезия, Һиндстан, Хиҗаз илләренә ясаган сәяхәте. Азияне башыннан азагына кадәр йөреп чыгып, андагы мөселманнарның проблемаларын тулысы белән төшенеп, аларны чишәргә хыялланган Габдерәшит Ибраһимов әлеге сәяхәтендәге күргәннәрен, кичергәннәрен «Галәм-и ислам» исемле китабында яза. Соңгы дәвер госманлы шагыйрьләреннән иң күренеклесе Мәхмәт Акиф Әрсой (1873—1936) бу китап турында: «Мин күптәннән бирле бу кадәр самими, бу кадәр тәэсирле китап укыганымны хәтерләмим»,— дип яза. Мәхмәт Акиф гомумән, Габдерәшит Ибраһимовның эшчәнлегенә бик югары бәя бирә, үзенең атаклы «Сафахат» әсәренең икенче бүлегендә ислам дөньясының хәлен аның авызыннан сөйләтә. Шулай итеп, татар галименең-руханиенең образы төрек әдәбиятында мәңгеләштерелә.




Габдерәшит Ибраһимовның әлеге сәяхәтнамәсе бүген дә мөселман дөньясында кызыксыну уята, чөнки ул күтәреп чыккан проблемаларның бик күбесе бүген дә көн кадагында. Шунлыктан Мәхмәт Паксу исемле төрек галиме гарәп әлифбасында госманлы төрекчәсендә язылган «Галәм-и ислам» китабын бүгенге төрек теленә һәм хәрефләренә күчереп, бераз гадиләштереп, 1937 елда Истанбулда бастырып чыгарды. Хезмәт ике томнан тора. Беренчесе «Егерменче гасырның башларында ислам дөньясы һәм Японияда исламият (Төркестан, Сибирия, Монголистан, Манчжурия һәм Японияда мөселманнар)» дип атала. Бу томда сәяхәтнамә текстыннан тыш, Мәхмәт Паксуның кереш сүзе, Габдерәшит Ибраһимовның тулы биографиясе, шагыйрь Мәхмәт Акиф Әрсойның «Гаять мөһим бер әсәр» исемле мәкаләсе, аның «Сафахат» әсәреннән өзекләр, фоторәсемнәр урнаштырылган. Икенче томда Габдерәшит Ибраһимовның Кытай, Һиндстан, Корея, Сингапур, Хиҗаз язмалары бирелгән. Китап соңында кызы Фәүзия ханымның 1949 елда язылган «Габдерәшит Ибраһимовның соңгы еллары» исемле мәкаләсе һәм Сеулдан тарихчы Җәмил Линең «Көнчыгыш Азиядә исламның үткәне, бүгенгесе, киләчәге» исемле хәбәре урын алу да китапның кыйммәтен икеләтә арттыра. Әлеге хезмәтне тиз арада татар теленә тәрҗемә итәргә кирәклеге бәхәссез. Чөнки анда Габдерәшит Ибраһимовның моңа кадәр безгә билгеле булмаган тәрҗемәи хәле дә, миссионерлык эшчәнлеге дә, фикер дөньясы да тулы ачыла, шуның өстенә татар тарихы, мөселман дөньясы, гомумән, кешелек дөньясы, культурасы турында искиткеч кызыклы мәгълүматлар бирелә.

Икенче бер күренекле ислам белгечебез Муса Ярулла Бигиев (1875—1949) хакында язылган китап та гаять житди. Мәхмәт Гөрмәз тарафыннан язылган һәм 1994 елда Анкарада Төркия Диянәт вакыфы матбагасында басылып чыккан китап галимнең исеме белән — «Муса Ярулла Бигиев» дип аталган. Кандидатлык диссертациясе өчен хәзерләнгән бу монография дүрт аерым бүлектән гыйбарәт. Автор беренче бүлектә Муса Ярулланың шәхсиятен, фикер дөньясын ул яшәгән заман һәм җирлек белән бәйләп аңлату өчен Казан һәм Казан татарлары турында мәгълүматлар китерә, шуннан соң гына Муса Бигинең тәрҗемәи хәлен аңлата. Аның мажара тулы бер романга охшаган тормыш юлын укыганда, «Җитмеш дүрт ел эченә никадәр вакыйга сыйган!» дип, хәйран каласың. Бу катлаулы һәм кызыклы гомер юлын тикшерүче шартлы рәвештә өч дәвергә бүлеп бирә: уку-белем алу чоры, Русиядәге көрәшләре заманы, Русиядән качып киткәннән алып вафатына кадәрге чор. Һәр заман Муса Бигинең үзенең, чордашларының, биографларының истәлекләренә, гыйльми хезмәтләргә таянып яктыр-

тыла. Китапның икенче бүлеге аның хезмәтләренә багышланган, аерым бүлекчәләр рәвешендә Муса Бигинең фикъһы, тәфсир һәм Коръән, хәдис, сөннәт һәм кәлям гыйлемнәренә караган фикерләре анализлана. Өченче бүлек «Муса Ярулланың уй-фикер дөньясы» дип атала һәм анда антик фәлсәфә, акыл һәм фикер хөрлеге, ислам дөньясының актуаль мәсьәләләре, реформизм, мәктәп-мәдрәсәләр системасында кимчелекләр һ. б. хакында Муса Бигиевнең үзенчәлекле карашлары бәян ителә. Әлеге бүлектән алынган мөселман Көнчыгышының артта калу сәбәпләрен ачыкларга тырышкан Муса Ярулла фикерләренең кыскача сөземтәсен түбәндә журнал укучыларына да тәкъдим итәбез.




Соңгы бүлектә М. Гөрмәз Муса Ярулланың күпсанлы хезмәтләренең исемлеген аннотацияләр белән бергә, тематик яктан бүлгәләп, «Тәфсир һәм Коръән гыйлемнәренә караган», «Хәдис гыйлеменә караган», «Сәяси һәм иҗтимагый мәсьәләләргә караган», «Гарәп, фарсы һәм төрек теле-әдәбиятына караган», «Диннәр тарихына караган әсәрләре» дип аерып урнаштыра. 120 дән артык хезмәте арасында Муса Ярулланың Казанда, Петербургта, Оренбургта, Истанбулда басылганнары белән бергәттән Берлин, Бхопал, Бомбей, Лахор һәм Каһирәдә нәшер ителгәннәре турында да хәбәр ителә, ягъни әлеге библиографиясе белән генә дә китап татар галимнәренә никадәр яңа мәгълүмат бирә. Табигый, әлеге китап Муса Ярулла Бигиевнең бай мирасын өйрәнү-тикшерү юлында бер башлангыч» кына әле, бу юнәлештә эшлисе эшләр бихисап. М. Гөрмәз үзе болай дип яза: «Берсе Финляндиядә, икесе Төркиядә, өч тапкыр Муса Ярулланың бөтен әсәрләрен бастырып чыгару омтылышы булса да, болар бер нәтиҗә бирмәде. Бу уңай белән планлаштырылган «Муса Ярулла институты» да бары бер хыял булудан артмады» (191—192 б.) Бәлки бу уй-планнар кайчан да булса, Муса Ярулла Бигинең үз ватанында тормышка ашар?! Һәрхәлдә, моңа өмет юк түгел, чөнки халкыбызда милли мираска, шул исәптән дини мираска, игътибар көннән-көн арта бара. Татарларда дини рух арта баруын төрекләр дә күреп куана.

Мәсәлән, Халит Гөләр әфәнде тарафыннан иҗат ителгән «Урта Азиядә исламның яңадан тууы» (Анкара: Төркия Диянәт вакыфы, 1994) китабы куанычлы хисләр белән сугарылган. «Урта Азия» төшенчәсе астына Төркиядә Урта Азия белән бергә Әзәрбайҗан, Дагыстан, Башкортстан һәм Татарстан да кертеп карала. Шуңа күрә әлеге китапта татарлар турында да шактый күп язылган. «Үзгәртеп кору» хәрәкәте башлангач, безнең илдәге мөселманнарның изге урыннарын зиярәт итү максаты белән, Төркия Дин эшләре министрлыгы рәсми делегацияләр оештыра. Шул вәкиллек эчендә Советлар Берлегенә килгән Халит Гөләр сәяхәтендә күргәннәрен сәгатен-сәгатькә язып бара. Татарстанга бу делегация Бөек Болгар дәүләтенең ислам динен рәсми рәвештә кабул итүенә 1100 ел тулу тантаналарына килә. Әле күптән түгел генә булып үткән һәм күпләребез шаһит булган бу вакыйгалар чит ил рухание тарафыннан бәян ителгәч, шактый кызык тоела. А. Әсәдуллин катнашындагы «Мәһди» рок-операсы, Сөембикә манарасы янындагы бәйрәм, мөселманнар белән очрашулар, Казан, Чаллы, Түбән Кама, Бөгелмә, Әлмәт шәһәрләрендәге мөселман җәмгыяте белән күрешүләр, мөфти Тәлгать Таҗетдин, Әзәрбәйҗаннарның Зәйнәп Ханларовасына охшатылган Фәүзия Бәйрәмова образлары автор тарафыннан балаларча бер сөенү, шатлану рухында сурәтләнә. Автор сөенә, чөнки, аның үз сүзләре белән әйтсәк, «Без хатыны-ире, яше-картының... һәр кешенең олуг бер тойгы белән Коръәне кәримгә таба йөз боруларын күрдек. Коръәне кәримгә таба сузылган куллар, теләсә нинди золым һәм басымга карамастан, иман нуры сүнмәгән күңелләр арасында яшәдек...

Чүл хәленә китерелгәндер дип уйлаган туфракларда кайнап торган чишмәләрдән су эчтек, яшәргән агачлардан җимешләр ашадык һәм боларны күрергә насыйп иткән Аллаһыга шөкер иттек. Шәһитләргә фатихалар укыдык, газиләргә дога иттек».

Халит Гөләр әфәнденең китабы әдәби рухта матур язылган һәм гади төрек укучысына адресланган. Анда хаталар да юк түгел, ләкин ул элеккеге Советлар Берлегеннән чыккан төрки мөселманнар яшәгән атмосфераны бирә белүе белән кыйммәтле.




Безнең хакта һәм, гомумән, дөньядагы бөтен төрки халыклар хакында күпьяклы гыйльми анализ, статистик мәгълүматлар исә профессор Надир Дәүләтнең «Чордаш төркиләр» исемле хезмәтендә бирелә. 14 томлы «Тууыннан бүгенгә кадәр Бөек Ислам Тарихы» исемле мәшһүр төрек энциклопедиясенә махсус кушымта том итеп басылган (Истанбул, Чаг Йайынлары, 1993, 607 б.) әлеге хезмәт чын мәгънәсендә хәзергә тиңдәше булмаган кыйммәтле энциклопедия. (Һәм аның бер генә кеше тарафыннан язылуы акылга сыймый). Хезмәт 24 бүлектән тора һәм анда Төркиядән кала, җир шарының һәр почмагында яшәгән төрки халык, кабилә, төркемнәргә тулы характеристика бирелә. Әлбәттә, китапта иң зур урынны элеккеге СССРда яшәгән төрки халыклар турындагы материаллар алып тора. Башта галим элекке совет системасына бер яклап анализ ясый (КПСС, дәүләт төзелеше, коммунистик идеология, гаскәр, социаль тормыш шартлары, культура, икътисад, мәгариф, СССРның хәрби көчләрендә, икътисадында төркиләрнең уйнаган роле һ. б.). Моннан соң 1988—1991 елларда булып узган сәяси вакыйгалар, бәйсезлек өчен көрәшләр хронологиясе китерелә. Август вакыйгасы, СССРның таралуы, илдә кешелек хокуклары саклану-сакланмау мәсьәләсе, урыс булмаган халыкларга каршы алып барылган сәясәт төрле басма чыганакларга таянып, объектив бәяләнә. Бәйсез дәүләтләр берлеге (БДБ), аның төзелеше, этник һәм демографик составы, БДБдагы мөселманнар саны аерым бер бүлек итеп алына. Профессор Надир Дәүләт элекке СССР да яшәгән төркиләрне дүрт аерым географик өлкәгә: Идел-Урал, Кавказ, Урта Азия һәм Себер өлкәләренә бүлә, һәр өлкәгә төркиләрнең ничек һәм кайчан килеп урнашулары турында кыскача тарихи мәгълүмат, һәр төрки җөмһүриятнең бүгенге хәленә бәя бирә. Татарстан Җөмһүрияте турындагы мәгълүмат алтынчы бүлектә тупланган, бер шушы бүлеккә тукталып кына да, хезмәтнең ни кадәр бай эчтәлекле һәм фәнни яктан камил икәнлеген аңларга була. Кайберәүләр монда, «Надир Дәүләт үзе татар булгач, әлбәттә, татарлар турында күбрәк белә, шуңа күрә тулы язган», дияр. Һич юк, башка төркиләр хакында материаллар да гаять киң һәм тулы. Монда тагын шуны да искәртәсе килә: Надир Дәүләт үзенең бу энциклопедик хезмәтен кырым татарларының бәйсезлек өчен көрәш лидеры Мостафа Җәмилевка багышлап язган.

Татарлар турында сүз башлау белән, Надир Дәүләт иң элек «татар» исеменең кемнәргә бирелүен аңлатып китә. «Татарлар»ны ул өч төркемгә бүлеп, схема-таблица рәвешендә күрсәтә.

## Татарлар

| Идел-Урал татарлары | Кырым татарлары | Себер татарлары |
|---|---|---|
| Казан | Кырым: Яр буе | Тубыл |
| Касыйм | Чүл | Төмән |
| Керәшен | Дабруҗа (Румыния) | |
| Мишәр | | |
| Типтәр | | |
| (Керәшеннәрне: иске керәшен, яңа керәшен һәм нугайбәк дип аера) | | |

Моннан кала, таблицада күрсәтмәсә дә, Идел-Урал татарлары эченә карагач (кондыр) татарларын аерым бер төркем итеп бирә.

Татарстанда яшәгән татарларга махсус тукталып, автор аларның тарихи, географик, демографик шартларын, шулай ук сәяси, икътисади тормышларын саннар китереп тасвирлый. Элекке СССР өчен Татарстан никадәр электр энергиясе, нефть, табигый газ, авыл хуҗалыгы чималы һ. б. житештерүе процентларда, саннарда күрсәтелә. Культура һәм мәгариф өлкәсен аңлатканда да, уку йортларының, аларда укыган татарларның саны, татарча газета һәм журналлар, фәнни оешмалар саны бик төгәл яктыртыла. Татарстанда диннең торышы исә аерым бер бүлекчә итеп алына һәм Надир Дәүләт тә татарлар арасында ислам диненә мөнәсәбәтнең яхшы якка үзгәрә баруын дәлилли.

Надир Дәүләтнең «Чордаш төркиләр» хезмәтенә багышлап, әле махсус мәкаләләр, бәяләмәләр аз язылмас. Чөнки бу игътибарга, югары бәягә лаек хезмәт.

Без исә үз фикеребезгә йомгак ясап куйыйк. Кыскача күзәтү ясалган әлеге китаплар буенча гына фикер йөрткәндә дә, без бер нәрсәгә инанабыз: тугандаш Төркия бездә мәчет-мәдрәсәләрнең ачылуын, халыкта мөселманлыкның, дини рухның ныгый баруын күреп сөенә, татарларның бөтен төрки халыклар гаиләсендә чәчәк атуын, сәгадәткә ирешүен тели, безнең арадан яңа Габдерәшит Ибраһимнар, Муса Яруллалар чыгасына ышана. Инде шул ышанычны үзебездә дә ныгытырга, моның өчен күп эшләргә, күп тырышырга кирәк. Шул вакытта гына «XXI гасыр төрки халыклар гасыры булачак!» дигән идея буш хыял булып калмас.

## Артта калуыбызның сәбәпләре

*(М. Гөрмәзнең «Муса Ярулла Бигиев» исемле китабыннан өзек)*

Муса Ярулла да, шул заманның һәр зыялысы баш ваткан бик әһәмиятле бер сорауга — «Көнбатыш халыклары культура ягыннан күтәрелгәндә, мөселман дөньясының артта калуы, токтарлыкка очравының сәбәбе нидә, нәрсәдә?» дигән сорауга җавап эзләде. Бөтен әсәрләрендә бу хәлгә китергән авыру-хасталыкларның дәвасын табарга тырышты.

Муса Ярулла бу мөһим мәсьәләне бик тиз генә хәл кылып, Көнбатышның алга китүен, Көнчыгышның артта калуын климат һәм географик шартлар белән аңлатучыларга, яки раса, җенесләр тәэсиренә әһәмият биргәннәргә кушылып китмәде. Аның фикеренчә, сәяси тормышка кешенең Көнчыгыштан яки Көнбатыштан, ак яки кара тәнле булуының һичбер йогынтысы юк. Элегрәк Көнбатышның инглизләре прогресс башында торса, бүген Көнчыгышның Японияся алда бара.

Муса Ярулла алга китү һәм артта калуның матди һәм хәяти сәбәпләрен аңлаткан төрле карашларны кире каккannан соң, хакыйкый сәбәпне иҗтимагый гамәлләрдә һәм ихтыяри эшләрдән эзләп карый. Аныңча, бер милләтнең сәяси хәяте һәм сәяси үлеме дин, хокук яисә фәлсәфә кебек иҗтимагый факторларның тәэсире аркасында була. Муса Ярулла бер милләтнең хәятен бер кешенең тормышына охшаткан Ибн-и Халдун фикерләрен уртаклашмый. Аның фикеренчә, кешенең тормышы табигый кануннарга бәйле булса, милләтләрнең сәяси һәм мәдәни гомере сөннәтуллаһ диелгән иҗтимагый кануннарга һәм ихтыяри факторларга бәйле (Муса Бигиев. Халык назарына берничә мәсьәлә. Казан, 1912, 4 б.)

Монда Муса Ярулланың әлеге фактор хакындагы фикерләрен кыскача, тезисләр рәвешендә бирүне кулай күрәбез:

1) Артта калуыбызның иң зур сәбәбе — исламиятне эш-гамәлдән аеру бәласе. Гыйлемнең дә, диннең дә хакыйкый критериен гамәли файда, иҗтимагый мәнфәгать һәм мәслихәтләр билгели. Гамәли файдасы булмаган гыйлем, иҗтимагый мәнфәгатьтән ераклашкан дин чын йөзен югалта. Ислях (реформа — Ә. С.) һәм эш-гамәл дәвам иткән вакытта гына исламиятнең куәте арта. Әгәр мөселманнар бу кагыйдәгә дикъкать иткән булсалар, бүген җир йөзенең төсе дә, картасы да бөтенләй башка булыр иде.

2) Ислам дөньясында гамәл һәм эшчәнлек рухы бик озак яшәмәде. Аеруча гарәп телле булмаган мәдәниятләр аркасында азгынлык, байлык-мөлкәт, кәеф-сафа кору һәм ялкаулык кебек чирләр дәүләт даирәләренә һәм югары катлаулар

арасында киң таралды. Тупланган милек дәүләт мәнфәгатьләренә түгел, хөкүмәт даирәсендәгеләрнең бозык эшләренә сарыф ителә торган булды.

3) Муса Ярулла фикеренчә, ислам галәмендә болардан да зуррак тагын бер фетнә чыкмаса, бәлки калган чирләр исламият төзелешенә бу кадәр зарар китерә алмаслар иде. Бу фетнә мифология һәм риваятьләрдән, үз сүзләре белән әйткәндә хыял, фантастикадан һәм теориядән гыйбарәт булган юнан фәлсәфәсенең тәрҗемә ителеп таралуы. Аныңча, бу фетнә берничә гасыр буенча бөтен мәчет һәм мәдрәсәләрне, мәҗлес һәм оешмаларны яулап алды. Шулай итеп, исламиятнең йөрәге дә, зиһене дә иң зәһәр, үтерә торган агу белән агуланды. Моның нәтиҗәсе буларак, башта кәлямнан[1] башлап, ислами гыйлемнәр файдасыз теория кысаларына кертеп бикләнде. Исламиятнең шәригати иҗтимагыйййәсе теоретик һәм фаразлы бер шәригать дәрәҗәсендә инсә дә, исламиятнең ул саф һәм ачык гакыйдәсе (иманы — Ә. С.) дә кәлям гыйлеме наданлыгы аркасында пычранды һәм юкка чыгарылды.

4) Миләре һәм күңелләре теория һәм каршылыклар белән мәшгуль булган әһле ислам иҗтимагый, икътисади һәм әдәби хәлләрне бөтенләй санга сукмый башлады. Бу санга сукмау мәдәният өлкәсендә хакимият башына бөтенләй ят кешеләрнең килүенә юл куйды. Нәтиҗәдә мөселманнар әсирлек богауларын үз куллары белән үз муеннарына тактылар...




5) Артта калуыбызның икенче бер зур сәбәбе — мәдрәсә һәм мөнбәрләребезнең бозылуы. Гыйлем-белем алу вакыты утыз елга кадәр сузылган Төркестан һәм Һиндстан мәдрәсәләре, унбиш еллап дәвам иткән Төркия һәм Гарәбстан мәдрәсәләре сарыф (морфология), нәхү (синтаксис), мантыйк (логика), әклаям һәм фикһы (ислам хокукы) хашияләре[2] белән китапларның титул битләрен укытудан һәм шул вакыт эчендә шәкертнең әхлагын бозудан башка берни бирмәделәр. Аеруча шәкертләрнең бергә яшәү тәртипләре әхлак начарлануга юл ачты. Мәдрәсәләр белән берлектә, вазифасы акылларга гыйззәт, күңелләргә рух бирү, дин-әдәп һәм Коръән тәгълим итү булган мөнбәрләр ислам өммәтенең наданлыкка төшүе, йомыкыйлануы өчен кулланыла башлады. Бу рәвешле диннең ике мөкатдәс кыйммәте булган мәдрәсә һәм мөнбәрләрдән таралган ялгыш тәрбия нәтиҗәсендә мөселманнар диннән дә, дөньявилыктан да мәхрүм калдылар.

6) Шулай ук, безне без иткән кыйммәтләребез бар иде, без аларга хуҗа була белмәдек. Хәдис, фикъһы һәм суфичылык кебек кыйммәтле хәзинәләр борынгылардан безгә мирас булып калса да, без бу хәзинәнең кыйммәтен аңламадык.

Без бай фикъһы мирасыбызны, грек хокукы кебек, мәдәният дөньясына таныта алу дәрәҗәсенә ирешмәдек. Без фәлсәфәбезне, юнан фәлсәфәсе кебек, гыйльми оешмаларда өйрәтелерлек итеп күрсәтә алмадык...

7) Башта Госманлы дәүләте, аннан соң бөтен ислам дөньясы, соң булса да, ниһаять, гафләттән уянды. Томаналыктан уяну дәвере башланды. Бөтен мөселманнар милләттә һәм дәүләттә булган кимчелекләрне күреп, ислях чараларын эзли башладылар, ләкин таба алмадылар. Милләт һәм мәмләкәтнең үзеннән эзләнергә тиешле чаралар тыштан кетелде. Иң мөһиме — исляхат хакында хөкүмәт һичбер тырышлык күрсәтмәде. Читтән алынган эреле-ваклы реформалар, авыру тәнгә куелган бизәк кебек кенә булды. Аларның файдасыннан хәтта зияны күбрәк булды. Аеруча Көнбатыштан алынган реформалар артыннан ук Көнбатышның сасыган әхлагы да килеп җитте. Элекке гасырлардан ук килгән

---

[1] Кәлям — гарәпчәдән: сүз, сөйләм, дин өйрәтүләре, Алла сүзләре турындагы фән — догматик система, теология. (Ә. С.)

[2] Хашия — бер китапның эчтәлеген ачыклаучы икенче китап (Ә. С.)

бозыклык Көнбатышның азгынлыгы белән берләшеп, милләтнең әдәби һәм иҗтимагый хәлләрен тагын да бозды.

8) Һәр милләтнең тормышы белән әдәбияты арасында тыгыз элемтә бар. Милләтнең хәяте әдәбиятына, әдәбияты хәятенә баглы.

Әүвәл заманнарда исламият яулап алулар һәм сәясәт белән мәшгуль булгач, ислам әдәбияты гаскәр башлыклары, батырлык, ганимәт (трофей — С. Ә.), ат һәм корал, кылычлар турында яза иде. Ул вакыт мөселманнарның гомуми фикере һәм милли максаты болардан гыйбарәт иде. Соңрак сәясәт һәм изге сугышлар урынына кәеф-сафа кору һәм күңел ачу башлангач, хосуси һәм гомуми мәҗлесләрдә сүз күбрәк кызлар, егетләр, җырлар, биюләр һәм шәраб турында була башлады. Ул заманның әдәбияты да эчемлек һәм сөйгән ярның чәч бөдрәләре турында яза торган булды.

Бүгенге төрки әдәбият та, культураның гаять югары дәрәҗәләренә, прогресска юнәлеш алган Аурупа хәзинәләрендә булган гыйлем, мәгариф, фән һәм индустрия кебек җитди нәрсәләргә мөмкин булган кадәр күңел бирергә тиеш булса да, җитдилектән ерак торган гыйшык романнары һәм хәерчеләр турындагы хикәяләрен тәрҗемә итү белән мәшгуль. Боларны тәрҗемә итүнең төркиләрнең ни сәяси, ни дини, ни әдәби, ни дә икътисади хәлләренә мөнәсәбәте юк.

Аурупа алга китте, әмма роман һәм хикәяләре белән түгел, гыйлем һәм мәгърифәт, сәүдә һәм промышленность белән прогресс алды. Гыйшык романнарының яки фантастик хикәяләрнең мәдәни хәрәкәтләргә торгынлык, тормыш гүзәллегенә хилафлык китерүдән башка ни файдасы булсын?

Әдәбиятның иң яхшы вазифасы — милләтнең фикеренә һәм хәл-әхвәленә тәрҗеман булу. Ләкин Франциянең мәхәббәт романнарыннан, Италиянең детектив серияләреннән тәрҗемә аркылы мәйданга чаккан әдәбиятта милләтнең уйларын һәм хәлләрен чагылдыра алу сәләте табылыр микән?

9) Милләттә гайрәт юк. Дини мәдрәсәләрдә диннең, гыйлемнең, акыл һәм әхлакның әсәре дә юк. Ялкаулык һәм гафләт чире тараткан ораторлар тарафыннан яулап алынган мөнбәрләрдә рух юк. Надан һәм явыз хакимнәр белән тулы судларда хак белән хокуктан, гаделлектән хәбәр дә юк. Вазифасы ислам шәригатенә хезмәт итү булган шәйхелисламлык оешмасында, мөселманнарны Көнбатыш сәясиләренең акыл өйрәтүләре буенча төзелгән, кабул ителгән канун һәм карарлардан саклап калачак кешеләр дә, көч тә юк...

Муса Ярулла фикеренчә, мөселманнарның артта калуында иң зур роль уйнаган сәбәпләрнең тагын берсе — тәкълид[1] хасталыгы.

Муса Ярулла фикеренчә, ислам дөньясында уй һәм фикер тарихында тәкълид мәсьәләсе кебек зарары зур булган башка бер бәла булмагандыр. Тәкълид афәте акылларыбызга да, күңелләребезгә дә тормоз булды. Ислам динен тормышчан дин булудан туктаткан да янә тәкълид. Соңгы гасырларда туган сәяси һәм иҗтимагый бөтен бәлаләрнең башы моннан чыккан.

Муса Ярулла сүккән тәкълид бер генә тармаклы тәкълид түгел. Ул үткәнгә, традицияләргә турыдан-туры ияргне кире кагу белән бергә, Көнбатышка иярүнең дә зарарларын күрмичә калмаган. Муса Ярулла фикеренчә, ислам ренессансы... ике афәттән котылу нәтиҗәсендә булачак. Берсе — үткәнгә тәкълид, икенчесе — Көнбатышка тәкълид.

*Төрекчәдән Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА тәрҗемәсе.*

---

[1] Тәкълид — иярү, башкалар эшләгәнне эшләү. *(Ә. С.)*

## Хөсни Кәримнең тууына 110 ел

(1887—1965)

XX гасыр башында татар әдәбиятына аяк баскан татар язучылары иҗатына бәяләмә биргәндә, талантына, аның нинди урын тотуына да карамастан, бик тә тирән мәгънәгә ия булган гыйбарә кулланырга яраталар — Тукай чоры әдипләре! Монда бернинди дә тарихи дөреслеккә хыйлафлык кылу юк. Чөнки һәрбер зур әдәбиятта, рәсмиләштерелмәсә дә, «күнелдән» кабул ителгән кануннар буенча, теге яки бу язучының тормыш юлын, иҗатын билгеле бер чор кысаларына кертеп өйрәнү гадәткә кергән, ә чорның асыл нисбәтен, үсеш-хәрәкәтен Казык йолдыз булып калыккан шәхесләр билгели. Татарның гасыр башы милли аң үсешендәге андый шәхес — Тукай! Шуңа күрә дә гасыр туып килгәндә иҗат итә башлаган әдипләрне без Тукай исеме белән бәйләп карыйбыз. Бу нисбәттән Хөсни Кәримгә дә күпмедер күләмдә «Тукай җиле» кагылып үтми калмагандыр.

Язучы, мәдәният хезмәткәре һәм җәмәгать эшлеклесе Хөсни Кәрим (Хөснетдин Минһаҗетдин улы Кәримов) 1887 елның 15 декабрендә Уфа губернасының Бөре өязе (хәзерге Башкортостан Республикасының Дүртөйле районы) Таймөрза авылында туа. Ул 1907 елда, атаклы «Галия» мәдрәсәсендә укыган чагында ук, каләм тибрәтә башлый. 1910 елда исә «Атна кич, яки Шәриф хәлфә» исемле ике пәрдәлек драма әсәре басылып чыга. Шушы чордан башлап ул әдәби эшчәнлеккә чума: татар телендә чыга торган төрле газета-журналларда күп санлы хикәяләре, шигырьләре, очерклары, публицистик мәкаләләре урын ала.

Аның «Идел» газетасында «Ике дус», «Тормыш тырнагы астында», «Айлы кичтә», «Ачлар шатлыгы» дигән хикәяләре, фельетоннары басыла. Г. Тукайның «Җан азыклары»на, Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләре»нә карата язылган «Матбугат дөньясыннан» дигән мәкаләсе дә шул чорда чыга. 1913 елда «Аң» журналының 17, 18 саннарында чыккан «Әдәбиятта үзгәрешләр көтелә» (милли әдәбиятыбызга бер караш) дигән күләмле мәкаләсе дә җәмәгатьчелек тарафыннан бик җылы кабул ителә.

Хөсни Кәримнең «Җан исәбен алганда» (1927), «Ертылган приказ» кебек повестьлары, «Ике дус», «Ак песи» кебек хикәяләре татар әдәбияты тарихында әле дә үзләренең эстетик кыйммәтләрен югалтмаганнар.

Хөсни Кәрим — шактый танылган җәмәгать эшлеклесе дә иде. Ул, 1911 елда Уфада «Галия» мәдрәсәсен тәмамлагач, гимназия программасы буенча урыс теле мөгаллимлегенә имтихан тота, аннары 1914 елның җәенә Әстерхан шәһәренең урыс-татар мәктәбендә балалар укыта. Ә шул ук елны уку елын тәгәлләп, сәяси рухтагы фельетоннары өчен полиция эзәрлекли башлагач, Хөсни Кәрим Уфа ягына китәргә карар кыла. Ул Бөре өязенең Бакыйбаш дигән авылында урыс-татар мәктәбенең мөдире һәм укытучысы булып эшли башлый. Аның анда да халык арасында мәктәптән тыш эш белән актив шөгыльләнүенә губерна земствосының алдынгы карашлы хезмәткәрләре дә игътибар итәләр һәм 1915 елны шул ук Бөре өязендәге Богдан авылы китапханәсенә мөдир итеп күчерәләр. Бу китапханә биш волостька караган 56 авыл халкының аң-белемен күтәрү максатыннан чыгып оештырылган була.

1924 елда ул язмышын Казан шәһәре белән бәйли. 1926—1936 елларда — Татарстанның Главлит җитәкчесе, Татарстан радиокомитетының әдәби-музыкаль тапшырулар редакциясе мөдире.

1936 елда, очраклы рәвештә каты имгәнү сәбәпле, ул әдәби һәм җәмәгать эшчәнлегеннән читләшергә мәҗбүр була. Шуңа да карамастан, Хөсни Кәрим 1912—1914 елларда язылган һәм басылган хикәяләрен яңадан эшләп чыга, 1958 елда аның «Ертылган приказ» исемле хикәяләр китабы басылып чыга.

Хөсни Кәрим 1965 елның 25 декабрендә вафат була.

## Сәхаб Урайскийның тууына 90 ел

Кырыгынчы, илленче елларда үзенең шигырьләре, бигрәк тә җырлары белән шактый билгеле булган шагыйрь Сәхаб Урайский (чын исеме-аты — Сәхабетдин Камалетдин улы Мәүлютов) — Самара өлкәсе Мәләкәс өязе, мәшһүр Кандалыебызның шигырьләренә кергән Татар Урайкино (Иске Кызылсу) авылыннан. Яшьли ятим калып, фәкыйрьлектә үскән егет сонрак Самара татар-башкорт педагогия техникумында укый; партия мәктәбендә укыта, «Колхозчы» исемле өлкә газетасында әдәби хезмәткәр була. Аннары Мәскәүдә Язучылар берлеге һәм Комсомол Үзәк комитеты оештырган курсларда да белемен арттыргач, ниһаять, 1938 елда Казанга килә; яшьләр газетасында эшли, шуннан сугышка китеп, 1946 елда гына кабат мәркәзебезгә кайта. Тагын яшьләр газетасында (бүгенге «Татарстан яшьләре»ндә) эшләү, китап нәшриятында яшьләр-балалар редакциясендә мөхәррирлек итү...

Шигырьдә ул егерменче еллар азагында күренә башлый, беренче китаплары («Көтүче кызы», «Таныш елмаю») Самарада басыла; аннары Казанда «Шигырьләр» (1941), «Якты еллар» (1950) кебек һәм күләмле «Сайланма шигырьләр» (1956) китаплары дөнья күрә.

Чорына күрә шактый актуаль темаларга язган поэмалары да бар. Әмма иҗатының калку бер түбәсе — җыр жанры. Мәсәлән, «Син кайтмадың» кебек җырны (М. Мозаффаров көе) сугыштан соң кем генә җырламады икән? Р. Яхин музыка язган «Син кал бездә», «Онытма» кебек җырлар да, халык көенә җырлана торган «Шомыртым» да — шактый популярлык казанган әсәрләрдән. Балалар өчен җырлары да бар. Шулай ук С. Урайский — публицистика, тәрҗемә өлкәсендә дә эшләгән әдипләрдән.

Вафаты — 1957 елның 15 февралендә. Урыны — җәннәттәдер дип беләбез: шагыйрьләр — шиксез, изге заттан алар!

## Сәет Шәкүровның тууына 80 ел

Элек-электән шулай килә: драматург әдипләрнең күпчелеге иҗат юлын актер булудан башлыйлар. Хикмәт шундадыр: сәхнә әсәре язу өчен сәхнә кануннарын яхшы белү зарур.

Сәет Шәкүров та (ул 1917 елның 14 декабрендә Татарстанның Балык Бистәсе районы Балыклы Чүкәй авылында туган) заманында Казан театр техникумын тәмамлап, төрле театр сәхнәләрендә актер булып эшли.

Ул Ватан сугышыннан кайткач та актерлык хезмәтен дәвам иттерә. 1946—56 елларда Мамадыш, Әлмәт, Минзәлә колхоз-совхоз театрларының һәм Республика күчмә театрында (хәзерге Казан драма һәм комедия театры) эшли, 1956—1959 елларда исә Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсендә төрле рольләрдә уйный. Аннары Казанның культура сарайларында үзешчән сәнгать коллективларына җитәкчелек итү, ун ел буе Академия театрының баш администраторы, 1975 елдан алып 1979 елгача Республика күчмә театрының директоры булып эшләү...

Сәет Шәкүров үзенең иҗат юлын 1938 елда «Орденлы Касыйм» исемле пьеса һәм хикәяләр язудан башлый. Аның күләмле икенче әсәре — «Тормыш бусагасында» драмасы. Гаиләдә бала тәрбияләүгә багышланган бу әсәр 1958 елда Минзәлә театры сәхнәсендә куела һәм тамашачылар тарафыннан яратып кабул ителә. Алтмышынчы еллардан соң, Сәет Шәкүров иҗатта аеруча актив һәм нәтиҗәле эшли. Минзәлә, Оренбург татар профессиональ театр сәхнәләрендә аның шигырь белән язылган «Зөһрә йолдыз» исемле фаҗигале тамашасы, «Уракчы кыз», «Мәхәббәт газабы», «Сары елан», «Кыз бирү», «Карт гашыйк» драмалары, татар дәүләт академия театрында «Туган туфрак», «Тол хатыннар, тол кызлар» дигән драмалары куела. Бу пьесаларны республикабыз халык театрлары һәм үзешчән театрлар да үз репертуарларына алалар. Әтнә халык театры, мәсәлән, 1967 елда «Уракчы кыз» спектакле белән Бөтенсоюз смотрында катнашып, беренче дәрәҗә диплом һәм лауреат исемен алуга ирешә.

Драматург Сәет Шәкүров татар театр сәнгатендә һәм драматургиясендә лаеклы өлеш кертеп калдырды, аның иҗаты әле дә милләтебезгә хезмәт итә.

# 1997 ЕЛДА ЖУРНАЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

1997 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. № 6

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА — 75 ЕЛ

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев котлавы. № 5
Фәйзуллин Р. Рухи елъязмабыз. № 5
А. Шамов, М. Әмир, Ф. Хөсни, Ә. Еники, Р. Ишморат, Г. Афзал «Казан утлары» турында истәлекләр. № 5
Редколлегия әгъзалары. № 5
Олуг юбилейга — шагыйрьләребез. Шигырьләр. № 5
Безне котлыйлар. № 10

## II БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫН КАРШЫЛАП

Борһанов Ә. Милли идея мәсьәләләре. № 8
Тарихым — данлы дастан, Ватаным — Татарстан. Шигырьләр. № 8

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Бәйрәмова Ф. Хикәяләр. № 1
Вәли М. Иртәнге пароход. *Новелла.* № 4
Вәли М. Мәхәббәт мажаралары. *Новеллалар.* № 11
Гадел Ә. Сәер затлар. *Хикәя.* № 9
Галиуллин Т. Элмәк. *Роман.* №№ 5, 6, 7, 8
Гөлшәһидә. Асылбикәне җирләгәндә. *Бәләкәй повесть.* № 11
Камалов Б. Ир хакы. *Повесть.* № 9
Миңлебаев К. Бакый. *Роман.* №№ 2, 3, 4
Низамиев Р. Кайтарыгыз! *Хикәя.* № 2
Расих А. Тыныч еллар күләгәсендә. *(«Елларны чигерсәм» исемле истәлек-трилогиянең өченче китабыннан.)* № 1
Сабирова Л. Көнләшү. *Хикәя.* № 1
Сафиуллин Ә. Үкенү. *Хикәя.* № 10
Сибат Р. Исабәт. *Роман.* №№ 11, 12
Тимбикова К. Нәфесле Нәфисә. *Хикәя.* № 10
Хуҗин И. Егетнең кайтуы. *Фантастик хикәя.* № 1
Хәким З. Гөнаһ. *Роман.* №№ 3, 4, 5, 6, 7
Юныс М. Соңгы сулыш. *Юльязма.* №№ 8, 9, 10
Әхмәтҗан Мәхмүт. Тормыш мизгелләре. *Парчалар.* № 2

## ШИГЪРИЯТ

Афзал Г. Ир йөрәге — сандугачлы урман. *Шигырьләр.* № 4
Баян Ә. Очу, төшү... *Шигырьләр.* № 2
Вәлиди К. Ходайга ялвару. *Шигырьләр.* № 9
Вәлиева Р. Юлга чыктым. *Шигырьләр.* № 10
Гайфин Р. Яшәү көче. *Шигырьләр.* № 9
Гатауллин Рәш. Дым булып җиргә сеңәм. *Шигырьләр.* № 7
Гаташ Р. Гөлбалага хатлар. *Газәлләр.* № 2
Гатина Ф. Моңлы җан кошы. *Шигырьләр.* № 7
Гыйләҗев И. Туган ил хисе. *Шигырьләр.* № 4
Зәйдулла Р. Безнең илдә. *Шигырьләр.* № 9
Ибраһимов Н. Миләш. *Шигырьләр.* № 9
Игәнәй Я. Соңгы шигырьләреннән. № 10
Идиятуллин Р. Бәндәләргә тамчы үпкәм юк. *Шигырьләр.* № 9
Иксанова И. Иделләрсез илдә мин булмам. *Шигырьләр.* № 11
Каштанов Н. Дингез — әкияти кыз. *Шигырьләр.* № 9
Мансуров З. Фәрештәгә әверелү. *Шигырьләр.* № 8
Мирза М. Килен. *Шигырьләр.* № 12
Мөслимова Ф. Хатирәләр сүтелә. *Шигырьләр.* № 3
Низами Р. Син әйттең... *Шигырь.* № 3
Низами Р. Тормыш трамвае. *Шигырьләр.* № 9
Нәҗми Н. Яңа шигырьләр. № 9
Рахман Р. Каенлы җыр. *Шигырьләр.* № 6
Рәхим Г. Уйдык-уйдык уйлар. *Шигырьләр.* № 7
Рәхимова Б. Әйтү кирәкме?.. *Шигырьләр.* № *10*
Рәхмәтулла С. Ялгыша күрмә, язмыш!.. *Шигырьләр.* № 11
Сафина Н. Язда шундый садә мәл бар... *Шигырьләр.* № 4
Султи Р. Ак намазлык өстендә. *Шигырьләр.* № 9
Сәгадәт К. Безнең сөю, безнең язмышлар. *Шигырьләр.* № 11
Сөләйман. Әтиемә җиде рәкәгать. № 9
Таңчулпан. Мәңге чишмәс табышмагым. *Шигырьләр.* № 7
Фазули И. Таллар таяна җиргә. *Шигырьләр.* № 7
Фәйзуллин Р. «Кыска поэмалар» циклыннан. № 3

Халитов Ә. Туган җиремә. *Шигырьләр*. № 9
Хисмәтулла Р. Акыл иленә юл. *Шигырьләр*. № 11
Хәким С. Ходайдан мин сорыйм... *Шигырь*. № 6
Хәлим А. Кипарис кайтты иленә. *Шигырьләр*. № 2
Юзеев И. Мин дә тибрәндем үз гөлемдә. *Шигырьләр*. № 10
Юзи И. Куларбамны тартып узган чакта. *Шигырьләр*. № 1
Яруллин Ф. Яшьсез генә елый йөрәгем. *Шигырьләр*. № 1
Әгъләм М. Кеше булып кычкырасы. *Шигырьләр*. № 8
Әхтәмова Г. Егерменче гасыр. *Шигырьләр*. № 12


«ЧИТ ҖИРЛӘРДӘ ЯШӘП ГЫЙБРӘТ АЛ...»


Габдрәхим Ф. «Бир!» дибез. *Шигырь*. № 5
Гайфин Р. Моң. *Шигырь*. № 5
Гатауллин Рәш. Авылга кайткач. *Шигырь*. № 5
Иделбикә. Сагынам. *Шигырь*. № 5
Мортазин Ф. Бүләк ит миңа... *Шигырь*. № 5
Мөдәррисова Х. Тәрәзәмне каерып давыл керде. *Шигырьләр*. № 5
Рафиков Б. Күпме гасыр инде. *Шигырь*. № 5
Риян Р. Олы Ока. *Шигырь*. № 5
Синугыл Ә. Баккал йолдызы. *Шигырь*. № 5
Султи Р. Бу кадәр гамьгә түзмәде сазы. *Шигырь*. № 5


## ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН


Гази И. Тургай картаямы икән? *Хикәя*. № 2
Гази И. Ерганак юл ала. № 2
Газиз Г. Эчке эмигрант. № 10
Еники Ә. Матурлык. № 5
Хуҗин М. Ул — түрдә. № 2
Хөсни Ф. Йөзек кашы. *Повесть*. № 3


## ОСТАХАНӘ


Башурина Н. Егетне бүлешәләр. *Шигырьләр*. № 3
Гөлнур. Бирдеме бу сөю хакын — Аллам?! *Шигырьләр*. № 3
Закирова Г. Серле төн бу җиһанда. *Шигырьләр*. № 3
Закирова С. Сөю сахрасында. *Шигырьләр*. № 3
Илгөлем. Саумы? *Шигырьләр*. № 3
Юзи И. Хуш киләсез, кыр кызлары. № 3
Җәлилова Э. Күзгә яңгыр үтте сибәләп. *Шигырьләр*. № 3


## ДРАМАТУРГИЯ


Хөсәенов Ш. Безнең подъезд төбе. *Бер пәрдәле драма*. № 2


## ӘДӘБИ МИРАС


Гаяз Исхакый хатлары. № 6
Надиров И. «Идегәй» дастанының шигърияте турында. № 5
Тубыли Ә. Шигырьләреннән үрнәкләр. № 1
Әхмәтҗанов Марсель. Шагыйрь Әхмәтҗан Тубыли. № 1


## ДУСЛАР ҖЫРЫ


Ахунов Г. «Сагышларым Агыйделдә чайкадым...». № 6
Аралбай К. Ак тирмә. *Шигырьләр*. № 6
Нәҗми Н. Җаваплылык тойгысы. № 10
Назар Х. Кардәшлек. *Шигырьләр*. № 10
Гаташ Р. Салават йөргән сукмактан. № 12
Әлибай С. Сөенче! *Шигырьләр*. № 12


## ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ


Саттаров М. Җырлыйк Арча көйләренә. *Шигырьләр*. № 5


## ПУБЛИЦИСТИКА


Борһанов Ә. Туган якның җиле татлы. № 3
Гали Ә. Кизләү. *Очерк*. № 10
Зарипов М. Яшел чишмәләр. № 7, 9
Латыйфи Ф. Ат җене. № 11
Низами Р. Азатлык — татлы сүз. № 8
Сыналабыз — сынмыйбыз. *(Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗановның журналның баш мөхәррире Р. Фәйзуллин белән әңгәмәсе)*. № 7
Уразаев Ф. Фаҗигале мизгел. № 6
Әйди Т. Биектау йолдызлары. № 5


## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


Проза турында сөйләшү. №№ 1—12
Шагыйрьҗан Л. Шагыйрь буласың килсә — бул! № 11
Өметне аклыйк *(1997 елда журнал битләрендә барган «Бүгенге проза турында сөйләшү»гә йомгак)*. № 12


## ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕ СҮЗ АЛА


Фәтхерахманов Р. Беренче җөмлә феномены. № 9


## ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ


Юныс М. Югалган кыйбланы табу. № 4


## «КАЗАН УТЛАРЫ» АРХИВЫННАН


Әдипләр хат алыша. № 5
Әй, гомер агышлары... № 8


## ӘДӘБИ БАГЛАНЫШЛАР


Татар ПЕН-үзәге колач җәя. *(Татар ПЕН-үзәге президенты Туфан Миңнуллин белән әңгәмә)*. № 5


## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА


Нәфыйков Р. Шагыйрьне өйрәнү юлында. № 6

## МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Дәүләт Н. Татар диаспорасы һәм Тукай. № 5
Әмирхан Р. Казанлы Әмирханнар... №№ 10, 11, 12

## ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Рамазанова Д. Пермь татарларының теле һәм тарихы. № 2
Сибгатуллина Ә. Төркиядә — безнең турыда. № 12
Урманче Ф. Сөембикә бәете. № 8
Фәйзрахманов Г. Азатлык рухы. № 7
Халкыбыз хакында яңа сүз *(профессор Ф. Урманче белән Т. Әйди әңгәмәсе)*. № 1
Хәмидуллин Б. Ерактан әйбәт күренә... *(Чыңгыз ханның үлеменә 770 ел тулуга карата)* № 9
Шәмси С. Куликово кыры сабаклары. № 4

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Кашапов Р. Польша-литва татарлары һәм Татарстан. № 2
Кәримуллин Ә. Төркиядә «Казан» журналы. № 2
Солтанбәк Б. Каһәрле карарлар. № 10
Әхмәдулла Ш. Үткәннәрдән гыйбрәт ал! № 7

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

Садыйкова А. Җан авазы *(Мөнәҗәтләргә бер күзәтү)*. № 10

## ХӘТЕР

Аяз Гыйләҗевнең Мөхәммәт Мәһдиевкә язган хатлары. № 10
Еники Ә. Гөмбәгә бару. № 10
Нәҗмиев Т. Ерак илләрне кичеп. № 9
Сабиров С. Еллар һәм юллар. № 9
Сугыш бәете. № 9
Шәрәфиев Р. Уятмакчы булсаң... № 4
Әхмәтҗанов М. Татар зиратлары. № 12
Латыйфи Ф. Дуска соңгы сүз *(Ф. Зөлкарнәй истәлегенә)*. № 8

## СӘНГАТЬ

Әйди Т. Рухы нык — үргә менә. № 6
Әхмәтова-Урманче Ф. Болгарый кылыр күнене. № 7

## ЮБИЛЕЙЛАР

### МӨХӘММӘДЪЯРНЫҢ ТУУЫНА 500 ЕЛ

Мөхәммәдъяр. Әсәрләреннән парчалар. № 8
Галиуллин Т. Тарих мизгелләре. № 8

### ГАЗИЗ ГОБӘЙДУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Гобәйдуллин С. Онытылмас әтием. № 6

### КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Батулла Р. Аның белән янәшә. № 9

### ҖАМАЛ ВӘЛИДИНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Гайнетдин М. Батыр яуда беленә. № 10
Вәлиди Җ. Әдәби мөсахәбә. № 10

### ЗЫЯ ЯРМӘКИНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Гаташ Р. «Яфраклары яшел ак каенның». № 1

### ГАЛИМҖАН НИГЪМӘТИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Галимуллин Ф. Г. Нигъмәти һәм эстетик фикер. № 7

### БАКЫЙ УРМАНЧЕНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Еники Ә. Шәхес. № 1

### ГАРИФ ГОБӘЙНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Рахмани Р. Тормыш чынлыгын эзләп. № 8

### МИРСӘЙ ӘМИРНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Әдипнең көндәлеге. № 1

### РӘЙСӘ ИШМОРАТОВАНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Ихсанова Л. Матур язмыш. № 7

### МӘХМҮТ ХӘСӘНОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Гамбәр Н. Ул тормышны ярата иде. № 12
Хәсәнов М. Зөбәрҗәт. Хикәя. № 12

### ЗИННУР НАСЫЙБУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Ә. Рәшит. Якты эзе калды. № 11

### ӘХСӘН БАЯНОВКА 70 ЯШЬ

Низамиев Р. Яшьлекне сагыну. № 11
Баянов Ә. Су өсләрендә пароход. *Автобиографик повесть.* №№ 11, 12

### САФУАН МУЛЛА ГАЛИГӘ 70 ЯШЬ

Гаташ Р. «Ыктан агып кергән бер тал мин». № 9
Мулла Гали С. И Чаганлым! *Шигырьләр.* № 9

### ЗӘЕТ МӘҖИТОВКА 70 ЯШЬ

Гаташ Р. Ир җанында — ни булмас. № 8
Мәҗитов З. «Ачулы еллар» дәфтәреннән. *Шигырьләр.* № 8

### КАВИ ЛАТЫЙПКА 70 ЯШЬ

Фәйзуллин Р. «Һәркем җирдә бер бизәк...» № 6
Латыйп К. Серле култамгалар. № 6

### МӨСӘГЫЙТ ХӘБИБУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Галимуллин Ф. Тарихтан гыйбрәт, халкыннан гайрәт алып... № 12

### ФАРСИЛ ЗЫЯТДИНГА 60 ЯШЬ

Маннап Ш. Туган җирдән көч алып. № 6
Зыятдин Ф. Кайту. Шигырьләр. № 6

### РӨСТӘМ МИНГАЛИМГӘ 60 ЯШЬ

Мингалим Р. Тау астында илле бүре. *(Ике пәрдәле сәер тамаша)*. № 8

НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВКА 60 ЯШЬ

Хисамов Н. XIV йөз шигъриятендә кеше идеалы. № 3

ШАМИЛ МАННАПКА 60 ЯШЬ

Баянов Ә. Даһилык дәгъваламыйча гына. № 12
Маннап Ш. Дәрья йөрәге. Шигырьләр. № 12

АЛЬБЕРТ ХӘСӘНОВКА 60 ЯШЬ

Хәсәнов А. Балыкчы маҗаралары. Хикәя. № 12

РАЗИЛ ВӘЛИЕВКӘ 50 ЯШЬ

Галиев М. Язмышка рәхмәт. № 1

НАИС ГАМБӘРГӘ 50 ЯШЬ

Зөлфәт. Уйный йөрәк. № 8
Гамбәр Н. Еллардагы юллар. *Шигырьләр.* № 8

ФӘРИТ ГЫЙЛЬМИНЕҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ

Гыйләҗев А. Истә, һаман да истә. № 4
Гыйльми Ф. Кунак кызы. Хикәя. № 4

ШАГЫЙРЬ ЗӨЛФӘТКӘ 50 ЯШЬ

Гамбәр Н. Ике урман арасы. № 1
Зөлфәт. Сөйлә ерак таңның нурларын! Шигырьләр. № 1

ЮНЫС САФИУЛЛИНГА 50 ЯШЬ

Гыйләҗев А. Пакь кеше, ак кеше. № 10
Сафиуллин Ю. Йөзек һәм хәнҗәр. Фаҗига, ике пәрдәдә. № 10

ЭЛЬМИРА ШӘРИФУЛЛИНАГА 50 ЯШЬ

Зөлфәт. Күңел агымының сере. № 6
Шәрифуллина Э. Кайда синең йөрәк турың? *Шигырьләр.* № 6

ГАЛИМ ӘНВӘР ХӘЙРИГӘ 50 ЯШЬ

Әмирхан Р. Мул җимешле иҗат. № 12

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Миргазиян Юныска — 70 яшь. № 5
Әхмәтсафа Ш. Рәшит Ибраһимовка — 70 яшь. № 7
Индус Сирматовка — 60 яшь. № 3
Әмир Мәхмүдовка — 50 яшь. № 7
Шагыйрь Рафаилга — 50 яшь. № 4
Мостафин Ш. Безнең кызлар — Салават күпере! *(Н. Кәримовага — 50 яшь)* № 6

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Хөсни Кәримнең тууына 110 ел. № 12
Шабаев М. Бари Рәхмәтнең тууына 100 ел. № 5
Рәхмәт Б. Бармагыңа акча түлим. *Шигырьләр.* № 5
Гази Кәшшафның тууына 90 ел. № 4
Сәхаб Урайскийның тууына 90 ел. № 12
Сәет Шәкүровның тууына 80 ел. № 12

## УКУЧЫ СҮЗЕ. № 5

Закир Л. Ни өчен Россия Аляскадан колак каккан? № 4

## ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ

Равил хәзрәт Гайнетдин. Бардыр, бердер. № 5
Һиҗридән — миладига һәм киресенчә. № 8

## МӘГАРИФ

Татарстанның баш мөгаллиме *(Татарстан мәгариф министры В. Г. Гайфуллин белән әңгәмә).* № 3

## ТАТАРНЫҢ ЯҢА ӘЛИФБАСЫ

Латыйпов Ф. Тарихи зарурият. № 8
Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. Өзек. № 8, 11
Фәхретдин Р. «Болгар вә Казан төрекләре» китабыннан өзек. № 10

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

Татарстанда беренче. *(Төркиянең Татарстандагы баш консулы Алыпхан Шөлән белән әңгәмә).* № 5

## КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

Әхмәтҗанов М. Гасырлар капкасын ачканда. № 3

## ӘЗ-МӘЗ ГЕНӘ МӘЗӘК

Маннап Ш. Мәзәкләр. № 2
Нәҗмиев Т. Мәзәкләр. № 3

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. № 1—12

# Татар язучыларының җәмәгать оешмасы — Татар ПЕН-үзәге мөрәҗәгате

Язучыларның демократик оешмасы буларак, Татар ПЕН-үзәге халыкларның милли хисләрен, хокукларын һәм ирекләрен чикләүгә юнәлтелгән вакыйгаларга карата үз мөнәсәбәтен белдермичә кала алмый. Россия, гәрчә үзен демократик федерация дип игълан итсә дә, чынлыкта федераль властьларның аерым эш алымнары демократик принципларга каршы килә. Россиядә, хокукый дәүләт принципларын санга сукмыйча, закон чыгару органнарының вәкаләтләрен инкяр итеп, империянең күп гасырлар дәвамында халыкларны изүен, аларның хокукларын һәм ирекен бастырып торуны гәүдәләндерүче ике башлы сәмруг кош символикасы кабул ителде.

Федераль властьларның, закон чыгару органнары һәм федерация субъектлары белән килешмичә торып, Россиянең яңа паспортын гамәлгә кертергә маташуы да, шулай ук, киң масштаблы провокация дип кенә бәяләнергә тиеш. Яңа паспортларда федерациягә кергән халыкларның дәүләт телләрендә язмаларның булмавы да хаклы рәвештә каршылыкка очрый. Россия Федерациясенең Конституциясендә барлык халыкларның да теле һәм мәдәнияте бердәй ихтирам ителергә тиеш дип игълан ителә, әмма федераль властьлар бу изге декларациягә төкереп карыйлар. Мәгълүм булганча, рус телендә башка милләт халыкларының исем-фамилияләрен һәр очракта да ана телендәгечә язу мөмкин түгел. Димәк, Россия Федерациясенең рус булмаган гражданнары рәсми документларда үзләренең исем-фамилияләрен дөрес язу хокукларыннан мәхрүм ителәчәкләр. Ниһаять, яңа паспортларда гражданнарның кайсы милләттән булуы бөтенләй күрсәтелмәячәк һәм бу «яңалык»ны кертү кеше хокукын саклауны гарантияләү өчен эшләнә дигән сафсата белән ныгытыла. Ләкин милләтен күрсәткәндә, кешенең нинди хокуклары бозылачак соң — һич тә аңлашылмый. Документларны тутырганда, үзенең кайсы милләттән икәнлекләрен күрсәтергә теләүчеләрнең дә, теләмәүчеләрнең дә теләкләре бердәй исәпкә алынырга тиеш. Демократик хокукларны саклау күзлегеннән караганда, монда бернинди дә аңлашылмаучанлык юк. Әмма, кызганыч, кемнәрдер илнең күпчелек гражданнарына үзләренең субъектив карашларын көчләп такмакчы булалар.

Паспортларда милләтне күрсәтү мәҗбүри түгел, дип еш кына чит илләр, аерым алганда, Америка Кушма Штатлары тәҗрибәсен мисал итеп китерәләр. Ләкин бу очракта да фактлар берьяклырак китерелә. Дөрес, Америка Кушма Штатларында гражданнарның милләте күрсәтелми, ләкин хикмәт шунда ки, анда эчке паспортлар бөтенләй юк.

Шушыларны истә тотып, Татар ПЕН-үзәге Россия хөкүмәтенең яңа паспортлар кертү буенча алып барган акциясенә каршы протест белдерә һәм, федерациягә кергән барлык халыкларның да мәнфәгатьләрен чагылдыручы карарга килгәнче, паспортлар бирү акциясен туктатуны таләп итә.

Татар ПЕН-үзәге, шулай ук, Татарстан гражданнары турындагы законны кабул итүне тизләтергә кирәк дигән тәкъдим белән Татарстан Республикасы Президентына һәм Дәүләт Советына мөрәҗәгать итә. Татар ПЕН-үзәге Татарстан гражданнары Татарстан паспортын да, Россия паспортын да йөртергә хокуклы дип исәпли.

*Казан. 1997 ел, 4 октябрь.*

## *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

*РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР*

### ӘДИПЛӘР БЕЛӘН ОЧРАШУ

24 ноябрьдә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Казан Кремлендәге резиденциясендә бер төркем әдипләрне кабул итте. Татарстанның халык язучылары Ә. Еники, Г. Ахунов, Язучылар берлеге рәисе Р. Мөхәммәдиев, язучы К. Миңлебаев әңгәмә барышында иҗат интеллигенциясен һәм дәүләт эшлеклеләрен генә түгел, ә бәлки халыкны да борчый торган байтак проблемаларны күтәрделәр. Аерым алганда, латин графикасына күчү, халыкның рухи мирасын яңарту һәм саклау, татар телен өйрәнү, китаплар чыгару һәм аларны тарату, махсус кибетләр ачу, каләм осталарының юбилейларын үткәрү мәсьәләләре турында эшлекле сөйләшү булды. Татар

әдәбияты классигы Г. Исхакыйның 120 еллыгын 1998 елда бөтенхалык бәйрәме итеп үткәрү турында килешенде.

Әңгәмәдә Президентның матбугат үзәге житәкчесе — Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Ә. Хәсәнов катнашты.

## ТАТАРСТАН ДЕЛЕГАЦИЯСЕ — ӘЗӘРБАЙЖАНДА

5—8 ноябрь көннәрендә Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе рәисе — шагыйрь Р. Миңнуллин, ТР Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов, ТР Мәгариф министры Ф. Харисов составындагы делегация Әзәрбайжан Республикасы башкаласында булды. Татарстан вәкилләре латин графикасына күчү һәм тел сәясәте мәсьәләләрен өйрәнделәр, әлеге республиканың Мәгълүмат һәм матбугат, Мәгариф министрлыкларында эшлекле очрашуларда катнаштылар, һәр ике җөмһүрият өчен мөһим булган килешүләргә кул куйдылар.

## БОРЫНГЫ БАБАЛАРЫБЫЗ ЭЗЕННӘН

27—29 ноябрь көннәрендә Премьер-министр Ф. Мөхәммәтшин җитәкләгән Татарстан хөкүмәте делегациясе Беларусь Республикасында булып кайтты. Ул анда татарларның Беларусь-Литва дәүләтендә, Бөек Литва кенәзлегендә яши башлауларына 600 ел тулу вакыйгасына багышланган олуг тантаналарда катнашты.

Ф. Мөхәммәтшин Беларусь Республикасы Президенты А. Лукашенко, Премьер-министр С. Линг әфәнделәр белән очрашып, һәр ике җөмһүрият өчен дә кирәкле һәм файдалы сөйләшүләр үткәрде.

## Г. НИГЪМӘТИГӘ БАГЫШЛАП

Атаклы галимебез Галимҗан Нигъмәтинең тууына 100 ел тулу уңаеннан, Казан дәүләт педагогика университетында, биредәге әдәбият кафедрасы инициативасы белән, гыйльми конференция үткәрелде. Конференция эшендә Татарстан Фәннәр академиясе президенты, академик М. Хәсәнов, Татарстанның халык язучысы Ә. Еники, педуниверситет ректоры, академик Р. Юсупов, әдәбият кафедрасы мөдире — язучы Ф. Галимуллин, галимнәрдән Ш. Абилов, Ф. Вәлиев (Омск) Г. Нигъмәтинең кызы белән улы — Йолдыз һәм Энгель Нигъмәтуллиннар (икесе дә — әдәбият белгечләре) катнашты һәм чыгыш ясады.

## ИМАМ ШАМИЛНЕ ИСКӘ АЛУ

Мәркәзебез Казанның Г. Тукай музеенда Кавказ халыкларының бәйсезлеге өчен фидакарьләрчә көрәшкән имам Шамилнең тууына 200 ел тулуга багышланган фәнни-практик конференция булды. Аны Милли Мәҗлес рәисе — язучы Айдар Хәлим алып барды. Россиянең Табигать фәннәре академиясе академигы, тарих фәннәре докторы Ибраһимбәй Хаҗи Морат (Мәскәү) «Шамил феномены, тарих һәм хәзерге заман», тарих фәннәре докторы Булат Солтанбәков «Шамил гаиләсе биографиясендә татар эзе» (Казан) дигән темаларга докладлар белән чыктылар.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

24 ноябрьдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Утырышта Халыкара Әдәбият фондының Казанда үтәчәк II конференциясенә, халкыбызның бөек улы Г. Исхакыйның — 120 еллык, күренекле язучыларыбыздан М. Хәбибуллин, Ә. Баян, А. Гыйләҗевларның 70 яшьлек юбилейларына хәзерлек мәсьәләләре тикшерелде. Утырышта шулай ук Татарстан зыялыларының республикабыз башкаласында үтәчәк I конгрессына язучылардан делегатлар сайланды, Мәскәүдә һәм җөмһүриятебезнең Яңа Чишмә районында «Татар әдәбияты көннәре» үткәрү турында сөйләшенде. Татарстанның үзендә язучыларыбыз өчен иҗат йорты булдыру мәсьәләсе дә идарә әгъзалары арасында киң яклау тапты.

Шул ук утырышта рус телендә иҗат итүче яшь прозаик Айдар Сәхипзадинов Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.

## ШАГЫЙРӘГӘ — ҺӘЙКӘЛ

6 ноябрьдә Әлмәт шәһәренең Сажидә Сөләйманова исемен йөрткән матур бер урамында әлеге күренекле шагыйрәгә һәйкәл ачу тантанасы булды. Ошбу бәйрәмдә шәһәр һәм район хакимияте башлыгы Илдус Гәрәев, шагыйрәнең ире — язучы Әдип Маликов, улы Әнвәр Маликов, һәйкәл авторы — сынчы һәм архитектор Азат Хәйриев, «Хәзинә» газетасы мөхәррире — язучы Нур Әхмәдиев һ. б. белән бергә, киң җәмәгатьчелек вәкилләре, С. Сөләймpraynованың туган җиреннән — күрше Башкортстаннан килгән кунаклар катнашты.

*ТУГАНДАШ БАШКОРТСТАН ҖИРЕНДӘ*

## ӘДӘБИ-МУЗЫКАЛЬ ОЧРАШУЛАР

Күренекле шагыйрь, прозаик һәм драматург — Татарстан Язучыларының Әдәбият фонды идарәсе рәисе Әхсән Баянның 70 яшьлек юбилее уңаеннан, аның туган ягында — Илеш районы үзәге булган Югары Яркәй мәдәният йортында тантаналы кичә үткәрелде. Әлеге кичәдә юбилярны райондашы — танылган шагыйрь Роберт Миңнуллин, Татарстан Язучыларының Әдәбият фонды директоры Данил Салихов, район хакимияте җитәкчеләре, якташлары кайнар котладылар. Илеш районының сәнгать осталары Ә. Баян әсәрләре нигезендә махсус концерт та хәзерләгәннәр иде. Нур өстенә нур өстәп, аларга атказанган артист Алмаз Хәмзинның иҗат бригадасы да килеп кушылды.

Шундый ук әдәби-музыкаль очрашулар әлеге районның Әшмән, Шәммәт, Тәҗәй, Игмәт авылларында да үткәрелде.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Зөлфәт Хәким. «Сайланма әсәрләр».
3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр.,
1997. Тиражы — 10 000 данә.

*«Соңгы елларда безнең әдәбиятка, сәнгатькә, гомумән, мәдәнияткә килгән кешеләрнең иң күренеклесе Зөлфәт Хәким дип санар идем. Аның иҗаты белән танышу гаҗәеп матур тойгы уята: ул — сирәк очрый торган, күпьяклы, күпкырлы талант иясе! Даһилыкка да якынрак сыйфатлары бар дип уйлыйм кайчакта. Аңа сокланып һәм яхшы мәгънәдә көнләшеп карыйм.*

*Зөлфәт Хәким — татар халкының Ходай биргән зур бер талант иясе, үзенә күрә бер могҗиза!»*

Сайланма әсәрләрнең 1 томы шагыйрь Равил Фәйзуллинның әнә шундый бәяләмә сүзләре белән ачыла. Шунда ук, җырчы, композитор, шагыйрь, прозаик, драматург буларак, З. Хәкимнең татар әдәбият-сәнгать дөньясына үзенә бер вакыйга булып керүе турында академик М. Госманов, режиссер М. Сәлимҗанов, язучы М. Юныс кебек мәшһүр шәхесләр дә, яшь талантны хуплап үзләренең олпат сүзләрен әйткәннәр.

I томга авторның үткен сюжетлы, тирән фәлсәфи мәгънәгә ия «Гөнаһ» исемле психологик романы урнаштырылган. Бу әсәр журналыбызның җәйге саннарында басылып чыгып, бер даирә укучыларга ирешкән иде инде. II томда язучының «Курку», «Әүлия кабере», «Агымсуда ни булмас», «Кишер басуы» дигән повестьлары һәм үз вакытында көндәлек матбугатта басылып популярлык казанган сатирик хикәяләре урын алган. Ә III том тулысы белән драма әсәрләренә («Мәңгелеккә изге сәфәр», «Җүләрләр йорты», «Карак», «Зәхмәт», «Хыянәтче», «Үтермә!», «Җен бутады») багышланган.

Томлыклар яхшы полиграфик ысул белән нәшер ителгән.

Индекс 73210



Язучы Вахит Имамов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)